
ISSN 0206—4138

# КАЗАН УТЛАРЫ

1. 1993



**Республиканың мәдәният һәм сәнгать, иҗат берлекләре эшлекләре җыенында катнашучыларның Татарстан Республикасы Президентына, Югары Советына һәм Хөкүмәтенә**

# МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле Президент! Хөрмәтле халык депутатлары!

Хөкүмәтнең хөрмәтле әгъзалары!

Без сезгә халык ихтыяры белән республиканың тарихи-мәдәни һәм рухи-әхлакый мирасы өчен бүгенге һәм киләсе буыннар алдында гаять зур җаваплылык йөкләнгән кешеләр буларак мөрәҗәгать итәбез.

Халыкның рухи мәдәнияте — җәмгыятьнең, дәүләтнең таянычы. Нинди генә тармакта эшләмәсен, иҗат кешесен нәкъ менә рухи мәдәният тудыра.

Безнең милли мәдәниятебез — хаклы рәвештә горурланырга тиешле гаять зур казаныш. Республиканың тарихи үсеш юлында гасырлар дәвамында бик күп мәдәни һәм иҗат байлыкларын үзенә берләштергән чын халык мәдәнияте һәрвакыт кешене тәрбияләргә булышып килде, кешеләргә гуманизм нуры сипте, миһербанлык һәм гаделлек сыйфатларын бирде.

Әмма безнең күпмилләтле республикабызда мәдәният һәрвакыт цивилизацияле җәмгыятьтә урын алмаска тиешле «калдык принцибы» буенча яшәде һәм үсте. Бүген дә, икътисадны үстерүгә өстенлек бирелгән, ә мәдәният һәм мираска ачыктан-ачык икенче дәрәҗәдәге роль калдырылган заманда милли мәдәниятнең үзенчәлекләрен югалту куркынычы туды. Тармакның бар өлкәләре кризиста.

Рухилык гаранты булып калу өчен татар халкының һәм республикабыз халыкларының мәдәнияте бүген зур чыгымнар таләп итә. Халыкның киләчәге турында уйлаган барлык җирләрдә андый чыгымнарны чикләмиләр, ә мәдәниятне үстерүгә булышучыларны салым өлкәсендә ташламалар ясап хуплыйлар.

Бүген барыбызга да кыен. Ләкин рухилыкны һәм мәдәниятне торгызу республика дәүләтчелеген ныгытуның, мәдәни мирасны саклауның мөһим факторына әйләнгән шартларда мәдәниятне һәм профессиональ сәнгатьне үстерү дәүләтнең өстенлекле программалары исәбенә кертелергә тиеш. Республиканың рухи байлыгыннан гомуми файдалану турындагы Конституция гарантияләрен тормышка ашыру кебек мөһим проблема халык хуҗалыгы комплексының беренче чираттагы проблемалары арасында югалып калмасын.

Базар икътисадының тискәре йогынтысыннан милли мәдәниятне саклау өлкәсендә аның ихтыяҗларына республика дәүләт бюджетының кимендә алты процентын бирү һәм җирле бюджетлардан мәдәниятне үстерүгә бүлеп бирелә торган процентларны тотрыклы итү нәтиҗәле чара булыр иде.

Мәдәниятнең ресурс мөмкинлекләрен үстерүгә төрле формаларда ярдәм итүче предприятие, оешма, шәхесләргә карата салым буенча ташламалар ясауны да актив куллану таләп ителә.

Житештерү өлкәсендә эш хакының бик тиз үсүе мәдәният һәм сәнгать эшлекләренең эш хакын үстерүдән аерылган хәлдә бара. Бүген мәдәният тармаклары хезмәткәрләренең эш хакы башка тармакларда эшләүчеләрнекеннән берничә тапкыр түбән, алар мохтаҗлык сызыгы артында калып киләләр. Мәдәниятне коммерциягә әйләндерү тенденциясе өлкәсендә, беренче чиратта, бәяләр билгеләү мәсьәләсендә, мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләрен социаль яклау, аларның хезмәтенә түләүне житештерү өлкәсендәге хезмәткә түләү белән тиңләштерү, ә сәнгать осталарының хезмәтенә түләү шартларын халыкара күләмгә житкерү, гонорар сәясәтен үзгәртү буенча хөкүмәтнең гамәли чаралар күрүе таләп ителә.

Мәдәният турында закон нигезләрен һәм шуңа туры китерелгән актларны ашыгыч кабул итү сорала, алар Татарстан халыкларының мәдәни мирасын яңарту һәм файдалану буенча реаль механизм тудырырга, базар шартларында мәдәниятне тотрыклы үстерү шартлары булдыруга мөмкинлек бирерләр иде.

Җыенда катнашучылар, Татарстан Республикасы Югары Советы һәм Хөкүмәте тормышка ашырган чаралар мәдәният өлкәсендәге җимергеч процессларны туктатыр, аның бөлгенлеккә төшүенә юл куймас, мәдәниятебезгә чын ирекле лек бирер һәм аның чәчәк атуын, республика мәдәният һәм сәнгать эшлекләрен ышанычлы төстә социаль яклауны тәэмин итәр иде, дигән ышаныч белдерәләр.

**Мөрәҗәгать республиканың мәдәният**
**һәм сәнгать эшлекләре җыенында**
**1992 елның 2 декабрендә кабул ителде.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**1**

**(843)**

**1993**

КАЗАН

## *Бу санда*

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Өметебез зур, ышанычыбыз нык . . . 3

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

М. ХӘБИБУЛЛИН. Шайтан каласы. *Тарихи роман* . . . 5
М. ӘГЪЛӘМ. Мин гаепле түгел. *Шигырьләр* . . . 84
К. СИБГАТ. Тынлык. *Шигырьләр* . . . 89
Б. КАМАЛОВ. Адашкан адәмнәр. *Повесть-хроника* . . . 93
Р. СҮЛТИ. Сусау. *Шигырьләр* . . . 117

ДУСЛАР ЖЫРЫ

Б. МАМБЕТ. Көндез дә сискәнеп... *Шигырьләр* . . . 122
В. ФЕДОРОВ. Чишмә. *Шигырьләр* . . . 124

ПУБЛИЦИСТИКА

Н. ФӘТХУЛЛИН. Хикмәт нәрсәдә? *Социолог уйланулары* . . . 126
Мәңгелек мәшәкатьләр. *(Татарстанның авыл хуҗалыгы министры Ф. С. Сибагатуллин белән әңгәмә)* . . . 135

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Гыйбрәтләр алсак иде... *(«Безнең тормыш. Безнең әдәбият» дигән дискуссиягә)* . . . 140

МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Я. АБДУЛЛИН. Фикри эзләнүләр юлында . . . 149
Р. НӘФЫЙГОВ. Фатих Кәрими турында . . . 158
Г. САТТАРОВ. Башкалабыз атамаларына — милли рух . . . 164

СӘНГАТЬ

К. МИҢЛЕБАЕВ. Иман нуры . . . 169

КИТАП КҮЗӘТҮ

А. ГАФИЯТОВ. Хәтер тәрәзәләре . . . 176
Р. ХУҖИН. Ялгызлыктан — халыкка, хаклыкка! . . . 178

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Р. ГАТАШ. Моң өчен рәхмәт белән . . . . . 182

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Х. ХАЛИКОВ. Яратам. *Шигырьләр* . . . . . 184

Безнең календарь . . . . . . . . . . . . . . . 187

ЛАТИН ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

С. ҖӘЛАЛ. Дим буенда. *Хикәядән өзек* . . . . 188

Китаплар дөньясында . . . . . . . . . . . 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . . . . 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Публицистическое выступление главного редактора журнала Р. ФАЙЗУЛЛИНА.
«Проза и поэзия»: начало исторического романа М. ХАБИБУЛЛИНА «Чертово городище», повесть Б. КАМАЛОВА «Заблудившиеся»; стихи М. АГЛЯМОВА, К. СИБГАТ, Р. СУЛЬТЕЕВА.
«Песня друзей»: стихи Б. МАМБЕТА, В. ФЕДОРОВА.
«Публицистика»: социологические раздумья Н. ФАТХУЛЛИНА «В чем дело?», «Вечные заботы» — интервью с министром сельского хозяйства Республики Татарстан Ф. С. Сибагатуллиным. «Литературная критика»: статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА на дискуссию «Наша жизнь. Наша литература».
«К истории культуры»: статья Я. АБДУЛЛИНА о творчестве Г. Исхаки, Р. НАФИГОВА о Ф. Карими, Г. САТТАРОВА об отсутствии национального духа в названиях улиц.
«Искусство»: статья К. МИҢЛЕБАЕВА о творчестве художника Х. Нафикова.
«Книжное обозрение»: А. ГАФИЯТОВ анализирует повесть В. Имамова «Кукушка», Р. ХУЗИН — сборник Э. Мустафина.
«Поздравляем»: статья Р. ГАТАУЛЛИНА посвящена к 60-летию И. Юзеева.
«Читайте детям»: стихи Х. ХАЛИКОВА.
Навыки чтения на основе латинской графики.
Наш календарь.
В мире книг.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Состязание акынов» — картина художника Х. Нафикова; известный писатель Ринат Мухамадиев.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Кояш Тимбикова, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 3.12.92 ел. Басарга кул куелды 6.01.93 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70 \times 108\ ^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 24675. Заказ В-562. Бәясе 20 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1993 ел.

# ӨМЕТЕБЕЗ ЗУР, ЫШАНЫЧЫБЫЗ НЫК

## Әссәламегаләйкем, газиз милләттәшләр, журналыбызны укучы мөхтәрәм кардәшләр!

Менә, ниһаять, «Казан утлары» журналының быелгы — 1993 елгы беренче саны сезнең кулларга барып ирешге. Быел безнең 25 мең чамасы мөштәриләребез бар. Мөгаен, сезнең күбегез журналның күптәнге дуслары — фикердәшләредер, дистә еллар буе бездә чыгып килгән йөзләрчә әсәрләр, төрле-төрле язмалар гомерләрегезнең аерылгысыз бер сәхифәсенә әверелгәндер. Шул ук вакытта журналыбызны беренче мәртәбә кулга алучы милләттәшләребез дә юк түгелдер. Мәрхәбә! Басмабыз сезнең дә гомерлек рухи юлдашыгызга әверелсен!

Хөрмәтле укучыбыз! Син яшьме-өлкәнме, акыл яки кул көче белән көн күрүчеме, котып тарафында, әллә чүл ягында яшәүчеме, әллә чит мәмләкәтләрдә гомер кичүчеме — син барыбер безнең якын милләттәшебез, кардәшебез. Син — безнең уй-хыялларыбызны аңлаучы, туган телебезнең тәмен-аһәңен тоючы, халкыбызның төп тарихи ватаны булган Татарстандагы рухи һәм сәяси хәлләр белән якыннан кызыксынучы, киләчәгебез турында борчылучы зат. Ниһаять, син — әдәби, иҗтимагый, сәяси яктан татар халкының төп журналы булган «Казан утлары»ның чын дусы, киңәшчесе, арка таянычы.

Яңа елга аяк басканда без һәммәбез дә әле күптән түгел генә үткән елларны юксынып-сагынып искә төшерәбез, алардан гыйбрәт-сабак алып, яхшыга, яктыга илтә торган дип санаган хикмәтләрне алдагы киләчәккә алып барырга ниятлибез. Бу җәһәттән соңгы бер-ике ел безнең өчен онытылмаслык булды — халкыбызның үткән Бөеклегенә кайту юлында дөнья хәтерендә калырлык адымнар ясалды. 1992 ел эчендә Татарстан Республикасы үзенең яңа исеме һәм бәйсез җисеме белән татар халкын бөтен җиһан хәтеренә яхшы ук сеңдерә башлады. Бөтендөнья халыклары арасында лаеклы урын алырлык милләт икән бит без ләбаса! Үткән елда татарларның Бөтендөнья Конгрессы гомумхалык бәйрәме булып үтүе дә моңа ачык дәлил. Үзаңыбыз үсешенең, халык тантанасының күрелмәгән бер чагылышы булды ул Конгресс. Бу тарихи вакыйга безнең журналыбыз юбилеена — «Казан утлары»ның 70 еллыгына туры килүе үзе бер олы символик мәгънәгә ия булды. Асылда Конгресс журналыбызның шул юбилей тантанасы белән ачылып китте дә. Халкыбызның кичәбездә чыгыш ясаган күренекле шәхесләре, шулай ук чит илләрдән килгән мөхтәрәм кунакларыбыз «Казан утлары» журналының милләтебез тарихындагы урыны, рухи тормышыбызның елъязмасы икәнлеген дәлилләп, горурланып сөйләделәр. Мондый бәяләмәләр, бер яктан, зур дәрәҗә булса, икенче яктан, безгә — язучыларга, редакция хезмәткәрләренә тау кадәр җаваплылык та өсти.

Үткән ел Татарстан Республикасының сәяси тормышы үтә киеренке булды. Март аенда мөстәкыйльлегебез референдум юлы белән, ягъни бөтенхалык ихтыяры, хуплавы белән гамәлдә беркетелеп куелды. Татарстанның үз илбашы — Президенты сайланды. Республикабызның үз символлары — әләме-байрагы, гербы-тугрысы булдырылды. Татар теле (урыс теле белән бергәттән) дәүләт теле итеп игълан ителде. Ниһаять, 1992 елның 6 ноябрендә, элеккеге СССР составында булган республикалар арасында беренчеләрдән булып, Төп Законыбыз — Татарстан Конституциясе кабул ителде.

Әлбәттә, бу тарихи вакыйгалар һәммәсе дә безнең журналда да теге яки бу дәрәҗәдә чагылыш тапты.

Яңа елда журналыбыз үз укучыларын нинди кызыклы әсәрләр, нинди гыйбрәтле язмалар белән сөендерәчәк? Әшен нинди юнәлештә корачак? «Казан ут-

лары» журналы моңарчы тоткан юлын дәвам итеп, алган мәсләгенә тугры булып калыр. Безнең төп бурыч — акыл иләренең, әдипләребезнең дәүләтчелегебезне ныгытуга өлеш керткән, халык ихтыяҗларын кайгыртакан, килер буыннарны әхлакый саф, рухи нык итеп тәрбияләүгә булышкан иҗади хезмәтләрен меңнәргә, миллионнарга җиткерү. Ул — роман-повестьмы, шигырь-поэмамы, хикәя-пьесамы, эссе-тәнкыйтьме, мәкалә-истәлекме, белешмә-информацияме — хикмәт жанрда яки күләмдә түгел! — иң мөһиме: ул әсәр кешелекле булсын, дөрес-хак булсын, талантлы булсын, уртак идеал-максатларга хезмәт итсен! Безнең бәхетебез шунда: талантлы каләм ияләренең күпчелеге үзләренең яхшы дип тапкан өр-яңа әсәрләрен иң элек безгә китерәләр. Яхшыларның яхшыларын сайларга мөмкинлегебез бар. Димәк, укучыларыбызның да күңеленә хуш килгәнен сайлап укырга мөмкинлеге булачак дигән сүз.

Төп әдәби журнал буларак, без, табигый, телебезнең камиллеген һәм сафлыгын саклый торган басма булырга тиешбез. Ә телне рәсми закон чыгарып кына саклап, үстереп булмый. Тел — милләтне милләт иткән төп сыйфатларның берсе. Шуңа күрә дә тел язмышы — милләт язмышы да ул. Беләсез, хәзерге Татарстан территориясендә татарлар республикада яшәүчеләрнең яртысы чамасын гына тәшкил итә... Журналыбызда инде берничә ел даими бирелеп барыла торган «Татар халкы: төрле төбәкләрдә, төрле илләрдә» дигән рубрика бер дә очраклы түгел икәнлеге аңлашыладыр. Без чәчелгән халкыбызны барларга, аның көчен-җегәрен ачыкларга, аннан соң бергә оеша-берләшә башларга, уртак генофондыбызны баетырга, туган туфрагыбызда тагын да тирәнрәк тамыр җибәрергә тиешбездер. Шуңа күрә, гасырлар буе татарлар тупланып яши торган (әйтик, Башкортстан, Оренбург, Төмән, Пермь, Чиләбе һ. б.) төбәкләр турында, аларның тарихы, гореф-гадәтләре, шивәләре, хәзерге көнкүрешләре турында без алга таба да даими язып торачакбыз. Бүтән рубрикаларга килгәндә, аларның күбесе дәвам итә, тагын да байый; заман таләпләреннән чыгып яңа сәхифәләр туа. Укучыларыбыз яратып кабул иткән рубрикалардан: «Әдәби мирас», «Мәдәниятебез тарихыннан», «Халкыбызның мәшһүр шәхесләре», «Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы», «Дөнья әдәбияты җәүһәрләреннән», «Яңалыклар хроникасы» һ. б. Шулай ук журналыбызда ислам дине нигезләрен аңлаткан фәлсәфи хезмәтләргә, гарәп һәм латин (киләчәктә латин имлясын кабул итәрбез дип ышаныйк) әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләренә, яшьләр иҗатына, сәнгать сәхифәләренә (сәнгатьнең аерым төрләре буенча махсус басмалар булмау сәбәпле, без күренекле композиторлар, артистлар, рәссамнар турында да еш язабыз) киң урын биреләчәк. Җыйнап әйткәндә, киләчәккә безнең уй-теләкләребез масштаблы, өметләребез зур, ышанычыбыз нык!

Кадерле укучыларыбыз!

Оешып җитмәгән базар икътисады күп кыенлыклар тудырса да, «Казан утлары» журналы үзен саклап кала алды. Ул гына да түгел, узган елның икенче яртысы елына караганда укучыларыбыз ишәя төште. Димәк, бердәмлек булганда, аңлашу булганда җиңеп була икән! Киләчәктә дә шулай булсын! Амин! Яңа еллар мөбәрәк булсын! Ак бәхетләр Сезгә!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
«Казан утлары» журналының баш мөхәррире,
Татарстанның халык депутаты.

*Гыйнвар, 1993 ел.*



## Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ШАЙТАН КАЛАСЫ

ТАРИХИ РОМАН

### 1

Әмир Хаҗи укыган китабын кечкенә өстәлгә куйды да кулына дисбесен алды, күзләрен йома төшеп, дисбе тарта башлады. Уй җебе еракта — атасы белән булган хәтәр хәлгә тоташа иде.

Кемдер керде, түргә узды, әмма әмир хәтта аңа күтәрелеп тә карамады. Ул һаман әле атасы кылган явызлык турында уйлана иде. Бары тик Дәүранны алып килгән бусагабашы тамак кыргач кына күзен ачты, остага күтәрелеп карады, әмма анда да сүз катмады. Колчуралыктан үзе азат иткән останың сеңлесе Назлыгөлне урлавы, Яңа Казанга китереп никах укытуы һәм һичкемгә сиздерми яшәп ятуы, ә атасының ил бетереп кызын эзләве, таба алмавы — башка сыймаслык хәл иде. Шундый хәлдә дә бу хакта ишеткәч, әмир Хаҗи каты бәрелмәде остага — кичерде. Илле барыбер күңелдә ошбу кешегә карата канәгатьсезлек билгесе калган иде. Колчура аларның кияве — хан кияве. Әмир белә иде, Назлыгөлне атасы алып китте һәм оста чарасыздан аның каршына килгән. Әмир Хаҗи дисбесен чапан кесәсенә койды, торып басты.

— Назлыгөлне эзләмә, аны атам алып китте,— диде.

Дәүран күкрәгенә кулын куйды, әмирнең аягына бөгелеп төште:

— Әмирем, булыгызчы бәхетем ачкычы, газапка дучармын. Коткаручым булдыгыз, хөкемдарым да булыгызчы! Ярдәм итегез Назлыгөлем кайтарырга? Бирегез фатихагыз, китим хатыным артыннан. Игелегегезне гомерем буена онытмам. Коръән тотып ант итәм.

Оста уң кулын өстәлдә яткан изге китап өстенә салды.

Әмир Хаҗи иягеп чөя төшеп, тураебрак басты, останы баштан-аяк күздән кичерде.

— Хан кызы Назлыгөл синең хатыныңмени, оста? Үз акылыңдамы син! Әмиреңалдына шул йомыш белән килдеңме?!

---

Журнал варианты.

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН (1927) — *прозаик. «Кубрат хан», «Илчегә үлем юк» h. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

— Әй, хөрмәткә ия әмирем, барыр җайларым, кылыр чараларым калмады ла. Назлыгөл минем никахлы хатыным иде,— диде оста Дәүран һәм аягүрә торып басты.

— Әнә ничек икән,— диде кинаяләп Әмир Хаҗи.— Хан кызы Назлыгөл синең хатының идемени? — Әмир Хаҗи ишек төбендә басып торучы җансакчысына карады.— Ишетәсеңме, Җанбай, хан кызы Назлыгөл — оста Дәүранның никахлы хатыны булган икән ич! Әмир Хаҗи исә бу хакта яңа ишетә, гәрчә хан кызының өлкән агасы булса да... Мин шуңа аптырап утырам әле, оста, ничекләр атам синең башыңны кистермәде, ничекләр котылып кала алдың син аңардан?

— Изге башны кылыч кисми, әмирем.

— Изге башны? — дип гаҗәпләнде башын чөя төшеп әмир Хаҗи.— Димәк, син — изге баш? Кем шулай ди?

— Баһадир Җик Мәргән.

— Димәк, Җик Мәргән коткарды сине, оста Дәүран?

Әмир Хаҗи ашыкмый гына урыныннан купты, ишекле-түрле йөрергә кереште. Ул уйланды,ниндидер нәтиҗә ясарга тырышты. Җай гына барган дөньяның ике-өч көн эчендә тәгаен асты-өскә килде. Әүвәл Бачман баһадир ярты гаскәре белән туган ягына чыгып китте. Ахыр килеп Акбикәсе гаип булды. Туган ягы Сәксингәме, Бачман баһадирга ияреп китүеме?.. Нишләргә тиеш ул хәзер?.. Бикәсен куа чыгаргамы? Бачман баһадирның китүен ул үзе теләде. Иллә бикәсенең баһадир белән китүенә ышанасы килми иде. Хәләл иреңнән, якыннарыңнан яшереп булмый торган хак нәрсә бар — мәхәббәт. Бикәнең Бачман баһадирга тартылуын, аның исемен ишетүгә йөзе-чырае балкып китүен күреп йөрде ләбаса! Әмма хатынының бу кыланышын күрде дә, күрмәде дә — гамьсез калырга тырышты. Ахыр чиктә әнә ничек бетте: кыланышларына түземе җуелды — юк сәбәпне бар итеп, баһадирны зинданга яптырды. Сәбәбен халык алдында ачыклап торырга вакыты тар иде — капка каршында гаскәре белән атасы тора иде.

— Димәк, сине баһадир Җик Мәргән коткарды, оста Дәүран?

— Әйе, әмирем, баһадир Җик Мәргән коткарды.

— Җик Мәргәнне баһадир итүче миндер, оста Дәүран.

— Җик Мәргән изге кеше. Ул миңа бик күп игелек кылды, әмирем. Мине коткаруда аның мыскал да гөнаһы юктыр.

— Иң әүвәл кем сиңа ирек бирде, оста! Кем сине кеше янында кеше итте!

— Сез, әмирем, сезнең аркада кеше янында кеше итеп сизә башладым үземне. Рәхмәт сезгә! Игелегегезне гомерем буена онытмам.

— Хан җәлладын кем үлтерде?

— Сез аны үзегез дә күрдегез, әмирем.

Әмир Хаҗи ни кылырга белми тирә-ягына каранып алды да, гасабилануын яшерүдән гаҗиз калып, янә йөренергә кереште.

— Йә, ни кылырга исәбең инде хәзер, оста Дәүран?

— Әмирем, миңа азатлар кирәкми, бирегез миңа фатиха, бирегез җайдак ат. Мин Назлыгөлне җир астыннан булса да табып алып кайтырмын...

Останың ошбу тәвәккәллегенә шаккатудан чарасыз калып, әмир Хаҗи аның каршына туктады.

— Атам кулына эләксәң, беләсеңме нишләтәчәк ул сине? Ат коерыгына тактырачак, табаның телеп кыл тутыртачак. Каһәр аңа, каһәр! Ул мине дә мыскыл итте, калама килеп фетнә кузгатты, халкымны рәнҗетте...

— Миңа ханның яман уйлары билгеле түгелдер, әмирем. Әмма мин Назлыгөлемне барыбер табармын.

Әмир Хаҗи бертын сүзсез торды. Ул бер нәрсәгә төшенгәндәй итте: атасы Яңа Казанны Булат оныгына бирергә дип килгән. Ләкин теләгенә ирешә алмады. Өлкән угланы бирмәде. Җитмәсә көчтемле Апанай,

«Үлдәмир кенәзе Болгарга яу чыккан», дип чаң сукты. Атасына шул җитә калды. Владимир кенәзе Болгарга яу чыкканмы, чыкмаганмы — әмиргә караңгыдыр. Ә менә шул хәбәрдән куркып атасының китүе хактыр. Остага йөзбашын биреп, Назлыгөлне коткарырга җибәрсә? Күренә ки, оста Назлыгөле өчен утка керергә тора.

— Ярый, оста, кайтырга теләсәң, коткар Назлыгөленне.

— Атка йөгән салганда: мин бу хайванны кулга өйрәтә алырмынмы, дип икеләнмиләр, әмирем. Кылыр игелегегезне кылыгыз, мин Назлыгөлне табармын. Исән-имин әйләнеп кайтсак, Казан каласын тирә-юньдә бер итәрмен. Яшәр дөньямда сездән башка хәерле кешем калмады.

— Хуш, оста. Инде әйт: йөзбаш озата барсынмы?

— Миңа азат та, йөзбаш та кирәкми, әмирем. Миңа җайдак ат, корал бирегез.

— Адәм баласы ике туып ике үлми, оста, үз көчеңә ышануыңны ни белән дәлилли аласың? — Әмир икенче җансакчысына дәште.— Тимер, бир остага җайдак ат, сораган коралын бир.

— Кылган игелелегезне беркайчан да онытмам, әмирем.

— Изгелек җирдә ятмый, оста. Ашыкма, барысын да алла кулына тапшырыйк!

— Иншалла барысы да әйбәт булыр, әмирем...

## 2

Хәрби киемнәр киеп алгач, Дәүран җайдак атынияр башына бәйләде дә әмир җансакчысы Тимергә:

— Рәхмәт сиңа, Тимер. Игелегең онытмам,— диде.

— Ак юл сиңа, оста. Тик бик ашыкма, атларың ешрак алыштыр. Нугай капкасыннан чыгарсың, мин ясавылга хәбәр иттем.

Үзе салган кала да артта калды. Дәүран ашыкты, атын җилле куалады. Бары тик ярты юл чамасы үткәч кенә, туктап, икенче атына күчеп атланды.

Аның уенча, Сәлим хан Ибраһим каласында булырга тиеш иде. Ни ашыкса да, хан юл өстендәге калага туктамый итмәс. Атлар тырк-тырк җай гына юрта, юлда берәү дә күренми. Дәүран тезгенен бушата төште, булган хәлләрне янә күз алдыннан кичерде.

Үлем балтасыннан ычкынгач, Дәүран хатыны Назлыгөлне төне буена эзләп йөрде. Кеше күзенә күренергә, сорашың йөрергә курыкса да, тәвәккәлләп Әхмәт тарханга барды, әмма ул да останы куандыра алмады. «Качып ятадыр, сабыр ит, кайтыр»,— дип кенә юатты. Йөри торгач, оста сарай бавырчысын очратты. Нәкъ менә шул бавырчы аңа дөресен әйтте: «Назлыгөлне хан алып китте»,— диде. Шуннан соң гына Дәүран әмир хозурына керергә дигән карарга килде. Хак, әмирнең тотып зинданга ябуы бар иде, әмма эчке бер тоемлау белән сизде Дәүран: әмир Хаҗи аңа тимәс, Назлыгөлне табуда ярдәм итмәсә дә, каласын салган останы рәнҗетмәс.

Күңеле дөрес сизгән булып чыкты — Дәүран теләгенә иреште. Ул юлда, аның күңеле ашкына, тизрәк Назлыгөлне күрәсе килә иде. Илаһи Сәлим хан каршына килеп басуга ни әйтәсен белми ул, әмма күңел түрендә ниндидер өмет чаткысы бар — бәлкем әле хан аңа тимәс тә, һич югы Назлыгөл тидермәс, ул минем ирем, аннан минем балам булачак, дияр. Атасы аягына егылыр, кичерүен сорар, гаебен таныр. Алла тәгаләнең рәхмәте зурдыр, иншалла, кичереп тә куюы бар.

Дәүран үлемнән курыкмады, курыкканы — Назлыгөлне күрми үлүе иде. Рәхмәт әмиргә, хәленә керде. Хәер, әмир Хаҗи аңа карата һәрчак игелекле булды. Алай да ул әмир иде, ә Дәүран оста, бары тик оста, җитмәсә, хан колчурасы.

Бүген ул ничек тә Ибраһим каласына җитәр. Әмма якты көздә барып керү хәерлерәк булыр иде.

Атлар җилле элдерә. Кирмән капкалары ябыктыр, ясавыллар аны танымый, кирмәнгә кертмәсләр. Бердәнбер юл — исемен атау, хан кияве булуын аңлату. Исемен ишетүгә, шундук ханга җиткерерләр, хан исә кол кияүне каршына китерүләрен таләп итәр.

Ә менә Сәлим хан: «Колчура киявемне күрергә теләмим»,— дисә, ни кылыр? Юк. Кабул итәр. Кияү балакай үзе үк җәллад балтасы астына килә ләбаса.

Аллаһы боерган булса, җан биргәнгә җай бирер әле. Әйе, аңа иң әүвәл Назлыгөлне күрәсе һәм үз авызыннан ишетәсе иде — үзе теләп атасы белән киткәнме? Инде үзе теләп киткән икән... Әйе, барысы да бер хода кулында, ни язганы булыр. Әмма ул Назлыгөлен барыбер күрер.

Дәүран белми иде — ничек, нинди юллар белән алып китте Назлыгөлне Сәлим хан? Ризалыгы беләнме, бәйләпме, әсир итепме? Дәүран өчен бу хәл бөтенләй үк буш нәрсә түгел иде. Хан кызы үзе китәме, көчләп алып китәләрме? Күңел шикләнә, әмма йөрәк тоя — Назлыгөл үз ирке белән китмәгәндер.

Әйе, янә бер ышанды оста Дәүран әмир Хаҗиның игелекле кеше булуына. Ә бит әүвәл башта ирек биргәндә дә ышанып җитмәгән иде.

Ирек!

Нинди татлы син! Тик язмыш аңа янә аяк чала — үзе үк янә җәллад балтасы астына ашыга. Баш кискәннән балта тотыкмый, ди торган иде хан җәллады, Казанда әнә үзенең дә башына җиттеләр. Әмма хан җәлладка мохтаҗмы?.. Икенче берәүне тапкандыр.

Ирек!

Менә нәрсә җитмәде мәрхүм атасына, ирек даулый алмады, бирерләр дип өмет итте, сабыр итте, көтте, ахыр кол булып дөньядан китте. Угланы Дәүран ирек алды алуын, әмма хан өчен ул һаман колчура иде әле. Кол. Хан колы.

Дәүран нindидер инеш янына туктады, атларын утлатып алырга булды. Атлары үлән кытыртата башлагач, чирәмгә ятып, баш астына кулларын куйды да күк йөзенә бакты. Кояш баеп бара, тиздән җиһан шәме дә инеш аръягындагы куаклар артына посар, ә аңа шактый юл үтәсе әле. Хәер, исәбе буенча, Ибраһим каласы ерак калмаган булырга тиеш иде инде.

Шулчак кай тарафтандыр тояк тавышлары ишетелде. Дәүран сикереп торды да, атларының тезгеннәреннән эләктереп, инеш буендагы таллыкка керде. Әмма аны күреп калганнар икән инде.

— Һәй, кем анда! Чык әле бире, азат, чык! Атларыңны да калдырма! — дип кычкырды алдан килеп җитүче азат.

Дәүран, атларын җитәкләгән килеш, аланга чыкты.

— Син кем, кай тарафка юл тотасың? Бәең кемдә? — дип сорау яудыра башлады унбаш.— Качкын түгелсеңдер бит?

— Юлчы мин, унбаш, юлчы!

— Нигә бездән качтың?

— Караклар дип курыктым.

— Кай тарафка юл тотасың?

— Ибраһим каласына.

— Җайдак ат, хәрби кием... Бәең кемдә?

— Бачман баһадирны беләсездер,— дип ялганлады Дәүран.

— Ясавыл, китик моннан, баш-аягы бер казан,— дигән булды икенче берәүсе.

— Китми тор әле. Кемгәдер охшатам мин бу бәндәне. Кайда күрдем соң әле үзен?! Һәй, алыгыз коралларын. Сиңа, кордашым, хан каршына кайтырга туры килер,— диде ясавыл кинаяләп.— Атлан әйдә атыңа. Кузгалдык!

Дәүранның атын уртага алдылар һәм җилле генә калага таба кузгалдылар.

— Унбаш, унбаш, мин дә бу адәмне таныдым. Беләсеңме кем бу?

— Кем, атаң коргыры, ат карагымы, сукбаймы, казакмы?

— Ат карагы да түгел, казак та түгел, хан кияве!

— Тпру-тырр! Китсәнә, булмаганны!

— Ышан, ясавылым, хан кияве безнең кулда.

— Шул кеше кирәк тә бит инде безгә, Батырбай.— Унбаш атын Дәүран янына ук китерде.— Әй, хан кияве, хан кызын кая илттең?!

— Унбаш Байсар, бер дә борчылма, безгә әйтмәсә, ханга әйтер. Хан бик тиз тел ачкычын табар аңа.

— Син хаклы, ясавыл. Назлыгөлне тапкан кешегә хан мең алтын вәгъдә итте. Алай да кая илттең хан кызын, колчура Дәүран?

— Унбаш Байсар, мин хатынымны тапкан кешегә үзем мең алтын бирер идем,— диде Дәүран.

— Колчурада мең алтын? Сөйләмә тузга язмаганны. Кузгалдык. Хак җавабыңны ханга бирерсең.

— Мин төшендем моның хәйләсенә, унбаш. Җайдак атын хан кызына дип алып килгән бу.

— Әйедер, ясавыл, тик хан кызы кайда соң?

— Унбаш Байсар, Назлыгөл — минем никахлашып өйләнгән хатыным.

— Никахлашып өйләнгән хатының! Хан кызы синең хатының?! Үз акылыңдамы син, колчура оста. Мин, унбаш Байсар, хан сараен саклыйсаклый чәчем агарттым, хан кызына түгел, җарияләренә сүз катырга кыймый идем. Ә син «хан кызы — хатыным» дигән буласың. Урлап алып киттең син аны, колчура оста, урлап. Ә моның өчен, беләмсең, нишләтәчәк сине Сәлим хан?! Хәтәр Сәлим хан диләр аны! Телсезне телле итә, аксакны йөгертә торган кеше ул.

— Хан кызы миңа үзе теләп килде, унбаш. Мин аны урламадым.

— Җитте, оста. Куала атың. Күп телеңә салышма. Сине хан көтә.

Кала каршындагы үрне менүгә, кирмән күренде. Күп тә үтми эңгер инде, күк йөзендә җем-җем йолдызлар кабына башлады. Хан киявен кулга төшергән унбаш караңгы төшкәч кенә әсире белән кирмән капкасы каршына килеп туктады.

— Ясавыл, төшер күперең, ач капкаң. Сөенче, хан киявен алып кайтам.

— Шылмы хан кияве... Ләхәүлә вәләкуәтә! Казер, казер!

— Әүвәлтен ханга сөенче җиткерең, ясавыл!

Асма күпер төшерелде, капка ачылды. Ул арада ханга сөенче җиткерүче әйләнеп тә килде.

— Ашык, унбаш Байсар, хан сабырсызланып көтә. Киявеңне тоттык дигәч, ике күзе дүрт булды, тизрәк китерергә кушты.

— Хан аңа тимәс, ясавыл, ул хәтле кинәнмә! — диде унбаш.

— Димәк, сөенче әйткән өчен миңа тиячәк,— диде кинаялап ясавыл,— мине дар агачына астырачак.

— Ә нигә, булмас димә. Онытма, бу адәм — хан кияве.

— Явызсың, унбаш. Әйдә, узыгыз, ятрәк кыланыгыз.

Тархан йортына җитүгә, хан бусагабашы аларны каршы алырга чыкты.

— Йа хода, чынлап та оста Дәүран! — дип гаҗәпләнде бусагабаш һәм чакырылмаган кунакны йортка әйдәде. Әмма Дәүран туктады һәм артына каерылып:

— Атларымны югалтма, унбаш Байсар, кирәк булып куюлары бар. Әйс, коралларымны да таратма, ханның таптыруы бар,— диде.

— Кыюсың, оста,— диде бусагабаш.— Ай-һай, кыюсың да. Кол бит әле син, колчура. Әүвәл ханнан ирек ал, аннары атың турында кайгыртырсың.

— Бүген кол, иртәгә никахлы кияү, дөнья күләсә, өйләнә дә бер баса, ди Ага-Базар халкы.

— Әйдә, әйдә, күп телеңә салынма,— дип бусагабаш Субай әсир ителгән останы хан янына алып кереп китте.

Алар киң вә якты бүлмәгә килеп кергәндә Сәлим хан дисбе тарта-тарта ишекле-түрле йөренә иде, инде Дәүранны күрүгә, туктап калды, дисбесен чапан кесәсенә койды.

— Йа алла мөхәммәдрәселулла, кемне күрүем, Оста Дәүран!

— Атам! — диде Дәүран һәм ханга таба бер-ике адым ясады да аягына төште.

— Бусагабаш,— диде хан.— Чыгып тор әле... Ә син, кияү балакай, рәхим ит, түрдән узып утыр,— диде хан әллә ихластан, әллә кинаяләп.

Дәүран белә иде, анасы аксөякләр затыннан, кайчандыр Сәлим ханның хатыны булып, атасы кол хәлендә гүргә керсә дә, ихтирамга лаек кеше иде. Дәүран хан белән икәүдән-икәү калырга курыкмады, түргә узды, колак мендәре ташлаган урынга утырды.

— Атам, мин сезнең алга баш иеп килдем, гәрчә башым кисәр хәлгә җитсәгез дә, мин сезгә, аллаһы тәгалә шаһит, мыскал да ачу тотмыйм...

— Китерделәр дәген, кияү балакай, китерделәр дәген. Йә, йә, йомышың әйт. Назлыгөл кайда? Бер урладың — эзең җуйдың, инде тагынмы? Аллаһы тәгалә каһәреннән дә курыкмыйсыңмы, балакай?

— Юк, курыкмыйм, атам. Аллаһы тәгалә алдында гөнаһым юктыр.

— Ата-ана рөхсәтеннән башка хан кызы кадәр хан кызына никах укытуны гөнаһка санамыйсыңмы?..

— Атам, мин әүвәлтен дә әйткән идем, янә кабатлыйм: Назлыгөлне мин урламадым, ул үзе минем кырга килде, үз ризалыгы белән.

Дәүран шактый кыен хәлгә калган иде. Ханның тел очыннан шуңа төшенде ул: Назлыгөл хан кулында түгел. Качканмы? Коткарганнармы? Димәк, хан алдына юкка килдем, коралларымны юкка ташладым.

Күңелен шундый борчу бимазаласа да, Дәүран Назлыгөл хакында ата кешедән сорарга кыймады. Ханның Назлыгөл турында юри соравы бар иде, әйтик, аның эч серен белү өчен. Хак анысы, Назлыгөл биредә булмаган хәлдә, аңа кыенга туры килер. Бу юлы хан аны кулыннан ычкындырмас, кияү балакайга бик тиз богау салыр.

Бүлмәгә Ягкуб бәк керде, ил карты исемен йөрткән абруйлы ошбу адәмне Дәүранның күргәне бар иде, инде бәк килеп керүгә, ул торып басты, күкрәгенә кулын куеп, олы кешегә баш иде.

— Әссәламегаләйкем, ил аксакалы,— диде Дәүран.

— Саумы, оста, иминлекме? — диде Ягкуб бәк һәм түргә узып, хан каршына утырды.

— Аксакал,— диде Сәлим хан аңа, дога кылгач.— Ошбу адәм мәрхүм Алпар останың углыдыр. Хан кызын урлап никах укыткан адәм.

— Олуг хан,— диде аксакал сабыр гына.— Үлдәмир каласыннан багучым кайтты. Урыс кенәзенең Болгарга яу чыгуы хак, дип бара. Всеволод кенәзгә энең Мөхәммәтгалим бәк белән Янтак хан ярдәмгә кузгалганнар, имеш. Илгә яу килгәндә ата-бабаларыбыз гаилә низагларын читкә куеп тора торганнар иде.

— Янтак хан хакында мин хәбәрдар, аксакал. Янтакның урысларга ияреп бер тапкыр гына Болгарга яу килүе түгел инде. Бу килүе үз башына булыр. Үзем монда булсам да, баһадирларым Бөек Каланы ныгыта. Урыс кенәзе Всеволод Янтак ханны ияртеп килсә дә, Бөек Каланы ала алмас, иншалла.

— Амин, бирсен ходай, бирсен ходай,— диде аксакал Ягкуб.

— Хаким бул, аксакал. Ни кылыйм бу бала белән?

— Сөбханалла машалла, олуг хан, мин хөкемдар түгел, мин бары тик кала бәге. Киңәшем шул булыр: илгә яу килгәндә, әүвәл илең сакла. Аннары балаң турында кайгыртырсың.

— Аксакал, игътибарыңны җәлеп итәм, мин хан кызын урламадым, ул үзе минем кырыма килде.

— Алай димә, оста. Хан кызы Назлыгөл акылы камил бала иде. Кыз бала башы белән синең кырыңа килергә аның башына тай типмәгәндер. Ата-ана фатихасыннан башка ир-зат бусагасын атлап керергә хан кызы саугат баламы? Инде үзе теләп синең янга килгән икән, никах та укыткансыз икән — барысы да аллаһы тәгалә кулында дип кенә әйтәсе кала. Очкан кошлар кире кайтса да, аккан сулар кире кайтмый, хан. Килеш. Останың аты-исеме халык телендә, мәһабәт итеп Яңа Каланы күтәрде. Илаһи дөнья илаһи теләк уятыр, ди...

— Ошбу оста минем колчурамдыр, аксакал!

— Без барыбыз да аллаһы тәгалә алдында колчурадыр, олуг хан. Инде миңа, хан, оста оланга бер сөаль бирергә рөхсәт ит?

— Бирә күр, аксакал.

— Оста угыл,— диде кала бәге Ягкуб.— Ни өчен син хан язмышы — минем язмыш дип халыкка сөйләп йөрисең?

— Бермәлне мин төш күрдем, аксакал. Төшемдә Газраил пәйгамбәр килде дә: «Оста Алпар углы Дәүран, синең гомерең хан гомере белән бер көндә, бер төндә бетәр»,— диде.

— Төшеңне кем юрады?

— Болгар атлы кам бабай.

— Сөбханалла машалла, кам Болгар исәнмени?

— Исән, аксакал.

— Хәтерем ялгышмаса, бәлигъ булганчы ул Шайтан каласында эрү таш юды. Аннары Чәчкә Ана аны үз янына алган иде. Күп тә үтми, тәүге таш юучы халык арасында кам булып йөри башлады. Әйе, үтә гомер дигәнең. Бер адәмгә: «Син далада үләрсең»,— дигәннәр. Шуннан ул урман-әрәмәдән дә чыкмаган, ди. Җиләк-җимеш ашап тәгаен урманда көн күрә башлаган, диләр. Бер тапкыр шулай шомырт агачын сыккан да җимешләрен ашый икән. Кинәт моның кулыннан шомырт агачы ычкынып китә. Шуннан тегеі: «Мин түгел, агач та җимешен бирергә теләми, качмакчы итте, ә мин аны барыбер сыктым»,— дигән дә, аллага тапшырып далага юнәлгән. Төш юраучыңны, әйтәм, оста, хан колы булуыңны белеп, гомер бакыеңа ханга хезмәт итәрсең, дип юравы гына булмадымы икән?

— Рәнҗемәгез миңа, олуг бәк. Мин сезгә бары тик төшем сөйләдем.

— Назлыгөл кая соң, хан кызы?

Назлыгөл кызы хакында Дәүраннан хан берничә тапкыр сораган иде инде, аксакал да шул ук сорауны бирде. Чынлап та, Назлыгөл монда түгел микәнни?

— Мин монда үзем Назлыгөлне эзләп килдем, аксакал.

— Назлыгөлне!? Сорап торган була тагын. Зинданга үзен, зинданга! Сакчылар! Алып китегез күз алдымнан! Базга, базга ябыгыз! — дип җикеренде Сәлим хан.

Дәүранның ике ягына җансакчылар килеп басты.

— Карагыз аны, башыннан бер чәче дә төшмәсен,— дип кисәтте Сәлим хан җансакчыларын.

Дәүранны алып чыгып киткәч, аксакал Ягкуб әйтте:

— Хан, ошбу олан илгә бер остадыр. Югалтма син аны. Борын заманда бер акыл иясе: «Дәүләтеңә акыллы затлар җый, кирмәнең таш белән тышлат»,— дигән. Назлыгөлең табыйм дисәң, бу оланны исән калдыр. Күбәләк үз чәчкәсен, адәм үз тиңен табар, ди. Хәтерем ялгышмаса, ошбу олан Туйбикәдән туган кебек иде, җан тартмаса да, кан тартадыр. Туйбикәң бик тә инле хатын иде, урыны оҗмахтадыр... Ишеткәнем хак булса, ошбу баланы табу белән анасы Туйбикә аны хан кызына юраган, фәрештәнең амин дигәненә туры килгәндер, хан.

— Хуш, аксакал, син дигәнчә итик. Йә, хәзер, нә кылыйм ошбу бала белән, ахыр нә эшлим?

— Борынгылар әйткән, кызың үз балаң булса, киявең аның яртысыдыр, дип. Адәм баласы бары тик дүрт нәрсәдән оялмый эш итәр, ди. Беренчесе — илтабарына ышанудыр, икенчесе — чит каннан булса да, үз гомереңә һич югы бер ир бала үстерүдән гыйбарәттер, өченчесе — үзең салган юлдан йөрү хыялыдыр, дүртенчесе — үзең ашаткан малны хәрәм түгел дип ризыкланудадыр. Хан, колчураң оста Алпар сиңа кала өстенә кала салды. Угылы кызына гашыйк булып, аңа өйләнүдә гөнаһ күрмәсәң иде дим. Кичер син аны, ил кырына дошман килгәндә, үз халкыңнан үч алмыйлар. Инде тиздән таң атадыр, юл кешесенең юлда булуы хәерле. Син бүген Бөек Калага кирәк, хан. Ә остаңы миңа калдыр. Табар ул Назлыгөлне. Таеп карамаган — танып белмәс, ди. Хатасын аңлар, шәт, иншалла. Әүвәл илең сакла, хан, аннары кызың акларсың...

— Аксакал, колчурам язмышын синең кулыңа тапшырам. Дошман явыннан исән калсак, мин аны үзем хөкем итәрмен.

3

Хан азатлары Дәүранны челтәрле баз авызын ачып, түбән төшереп җибәрделәр. Баз тирән икән, Дәүран аяк белән төшсә дә тәгәрәп китте. Баз авызын ябулары булды, ул һични күрмәс булды. Дөм караңгылыкта, тын алырга да куркып, бертын аякка басмыйча ятты. Баз төбенә салам җәйгәннәр, йомшак. Йөрәге дөп-дөп тибә, тынлыктан колаклар чыңлый.

— Кем булса бармы монда?

Дәүран күзләрен йомды, соңгы көннәрдәге изге мәлләрне тәгамтәгам күз алдыннан уздырды. Сәлим хан Яңа Казанга килгән көнне күңеле сизгән кебек, Назлыгөл аның иңенә килеп сарылды. Дәүран эштән кайтып кергән генә иде, сөеп туймастай бер халәттә хатынын кулына күтәреп алды да түшәккә илтеп салды. Назлыгөл аңа һәрчак тансык булды, һәрчак сөеп-назлап туймас халәттә калыр иде. Наз-иркәләүгә бирелеп, дөньяларын оныткан мәлләре күп булды. Әмма ул көнне Назлыгөлен бигрәк тә тансыклаган иде, гүяки, баш очларында мәхәббәт фәрештәләре канат кагып утырды. Сыгылмалы зифа сын вә нечкә бил назга тансыклавын сиздереп, кочагына эреп сеңгәндәй итте. Дәүран хатынын сөйде, шашынып үбә-үбә, татлы сүзләр тезде. Хиссият ташкынында чайкалган ахырзаман килдемени, гүя, күккә ашты. Җан-тән тәменең татлы сөю мизгеле икесен дә мәҗбүриятсез, ихтыярсыз итте.

Кабатланмас мизгелләр үткәч, дәшми-тынмый гына бертын таралып яттылар. Әмма тансыклау галәмәте әле узмаган, кытыршы кул нечкә билгә, калку күкрәккә тартылды. Тән җылысы вә кайнарлыгы әле сүрелмәгән, күңел җан эремтәсендә йөзүен дәвам итә иде.

Шул вакытта ул Назлыгөлгә атасы Сәлим ханның Яңа Казанга килүе турында әйтте. Ир-канаты авызыннан бу сүзне ишетүгә, Назлыгөл кинәт торып утырды, куш толымнары калку-калку күкрәкләренә сузылып ятты, толым очларындагы көмеш тәңкәләр алсуланып киткән битенә тиеп-тиеп китте.

— Мин атамнан куркам, Дәүраным! Куркам,— диде Назлыгөл гасабиланып.— Үзем өчен дә, синең өчен дә куркам!

— Курыкма, ханның максаты башка: каланы абаң кулыннан тартып алу. Булат онытына бирмәкче. Миңа калса, ул ошбу каланы ким куйганда башкаласы итмәкчедер.

— Хаҗи абам моңа ризалык бирерме соң?

— Абаң — әмир, атаң — олуг хан. Бирми кая барсын. Көч-куәт атаң ягында.

Назлыгөл битен җанашының битенә куйды, кайнар сулышы белән, гүя, ирнең җанын көйдерде.

— Ниләр генә булса да, мине беркемгә дә бирмәссеңме, Дәүраным?

— Сине!? Мин сине бирәүгә дә бирәчәк түгел, Назлыгөлем, беркемгә дә...

Ул мизгелләрне оныту мөмкинме! Шул мәлдә Назлыгөлнең сагышланып сарылуы, нидер сизенгән кебек тансыклап янә ир-канатына сыенуы күз алдына килүгә, Дәуранның тәне кымырҗып, чемердәп куйды.

— Назлыгөлем, күгәрченем, былбылым...

Дәуран айнып киткәндәй капшанып капка янына килде, тимер кадаклар белән ныгытылган имән такталарны каерырга теләгәндәй, селкетеп карады. Ахыр, хәле бетеп, салам җәйгән җир идәнгә утырды. «Менә аерылыштык та, Назлыгөлем. Менә безне аердылар да»,— диде Дәуран үзалдына чарасызланып.

Яратырга, мәхәббәттә ихлас булырга аны мөгаллиме кәтиб Хафиз өйрәтте, гәрчә үзе кырыкка җитеп өйләнеп карамаган булса да. Мөгаллименә рәхмәте зур иде Дәуранның. Әле булса хәтерендә, ул аңа мәхәббәт турында язылган китаплар укырга бирде. Мәхәббәттә ихласлыкка аны кәтиб Хафиз өйрәткән булса, гүзәллекне күрергә аны атасы Алпар күндерде. Бары тик гүзәллекне күрә белгәч кенә мәһабәт биналар сала башларсың, улым, дияр иде ул. Дәуран әүвәл башта гүзәл әйберләргә атасы күзе белән караса, тора-бара ул моңа кадәр кабатланмаган, күз төшүгә сокланырдай үз нәкышләрен төшерә башлады. Аның халык алдында, хан алдында, ахыр килеп Назлыгөл алдында абруй казануы шуннан иде. Хан кызы Назлыгөлне күргәндә ул хатын-кыздагы гүзәллекнең ни икәнен белә иде инде. Таш-кыяларга төшергән бизәкләрне ул һәрчак Назылгөл гүзәллеге белән тиңләде. Әмма ахыр чиктә төшенде: ни тырышса да, җанлы гүзәллектәге матурлыкны бирә алмаячак, дигән фикергә килде. Иҗат җәфасы аңа әнә шулай хан кызын күргәч килде, Назлыгөлгә кабынган мәхәббәте аша.

Хан сараен нәкышләгән елны Дәуран яшертен генә Назлыгөлнең сурәтен ясарга кереште. Шәех мөридләре белсә, аңа көн күрсәтмәячәкләр иде. Әмма ясаудан туктамады, туктар әмәле калмаган иде, чөнки хан кызы көн-төн күз алдыннан китмәде. Ясады да бозды, ясады да бозды. Чөнки ул ясаган сурәттән хан кызы күп тапкыр матуррак, гүзәлрәк тоела иде.

Күп сагышлана торгач, ул аңа хат язды. Хатында ул хан кызын әле йолдызга охшатты, аннары ай белән чагыштырды, ахыр кояшның үзенә тиңләде. Чынлап та хан кызын күрүе булыр иде, гүя, аның өчен кояш чыгар, күк капусы ачылыр иде. Кызның кыйгач кашларын карлыгач канатлары белән чагыштырды, күзләрен күк йөзенә охшатты. Хан кызы елмайганда бит очларына бармак бите хәтле генә чокырчыклар кунар иде, әнисе аңа ул чокырчыкларны мәхәббәт чокырчыклары, фәрештәләр үпкән җирең, дияр иде. Ә инде күперенке сусыл иреннәрен баллы кәрәзгә тиңләр иде.

Назлыгөл аңа качып килгәч тә, никах укытып, ир белән хатын булып яши башлагач та Дәуран аны сөеп тә, күреп тә туя алмас кебек иде. Ул аның янына сагынып, тансыклап кайтты, аның белән булган мәлләрен сизми дә калыр иде.

— Назлыгөлем-сандугачым, кайда син!..

## 4

Олуг кенәз Юрий Долгорукның Румнан алган хатыныннан туган угланы Михаил вафат булганнан соң, Владимир-Суздәл тәхетенә кенәз Всеволод утыра. Тәхеткә яңа утырган Всеволод кенәзнең Болгарга яу чыгарга җыенуы турындагы хәбәр килеп ирешкәч, Сәлим хан тәмам пошаманга калды. Владимир-Суздәл кенәзлеге Болгар белән солыхта иде. Димәк, яшь кенәз солыхны бозарга уйлаган, моның өстенә яу

чабуының сәбәбен дә җтикермәгән иде. Гадәттә, яхшымы-начармы, күрше булып яшәгән кенәз вә ханнар әүвәл яу чабуларының сәбәбен берберсенә җтикерерләр иде. Яшьләр ата-бабаларыбыздан калган ошбу изге гадәтне дә бозарга исәп тоталар микәнни? Сәлим хан белә иде: Болгар икмәк игеп, мал асрап, сәүдә итеп көн күрсә, урыс кенәзләре гадәттә яу йөрүдән табыш эзлиләр. Кара халык баш калкыта башладымы — кенәзләр тиз арада кай илгә булса да яу чабалар. Яу уңышлы булганда әсирләр кайта, байлык ишәя, халык та беразга тынып тора, бигрәк тә куштаннар, баярлар, рухи атакайлар. Рухи атакайларның кан дошманнары — мөселманнардыр, димәк, Болгар дәүләте.

Шымчы-багучылары аша Сәлим ханга шул нәрсә билгеле булды: кенәз Андрей заманында баярлар һәм рухи атакайлар үсенеп киткән кенәздән читләшәләр. Кара халык арасында кенәзгә каршы үгет-нәсихәт бара. Баярлар кенәзгә, су юллары Идел болгарлары кулында, дип барса, рухи атакайлар, «бусурманнар» христианнарны кысырыклый, дип зарлана. Ул гынамы, «бусурманкага» өйләнгәч Болгарга яу йөрми башладың, дип олуг кенәзгә үпкә белдерәләр. Андрей кенәз, кенәгинә Рокыя үтенече беләнме, Болгарга яу килүдән чынлап та баш тарта. Әмма рухи атакайлар вә баярлар тукталып калмый, кенәз угланы Мстислав белән яу чыга. Мстислав җитәкләгән бу яу аның өчен фаҗигале бетә, яу килүне белеп, болгарлар куа чыккач, елганы кичкәндә аты белән боз астына китә, батудан котылса да, соңра барыбер дөнья куя. Алла бар ул, бар, балакай Мстислав. Дөрес, шул хәлдән соң урыс кенәзләре Болгар юлын онытып торалар иде, әле әнә тәхеткә яшь кенәз Всеволод утыргач, янә Болгарга яу чыгарга исәпләре. Әйе, яу турындагы хәбәр Сәлим ханга вакытында килеп ирешә. Болгарның көч-куәтен белгәнгәме, Всеволод кенәз әүвәл кардәшләре билгән Рәзан кенәзләренә бара, тегеләрнең яуга катнашуларын үтенә. Рәзан кенәзләре бу эштән баш тарта. Всеволод көч куллана, Рәзан кенәзләрен җиңә һәм дружиналарын үзенә ала. Димәк, яшь кенәз көч туплый.

1184 елда Всеволод кенәз Болгарга яу чыккач, һөҗүмне туктату нияте белән Сәлим хан аңа илче итеп үзенең сарай баһадирын җибәрә. Баян баһадир яу килеп яткан кенәзне ярты юлда булса да туктатырга, сөйләшүләр алып барырга тиеш була.

## 5

Олы мәҗлескә илнең аксакаллары, бәкләре, куштаннары, баһадирлары чакырылган иде. Өйлә намазыннан соң алар барысы да тәхет янына килеп тулдылар. Һәммәсе дә утырышкач, Сәлим хан шәехтән дога кылуын сорады, үзе дә кулларын күтәреп, догасын укыды һәм иреннәрен кыймылдата-кыймылдата бит-сакалын сыпырып куйды. Мәҗлескә килгәннәр ни өчен тәхет бүлмәсенә җыелуларын белмәсәләр дә, бераз чамалыйлар иде — илгә яу килә. Һәм һаман шул бер урыслар.

Сәлим хан вәзире Камайга булган хәлне аңлатып бирергә кушты. Вәзир Владимир-Суздәл кенәзенең Болгар иленә яу чыгуы турында хәбәр итте дә, бу хакта фикер әйтергә дип берәм-берәм аксакалларга, аннары башкаларга сүз бирде. Сәлим хан аларның һәммәсен дә дикъкать белән тыңлап утырды. Ханның янәшәсендә ханбикәсе Зөбәрҗәт утыра.

Сәлим хан тәхетеннән күтәрелде, кам таягын кулына алды.

— Аксакаллар, кардәшләр. Нә кылабыз, калаларыбызга бикләнәбезме, дошманга каршы чыгып орышабызмы? Соңгысы минем өчен үтә хикмәтле хәлдер, аксакаллар. Илһам углан, син дә фикереӊ әйтерсең.

— Мин калаларда бикләнеп орышу ягында, атам.

— Мин дә, мин дә,— диештеләр аксакаллар. Шул ук вакытта беръякка да дәшми-тынмый утыручылар да бар иде. Әмма Сәлим хан

аларны күрмәмешкә сабышты. Әмир Хажи угланы бөтенләй килмәгән. Шуны гына көткән кебек, бер аксакал:

— Өлкән угланың кайда соң, хан? — дип сорады.

— Хөрмәткә ия Таштургай аксакал, әмир Хажи угланым миңа буйсынмас булды,— диде Сәлим хан, һәм үз сүзләреннән үзе үк куркып китте.— Боерыгым тыңлагыз, аксакаллар. Мән болай итәрем. Бөек Каланы саклауны Илһам угланыма тапшырам. Баһадирларымның барысы да аңа буйсыныр лар. Инде фатиха бирегез, аксакаллар.

Аксакаллар сакалларын сыпырып куйдылар, авыз эченнән генә дога кылдылар, алладан ярдәм сорадылар. Ахыр килеп халык тарала башлады. Сәлим хан вәзиренә янында калырга кушты.

— Сиңа, вәзирем, Янтак хан ыстанына барырга туры килер,— диде.

— Баш өстем, ханым,— диде вәзир.

— Хәтерем ялгышмаса, Камай, син энем Мөхәммәтгалим бәк белән бер мәдрәсәдә укыган идең?

— Хәтерегез ялгышмый, хан, Мөхәммәтгалим бәк белән без бер мәдрәсәдә укыдык. Кызлар тавына да бергә чыгар идек.

— Кызлар дигәннән, вәзир Камай, өйләнергә ниятең юкмы соң? Мин сиңа Казаннан бер кыз алып кайттым. Өйләнәм дисәң, никахны шәех бүген үк укыр иде.

Вәзир Камай кәтиб Хафиз ягына күз төшереп алды. Көлми иде кәтиб. Димәк, хан шаяртмый. Мәгәр, ханбикә Зөбәрҗәткә күз сирпү белән Камайның күз кабагы тартыша башлады. Ә ханбикә ирен чите белән тымызык кына көлемсерәп утыра бирде.

— Хан иям, коткар мине ошбу мәшәкатьтән. Чыкмас ул миңа кияүгә, күрү белән гайрәте чигәр. Йөрәккә йөгән салып булмый, йөрәк ат түгел.

— Син аңардан курыкмасаң, ул синнән курыкмас, иншалла, вәзир Камай,— диде ханбикә. Бу юлы Зөбәрҗәт ханбикә көлми иде инде.

— Хан иям, килешерме соң? Борын төбендә яу, ә син вәзиреңне өйләндереп ятасың? — диде вәзир Камай.

— Риза, димәк,— диде Сәлим хан.— Бусагабаш Субай, шәехне китер, ә син, ханбикә, бар, Зәмзәмбикәне дәш. Бар, бар, ханбикә, шулай кирәк...

Сәер хәл, Сәлим хан Зәмзәмбикәне күргәч тә: «Менә вәзирем Камайга кәләш»,— дип уйлаган иде. Шул исәп белән ул аны Назлыгөлгә ияртеп тә җибәргән иде. Назлыгөл юлда ук юкка чыкты, ә Зәмзәмбикәне урлаучылар табылмаган. Бернинди гаебе булмаса да, Назлыгөл югалганнан соң, сыкталып елап утырган кызны күреп, хан кызганып куйган иде. Кыз кияүгә чыгам дип тора, әйдә, чыксын, кинәнсен, иләгенә күрә чиләге. Аның каравы Сәлим хан икс куянны тотачак: Зәмзәмбикә дә кияүле булачак, татлы аен ташлап киткән вәзир Камай да Янтак хан ыстанында калмаячак. Дөрес, Зөбәрҗәт ханбикә ханның бу чарасын килештереп бетермәде. Әмма хатын-кызгамы олуг ханның ни теләвен аңларга. Зәмзәмбикә беренче карашка котсызрак күренсә дә, тәнгә йомшак, телгә юмарт шикелле. Вәзир Камай яратыр. Кыз жансыз, бал тәмсез булмый.

Ул арада сарайга шәех килде, аның артыннан ук тәхет ягына Зәмзәмбикәне алып керделәр.

Вәзир Камай кызны бер күрүдә үк ошатты. Ул аңа бик тә сөйкемле тоелды. Үзе кебек үк юан гәүдәле, симерүе житкән үрдәк кебек ауман-тәүмән йөри, мөбәрәк чырайлы, битләре алсу, йөзе мөлаем иде. Һәрхәлдә, кияү егет Камайга шулай күренде ул. Ханбикә кызга аны вәзир Камайга димләүләре хакында әйтмәгән булып чыкты, әллә инде икеләнде, ә инде сарайда шәехне дә күргәч, төгаен ышанды, хан янына килеп:

— Мин аңа вәзиреңә димләвең хакында әйтмәдем,— диде.

— Зәмзәмбикә,— диде хан.— Ибраһим каласыннан Назлыгөлне урлаган чакта син аның белән бер бүлмәдә булгансың. Сине белми-күрми калдылармы, әллә булмаса...

— Күрделәр, олуг хан, күрделәр, әйтергә оялам,— диде кыз.
— Нә ояты бар аның, әйт!
— Моны нинди ат күтәрсен, калсын, диделәр.
Сәлим хан Зәмзәмбикәнең гәүдә-сынына кабат күз төшереп алды да карашын вәзир Камайга күчерде. Хан артыннан Зәмзәмбикә дә шул якка карады һәм: «Бу нинди күзле бүкән тагын»,— дип уйлап куйды. Әмма икенче мәлдә инде: «Затлы нәселдәндер, өс-башы ару»,— дип уйлады.
— Зәмзәмбикә балакай, каршыңда сиңа күзе төшкән вәзирем басып тора. Ул синең кулыңны сорый, балакай... Аты Камайдыр, минем кадерле вәзиремдер.
Вәзир Камай, ихтыярсыздан сирәк тешләрен күрсәтеп, елмаеп куйды. Гаҗәп, Зәмзәмбикәгә кияү буласы адәм алай ук тәүгечә шыксыз күренмәде. Кайберәүләр аңа әйтә торганнар иде: ир-ат аюга тартым булса да ярый, явыз гына булмасын, дип. Язмышымдыр, килешим, җитмәсә үзе вәзир дә икән, дип уйлады.
Зәмзәмбикәнең йөзенә, гүя, комач җәйделәр, колакларына кадәр кызарынып чыкты.
— Йә, балакай?— диде Сәлим хан.— Фатиха биримме? Риза буласың икән, никахны да укытып алырбыз, шәех монда.
— Мин ризамындыр.
— Шәех Ишкул, аллага тапшырып, никахны укы. Йә, янәшә басыгыз,— диде Сәлим хан.
Никах укылып, яшьләрне үз якларына чыгарып җибәргәч, Сәлим хан казнабашы әрмән Варданны чакырды һәм шәех Ишкулга өч алтын бирергә кушты. Шәех Ишкул чыгып киткәч, тәхет ягында икәүдән-икәү генә калгач, ханбикә Зөбәрҗәт иренең күзләренә карады.
— Нигә кирәк булды сиңа бу тамаша, ханым?— дип сорады.
— Иртәгә вәзир Камай Янтак хан ыстанына китә. Ханны килештереп карасын. Янтак гомер-гомергә ялланып орышты.
— Уең барып чыкса, бу хәйран хәйләдер, ханым. Әйе, күрше белән күрше орышу язык түгел, телебез, динебез башкадыр. Ничек тә телебез вә динебез бер булган Янтак ханны туктатасы иде.
— Камай шуның өчен бара, аңа игелек телик, ханбикә. Морадына ирешеп кайтуын телик, аллаһы боерган булса...
Атыла-кабалана тәхет ягына бусагабаш килеп керде.
— Хан иям, кыпчак ханы Янтак Сәкъсин каласын алган. Бачман әмиренең азатларын далага сибеп, Бөек Калага юнәлгән. Азатларның беришесе Нугай капкасына килеп туктады.
— Ачыгыз капкаларны, кертегез азатларны! Таймас баһадир кая?
— Таймас баһадир Үлдәмирдә, хан иям, кайтып җитмәде.
— Илчене тотып япкан булсалар? Кенәз Всеволод Болгарга яу килә.
— Таймас баһадир Күчтем сәүдәгәр кул астында. Күчтем безгә хыянәт итмәс, Бөек Кала тулы кибете, аннары энесе Апанай ислам динен кабул итте, Болгарда яши.
— Шул Апанайны минем кырга китерегез әле.
Бусагабаш чыгып киткәч, Сәлим хан хәрби киемнәрен соратып алды, түр якка кереп, киенеп чыкты. Ул арада сарайга Апанайны китереп җиткерделәр. Хан каршына килеп басуга, Апанай баш орды һәм торып:
— Аллаһы тәгалә куәт бирсен, олуг хан!— диде.
Куәт теләве урынлы иде. Сәлим хан Апанайга текәлеп бераз дәшми торды. Ул бу кешене белми дә, ә шулай да Яңа Калада яу турындагы хәбәрне җиткерүче шул кеше булды.
— Утыр, кем дип белик инде үзеңне, алла бәндәсе,— диде.
— Сәүдәгәр мин, олуг хан, һөнәрче дә.
— Яу турында каян белдең?
— Яуга кенәз теләп килми, хан. Михаил үлгәннән соң тәхеткә Всеволод утырды. Баярлар кенәз нәселенә үчле. Всеволод баярлар көен көйли, баярлар кубызына бии. Баярлар котыртуы белән башта Рәзан

кенәзләренә яу чапты. Тегеләрне буйсындырды. Рәзанга үз угланын — Ярукны утыртты. Андрей кенәзнең башына җиткән тиуннар әкренләп Всеволод кенәз ягына күчә бара. Кенәзнең Болгарга яу чыгуына баярлар гына түгел, тиуннары да, рухани атакайлар да гаепле, хан.

— Ул турыда без хәбәрдар, оста. Урыс явы Сүрә елгасына якынлашып килә, көч-куәте күпме?

— Бу яуга Всеволод кенәз бөтен көч-куәтен җыйды. Яуга Киев кенәзе Святослав, кенәз Изяслав, кенәз Мстислав катнаша. Мондый яуга урысның чыкканы юк иде әле, хан. Всеволод кенәзнең максаты да билгеле миңа, хан. Урыс сәүдәгәрләренең үзбаш Өргәнечкә, Табгачларга чыгасылары килә. Ә юл өстендә, бугазга төртелгән сөяк кебек, Болгар сәүдәгәрләре утыра.

— Хуш, Апанай, хәбәрең өчен рәхмәт. Игелекле юлда бул, уңышлар телимен...

Түр яктан вәзир Камай балкып чыкты, ул тыенкы гына елмайган Зәмзәмбикәне җитәкләгән иде.

— Йа алла, килештенездәме? Бусагабаш, казнабаш Варданны дәш,— диде хан урыныннан күтәрелми генә.

Казнабаш килеп кергәч тә, Сәлим хан аның колагына нидер әйтте. Казнабаш чыгып китте һәм бераздан әйләнеп керде дә хан кулына затлы балдак салды.

— Менә бу балдакны, вәзирем Камай, энем Мөхәммәтгалим бәккә бүләк итәрсең. Исеңдә тот, балдак бары тик энем Мөхәммәтгалим бәк кулына керергә тиеш.

— Балдакның сере нидән гыйбарәт соң, ханым?

— Анысы сиңа кирәкми. Син миннән качып киттең. Уй-ниятең вә теләгең — сабакташыңны Болгар тәхетенә утырту.

— Ниятең аңладым, ханым. Барысын да син дигәнчә итәрмен.

— Хода юлдашың булсын, вәзир Камай.

Вәзир Камай белән Зәмзәмбикә чыгып киткәч, Сәлим хан бусагабашны чакырып алды, болдыр янына атын китерергә кушты.

Сәлим хан өчен авыр сынау көннәре башланды.

### 6

Вәзир Камай китеп өч көн үтүгә, Биек Кала кирмәнен урыс-кыпчак гаскәре камап алды. Камау ике көнгә сузылды, ике яктан да хәзергә ни атыш, ни сөйләшүләр алып барылмады. Һәрьяк үз эше белән мәшгуль иде. Кирмәндәгеләр диварларга сәрпи ук җайланмаларын урнаштырды, атакайлар, меңбашлар үз урыннарын алдылар. Сәлим хан угланы Илһам белән бергә кирмән ныгытмаларын карап чыкты. Иравыл азатларны Нугай капкасы янында күреп, хан шунда туктады. Илһам углан атасына аңлатты, җай туса, иравыл гаскәриләр кирмәннән чыгып, дошманны борчып, кире борылып керергә тиешләр икән. Камауның икенче көнендә баһадир Тубыкбайдан чаптар килде. Авырлык белән булса да кирмәнгә үтеп кергән чаптар Сәлим ханга Тубыкбай, баһадир үз гаскәре белән Чирмешән елгасы артындагы урманда яшеренеп тора, дигән хәбәр китерде. Сәлим хан шатлыгын сиздермәсә дә, Тубыкбайның ярдәмгә килүенә шат иде. Ләкин ул тагын бер кешедән — угланы әмир Хаҗидан да чаптар көтә иде. Әмма ул яктан хәбәр килми дә килми.

Өченче көн дигәндә дошман беренче тапкыр кирмәнгә һөҗүм итте, әмма су базына да җитә алмыйча, йөзләрчә мәет калдырып, чигенергә мәҗбүр булды. Камаучылар һичнинди сөйләшүләр алып бармыйлар, димәк, максатларына ирешмичә китәргә исәпләре юк иде. Бу көннәрдә Сәлим хан һаман күзәтү манарасында булды. Үзе янында җансакчыларын һәм табибен тотты. Әмма табибе еш кына китеп югалгалады. Сәлим ханга бу ошамады. Бер тапкыр табиб Антоний манарага менеп, янына басуга:

— Кирмән камауда чакта син кая булырга тиешсен, табиб? — дип сорады.

— Хан янында, шөһрәтлем.

— Хан янында булырга тиеш булгач, хан янында бул, табиб,— диде хан, ачулана төшеп.

— Баш өстем, хан.

— Әйт әле, табиб Антоний, кенәз Всеволод ни сәбәпле төрки Болгарына яу килде?

— Мине хан белән кенәз арасындагы сәяси хәлләр кызыксындырмый, олуг хан. Мин — табиб. Иң әүвәл сезнең сәламәтлекне саклаячакмын.

— Бәлкемдер, бәлкемдер, табиб. Ә шулай да ни өмет итеп килде кенәз? Һәм бер үзе генә түгел, бөтен урыс кенәзләре белән? Белмисен?.. Ә мин беләм, табиб. Син бит христиан, кяфер, шуны белеп торсаң иде — дин белән дин орыша, болгар белән урыс түгел. Олуг кенәз шул хәтле гаскәр белән гомер бакый сәүдә итеп яшәгән күрше болгар халкына каршы түгел, мөселманнарга каршы килгән бүген, табиб Антоний.

— Олуг хан, миңа калса, кенәз кирмәнне озак камап тора алмас, ташаткычлары юк, утчагырлары да күренми.

— Утчагыр! — диде Сәлим хан кисәк табибенә таба борылып.— Утчагырлары булса, алырлар идеме?

— Утчагыр — яңа корал, олуг хан. Урысларда ул юк. Димәк, торыр-торыр да кенәз Всеволод китеп барыр.

— Буш кул беләнме? Буш кул белән китсә, аны кенәз Әндрей язмышы көтә. Баярлар вә рухани атакайлар моны кичермәячәк. Шуның өчен кенәз Всеволод соңгы сулышына кадәр орышыр, табиб Антоний. Иллә кирмәнне ала алмас ул. Тиздән аңа Тубыкбай баһадирның кылычын да татып карарга туры килер. Юк, кирмәнне мин кенәзгә бирмәм, табиб. Мине кенәз борчымый, кирмәнне ала алмавына инануга, кенәз сөйләшү башлар. Мине, табибем Антоний, энем Мөхәммәтгалим бәкне алып килгән Янтак хан гаскәре борчый. Кыпчак ханы Янтак бик күп кирмәннәрнең башына җиткән кеше. Төлке дә төлке, ул да төлке. Оста орыша.

— Угланың әмир Хаҗи аны тиз куып җибәрер.

— Әмир Хаҗи углан ярдәмгә килер дип уйлыйсыңмы, табибем? Мин аның белән пычакка пычак. Чарасыз калдым ул хакта.

— Килер ул, олуг хан, түзмәс. Ил саклау, кыз саклау түгел, хан.

— Безнеңчә ару гына сөйләшә башладың әле син, табиб Антоний.

— Олуг хан, сезне ханбикә көтә, иртән авызына ризык салмый чыгып киткән иде, ди.

— Табиб Антоний, ханбикә миңа кенәз янына чыгып баш ияргә куша. Килешү алып бар, ди. Ә минем яу белән килгән күршемә баш иясем килми, табиб. Дәүләт саклауны хатын-кыз кулына калдырсаң, бөтенләй югалтуың да бар.

Хан күзәткән манарага йөгереп әмир Илһам менде.

— Атам, кенәз һаман китми, әллә чыгып орышыйкмы?

— Ашыкма, углан. Кем белә, бәлкем кенәз белән Баян баһадир сөйләшүләр алып барадыр. Янтак хан ыстанында вәзир Камай. Ходай кушып алар да килешеп куйсалар...

— Атам, кирмәндәге чит ил сәүдәгәрләре дә коралланырга телиләр, ни кылыйк?

— Өләшегез булган коралны. Алар үз малларын, без калабызны саклarбыз.

* * *

Яңа көн туган саен Сәлим хан манарага менде, дошман ягын күзәтте. Сәлим хан кирмән диварындагы ташаткычларга, сәрпи ук, бихисап азатларга күз төшереп ала. Берничә көн инде дошман ягында иртән-

иртүк хәрәкәт кузгала. Өченче көнне һөҗүм башланды. Урыслар кирмән тирәли казылган сулы чокырларга бүрәнә тутырырга тотындылар. Читән ышыкламалар артыннан, аларны сакларга тырышып, ук яудыра тордылар. Бүрәнәләр тутырылган күперчек аша дивар ягына якынлашкан кыюлар да табылды. Әмма һөҗүм көнозын барса да, диварга менәргә баскычлар тоткан дошман гаскәре максатына ирешә алмады, чигенергә мәҗбүр булды. Очлап утыртылган имән баганалары арасында, чокыр буйларында меңләгән мәет ятып калды. Урыс кенәзенең һөҗүм дулкыны сүрелергә өлгермәде, Сәкъсин капкасы ягыннан Янтак хан гаскәре ташланды. Сәлим хан, угланы Илһамны ияртеп, Сәкъсин капкасына чапты. Күзәтү манарасына менүгә, коты алынды. Янтак хан азатлары су чокырын узып, диварга якынлашып килә, кулларында баскычлар, ыргаклы баулар. Сәлим хан манарадан төште, йөгереп диварга менде. Һәм азатларына куәт биреп, сәрпи ук атучыларга боерык биреп торды. Ул да түгел, кардәш төркиләр сөягән баскычлар аша күтәрелә башладылар, хан сугышчылары алар өстенә кайнар сумала түктеләр, утлы кисәү ташладылар, таш аттылар. Артык кыюланып киткән дошман сугышчыларын болгар мәргәннәре укка алып, берәм-берәм чүпли тордылар. Мәгәр Янтак хан ягында мәргәннәр күп иде, дивар өстендә йөзләрчә болгар азатларын һәлак кылды. Сәлим хан сугышчылар арасыннан Мөхәммәтгалим бәкне эзләде. Ләкин ни караса да күрә алмады.

Янтак хан гаскәре кичен кояш баегач кына ыстанына таба чигенде. Төнлә белән мәетләрне җыясы, туганнар каберлегенә күмәсе бар иде. Кирмән эчендә дә шундый берничә туганнар кабере калкып чыкты.

Шактый югалтуларга дучар булган Янтак хан иртәгә дә көчле һөҗүм итәр, шуңа күрә хан Нугай капкасы ягыннан ике йөз мәргәнне Сәкъсин капкасы ягына күчерергә боерык бирде.

Яңа көннең кояшы бик акрын күтәрелде. Кояш чыга башлауга, ил башы Хан капкасы янына юнәлде. Багучылары ханга җиткерделәр: Всеволод кенәз төн эчендә бөтен көчен шул тарафка туплаган икән.

Кояш күтәрелүгә, урыслар һөҗүм башладылар. Бер төркем кыю сугышчылар Хан капкасы янына ук килеп җитте, капкага менә башладылар. Мәргәннәр кыюларны чүпли торсалар да, дошман дулкындулкын агыла торды. Капка тирәсе мәет белән тулды, болгар да күп кырылды. Бары тик кич якта гына һөҗүм басыла төште. Шунда гына Сәлим хан җаны көюен тоеп, аска төшеп, кем кулыннандыр алып бер чүмеч су эчте.

Шулчак хан янына Таймас баһадирдан багучы килде.

— Олуг хан, капка янында яшь кенәз Изяславны каты яралаганбыз. Илче килгән, капканы ачуны сорый, кертикме?

— Бау белән тартып алыгыз! — дип боерды Сәлим хан.

Күп тә үтми кенәз илчесен хан янына китереп тә җиткерделәр.

Сәлим хан эңгер иңеп килсә дә, илченең затлы киеменә игътибар итте.

— Тылмач! — диде Сәлим хан.— Тылмач кая?

— Миңа тылмач кирәкми,— диде илче.

— Яхшы, илче. Йомышың җиткер.

— Сезгә кенәз Всеволод мөрәҗәгать итә. Бүгенге һөҗүмдә яшь кенәз Изяслав каты яраланды. Кенәз сездән табиб сорый.

— Табиб кирәк булдымыни кенәзгә! Менә бит син аны. Яу килә, җитмәсә табибемне сорый,— диде ачуын яшерергә теләп, әмма тешен кыса төшеп Сәлим хан.

Хан ачулы иде, азатларының кырылуын күрүе бик кыен иде, кирмәндә камауда тору җиңел түгел, ә шул кирмәнне камап торучы кенәз аңардан ярдәм сорый. Шаккатмалы хәл иде. Әмма уйлана торгач, Сәлим хан сабырлана төште.

— Кенәзнең хәле авыр,— диде илче.

— Минем хәлем жиңелме! — диде ул, әмма шунда ук: — Табиб Антоний кайда?! — дип сорады.

Ул арада хан янына табиб Антоний килеп басты.

— Мин монда, олуг хан.

— Әйтче, табибем, кенәзне Болгарга мин чакырып китермәдем, үзе килде. Ә мин аңа игелек кылырга тиешме?!

— Изгелек җирдә ятмый, хан,— диде илче.

— Изгелек, әйе, әмма игелек кылган кешегә яманлык кылынса...— Сәлим хан әмир Илһамга таба борылды.— Хәл ит, углан. Ил-җирем сиңа каласы. Тик әүвәл әйтер сүзем тыңла: кенәзгә ышанмыйм, табиб Антонийны кире җибәрмәс. Яшь кенәз яралангандыр, орыш корбансыз булмый. Үзең хәл ит.

— Яхшы, атам. Табиб Антоний, җый әйберләреңі — дип боерды әмир Илһам.

Сәлим хан акрын гына атына атланды, сараена таба юнәлде. Ул тәмам арыган иде, тизрәк кайтып ханбикәсен күрәсе итте, аны күрсә, аз гына булса да җаны тынычланыр сыман иде.

## 7

Всеволод кенәз рухи атасы Савваны тыңлады да, тыңламады да. Әмма ара-тирә колагына эленеп киткән атаның сүзләре йөрәгенә шырпы сыман кадалгандай булды. Рухи ата кирмәнгә көн-төн һөҗүм итүне таләп итә иде. Кирмән дивары янында ятып калган сугышчыларының саны ишәя бара, рухи атакай өчен алар, гүя, адәм балалары да, җантуганнар да түгел иде. Кенәз баштан ук Болгарга теләп яу чыкмаган иде. Берничә кала-кирмәнне алсалар да, болгарлар нык каршы тора, бер дә бирелергә теләмиләр иде.

Хан капкасына һөҗүм иткәндә каты яраланган бертуган агасының угланы яшь кенәз Изяславның үлем белән тартышып, ыңгырашып ятуы, үзе белән алып килгән табибнең яралы белән һични кыла алмавы кенәзне чарасыз итте. Ул белә иде, ханда даны-аты Владимирга җиткән табиб бар, кенәз Сәлим ханга табибен бирүен үтенеп илче җибәрергә булды. Хан әллә бирә иде табибен, әллә юк, ә энесе җан тартыша, үлем белән көрәшә. Рухи атакай исә, гүя, моны күрми дә, кенәзне һаман исә һөҗүмгә өнди.

— Илгә буш кул белән кайтсак, халык сине дә, мине дә кичермәс. Андрей кенәз көненә каласың киләме әллә?!

— Кичерер,— диде Всеволод кенәз.— Мин сугышчыларымны саклап калырга тырышам. Миңа һәр сугышчым кадерле.

— Сугышчы орышыр, даны сиңа калыр. Кенәзләргә дан тәхеттә утырып килми, орышларда килә, балакай. Һөҗүмең туктатырга ниятләгәнсең икән, ханга шарт куй: тынычлыкны алтынга сатып алсын!

Кенәз Всеволод яңак итен чәйни-чәйни чатыр ишегеннән болгарлар кирмәненә карап торды, анда һөҗүмгә ташланган сугышчылар дулкын-дулкын булып кире чигенәләр иде, ә рухи атакай һаман корбан таләп итә. Әтәчләнеп, хан энесен Болгар тәхетенә утыртам дип килгән Янтак та әллә ни кыра алмый иде күрәсең, чаптарлары ыстан туктаган, дип хәбәр итеп торалар. Мондый очракта мәрхүм абасы Андрей кенәз нишләр иде икән? Юк, ул тыңламас иде рухи атакайны, кысылма минем эшемә, дияр иде. Хәер, шул башбаштаклыгы, баярлар белән рухи аталарны тыңламавы аркасында башына да җиттеләр бахырның. Әмма Всеволод кенәз абасы Андрейның язмышын кабатламас, чөнки Владимир-Суздәл тәхете аңа артык кыйммәткә төште. Андрейның бикәсе Рокыя да, Всеволод кенәзнең Мариясе дә Болгар кызлары иде. Икесе ике анадан тусалар да, Андрей абасы белән бажайлар булып яшәделәр. Кенәгинә Екатерина (Рокыя) Андрейның Болгарга яу баруын теләмәде, каршы булды ә

Всеволод кенәз үткән хәлләр турында бар нәрсәдән дә хәбәрдар иде. Ата ягыннан туганнар булган Андрей кенәзне кемнәр, кайда үтерәчәкләрен ул алдан белде. Белде, әмма ярдәмгә ташланмады, киресенчә, рухи атакайга барып Андрей турында зарланды. Имеш, тыңламый, баш бирми башлады атасы олуг кенәз. Кыскасы, кенәз Всеволод рухи атакайның теләген үтәде.— Ул туганы Андрейга үчле иде. Анасы Еленага Андрей көн күрсәтмәде, ахыр килеп Чехия короленең кызы кенәгинә Елена ике угланын алып, туган иленә кайтып китәргә мәҗбүр булды. Анасы кенәз Андрейга карата һәрчак нәфрәт тотты, Всеволод моны күрмәде түгел, күрде. Всеволод балачагы узган туган ягын оныта алмады, анасыннан яшереп, абасы Андрейга: «Минем туган илемә кайтасым килә»,— дип хат язды. Кенәз Андрей аңа: «Ростов тәхетенә утырырсың, кайт»,— дип җавап бирде. Кайткач ул аңа чынлап та Ростовны бирде һәм үз хатынының туганы Зөһрәгә өйләндерде. Зөһрәне чукындыргач, рухи атакай аңа Мария дип исем такты.

Егерме яшендә иленә әйләнеп кайткан Всеволод Ростов кенәзе булган иде. Күп тә үтмәде, олуг кенәз дәрәҗәсенә иреште. Шушы еллар арасында Всеволод халык алдында шактый абруй казанды. Аны халык кына түгел, тиуннар, куштаннар да, дружина җиһангирлары да, хәтта рухи атакайлар да хөрмәт итә башлады. Фәкать атакай Савва аннан һаман да канәгать түгел сыман. Рухи атакайларның күбесе урыслашкан славян болгарлары яисә греклар иде. Шуның өчендер, ихтимал, Всеволод кенәз рухи атакайларны яратып бетерми. Әмма бу хакта кыеп кына сүз әйтергә базмады. Аларны тыңлап, үзенчә эшләгән чаклары булса да, ахыр чиктә барыбер руханилар киңәшен тотты. Бүген менә кардәше Изяслав җан тартышып ятканда рухи атакайның үзенә басым ясавын бөтенләй дә ошатмады.

— Епископ Савва, безгә әлегә яхшы табиб кирәк,— диде ул коры гына.

— Сәлим ханда грек Антоний табиблек итә, сорат, бәлки бирер!

— Сәлим хан моңа килешер дип уйлыйсызмы, атакай?

— Ханның табибен бирми хәле юк. Кирмән камауда, кеше түгел, кош та очып чыкмас.

— Ләкин Сәлим хан бер дә бирешергә җыенмый. Кичә, әнә, әмир Хаҗи угланы корабчылар янына килеп, каравыл сугышчыларымны кырып киткән. Тубыкбай баһадир һәркөн борчып тора. Өермәдәй килеп чыга да йөзләгән сугышчыны чәнчеп-чабып китеп бара. Куып җитеп орышыйм димә, гүя, җил ала үзен.

— Ханга илче җибәр. Табибен сорат. Соңыннан күз күрер,— диде рухи атакай Савва, сүзе бетүен аңлатып, кузгала башлады.— Безгә су юлларын уртак итәргә кирәк. Бөтен Рәсәй белән яу килеп, буш кул белән әйләнеп кайтырбызмы? Һич югы ханнан һәр һәлак булган сугышчың өчен бер алтын сора.

## 8

Сарайга кайтып кергәндә Сәлим ханның башына янә бер уй килде. Әмир Илһам угланын илче итеп Всеволод кенәз янына чыгарса? Әйе, табиб Антоний белән үк?..

Менә хикмәт, зиһенен телеп үткән бу уеннан ул ханбикә янына кайтып кергәч тә арына алмады. Ахырдан барысын да ханбикәгә сөйләп бирде.

— Чыгар угланың, ханиям. Белеп кайтсын, ни тели кенәз?..

Сәлим хан бусагабашны чакырып алды, Илһам угланын дәштерде.

...Икенче көнне таң беленер-беленмәс Илһам углан белән табиб Антоний, кенәз Всеволод илчесенә ияреп, дошман ягына чыктылар. Чатыр ишеге янында олуг кенәз аларны үзе каршы алды.

Чатырга керү белән табиб Антоний үз вазифасын үтәргә кереште. Кенәз Всеволод илче Илһам угланны икенче чатырга алып чыкты. Епископ Савва, энәгә таккан җептәй, аларга иярде. Керделәр. Утырыштылар. Кенәз сүзсез генә Илһамга карап алды.

— Урысча сөйләшә?— дип сорады ул, ниһаять.

— Сөйләшәм, кенәз,— диде Илһам. — Хатыным Мария кенәз токымыннан, бераз өйрәтте.

— Илченең шартлары бардыр, кенәз,— диде рухи атакай Савва.

— Бардыр, сорармын,— диде кенәз кырт кына.

Әмир Илһам сизеп алды: кенәз рухи атакай Савваны өнәп бетерми, мәгәр, күрәсең, ансыз да яши алмыйдыр, юкса ияртеп кермәс иде. «Бер караганда без якыннар ич. Син, кенәз, Болгар кияве, мин Владимир кияве. Ә менә орышабыз» — дип уйлады әмир Илһам, каш астыннан гына епископ Савваны күзәтеп.

— Йә,— диде кенәз, түмәренә җәелеп утыргач.— Ни тели Сәлим хан миннән? Мин беләм, ул китүемне телидер? Ләкин мин буш кул белән генә китәргә исәп тотмыйм, әмир Илһам. Минем батыр сугышчыларым күп тапкыр кирмәнгә һөҗүм итте, өч меңнән артык сугышчымны югалттым, Изяслав кенәз үлем белән тартышып ята. Димәк, иртәме-соңмы, мин барыбер кирмәнне алырмын, әмир Илһам.

— Ханның шарты бер, олуг кенәз — китүегезне үтенә. Болгарга яу килгән өчен генә түгел, иржә-мукшы җирләрен талаган өчен дә хан сезгә рәнҗүледер.

— Юкка рәнҗемәсен хан, иржә-мукшы җирләрен мин барыбер буйсындырырмын. Мөстәкыйль тормыш булмас аларга. Пуреш инде минем кул астымда, тиздән Пургасы да аягыма килеп егылыр. Кыскасы, әмир Илһам, һәлак булган сугышчыма бер алтын биргәндә генә Всеволод кенәз Болгарны ташлап китәр.

— Мин олуг хан белән киңәшеп карармын, кенәз.

— Илче табиб Антонийны миндә калдырыр,— диде Всеволод кенәз.

— Табиб ирекле адәмдер, кенәз. Тели икән — кала бирсен. Әмир буларак мин моңа үзем дә җавап бирә аламдыр. Инде безнең шартны тыңла, кенәз. Сиңа мәгълүм булса кирәк, кенәз, ханның энесе, ягъни минем агам Мөхәммәтгалим бәк Янтак хан даласына китеп, аның кызына өйләнә. Мөхәммәтгалим бәк агам теге вакытта Болгар тәхетенә дәгъва тоткан кешедер. Олуг хан бер шарт куйды: барлык гаскәрләрне алып киткәндә генә кенәзнең шарты үтәлер.

Кенәз Всеволод епископ Савва белән озара киңәшеп алды. Ахры, әмир Илһамның шарты аларны шактый кыен хәлгә куйган иде, кенәз илчегә чатырдан чыгып торырга кушты. Һәм гаҗәбе шул булды: бары тик кич якта гына илчене чатырга чакырып алдылар.

— Әмир Илһам,— диде Всеволод кенәз, илче чатырга кереп, күрсәтелгән түмәргә утыруга.— Ханга да, сиңа да минем хөрмәтем зурдыр. Киңәшең тотып, бүген төнлә гаскәрем алып китәргә булдым. Хан табибе Антоний минем белән китәр. Алтынны хан казнабашы елга буена китерер. Без киңәштек-киңәштек тә, аталарымыз кебек, Төрки Болгары белән солых төзергә булдык. Инде җавабың көтәм, әмир Илһам. Ошбу солых битеген олуг ханга бирерсең.

— Ходай тәгалә ярлыка кыла күрсен, мин ризамындыр, кенәз,— диде әмир Илһам һәм үзенә ияргән җансакчылары белән кирмәнгә юнәлде.

Шул ук төндә кәтиб Хафиз кенәз Всеволод битекчесе белән ике телдә дә солых шартларын яздылар. Солых битекләренә әүвәл Сәлим хан кул куйды, аннары шул ук төндә аны кенәзгә илттеләр. Бер нөсхәсен аңарда калдырып, ул кул куйган икенче нөсхәсен хан сараена алып кайттылар. Олуг кенәз белән олуг хан атаулы имзаларын салган солых битеген күрде дә, ханбикә Зөбәрҗәт ир күкрәгенә капланып елап җибәрде. Сәлим ханның да күзләре яшь белән мөлдерәп тулган иде.

Әнә шулай 1184 елда урыс кенәзе Всеволод белән Төрки Болгары ханы Сәлим тату яшәү һәм тыныч сәүдә итүгә солых төзеделәр.

Кенәз Всеволод үз сүзендә торды: шул төндә, хан вәгъдә иткән алтынны алып, шау-шусыз гына елгага таба кузгалды һәм иртәнге якта корабларына төялеп, китеп барды. Әмир Илһам ана өч мең тәңкә алтынны үзе илтеп бирде. Тан алдыннан гына кирмәнгә әйләнеп кайтты һәм атасы Сәлим ханга:

— Атам, соенче, кенәз Всеволод гаскәре белән корабларга төялеп китеп ята,— дигән хәбәрне житкерде.

Сәлим хан башта Чирмешән елгасы буйларында яшеренеп йөргән Тубыкбай баһадирга чаптар жибәрә, урысларның камауны ташлап китүләре турында хәбәр итә, кирмән янында гаскәре белән Янтак ханның гына калуын искәрә. Һәм баһадирына хан ыстанын камарга куша. Үзе исә таң атып килгәндә Нугай капкасы аша бар булган гаскәре белән чыгып, көтмәгәндә дала ханының ыстанын камый. Бу яман хәлне соңгарак калып сизеп алган Янтак хан ермак алае белән орышка ташлана, әмма көтелмәгән югалтуларга дучар була. Хәлнең асылын аңлап алган азатлар кайсы-кай тарафка тәртипсез рәвештә кача башлыйлар. Чакырылмаган тугандаш яуны турау, укка алу кичке якка кадәр бара.

Сәлим хан сөрәнчеләре бертуктаусыз кычкырып торалар: «Болгар ханы бары тик энесе Мөхәммәтгалим бәк белән генә орышырга тели. Бәкне ташлап киткән азатка, унбашмы, йөзбашмы, меңбашлы ирек биреләчәк!»

Шулай кычкыра торгач, Янтак ханның азатлары, ук-коралларын ташлап, әсир төшә башлыйлар. Янтак хан исә, иң батыр азатлары белән камауны ерып, качып китә. Тубыкбай баһадир азатлары аларны куа бара. Янтак хан киткәч, ике йөз азаты белән генә калган Мөхәммәтгалим бәк Янтак хан кебек качарга омтыла, әмма өлгерә алмый. Ханның сөрәнчеләре: «Бөек Болгар ханы Сәлим бары тик энесе белән орышырга тели. Кем жиңә — шул тәхеткә утырыр ди!» — дип кычкыруы, ниһаять, Мөхәммәтгалим бәккә дә барып ирешә. Азатларның күбесе соекле бәкләрен ташлап, хан ягына күчә. Бу мәлгә жан ачуы чыккан Мөхәммәтгалим бәк агасы ягына күчә башлаган азатларын укка ала. Әмма шунда ук аның ягына да уклар ява башлый. Мөхәммәтгалим бәк абасы белән орышырга ризалык бирергә мәжбүр була. Көчле ягына авышырга өйрәнгән дала азатлары өер-өер Сәлим хан ягына күченә. Мөхәммәтгалим бәк янында жансакчылары гына кала. Ниһаять, Мөхәммәтгалим бәк:

— Нинди корал белән орышабыз,— дип оран салдыра.

Сәлим хан сөңге сайлый.

Ул арада хан мәргәннәре Мөхәммәтгалим бәкнең жансакчыларын аерып алалар. Ук очар арада, күзгә-күз дияргә була, абасы белән энесе генә кала.

Сәлим хан нигәдер үлемнән курыкмады. Ул белә иде: энесе Мөхәммәтгалим бәк, жиңгән хәлдә дә, барыбер тәхеткә утыра алмас, углань әмир Илһам каршы төшәр, чөнки гаскәр аның кулында. Угланына бу хакта әйтергә теләсә дә әйтми торырга ниятләде, чөнки ахыры шулай буласына иманы камил иде. Аннары батырга батыр чыккан хәлдә сөңге сайлавының да хикмәте бар иде. Сәлим хан яшьтән үк сөңгене тәз атты, шул ук вакытта жилле итеп кылычта алышты. Ахыр чиктә барысы да Алла кулында иде. Әмма ханга бер нәрсә ачык иде: ул исән чакта Мөхәммәтгалим бәк Болгар тәхетенә утырмаячак.

Мөхәммәтгалим бәкнең аты, жансакчыларын бүлеп алгач, ямансулап кешнәде. Бер көтүдә үскән, бер болында утлаган ишләреннән аерылуын сизүе идеме хайванның — бер хода белә. Атының ямансулап кешнәвеннән Мөхәммәтгалим бәкнең ачуы гына кайнады. Ул атына каты итеп сукты да абасына таба кузгалды.

Бер анадан тумасалар да, алар бертуганнар иде. Туган туганга кул күтәрү зур гөнаһтыр, әмма мөселман доньясында да тәхет өчен булган

бәхәсләрдә туган туганга каршы чыгу гадәткә кереп бара иде инде. Хәер, моның яман мисалын әүвәл башта мөселман халифәләре үзләре үк күрсәтте. Мөхәммәтгалим бәкнең агасына каршы чыгуы шул яман гөрнәкләрнең дәвамы гына иде булса кирәк.

Ханның да, бәкнең дә башларында тимер очлым, тересәк-тезләренә каплагычлар куелган, өсләрендә исә кыска җиңле челтәрле тимер күлмәк. Шулай бердәм киенергә вә коралланырга сөйләшкәннәр диярсең.

Батырга батыр килә, кулларында сөңге. Юк, батырга батыр түгел, туганга туган, ханга каршы бәк килә.

Азатларның барысы да тын алырга куркып, туктап кала. Чөнки мондый хәлгә шаһит булганнар бик сирәктер. Икс батыр гына көрәшми ич!

Чаптырып килгән җайдан Мөхәммәтгалим бәк ни сәбәпледер, атын кисәк кире бора һәм берара бер урында таптана.

— Атының канын кыздыра, күр әле моны,— диләр күзәтүче азатлар бәкнең бу хәленә.

Сәлим хан атын куаламый, ул берчама гына юырттырып, энесенә якынлаша. Энесен күптән күргәне юк, егерме еллар булыр. Гаҗәеп, ул энесендә тәүге таныш чалымнар күрмәде, гүя, аңа таба ят бер кеше килә иде. Яшь чагында Мөхәммәтгалим бәк уктан оста атыр, мәргән атын йөртер иде.

Кемдер:

— Сәлим хан җиңә, Сәлим хан җиңә! — дип кычкырды.

Әмма Сәлим хан берәүне дә ишетмәде, энесеннән башка берәүне дә күрмәде. Ара якынаюга, Мөхәммәтгалим бәк акыра-бакыра башлады, әйтерсең, дию пәриенә каршы килә иде. Аның акыруыннан Сәлим хан курыкмады, ләкин сискәнеп куйгандай итте. Үз сөңгесенең энесе күкрәгенә кадалуын күз алдына китерде. Юк, ул аны үтерә алмый. Алар — бер анадан туган балалар, бертуганнар. Сәлим хан бар көченә тезгенен уң якка тартты, атын борды да елгага таба китте. Ул ашыкмады. Кусын, житсен, кадасын, дип уйлады. Абасының борылып кача башлавын күреп, Мөхәммәтгалим бәк батырая төште, атын куалый-куалый Сәлим хан артыннан китте. Елгага җитәрәк кенә Сәлим хан атын энесенә таба борды һәм, сөңгесен күтәрә төшеп, энесенә таба килә башлады. Ике ара күзгә күренеп якынайды. Мөхәммәтгалим бәк ыргытырга дип сөңгесен күтәрде. Шунда янә көтелмәгән бер хәл булды. Сәлим хан атын туктатты һәм сөңгесен җиргә кадады. Батырга батыр чыкканда гына түгел, гомумән, орыш кырында бу хәлне күрмәгән азатлар өзәңгеләренә баса төшеп үрелделәр. Азатлар тезмәсе буйлап: «Сәлим хан сөңгесен ташлады, Сәлим хан орышырга теләми»,— дигән аһ-зар узды.

Мөхәммәтгалим бәк туктамады, сөңгесен ташламады, ярсынган вә нәфрәтләнгән кыяфәттә ханга якынайды. Абасының сөңгесен ташлавы, атын туктатып, үлемен көтүе аның ачуын гына чыгарды. Менә ул сөңгесен күтәрде, чак кына артка каерылды... Нәкъ шулчак зәһәр ук сызгырганы ишетелде һәм кан төсенә буялган каурыйлы ук Мөхәммәтгалим бәкнең аркасына килеп кадалды. Мөхәммәтгалим бәк кинәт аркан ташлагандай артка чайкалды, ул да түгел, сөңгесе-ние белән аттан ишелеп төште. Иясе егылуга ат шып туктады, каерылып хуҗасына карады да рәнҗүле рәвештә кешнәп куйды.

Бу хәл Сәлим ханның төшендә түгел иде, ул барысын да үз күзе белән күрде, энесе Мөхәммәтгалим бәкне дала канунын бозып, җансакчыларының берсе укка алды. Мәгәр кем?

— Кем укка алды бәкне?! — дип сорады Сәлим хан. Ул инде үз хәленә кайткан, карашы белән энесен укка алучыны эзли иде.

Берәү дә дәшмәде.

Атасы янына әмир Илһам чаптырып килде.

— Атам, юкса ул сине сөңгегә алган булыр иде,— диде.

— Синме? — диде Сәлим хан.— Син алдыңмы укка?

— Мин түгел, атам. Мөхәммәтгалим бәкнең үз азатлары.

— Ук тамгалымы?

— Анысын тикшербез, атам.

— Укка алучыны сарайга килтерерсең! — диде Сәлим хан һәм атын куалый-куалый кирмәнгә чапты.

Сараена кайтып кергәндә хан башкача уйлый иде инде. Энесе Мөхәммәтгалим бәкне укка алмасалар, аның урынына орыш кырында ул ятып калган булыр иде. Хан хәтта күкрәгенә кадалган сөңгене күз алдына китерде һәм янә курку килде. Ул тәхет бүлмәсенә узды һәм анда вәзире Камайны күреп, туктап калды:

— Син исән? — диде ул тәмам аптырый калып.

— Исән, хан иям, мин аңа балдакны бирдем.

— Мөхәммәтгалим бәк һәлак булды, вәзир,— диде Сәлим һәм хәлсезләнеп тәхетенә утырды.— Мөхәммәтгалим бәк һәлак булды. Ә Янтак хан качып китте.

— Всеволод кенәз дә киткән икән,— диде вәзир Камай.

— Әйе, ул да китте,— диде Сәлим хан.— Боерам, вәзирем, энем Мөхәммәтгалим бәкнең мәетен ханнар зиратына күмегез, җиренә җиткереп.

— Баш өсте, хан иям.

Вәзир чыгып киткәч тә Сәлим хан тәхетенә чумыбрак утырды. Янә күз алдына аркасына ук кадалган энесе килде. Иясе үлгәч тә атның бермәл чабуын, мәетнең сөйрәлеп баруы, иясенең егылуын сизеп булса кирәк, атның кисәк туктап калуы, ямансулап кешнәп җибәрүе — барысы да күз алдында иде. Кеше түгел, хәйван да иясе үлемен сизә. Ә бит алар туганнар иде. Ундүрт яшькә кадәр бергә уйнап үстеләр, аннары аталары аларга, балигъ булу билгесе итеп, икесенә дә кылыч-хәнҗәр, бил каешы бүләк итте. Энесе Мөхәммәтгалим бәккә ундүрт яшь тулмаган иде әле, әмма үпкәләмәсен дип булса кирәк, аталары хәрби киемнәрне аңа да биргән иде. Соңыннан бу хәлне төрлечә юраучылар табылды. Берәүләр олуг хан тәхетен Мөхәммәтгалим бәккә калдыра икән, дип әйттеләр. Икенчеләре беренчеләрен, тәхет хан кулында түгел, Алла кулында, дип үртәделәр.

Ундүрт яшендә чакта ук Сәлим хан тәхет турында хыяллана иде.

Болгар ханы булып алгач, Сәлим хан энесе Мөхәммәтгалим бәкне сарайда тотарга теләмәде. Ул аңа башта Суар каласын бирде, ахыр Сәкъсинга күчерде. Ике арадагы татулык әнә шулай бозыла торды. Соңра энесе Мөхәммәтгалим бәк Янтак ханның кызына өйләнде һәм Болгардан бөтенләй китеп барды. Болай гына китмәде, каладагы сәүдәгәрләрне һәм тархан кулындагы казнаны талап китте. Баштарак Сәлим хан Янтак хан ыстанына яу чабарга уйлаган иде, Ибраһим каласы бәге Ягкуб бу уеннан ваз кичтерде.

— Ике туган орышса — ил бетәр, ике сеңел талашса — ир китәр,— диде.

Ул вакытта каны кызган булса да, Сәлим хан аксакалны тыңлады, Янтак ханга яу чапмады, ә менә күп еллар узгач дала ханы үзе Болгарга яу килде. Ахыр чиктә ходай тәгалә аларның язмышын әнә ничек хәл итте.

Шулвакыт хан янына баһадир Таймас керде.

— Олуг хан, сезне җиңү белән котлыйм! — диде.

— Җиңү Болгарга ансат бирелмәде, баһадир. Инде әйт, ни өчен әмир Хаҗи ярдәмгә килмәде?

— Әмир Хаҗи баһадиры Җик Мәргән белән урысларның җиде корабын яндыра, шактый коралларын кулга төшерә, хан иям.

— Хакмы бу хәл, Таймас баһадир?

— Хак хәбәрдер, хан иям. Әмир Хаҗи кораблар саклаучы йөзбашның башына җитә. Шактый урысны әсир итеп алып китә.

— Ни сәбәпле кенәз Всеволод аны куа бармый?

— Анысы миңа караңгыдыр, хан иям. Всеволод кенәз хәтта Ибраһим каласына да туктамаган. Кала тарханы аксакал Ягкуб кенәзгә бирнә биреп котылган, диләр.

— Аксакал Ягкубны сарайга дәшегез,— диде хан.— Инде бар, баһадирым, син дә ял ит.

Сәлим хан, сарайга кайткач тынычланырмын, дип уйлаган иде, кайтты, тәхетендә утыра, ә тынычлану килми дә килми, киресенчә, хәтер күгенә энесе Мөхәммәтгалим бәк белән уйнап үскән чаклары төшә.Бүгенге фаҗигадән соң энесе белән ике арадагы хәлләргә ул башкачарак бәя бирергә мәҗбүр. Юк, бу яман хәлдә ул үз-үзен акларга теләми. Ике туган арасындагы бәхәс вә низаг дошманлашуга кадәр җиткәч, ул энесен илдән куып җибәрде. Әйе, ул вакытта Сәлим хан бары тик үз язмышын гына кайгыртты бугай. Мөхәммәтгалим бәкне куармын да ил вә халык белән үзем генә идарә итәрмен, дип уйлаган иде, хакимлек аңа берсеннән берсе катлаулырак хәлләр китереп бастырды. Владимир-Суздәл кенәзенең кат-кат яу килүе, Ибраһим каласына күз атуы, ниһаять, башкалага җитеп, аны атналар буена камап торуы, шушындый хәлдә энесенең дошман ягында булуы — аны илдән куып хәтәр хата ясавын янә бер раслаган иде.

Хәтта шул хәлдә дә Сәлим хан энесе Мөхәммәтгалим бәктән өметен өзмәгән иде. Акылга утырыр, баш иеп абасы каршына килер, дип көтте. Килмәде. Инде ике туган орышырга иткәч тә соңгесен ташлар да баш иеп килер, дип уйлады. Ул гынамы, Сәлим хан энесенә янә бер мөмкинлек бирде, инде соңгысын, чарасыздан: бер-берсенә каршы килгәндә беренче булып сөңгесен җиргә кадады. Әмма сөңгесен җиргә кадап, орыштан ваз кичүен аңлатса да, энесе Мөхәммәтгалим бәк җан алышудан баш тартмады — акыра-бакыра абасы Сәлим ханга таба килүен белде. Менә шунда, нәкъ шул чакта Сәлим ханның энесенә җен ачулары чыкты, йөрәге кабарды, авыз эченнән генә: «Аңламасаң аңламассың икән, ахмак»,— диде дә сөңгесенә үрелмәкче булды. Ләкин нәкъ шул мәлдә көтелмәгән хәл булды: энесенең аркасына ук кадалды... «Бар икән ходай»,— дип уйлап өлгерде Сәлим хан, чөнки анын һич кенә дә бер анадан туган энесенең гомерен аласы килмәгән иде. Бу хәлне халык та, ханбикәсе Зөбәрҗәт тә, туган-тумачалары да, хәтта үзе дә кичерә алмаган булыр иде. Ә бит ул һич тә шикләнмәде, ул аны үтерәчәк иде, чөнки сөңгедә анын кебек оста алышучы юк. Әйе, Мөхәммәтгалим бәкне кемдер укка алды. Сәлим ханның азатлары алдында да, халык алдында да намусы саф иде. Намусы саф, әмма йөрәкне әллә ни тырный, күңел түрендә әллә ни көйрәп тора. Ә бит тынычланырга вакыт иде инде, ул ике туган арасындагы канлы бәхәсне үзе корал күтәрми генә хәл итте. Ләкин барыбер анын исеменнән кан коелды. Һәм шуның белән анын исеменә кара күләгә төште. Бу күләгә аннан гомере буена калмас. Энесе Мөхәммәтгалим бәкнең балаларының балалары бер аңа гына түгел, бөтен Болгар халкына үч сакларлар, очраган бер болгарны дошман күрерләр. Ә үч вә нәфрәт кайчак нә изге теләкне дә яман итә, игелек кылганны аяк астына салып таптый.

Сәлим хан, авыр уйларыннан арынырга теләпме, башын күтәреп кәтибенә карады.

— Барысын да яза барасыңмы, кәтиб? — дип сорады.— Яз-яз, тарих ул халык хәтере, тарих ул үрнәк һәм гыйбрәттер... Карале, Хафизҗан, нигә син һаман өйләнмисең?

— Йөгәнем юк, хан иям.

— Өйләнү өчен йөгән кирәкме, Хафизҗан? Хатын-кыз ат түгел кебек миңа.

— Нәфрәте ашкан чакта хатын-кыз аттан да яман, хан иям.

Сәлим хан тыенкы гына кеткелдәп көлеп алды.

— Ибраһим атамыз, Хафизҗан, ир терәге — хатын, ир канаты — углан, дияр иде, мәрхүм. Өйлән. Балаң булыр. Вәзир Камай да өйләнде

әнә. Хатыны кибән хәтле булса да, тычкан кибәннән куркамы, гөрләп яшиләр.

— Изге теләгегез өчен, рәхмәт, шөһрәтлем. Сез дә әйткәч, фатихагыз да бирсәгез, уйлап карармын.

— Уйлап кара, Хафизжан, уйлап кара. Ләкин бик озак уйлама, хатын-кызлар озак уйлаганны яратмыйлар.

Кәтиб Хафиз каләмен кара савытына куйды да аягүрә басып ханга баш иде. Сәлим хан ирен чите белән генә елмаеп куйды. Ул кәтибенә рәхмәтле иде, авырсу уйларын аз гына булса да читкә тайпылдырып торды.

## 9

Җик Мәргән хатыны Зәйтүнә белән оста Дәүран өенә урнашты. Иртән аны әмир чакырып алды һәм Дәүранның Назлыгөл артыннан Ибраһим каласына китүе турында әйтте. Җайдак атлары һәм коралы булса да останы атасы үзе белән алып китмәгәе, дип борчылып утыра әмир Хажи. Җик Мәргән баһадир Мамак, Артык һәм Зәйтүнәнең кичә үк Назлыгөлне хан кулыннан коткарырга китүләре хакында белсә дә әмир Хажига әйтергә кыймады. Әмирнең эшне бозып куюы бар иде. Иртәнге яктаниндидер юллар белән алып кайтылган Назлыгөлне Иске Казан кирмәненә илтеп куярга кушты. Әйтерсең, ханга хәбәр итеп куюы бар, ата белән углан арасына кереп булмый, гәрчә ата кеше угланы әмир Хажига шактый зыян-зәүрәт кылып китсә дә.

Оста Дәүран өендә Җик Мәргән сәкегә утырды һәм уйга калды. Ике-өч көн эчендә кинәт кенә булган хәлләргә төшенерлек түгел иде. Әүвәл башта Сәлим хан Яңа Казанга килә, угланы әмир Хажидан каланы тартып алмакчы була, әмма бернәрсә дә кыла алмый. Шул мәхшәрдә әмир Хажи баһадиры Бачман белән телгә килә, Бачман әмирнең бикәсен алып Сәкъсинга чыгып китә. Әмир Җик Мәргәнне баһадиры итә һәм бүген иртән чакыра да, атасы алып киткәнне белсә дә сеңлесе Назлыгөлнең кайда булуын сорый. Шул ук вакытта Акбикәсе турында ләм-мим. Баш җиткесез хәл иде.

Ишек шакыдылар. Җик Мәргән иренчәк кенә күтәрелеп, барып ишекне ачты. Шаулап-гөрләп Артык белән Мамак килеп керделәр.

— Назлыгөл Иске Казан кирмәнендә, баһадир.

— Ә Зәйтүнә, минем Зәйтүнә кайда?

— Ул Назлыгөл белән калды, сине күрәсе килә,— диде Мамак.

— Сагынган,— дип өстәде үртәгән сыман Артык.

— Йә, күп телегезгә салышмагыз, узыгыз, утырыгыз, сөйләгез.

Артык белән Мамак берсен-берсе бүлә-бүлә Назлыгөлне хан азатлары кулыннан ничек урлаулары турында сөйләгәч, Җик Мәргән:

— Артык, сиңа тагын Ибраһим каласына барырга туры килер, ахрысы,— диде.— Әмир Хажига Ягкуб бәктән чаптар килгән, Сәлим хан аксакал аша угланы Хажидан ярдәм сораган икән. Всеволод Олы Оя кенәзенең Болгарга яу килүе хак икән. Шунда Ягкуб бәк, әмир Хажига әйт, оста Дәүраны минем кулда калды, алыр кешесе килсә, биреп җибәрермен, дигән.

— Бүген үк җыеныйммы, баһадир?

— Иртәнге якта юлга чыгуың хәерлерәк булыр. Ул тарафта әллә кемнәрнең очрап куюы бар, азатлары белән йөзбаш Шиһапны алырсың.

— Баш өсте, баһадир.

— Йә, кыланма, ә хәзер, әйдәгез ашарга әмәллибез. Хатын-кызлар юк...

— Баһадир, аларны монда кайтарырга ярамыймы соң?.. Назлыгөлнең күзендә гел яшь иде, ә Зәйтүнә сине дәште.

— Ул ягын мин үзем җайлармын, Мамак. Ләкин мин әлегә моннан беркая да китә алмыйм. Әмир боерыгы.

— Хан кызын коткардык, инде хәзер киявен табасы гына калды,— диде Артык, әллә шаярып, әллә уенын-чынын бергә кушып.

— Синең йомышың гаять җитди, Артык. Останың Всеволод кенәз кулына эләгеп куюы бар. Дәүран кебек остага кенәзнең йөз кеше бирүе бар.

— Бер дә булмас димә. Ләкин Всеволод кенәз китте бит инде. Сәлим хан алтын биреп котылган, диләр. Кенәз Ибраһим каласына сугылып та тормаган. Аксакал хәйләкәр, ул да, Сәлим хан кебек, кенәзгә алтын биреп котылган, диләр,— диде Мамак.

— Карга карга күзен чукыймы? Ханнар, кенәзләр килешә белә алар. Менә безгә һаман рәт-җай юк. Син әнә өйләндең, баһадир, ә мин һаман эт көтүе куып йөрим.

— Өйлән, кем сиңа кушмый, йортка керә аласың. Беткәнме әнә синдәй азатларга тол калган хатыннар.

— Оялам, оят. Бачман баһадир кебек берәр байбичәне ябыштырып чыгарсаң икән ул.

— Нәрсә сөйләгәнеңне беләсеңме син, Мамак! Колагыңа киртләп куйсаң иде: бикә угланын күрергә китте — Өргәнечкә. Тәтеш шәех Сәлим ханга оныгы Галине Өргәнечтә күрдем, дип әйткән. Хәтта Коръән тоткан, ди. Хан оныгы исән икән, шаһ мәдрәсәсендә мөгаллим, ди.

— Әйттем дә кайттым, баһадир. Әмир Хаҗиның бикәсе угланын эзләп киткән икән, миңа ни? Кеше сөйләгәнне генә әйтүем. Кайбер тел бистәләре базар мәйданында Акбикәне Бачман баһадирга ябышып киткән, дип тәкърарлыйлар.

— Азатмы, меңбашмы син, Мамак, ә?! Әллә чүпрәкме?! Әллә кичәле-бүгенле башыңа яулык бәйләдеңме?!

— Ябышып китү гаепме, баһадир,— дип ишен якларга керешә Артык.— Әйтик, миңа әмир Хаҗиның Чулпан исемле җариясе ошый. Өйләнер идем үзенә, әмма бикәсе киткәч, үзе караштыргалый, дип ишеттерделәр, баһадир.

— Куеп торыйк әле кысыр кайгыларны, егетләр. Бер киңәшем бар сезгә. Сез ничек хәл итсәгез — шулай булыр. Назлыгөлнең Иске Казан кирмәнендә икәнен әйтимме әмир Хаҗига, юкмы?

— Менә анысын инде, баһадир, үзең хәл ит. Шулай бит, Артык?— диде Мамак табынга кискән итләр куя-куя.

— Нишләргә дә белмим. Әмирнең гелән кәефе юк. Аңлашыладыр, бичәсе китте, атасы каласын җимерә язды. Җитмәсә, Всеволод кенәз киткәч, ярдәмгә килмәгән өчен мин Яңа Казанга яу киләм, Булат оныгымны утыртам, дип әйтеп әйткән икән, диләр.

— Тагын болгар белән болгар сугышырмы, баһадир?

— Без әмир азатлары, Артык. Ә әмир Хаҗиның үз биләмәләре, үз калалары, авыллары бар.

— Йа ходა, бу ни була инде тагын!

— Кеше сүзе кеше үтерә, ди. Сәлим хан урыс кенәзе явыннан соң айнысын әле. Бер тапкыр авызы пеште бит инде, миңа калса, бу тарафларга яңадан килмәс ул. Ә синең йөгең билгеле: таш яуса да, оста Дәүранны Яңа Казанга алып кайту.

— Мин беләм әмирнең ни өчен останы дөнья бетереп эзләвен, баһадир,— диде Мамак.

— Мин дә,— диде Артык.— Хәер, баһадир да беләдер. Шайтан каласы астындагы төньюлларын гына түгел, Яңа Казан астындагы төньюлларын да оста Дәүран сала.

— Ул ягы миңа караңгыдыр, Артык, әмма миңа бернәрсә билгеле: без оста Дәүранны табарга тиешбез. Аннары хан кызы Яңа Казанда калган хәлдә, Назлыгөл бала тапса, калага ул ир бала әмир булу ихтималы бар. Бу очракта, миңа калса, Сәлим хан Яңа Казанга яу килмәстер.

— Назлыгөл кемне табар бит әле. Анысы ходა кулында.

— Малай табачак,— диде Мамак.— Малай булыр. Әмир Хажиның ике угланы исән чакта — ни уйлыйсың син, баһадир. Була торган хәлме?

— Кем әйтә әмир Хажиның ике угланы бар дип?

— Мин, баһадир, мин. Башкаладан килгән чаптар әйтте, әмир Хажиның өлкән угланы кайткан икән, тик кеше күзенә күренеп кенә йөрми икән ди. Аннары Җаффарны кая куясың, Җаффарны Ашлы каласында калыр дип беләсеңме?

— Әйе, азатларым, хикмәтле чорда яшибез икән шул. Әмма ни генә булмасын, без әмир Хажига тугры калырбыз,— диде Җик Мәргән.— Мин сезгә ышанам.

— Без синең белән, баһадир, синең белән!— диештеләр Мамак белән Артык.

## 10

Дәүран инде өметен өзгән иде, икенче көнне иртән су бирделәр. Бер чүмеч суны эчеп бетерде дә башы әйләнүдән тәгәрәп китте.

— Су эчкәч бу чукынганга әллә нәстә булды, мәтәлеп ята,— диде каравылчы азатларның берсе.

— Мин аны алып чыгам, Сәлим хан китү белән Ягкуб бәк чыгарырга кушкан иде,— диде икенчесе һәм аска төшеп, тәгәрәп яткан Дәүранның биленнән алды да бау бәйләп өстәге ишенә очын ыргытты.— Тарт!

Каравылчылар аһ-ваһ килә-килә яңа аңына килә башлаган Дәүранны түр як сәкегә салып, баш астына меңдәр кыстырдылар.

— Уяна, хәле киткән булгандыр. Йә-йә, оста, тор. Башта ашап ал, аннары сөйләшербез.

Дәүран авырлык белән генә торып утырды, каравылчыларның әле берсенә, әле икенчесенә карап алды. Тәлинкә төбенә генә салып тары боткасы китерделәр. Майлы ботка исе танавына килеп бәрелүгә, янә башы әйләнеп китте.

— Кабаланма, чәйнәп йот,— диде каравылчы.— Чәйме бирик? Төнәтмәме?

Дәүран дәшмәде, ашавын белде. Күңеле бераз хушлангач кына тураебрак утырды. Амин тотты. Рәхмәт әйтте.

— Рәхмәттән күлмәк тегеп булмый, малакай, тегe ни...

— Минем Ягкуб бәкне күрәсем килә,— диде аны бүлдереп Дәүран.

— Күрерсең, күрерсең, оста. Ул әлегә өйдә юк, менә исән-имин әйләнеп кайтсын да сине кабул итәр. Ә әлегә безнең белән сөйләш. Нә телисең? Әйе, нә тели әмир Хажиның остасы бездән?

— Син минс каян беләсең, унбаш?

— Үзеңнең кем икәнеңне дә белми торасыңмыни әле! Син хан кияве ләбаса! Сине кенәз тиуннары да эзләде. Тапсалар, алып та киткән булырлар иде. Урыс кенәзе калалар салырга ярата икән бит. Ягкуб карттан сине сорадылар, әмма безнең карт төлкебез синдәй кешеләрне урыска бирә буламы, кенәз белән сөйләште дә калага тиуннарны керттермәде. Ни вәгъдә итеп килешкәндер, кенәз белән бер хода үзе белә.

— Хан кызы Назлыгөлне патшабикә кулыннан урлаулары хакмы, каравылбашлар?

— Хак булмый, ха-ха-ха! Кызын икенче тапкыр урлаткач, Сәлим хан сакалын йолка-йолка ант итте: урлаучыларны тотсам, тереләй тиреләрен туныйтам, диде. Кызын табып алып кайткан меңбашларга ат башы хәтле алтын вәгъдә иткән, дип сөйләделәр. Ә хан кызы, гүя, җир астына инде. Кичтән калага килеп керделәр, ә иртән хан кызыннан җилләр искән иде инде. Әнә нинди егетләр бар дөньяда, оста Дәүран. Берәүләр хан кызын Шайтан урлаган, дип баралар. Чөнки бикле бүлмәдән хан кызын бары тик Шайтан гына алып чыга алса алыр иде. Түр якка берәү дә кереп

йөрмәде кебек, иртән уянсалар, асрау йоклап ята, ә хан кызы юк. Шаккатмаслык та түгел шул.

— Нинди Шайтан булсын монда, тузга язмаганны,— диде Дәүран.

— Синең күргәнең бар, диделәр аны безгә, белмәмешкә салышасыңмы, әйтергә теләмәвеңме? Шайтан манарасына кергән бер кешене нигә мәет хәлендә елгадан табып алалар? Кем эше бу, Шайтан этлеге булмаса?!

— Шайтан каласында бернинди дә Шайтан юк, каравылбаш.

— Туктале, тукта, син үзең түгелме ул Шайтан дигәннәре, ә? Манараны төзәтүче, кирмән диварын ныгытучы — син. Шуннан менә нәрсә, оста Дәүран: йә үзең Шайтан, йә син аның белән бер сүздә торасың. Һоп! Менә эләктең дә. Димәк, хан кызын да син урлаткансың. Шайтанга әйткәнсең дә...

— Сөйләмә булмаганны, каравылбаш!

— Оста Дәүран, сине аның белән күргән кешеләр булган. Ни өчен Ягкуб бәк сине базга ябарга кушты дип беләсең? Шайтанга хәбәр итмәсен дип. Рәхмәт әйт каравылбашка, баздан чыгардык, ашаттык-эчердек.

— Рәхмәт сезгә азатлар. Кылган игелегегез өчен мин дә сезне буш итмәм,— Дәүран түш кесәсеннән бер янчык акча чыгарды, уч төбендә сикерткәләп алды.— Мин дә төшеп калган егетләрдән түгел, азатлар.

Азатларның күзләре уч төбендә сикергән янчыкта иде, Дәүран әле берсенә, әле икенчесенә карады.

— Ягкуб бәк изге кеше, сезгә каргышы төшмәс, иманым камил, ат-коралларым бирсәгез, янчык сезнеке, азатлар.

— Ташкари агай, килешик,— диде яшьрәге түземлеген җуеп.

— Тик тор! Ягкуб бәккә нә әйтербез?

— Качты, диярбез. Кичерер.

— Ә бу безне сатса, акчага алданып, үзләре җибәрделәр дисә?.. Таякның калын башы сиңа түгел, миңа төшәчәк.

— «Әле дә яши икән бу дөньяда куян халкы»,— дип көлемсерәде Дәүран.

— Ни сөйлисең син, хан кияве. Безме куян?!— дип түшен киеребрәк басты каравылбаш.

— Сез түгел, мин куян. Хан миңа тия буламы, мин аның кияве ич,— диде Дәүран һәм янчыкны каравылбашка ташлады.— Мә, ал, каравылбаш, иш янына куш ярап торыр. Ягкуб бәкне нә мактасаң да, уч тутырып акча бирмидер әле, кул очына ярап торыр. Мине Ягкуб бәк барыбер коткарыр иде.

— Әллә бик хәйләкәр син, оста, әллә беркатлы садә кеше, аңламас булдым. Хәер, нә тора кеше башы хан киявенә.

— Сезнең хакта авызымнан яман сүз чыкса, юлга чыгуыма җир упсын, каравылбаш. Ышанмасагыз Коръән тотам.

— Бар әле, Гаяз, китер әле Коръәнне,— диде каравылбаш.

Тегесе эһ дигәнче күн тышлы изге китапны китереп тә житкерде. Дәүран Коръәнне кулына алды да бертын күкрәгенә кысып торды, аннары азатлар ишетелерлек итеп:

— Әгузү билләһи минәш-шәйтанирраҗим. Бисмиллиһир-рахманир-рахим. Инде доганы ана телемездә тыңлап карагыз, азатлар. Аллаһы — тәрәк булгучы, галәмнең һәрбер эшенә тәдбир кылгучыдыр. Тәүге Аллаһы тәгаләдән башка һичбер Тәңре юктыр...

— Бәрәкалла-машалла, оста. Мулламы син, мөдәррисме? Менә хикмәти димәсәң хикмәти, Гаяз, ә!— диде каравылбаш гаҗәпләнүен яшермичә.— Бар, Гаяз, иярлә останың атларын, китер кием-коралларын. Бездән фатиха. Тик кара аны, ай күрде, кояш алды ит. Әй!— дип иптәшенә эндәште каравылбаш.— Кымызчыны дәш. Буш кул белән килмәсен!

Дәүран китергән кымызны эчеп, касәне куйды да каравылбашка:

— Аллаһы тәгалә сәне, каравылбаш, яманнан сакласын, ил игелеген иләңдә күр. Изгелек җирдә ятмый, иншалла, мин дә сине онытмам.

— Кыласын кылгач, чарасын табармын, оста. Үз жаен кара, язмышың бер дә кеше кызыгырлык түгел сыман миңа. Тор, җыен, ак юл сиңа, оста.

## 11

Аның исәбе буенча, әмир Хаҗи Шайтан каласында булырга тиеш иде. Ул гынамы, хан кызы Назлыгөлне урлаучылар Җик Мәргән кешеләре булган хәлдә янә аларның Шайтан каласында булулары ихтимал. Чөнки кеше-кара күзеннән хан кызын яшереп тоту өчен Шайтан каласыннан да кулай урын табуы читен иде. Һәрхәлдә, Назлыгөлне эзләүне ул Шайтан каласыннан башларга булды, ирекккә чыгу белән шул тарафка юнәлүе дә шуннан иде. Әйе, ул аны — Назлыгөлен табар. Иң мөһиме — ул иректә.

Дәүран иш аты белән йөзмә күпергә җитте, күпер тотучыларга акча түләп, аръякка чыкты. Көнозын юлда булды, бары тик кичкә якта гына атларын утлатып алырга булды. Кече инеш буенда яшел тугайлык күреп, шунда тукталырга теләгән иде, олы юл башында хан азатлары күренде. Алар аны күреп калганнар икән, чаптырып инеш янына килделәр. Дәүран атына атланырга иткән иде, һични кыла алмавын, азатларының күп булуын күрде дә туктап калды.

— Юлчы кай тарафка юнәлә?

— Шайтан каласына.

— Кая-кая?! — дип сорады якынрак килгән йөзбаш. Аның өстендә кызыл төстәге сырма, очлымында дүрт каурый, кулында камчы. Садагы да, җәясе дә юк, нәкышлап бизәлгән кылыч кынысы сульяк янында. Кара кашлы, тут йөзле, калын иренле, юан борынлы. Тавышы көр, тамак төбе белән сөйләшә.

— Җайдак атын алырга! — дип боерды ул унбашларына. — Күрмисезмени, тутый кош үзе кулыбызга килеп керде. Безнең алда — хан кияве.

— Хан кияве! — дип гаҗәпләнделәр азатлар һәм Дәүранны күрергә теләп, өзәңгеләренә баса төшеп, үрелеп карадылар.

Ике атының тезгенен тоткан, биленә кылыч аскан, ыспай киенгән, йомры сакаллы кешене хан кияве итеп күрү сәеррәк иде, шулай да меңбашлары хан кияве дигәч, һәммәсе дә:

— Алай икән, — диештеләр. — Димәк, без атна буена шушы кешене эзләдек, йөзбаш?

— Ходай безгә аны үзе чыгарып бирде, дип уйлагыз, азатлар. Ошбу кешене сарайга исән-имин алып кайтсак, хан, алтын бирмәсә дә, берәр көмештән мәхрүм итмәс, дип уйлыйм. Йә, атлан атыңа, хан кияве. Без сине Болгарга алып кайтабыз.

— Әүвәл мине оста Бәкер янына алып барыгыз.

— Ә нигә, Шайтан каласы янәшәдә. Кашан бер чакрым, рәхим ит. Азатлар, Шайтан каласына! Чаптар, бар каравылбашка житкер, күперне төшереп, капкаларны ачып торсын — хан кияве килә диген.

Ул арада Шайтан каласы күренде, манара. Дәүран манарага эләксә, аны һичкем таба алмаячак. Ләкин ничек манарага эләгергә. Бәлкем оста Бәкер ярдәм итәр. Бергәләп манарага керерләр, ә чыгу юлын ул белә. Калага Дәүран өмет белән килде. Каравылбаш йөзбашның боерыгын үтәгән, күперне төшереп, капкаларны ачып куйган иде. Кирмәнгә кергәч:

— Мин оста Бәкер янына! — дип китеп барырга иткән иде, йөзбаш аңа аркылы төште.

— Сабыр ит, хан кияве. Оста Бәкерне минем дә күрәсем бар.

Йөзбаш алдан кузгалды, тар тыкрыклар, алачыклар яныннан үтә-үтә, ниһаять, оста Бәкер торган ике катлы өйгә килеп җиттеләр. Дәүранның килүен белгәндәй, хуҗа аларны болдырга чыгып каршы алды һәм оста аттан төшүгә, аңа каршы китте, колачын җәеп исәнләште.

— Нинди җилләр белән, кордаш! Өнемме-төшемме!— диде ул һәм Дәүранның колагына:— әмир Хаҗи Кашанда,— дип пышылдарга өлгерде.

* * *

Дәүран киткән көннең яртысында Ибраһим каласы кирмәне капкасы каршына азатлары белән меңбаш Артык килеп сугылды. Артык, Ягкуб бәктән алган фәрманны селкә-селкә, капкабашка оста Дәүранны алырга килүе хакында кычкырды. Капканы ачтылар, эчкә керттеләр. Артык фәрманны каравылбашка күрсәтте дә сарайга таба чапты, сарай каравылбаш Ташкари болдырда аны көтеп тора иде инде. Ул фәрманны алды, әйләндереп-тулгандырып карады, укыган итте.

— Меңбаш Артык, сиңа хөрмәтем зурдыр, иллә бу хакта соңга калдың. Качты оста Дәүран.

— Ничек качты?!

— Менә анысын аның үзен тапкач сорашырсың инде, меңбаш Артык. Зинданның тәрәзәсен алган да качкан, ышанмасаң кереп кара.

— Син курыкма, каравылбаш Ташкари, фәрман дөрес, бәк мөһере дә сиңа таныштыр.

— Бәкнең имзасын да, мөһерен дә күзем йомып та таныйм, меңбаш. Иллә игелек кылыр чарам юктыр. Хан кияве чынлап та качты.

— Качырдыгызмы, качтымы?

— Менә анысын тикшерү синең эш түгел инде, меңбаш, анысын Ягкуб бәк тикшерер. Ә фәрманы дөрес, ышанам, иманым камил.

— Мин останы җир астыннан булса да эзләп табармын, каравылбаш Ташкари. Ә инде хан киявен миннән яшереп калдырам дип өмет итсәң — ялгышасың. Артыктан бераүнең дә качып котыла алганы юк әле, мин сине теге дөньяда булса да эзләп табармын...

* * *

Табын янында алар иркенләп сөйләштеләр. Меңбаш әле сылтау табып һавага чыгып керде, әле чуен коючы хатыны белән сөйләшкәләп алды. Кыскасы, аны, гүя, бу ике кеше арасындагы әңгәмә бөтенләй кызыксындырмый кебек кыланды. Әмма колагына ирешкәне дә аның өчен бик җиткән иде. Ике останың әңгәмәсеннән ул шуны аңлады: әмир Хаҗи биредә булып киткән, яшь хатыны белән килгән булган икән. Хатыны яшь, тыйнак, гүзәл икән.

Ашап-эчкәч, алар китәргә җыендылар, оста Бәкер аларны капкага кадәр озата барды. Йөзбаш алардан бер адым да калмады. Бу хәлдә манарага кереп качу турында уйларга да ярамый иде. Дәүран шул хакта оста Бәкергә әйтергә дип авызын гына ачкан иде, артларыннан килүче йөзбаш:

— Оста Дәүран, манарага керү булмас, мин сине бүген үк хан каршына алып кайтырга тиеш,— диде, аннары оста Бәкергә баш иеп:— Ә син, дускай, кичер безне, кичерә күр. Кунак итүең өчен рәхмәт.

Ике оста күзгә-күз карашып алдылар. Ләкин икесе тиң авыз ачып сүз катмады. Дәүран дустының кулын кысты.

— Язганы булыр, Бәкер,— диде һәм сикереп атына атланды.

Кирмәннән чыккач, житез генә атларын юырттырып киттеләр, йөзбаш Дәүран белән янәшә барды. Ярты юлны үткәч, кояш баеды, караңгы төшә башлады. Йөзбаш азатларына туктарга боерды, Дәүранга, шунда кунабыз, диде.

— Син мине ханга кайтарып тапшырырга җыенган идең түгелме?— дип сорады Дәүран.

— Хан йоклыйдыр инде, оста. Ашыкмыйк, ашыгып куян куалар. Атлар да ял итәр, су буенда кунуга ни житә. Хәзер менә казан асарбыз, кымызлап утырырбыз.

Ияргә башын куеп уйланып ята-ята йокыга китә язган, уянып китсә, йөзбаш аңа түтәрәме белән ит бирә.

— Башта ашап ал, оста, аннары йокларсың. Тоз-суган табында.

Табын янында Дәуран йөзбаш ягына карап-карап алды. Ул аның хәтта атын да белми иде. Тик хикмәт андамы. Ул аның әсире, аны бу йөзбаш таш яуса да хан каршына кайтарып тезләндерер һәм үзенә тигән бүләген алыр да Дәуран турында онытыр.

— Әйт әле, йөзбаш, хезмәтең өчен хан күпме түли?

— Түләгәне житкән, оста. Бал-майда йөзмәсәм дә, аллага шөкер, житәрлек.

— Йөзбаш, мин нигә кирәк дип беләсең ханга?

— Анысын үзеннән сорарсың инде, оста. Таймас баһадир миңа сине табарга кушты, аллаһы тәгалә рәхмәте белән мин сине таптым, калганын карга кайгыртсын.

— Хатының, балаларың да бармы, йөзбаш?— дип сорады аңа күтәрелеп карамый гына Дәуран.

— Хатыным да, балаларым да бар, оста. Бүрегә булгач, чөе була да була инде аның. Өлкән улым хан мәдрәсәсендә укый. Боерган итсә, мулла булганчы укытам үзен.— Йөзбаш тирә-ягына каранып алды.— Беләсең килсә, оста, Болгарга Казан каласы нигезенә күмелгән Гали олан кайткан, ди. Исән икән, хикмәт. Изге зат булган икән, диләр. Имеш, аллаһы тәгалә аны үз янына алып торган да менә хәзер илгә иңдергән, белекле иткән. Әллә ниткән шигырьләр яза, диләр. Ил мәчетенә кереп намаз укыган, диләр. Ә бит ул оланны Сәлим хан Казан каласы нигезенә күмдерергә боерган, дип әйтеп әйтәләр.

— Кала нигезенә эт күмгәннәр, мин аны үзем казытып карадым, йөзбаш. Ә менә Гали оланның бәлигъ булып илгә кайтуына ышанам.

— Мин дә ышанам, оста. Имеш, ул әлегә кадәр Хәрәземдә яшәгән диме. Болгар сәүдәгәре коткарган, диләр. Ә бит Гали оланны кала нигезенә күмгәнне күргән затлар булган. Алар ул хәлне үз күзләре белән күргәннәр. Һәм менә могҗиза: хан оныгы исән. Тамаша. Бер дә бүтән түгел, фәрештәләр эше бу. Алар шулай изге жанны коткаралар, ди.

— Димәк, Гали олан гөнаһсыз бала булган, йөзбаш. Ә без синең белән языклы халык,— диде Дәуран.

— Син языклыдыр, оста, әмма мин үземне языклы кешегә санамыйм. Ил вә ханга тугры хезмәт иттем, күзем төшкән кызга өйләндем, юлга чыкмаганда намазым калдырмадым, әйе, уразасын да тоттым, хатыныма да хыянәт итмәдем. Әнә кайберәүләр икешәр, өчәр хатынга өйләнәләр. Мөхәммәт пәйгамбәр дүрт хатынга кадәр өйләнергә ярый, дигән дип әйтәләр. Ихтимал, әйткәндер дә. Иллә чарасыздан әйткәндер. Чөнки гарәп халкы гомер буена сугышып яшәгән. Орышта кем башта үлә? Ир-ат. Илдә хатын-кыз өелеп кала. Сугыш өчен ир бала кирәк, ә алар орыш кырында ятып калдылар. Шуннан Мөхәммәт пәйгамбәр әйткәндер, өйләнегез өч-дүрт хатынга, миңа азатлар кирәк, сугышчылар. Һәм тегеләр өйләнгәннәр. Әмма пәйгамбәр бер шарт куйган: ул хатыннарны ашатып-эчертеп, киендереп тота алсаң гына өйлән. Әнә ничек булган гарәп дөньясында, оста. Гарәпләргә карап безнең болгар иратлары да күпләп хатын алмакчы. Тик кайберәүләрнең чабулары кыска булып чыкты. Менә минем дә чабу тезгә житәр-житмәс, кая ул хатын оятын каплау, үз хикмәтеңне капларга да житәр-житмәс. Әмир Хажины әнә тагын өйләнгән, диләр. Нигә, өйләнер дә әмир кадәр әмир. Кашанда бер сарае, Казанда икенчесе. Ә шулай да Акбикәсе качкан, диләр. Бачман баһадирга тагылып качкан, дип әйтеп әйтәләр.

— Әмир Хажиның хатыны Акбикә Бачман баһадирга тагылып китмәде, йөзбаш. Ул Хәрәзем каласына улын эзләп китте.

— Һэ, углына ничә яшь тә, үзенә, дигәндәй. Тузга язмаганны. Бачман баһадир белән бер-берсен яшьтән үк яратышып килгәннәр, диләр, оста. Бигрәк беркатлы булдың әле син, бахыр. Ничек сине хан кызы ярата алды... Хәер, хатын-кызны белмәссең, пәри заты бит ул, изге кешене шундук күрә. Аннары ыспайны. Синдә әнә гәүдә-сын, аллага шөкер, йөз-кыяфәт тә Гайсә пәйгамбәрнекеннән ким түгел. Күрдем мин ул Гайсә пәйгамбәрнең сурәтен. Мерем каласын алгач, чиркәүгә кергәч күрдем. Идәннән түшәмгә җитәрлек итеп ясаганнар. Күз камашырлык буяулар. Менә торыр да кузгалып китәр, яисә сиңа бер-бер сүз әйтер кебек, хикмәти. Урыслар шуңа карап чукыналар, тәгәрәп-тәгәрәп чукыналар. Имеш, шул сурәт аша аллага мөрәҗәгать итәләр. Сурәт алла буламы?!

— Йокларга ятыйк, йөзбаш.

— Әйе, ятыйк, оста. Тик син мине кичерә күр, мин сине үземә бәйләрмен. Җан тынычлыгы өчен. Син качсаң, оста, минем өлкән углым хан мәдрәсәсен күрмәячәк, үземне дә сарай меңбашы Таймас кул астында әллә калдыралар, әллә юк. Гафу ит. Йөзбаш аның кулын үз кулына нык итеп бәйләде дә кырын төште һәм шундук гырылдап йокыга да китте.

* * *

Болгарга җитәрәк аларга каршы чыктылар. Иң алдан Таймас баһадир килә иде. Дәүран аны ерактан ук таныды.

— Ә-ә,— диде ул җитәр-җитмәс үк.— Сине күрер көн дә булыр икән, хан кияве. Исәнлекме, саулыкмы, оста Дәүран!

— Аллага шөкер, баһадир. Тик белмим, нигә кирәк булды икән әмир остасы сарай баһадирына.

— Хан кияве булсын да кирәкмәсен, имеш. Син хәзер олуг дәрәҗәдә, оста. Ханның ярты азаты диярлек ил бетереп сине эзли.

— Кызын ятим итмәкчедер, баһадир.

— Кызны түгел, сине, сине, оста. Хан олыгаеп килә, атта йөри алмас булды. Ә кияве әллә кайларда кала сала. Йә, җиллерәк юыртыйк әле, оста. Сине анда хан көтә,— диде Таймас баһадир һәм Дәүран атына камчысы белән сыдырып алды.

Кала капкалары ачык иде, Таймас баһадир оста Дәүранның атын вә үзенең туры айгырын куалый-куалый кушаяклап чаптырып диярлек кирмәнгә килеп керде.

— Әйт әле, оста, кем сине зинданнан качырды?

— Үзем, баһадир, үзем. Мин оста бит. Һәр зинданның ничек салынуын беләм, керер-чыгар тишекләрен.

— Син барыбер беркая да китә алмаган булыр идең, оста. Чөнки һәр йөзмә күпердә, һәр олы юлда сине минем азатларым көтәр иде.

— Баһадир, мин хан колы идем, син кем соң?

— Мин кеше кешесе, оста. Әйе, син кол, ә мин кеше кешесе.

— Аермасы нидә соң? Кеше кешесе дә кол хәлендә үк ич.

— Колчура ханга бушлай, тамак исәбенә эшли яисә хезмәт итә, ә мин алтын исәбенә эшлим. Авылым-кырым бар, өч йөздән артык хуҗалыгым. Ул хуҗалыкта адәм балалары эшли. Икмәк игәләр, кием тегәләр, аяк киемнәре җитештерәләр. Һәр унынчы итек минеке, һәр унынчы көлтә баһадирныкы. Үз чиратымда мин дә ханга уннан бер өлеш табышымны бирәм. Урыс кенәзе Всеволодка биреп җибәргән өч мең алтынның йөзгә якыны минеке иде оста.

Сарайга җитүгә, Таймас баһадир оста Дәүранны хан янына алып керде. Ишекләрне узганда Дәүран баһадир Таймастан сорап куйды.

— Назлыгөл мондамы, хан кулындамы?

— Анысын сиңа хан иям әйтер, оста, атаң!— дип көлемсерәде Таймас баһадир.

Тәхет ягында Сәлим хан үзе генә утыра иде, ишектә баһадиры Таймас белән Дәүранны күргәч, тураебрак утырды.

— Сөбханалла-машалла, кемне күрәм, кияү балакай!— диде хан әллә кинаяләп, әллә чын-чынлап.— Әйдә-әйдә, үт, утыр. Тансыклатып кына киләсең тагын үзең, кияүкәй. Назлыгөлне урлаганнан соң, гүя, үзеңне ай күрде, кояш алды. Утыр, утыр, ятсынып торма, ят кешемени син хәзер, үз кеше. Шулаймы, баһадир?— дип сорады кинәт кенә Таймас баһадирга карап Сәлим хан.

— Шулай, шулай, олуг ханым.

— Инде бар, китеп тор, баһадир. Минем кияү балакай белән үзем генә каласым килә.

Дәүран тирс җәйгән түмәргә кыяр-кыймас кына утырды. Хан тамак кырды, тәхетеннән торды, бермәл йөреп килде.

— Оста Дәүран, без синең атаң Алпар белән тату яшәгән идек. Изге кеше иде, мәрхүм, урынысы оҗмахтадыр. Үзең дә, шаһит атаң да беркайчан миңа зарланмады сыман.

— Зарланды, олуг хан, көче бар чакта зарланмаса да, урынга калгач зарланды. Сез аңа үлем түшәгендә ятканда да ирек бирмәдегез. Ә бирә ала идегез ич!

— Йа хода, кияү балакай, мин аны бары тик аның файдасына кылдым. Китапта кол булып вафат булган кеше җәннәттә булыр, дигән. Ошбу дөньяда адәм баласы кунакка гына килә, ә анда аңа яшисе дә яшисе, ахырзаман житкәнче.

— Алай булгач, олуг хан, нигә һәр кол булган кеше дөньялыкта ирек даулый, нигә хан вә бәкләрнең бер дә кол буласылары килми? Ә бит алар арасында гөнаһлылар да бардыр. Нигә алар бер дә дөрләп янган тәмуг утыннан курыкмыйлар икән? Чөнки, ошбу дөньяда иң кадерле нәрсә — иректер, олуг хан. Ирекнең бары тик дивана кеше генә кадерен белми.

— Син беләсеңме, син дивана түгелме?

— Беләм, олуг хан. Бик яхшы беләм.

— Син күптән оҗмахтан баш тарттың бугай бит инде.

— Ирекне миңа әмир Хаҗи бирде, олуг хан. Ә сез кире алырга итәсез.

— Син минем остам, димәк, колчурамдыр да, кияү балакай. Ярый, мин сине коллыктан азат иттем, ди. Ары таба нә кылырга исәп тотасың соң?

— Олуг хан, кош канатсыз, ир-зат хыялсыз булмый.

— Азат итәрмен мин сине, әйе, дөньялыкта ук азат итәрем. Тик бер шарт белән — Назлыгөлне тап, мине каршыма китер.

Дәүран кисәк дерт итеп китте, ни кылырга белми як-ягына каранды. Димәк, дип уйлады ул, Назлыгөл хан кулында түгел, Назлыгөл Жик Мәргән кулында. Шул ук вакытта Сәлим ханның көлемсерәп торуын күреп, күңелен кара болыт каплады. Ханның юри әйтүе дә бар иде.

— Оста Дәүран, мин сиңа бер атна вакыт бирәм. Әмма ул атна эчендә дә тик ятмассың, яңа салынып яткан мунчама нәкышлар төшерә торырсың. Бусагабаш, алып кит остаңы. Кунар якта сарайга алып кайт. Хәер, кирәкмәс, анда торсын, бизәк төшерүчеләрне өйрәтсен.

* * *

Бары тик ун көннән соң гына оста Дәүранны кешелек киемнәрен киендереп, сарайга алып килделәр.

— Кем дәштерде, ясавыл?— дип кызыксынды Дәүран үзен озатучы азатлар унбашыннан.

— Ханбикә тансыклаган, киявемне күрәсем килә, дигән булды.

— Саумы?— диде ханбикә һәм җиләк-җимеш куелган өстәл янына таба үтте, түмәргә утырды. Дәүран бер тезенә төшеп баш иде.

— Анам, кичер мине ходай хакына.

— Йә, балакай, уз түрдән, утыр, сөйлә.

Ни турында сөйләргә тиеш ул аңа? Назлыгөлгә өйләнүе хакындамы? Бәлкем Назлыгөлне ничек урлавы хакында беләсе киләдер? Алай дисәң, ул аны урламады, хан кызы үзе килде.

Ханбикә хаклы иде, хәзер аның алдында үсмер егет түгел, йомры кара сакаллы, кара мыеклы матур сынлы ир-ат иде. Дәүранны күрде дә Зөбәрҗәт ханбикә, шундук Назлыгөл кызының хәленә керде. Баш алып качып китәрлек икән шул егете дә, кол оста гына димәссең. Иллә шулай дип үз-үзен юатса да, күңеленә юану килмәде. Гүзәлләрнең гүзәле Назлыгөлен, хан кадәр хан кызын, бердәнберен бер дә колчура егеткә бирәсе килмәгән иде аның, әйе, гәрчә сынбат гәүдәле, күрер күзгә пәйгамбәрләр кыяфәтле булса да. Иллә кылынасы кылынган иде инде, аңа җиткерделәр, Назлыгөл йөкле, диделәр. Димәк, булачак баланың әтисе ошбу кешедер. Тик Зөбәрҗәт ханбикәнең тизрәк беләсе килә иде, кая итте ошбу кеше аның кадерле баласы Назлыгөлне? Кай тарафларда тота, нигә анасына килтереп күрсәтми?..

— Назлыгөлең кая инде, кияү балакай? Үзеңне тотып килтерделәр, хатыныңны кай тарафларда интектерәсең? Хак булса, авырлы икән Назлыгөл, дип ишеткән идек. Синнәнме?..

— Анам,— диде Дәүран, ханбикә алдына төште.— Анам, әйтмәгез алай, кимсетмәгез кызыгызны. Назлыгөл минем никахлы хатыным.

Дәүран авырлык белән башын күтәрде, беренче тапкыр дияргә була, Зөбәрҗәт ханбикәнең күзләренә карады.

— Утыр, утыр, кияү балакай. Минем сине дә, Назлыгөлне дә рәнҗетәсем килми, иллә сез икегез дә минем йөрәгемә бик күп тоз салдыгыз, бик нык әрнештем йөрәк парәм югалгач.

Шулчак бүлмәгә Сәлим хан килеп керде.

— Ә-ә, сез монда икән. Йә, әйттеме Назлыгөлнең кайда икәнен?

Ханбикә урыныннан кузгалмады, тыныч вә тыйнак кына:

— Атасы, ошбу бала безнең кияүдер,— диде.

— Йә-йә, ханбикә, әйт әйтер сүзең.

— Минем шуны беләсем килә, ханиям, Ягкуб бәктән ошбу бала үзе качтымы, әллә булмаса качырдылармы? Карт төлке Ягкуб бәк ошбу баланы качты дип бара. Мин аңа ышанып җитмим, ханиям.

— Йә, ни диярсең, оста?— дип, Сәлим хан күпереп торган мендәргә кырын төште, көмеш җеп белән тукылган чапанын тезенә яба-яба, янына килгән песинең сыртыннан сыйпады. Иясе янында сырпалана-сырпалана, песи мырылдарга тотынды.

— Мин аннан качтым, аксакалның гаебе юктыр, ханиям.

— Димәк, син Назлыгөлнең анда булу-булмавын белми килдеңме?.. Һәм сине Ягкуб бәк азатлары тотып алдылар. Мин сине зинданга ябарга куштым, ә Ягкуб бәк иреккә чыгарып җибәргән. Яу вакытында синең белән шөгыльләнергә вакытым булмады, хәзер мин белергә телим: кайда Назлыгөл, кем кулында?

Дәүран күзләрен түбән төшерде, ул күтәрелеп карарга кыймады. Хан аңардан сорау ала иде. Ә бит ул үзе дә белми Назлыгөленең кайдалыгын. Белгән хәлдә бүген үк торып чабар иде.

— Мин килгәндә Назлыгөл Ибраһим каласында юк иде инде.

— Сине анда кенәз Всеволод тиуны эзләп йөргән икән. Сине дә, оста Бәкерне. Ни өчен? Әллә соң Назлыгөлне Всеволод кенәз тиуны урладымы? Ягкуб бәк Всеволод кенәз белән орышмый, алтын биреп котыламы, әллә булмаса, сине биреп котылырга иттеме?..

— Мин Ибраһим каласыннан качып киттем, ханиям. Аксакал Ягкубның әсиренә нә кылырга җыенуы миңа караңгыдыр.

— Әмир Хаҗи углан Ягкуб бәк кызына өйләнгән. Хак булса, Ягкуб бәк угланга барып сыенгандыр. Шулай булгач, Всеволод тиунына нигә кирәк булды икән синдәй оста?

— Всеволод кенәз калалар салырга ярата, ханиям.

— Мин яратмыйммы? Казан каласын кем салдырды, кем аны углан кулына бирде? Ибраһим каласын кем саклады! Картлач Ягкуб бәкме? Ә бит мин аны сараема алмакчы идем. Ә ул әнә нишләп ята. Урыслар белән килешеп, тигез сәүдә итү турында сөйләшеп ята икән. Һәм моны әмир Хаҗи углан хуплаган. Хаҗи угланым узына, баш бирми хәзер әнә икенче базар каламны канат астына җыймакчы. Назлыгөл дә аның кулындадыр әле!

— Назлыгөл аның кулында түгел, ханиям. Әмир мине Назлыгөлне алып кайтырга дип Ибраһим каласына үзе җибәрде.

Хан белән ханбикә күзгә-күз карашып алдылар.

— Йә-йә, шуннан соң Назлыгөл кем кулында була инде, оста Дәүран?— диде Сәлим хан, ыңгыраша төшеп урыныннан кузгалды да кияү каршына килеп басты.— Йә, бәлкем син беләсеңдер?

— Белмим, ханиям.

— Әгәр дә мәгәр Всеволод кенәз Назлыгөлне кулына төшергән булса, тиздән сине дә урлаулары бар, оста.

— Мин сезнең кызыгыз түгел, ханиям. Мин кемгә кирәк?

— Син миңа кирәк, кияү балакай, миңа! Аннары Всеволод кенәзгә!

— Озын сүзнең кыскасы, ханиям,— диде кисәк кенә Зөбәрҗәт ханбикә.— Кияү балакай миңа Назлыгөлне алып кайтсын. Баланы йокле диделәр, оныгымны үз кулым белән аласым килә.

— Кайда дип беләсең инде, ханбикә, Назлыгөлне?— дип сорады Сәлим хан.

— Анысы миңа караңгыдыр, ханиям, урлый белгәч, таба да белсен. Ил өстенә килгән бәла түгел, иншалла, җае чыгар, бала исәндер, ерак китмәгәндер. Азатларыңны чакыртып ал, ханиям, кеше көлдереп, балага узган кызыңны эзләп йөрмәсеннәр. Ә моңа шарт куй: йә Назлыгөлне таба, йә...

Ни өчендер Дәүран ханбикә Зөбәрҗәт аягына төште. Бу хәлгә аптырабрак калган ханбикә беренче тапкыр дияргә була калтыранган бармаклары белән кияү балакайның башына кагылып алды һәм шундук кузгалып китте. Дәүран бертын тезләнгән килеш торды, ул сизде, тойды: ханбикә аңа кагылып куйды һәм ят итеп түгел, үз итеп, якын итеп.

— Мин аны табармын, анам,— диде Дәүран һәм тавышы калтыраныш китүдән курка калып.— Мин аны йөрәгем белән эзләп табармын.— Аягүрә басты, әүвәл ханга, аннары ханбикәгә баш иде.

— Синдә каным кайнаган чакларым күп булды, балакай. Әле дә яшермим, эчемә җыеп каласым килми, балам табып алып кайтмасаң, гомер бәхиллегемне алмассың.— Ханбикә Сәлим ханга таба борылды.— Гаскәриләр бирәсеңме бу балага, үзе генә китсенме?

— Иң әүвәл аны әмир Хаҗи углан җибәрмәс. Ахыр килеп, әүвәлтен кай тарафка юл алмакчы? Казан ягынамы, әллә булмаса...

— Уйлап-уйлап торам да, ханиям, бүре баласын урманга гына чыгарып җибәрмибезме икән?

— Ни кушсагыз, мин шуны кылырмын, анам.

— Иелгән башны кылыч кисми, дисең инде. Хуш-хуш,— диде Сәлим хан.— Кияү балакай Казан каласына бармас, ханбикә. Назлыгөлне мин үзем алып кайтырмын.

— Тагын гаскәр белән барырга исәбеңме әллә, ханиям?!

— Кирәк дип тапсам, гаскәрен дә алып барырмын, ханбикә, әллә мин ул угланга баш бирми яшәргә ирек куймам.

— Ул сине, ханиям, Гали олан өчен кичерми.

— Ул оланны минме кала нигезенә күмдердем?!

— Син, ханиям, син,— диде Зөбәрҗәт ханбикә тыныч кына.— Син булмый кем булсын... Менә киявем алдында әйтәм, Хаҗи углан сине оланың кала нигезенә күмдергәннән соң куралмый башлады. Иң акыллы, баш баламны дошман итте бит!

— Углан буларак ул миңа баш бирми башлады!— дип кабатлады Сәлим хан ни кылырга белми аптыраудан.

— Атам, анам, кичерә күрегез, кичерегез... Мин ул каберне казыттым, анда адәм баласы күмелмәгән иде, аннан эт мәете чыкты.

Сәлим хан киявенә карады да бертын ачкан авызын ябалмый торды. Ханбикә Зөбәрҗәт Дәүран янына килде дә кулыннан алды.

— Чынмы бу, балакай?

— Чын, анам, эт мәетен без яңадан күмдек. Төнлә белән казып караган идек, халыкка әйтергә курыктык. Ләкин кабердә эт мәете хакындагы хәбәр барыбер халыкка таралган булып чыкты.

— Димәк, Акбикә килен чынлап та Өргәнечкә Гали оланны эзләп киткән булып чыга,— диде Сәлим хан.— Ходавәндә, йа алла, мөхәммәдерәсүлулла, колакларым дөрес ишетәме. Бу ни инде тагын, вәзир Исхакны...

— Атам, кабердә эт мәете иде. Коръән тотып ант итә алам.

— Ханбикә, ханбикә дим, болай булгач, минем углан Хаҗи алдында һичнинди дә гаебем юк. Йа Алла, Мөхәммәдерәсүлулла...

— Инде нишләргә исәбең, ханиям,— диде ханбикә Зөбәрҗәт.

— Ошбу хакта Тәтеш шәех әйткәч, ышанмаган идем инде, ниһаять, инандым, ханбикә, инандым. Димәк, Гали олан чынлап та Өргәнечтә Олуг Пәһлеван Мәхмүттән сабак алып яткан. Хәзер әнә шаһ мәдрәсәсендә мөдәррис икән.

— Йә, ханиям, кайсыгыз бара инде Казанга? Синме, кияү балакаймы? Иншалла, исән булса, Гали олан бер кайтмаса, бер кайтыр. Туган ил үткән юл түгел, җан тартмаса, кан тартыр, кайтыр бер, иншалла.

— Үзем барам, ханбикә, үзем. Бер җайдан углан Хаҗи белән дә килешеп кайтырмын...

— Барыр кылгач, барырсың, ханиям. Әүвәл минем киңәшем тыңлар идең. Кияү балакай Назлыгөлгә хат язсын. Шушы хат белән каладан-калага чаптар җибәр. Ир кулын таныр да кайтмый калмас.

* * *

Булган хәлләр Дәүран өчен барысы да төштә кебек кенә иде. Менә-менә ул уяныр да зинданда ятуы расланыр шикелле иде. Аның өчен аерым урын җәйделәр. Кунаклар өчен булган ошбу бүлмәдә хан үзе дә кереп яткалаштыргалаган, күрәсең, чүәкләре тора. Кеш тиресе җәелгән зур сәке, нәкышлап тукылган келәм, түр яктагы кечкенә өстәлгә куелган ризык-нигъмәт, ярым ачык тәрәзәдән кергән саф һава хыялда гына күз алдына китереп була алган җәннәтне хәтерләтә иде. Дәүранның сәкегә барып утыруы булды, кырын яктагы ишектән җария кыз килеп керде.

— Галиҗанәпләренә нәмә булса кирәкмиме?— дип сорады ул һәм тыйнак кына елмайды, бөрмә күлмәк итәген чеметеп кенә тотып, сизелер-сизелмәс кенә чүккәндәй итте.

— Рәхмәт, миңа берни дә кирәкми.

Җария кыз борылып чыгып китте. Дәүран кечкенә өстәлдә көмеш кыңгырау күрде, кызыксынудан чарасыз калып, барып зеңләтте. Янә тәүге кыз бүлмәгә керде, янә тәүгечә тез чүккәндәй итте, янә чеметеп кенә бала итәкле күлмәгенә тотынып алды.

— Су кертсәң иде, сылукай.

Түр яктагы икенче бер өстәлдә өч-дүрт кувшин тора иде, кыз шул тарафка үтте, бер савыттан таш йомрыга салкын су салды һәм Дәүранга китереп бирде. Дәүран суны эчеп куйды да савытны кызга бирде. Кыйгач кара кашлы, бер-берсеннән качып китәргә җыенган кебек елтыр күзле, тулы вә түгәрәк йөзле иде кыз. Дәүран аның атын сорамады, рәхмәт әйтеп елмайды гына. Кыз бүлмәдән чыгып киткәч, ул уйга калды, шундук мәрхүм әнисе күз алдына килеп басты. Мәрхүмә аңа әйтер иде:

«Улым, дөньяда иң-иң йомшак ни була?»— дип. «Мамык мендәр»,— дияр иде Дәүран. «Юк, улым,— дияр иде анасы,— дөньяда иң-иң йомшак нәрсә — үз кулың»,— дияр иде. Моңа ул ышанмады, соңыннан нинди йомшак мендәргә ятса да, кулын баш астына куюын абайлап, анасының хак булуына төшенгән иде. Аннары ул: «Дөньяда иң-иң татлы ризык нәрсә?»— дияр иде. Дәүран анасына барлык белгән тәмле вә татлы ризык-нигъмәтләрне тезеп чыгар иде, әмма әнисе барыбер: «Юк, улым, дөньяда иң-иң татлы ризык — су»,— дияр иде. Һәм Дәүран соңыннан янә моңа инанды. Нинди тәмле ризыклар ашасаң да, иң тәмлесе су булыр. Янә тагын әнисе: «Бәхет ни ул?»— дип сорар иде. Дәүран аңа хан сараенда яшәү, мәхәббәт, дияр иде, ә анасы уфтанып куяр иде дә: «Их, балакай, дөньяда иң-иң зур бәхет — ирек!»— дияр иде. Шуннан күз яше белән мөлдерәп тулган күзләрен бер ноктага текәп: «Атаң әнә шул ирекне даулый алмый дөньядан да китте»,— дигән иде. Шулчак әтәчләнә төшеп Дәүран: «Мин ул ирекне даулап алырмын, анам бәгърем!»— дигән иде.

Даулый алдымы ул ирекне? Ханның аны әле булса коллыктан азат иткәне юк. Дөрес, угланы әмир Хаҗи аңа ирек бирде, коллыктан азат итте, әмма ул хан колы иде. Хәзер әнә көтмәгәндә кияве булып китте. Тик була алырмы хан кияве? Назлыгөлне алып кайтып, аңардан аерып куймаслармы?

* * *

Ул тагын зинданда иде, бу юлы инде җәннәт кебек, ягъни оҗмах кебек зинданда. Нинди генә булмасын, зиндан барыбер зиндан икән. Җәннәттә яши, ни теләсә шуны ашый, ятар урыны кеш тиресе, басар урыны җем-җем иткән келәм, ә менә күңел богауда, күңеле генә түгел, җаны-тәне, ирке-мәхәббәте.

— Кияү балакай, кияү балакай,— дигән тавышка уянып китсә, янында ханбикә басып тора. Дәүран күзләрен уарга да онытып, торып утырды, сикереп идәнгә төште.

— Ятып кына торыйм дигән идем, йокыга киткәнмен, кичерә күрегез, анам.

Ишек янындагы кечкенә өстәл янына узды, җиз комганнан җиз таска кул-битен юып, сөлгегә сөртенде һәм янә ханбикәдән кичерүен үтенде.

— Сине хан көтә, әйдә,— диде ханбикә һәм, җавап та көтмәстән, алдан китте. Ишек янына җиткәч, әйләнеп кияү балакайга карады, гәүдә-кыяфәтен күздән кичерде. Коңгырт кара чәч, җай утырган борын, кара йомры сакал, кыска мыек. «Сакалын буяганмы, үзе карамы»,— дип уйлап алды ханбикә. Кияүнең кыяфәте аңа ошады һәм: «Барысын да анасыннан алган бу бала, суеп капланган Туйбикә»,— дия-дия авыз эченнән сөйләгәндәй итте. Әмма ул мәрхүмә хатынга карата тәүге ачуы юк иде инде. Хәер, теге вакытта да ул аңардан чын-чынлап көнләшмәде. Хак анысы, Сәлим хан аның исемен телгә алганда теш арасыннан: «Җитәр булмаса ул хатының турында»,— дип әйтеп куяр иде куюын. Ул мәлләрдән соң күп сулар акты, кем бар да кем юк, горур вә зифа сынлы Туйбикә дә әнә гүр иясе инде. Әнә шул хатынның угланы аның җан кияве булды. Бу хәлгә шаклар катмалы иде, әмма бу хак иде. Ә бит Туйбикә: «Минем угылым хан кызына өйләнәчәк»,— дип, кендек әбисенә әйтеп җибәргәч,шартлый язган иде. Хәтта Сәлим ханнан ул тәкәббер хатынны зинданга яптырырга кушасы иткән иде, соңыннан сүрелде тагын күңеле. Ярый әле ходай саклаган, язмыш әнә ничек хәл итте — шушы көндәшенең углы аның кияве. Әйе, бу дөнья дигәнең әллә нәмәләр эшләтә адәм баласын, турыны — бөгә, бөкерене турайтып куя. Сәлим хан да әнә ошбу якты дөньяга гомер бакыйга килгән кебек йөрер иде, хәзер әнә әле биле ката — йөри алмас булып урында ята, әле эчем авыртып тора, дип

бөяттәй бөкләнеп көннәр буена ыңгыраша. Табиблар да һични әйтә алмыйлар. Шулай шул ул гомер дигәнең, бер безгә генә түгел, аллаһы тәгалә пәйгамбәрләргә дә гомер дигәнеңне үлчәп-чамалап кына биргән. Сәлим ханны түгел, аларны яшәтер иде. Димәк, һәммәбезгә дә шулай язган, ә язмыштан узмыш юк, диләр картлар. Ханга да тәхет турында уйларга вакыттыр. Шулай бөкшәеп ята-ята телдән калуың бар. Зиһенең саф, тәнең таралмаган чакта васыятеңне әйтеп кал — кайсы угланыңа, кайсы оныгыңа калдырырга исәбең тәхетеңне. Ярый, вәгъдә иткән Гали оныгына тәхетеңне бирә алмадың, нигә, әйтик, Хаҗи угланның кече улына — Җаббарга бирмәскә. Абасына вәгъдә иттең, энесенә бирдең. Халык та канәгать, синең дә күңелең тыныч. Җаббар оныгына бирмәгән хәлдә, каладыр ике угланың: йә Хаҗи, йә Илһам. Аллага шөкер, икесе дә үз акылларында, тәүфикълы, әдәпле, уңга-сунга карап дога кылмыйлар, кыйблаларын беләләр. Икесе дә синең кебек өчәр хатынга өйләнмәде, бер белән берәгәйле итеп яшәделәр. Акбикә киленең өлкән угланыңнан киткән икән — анысына син үзең гаепле, ханиям.

Ниндидер тарлавыклардан үтә-үтә, ниһаять, тәхет бүлмәсе ишеге каршына килеп туктадылар.

— Атаң әйткәндә сүз катма, тыйнак кына тыңла, авызыңа су кабып та утырма,— диде Зөбәрҗәт ханбикә киявенә кырыс кына һәм алга таба атларга иткән иде, нидер исенә төшеп, янә Дәүранга әйтте: — Атаң авыртып тора, кычкырып сөйләшмә, ил хакименең игелеген алыйм дисәң, ир түренә баш иеп кер, дигәннәр.

— Ярый, анам, сез дигәнчә булыр.

Ханбикә Зөбәрҗәт кияү балакай сүзләрендә киная кебегрәк агыш күреп, туктагандай итте, әмма һични әйтмәде, алга атлады.

Сәлим хан зур вә киң сәкедә ястыкта ята иде, аның янында кәтиб Хафиз, вәзир Камай, хан аларга нәрсәдер сөйли иде, ишектә ханбикә белән кияве күренүгә, торгандай итте, баш игән Дәүранга ияк каккандай итте.

— Ханбикә,— диде хан.— Ишкул шәех урында ята икән, хәле мөшкел, ди, табибемне шунда җибәрдем әле.

— Ул сакаллы сабыйның бер дә синең янда буласы килеп тормыйдыр әле, ханиям. Үз хәле хәл, диделәр.

— Хак хәбәр, ханбикә, шулай, телдән язып алгалый,— диде вәзир Камай.

— Әйе, Ишкул да урынга калган, безгә дә әнә чират килеп ята,— диде хан һәм түшәгенә сузылып ятты.— Тәкъдирдән берәүнең дә котыла алганы юк әле.

Ризык-нигъмәтләр керттеләр, көмеш табак белән хан алдына куйдылар. Сәлим хан торып утырды, савытлардагы ризыкларга күз йөртеп чыкты.

— Күз тели, күңел алмый,— диде ул кире урынына ятып, ахыр зәгыйфь кенә итеп кул селтәде, янәсе алып китегез ризыкларыгызны.

— Азрак булса да капкалар идең, ханиям,— диде ханбикә.

— Хәл юк, ризык чәйнәргә түгел, сөйләшергә дә хәл юк,— диде Сәлим хан.— Син, кияү балакай, мунча бизәкләрен тәмамла да Назлыгөлне алырга кит. Үзең бар. Шымчыларым җиткерделәр, Назлыгөл Иске Казан кирмәнендә икән.

— Киявеңә гаскәр бирәбезме?— дип сорады вәзир Камай.

— Анысын соңыннан, Хаҗи углан Назлыгөлне бирмәсә, җыйган ясагын түләмәсә генә, гаскәр җибәрермен, вәзир. Ходa үзе шаһит, бер дә болгар белән болгардан кан койдырасым килми.

— Борынгылар: туганына таш күтәргән ташка абынып булса да егылыр, дигәннәр. Сиңа киңәшем бар иде, ханиям. Ары таба соң булып куюы бар, чөнки ил юрганы бердер, кем тартса да, икенче берәүнең өсте ачылыр. Мәгълүм ки, әүвәл башта сәнең сүзеңне тыңлап, әмир Хаҗи кирмән каласын Елан тавына сала башлаган иде. Әмма, кем

кинәше беләндер, ахырдан каланы Казан елгасы тамагына чыгарды. Каланы салучы киявендер. Урыны хозур, таулы, уңай, кәттә базар каласы итү өчен иңледер. Моннан нәтиҗә шулдыр, хан, каланы әмир Хаҗи сала. Ә бит ул каланы салырга син әмер-фәрман биргән иден.

Сәлим хан торып ук утырды, бертын вәзиренә карап торды.

— Син хаклы, вәзир. Васыятем язганда мин боларның барысын да истә тотармын. Хаҗи углан бүгенге көндә Казан каласында ята, диделәр. Шунда ята бирсен. Ә Казан каласын мин Назлыгөл кызыма бирермен. Кияве каланы тиңе булмаган итеп суктырыр, кулы-коралы үзендә.

Хан елмайгандай итте. Дәүранга күз ташлап алды, ханбикә дәшмәде.

Хан дөрес фикерли иде. Өлкән угланы Хаҗи утыра икән Елан тавында, утыра бирсен, ә инде Назлыгөл каласына килеп кушыла икән — рәхим итсен. Ул арада Назлыгөлнең, иншалла, балалары да үсеп житәр. Барысы да алла кулында булса да, адәм баласы да кул кушырып утырмаска тиештер. Һәрхәлдә, ханбикә Зөбәрҗәт шулайрак уйлый иде. Аның өлкән угланы Хаҗига ачуы килми, ул аны хәтта кызгана. Дөрес, Ягкуб бәк кызына өйләнгән, диләр. Хәбәр итмәсә дә, сүз — сандугач, килеп сайраучылар бар. Өйләнгән икән — тора бирсен, ул баланы акыллы мөгаллимә, диделәр.

— Йә, вәзирем, син ни әйтерсең?

— Ханиям, мин хуплыйм, чын күңелдән хуплыйм. Кара Иделгә койган Казан елгасы тамагында тиңе булмаган базар-кала күтәрергә була.

— Шуның өчен, вәзир Камай, иртәгә үк кияү балакайга нәртеп диярлек. Казан каласын күтәрергә ташчылар җибәр. Казанбаш Вардәнга әйт: кирәк кадәр алтын бирсен.

— Ханиям, изгелек җирдә ятмый, моны күреп әмир Хаҗи угланның да күңеле йомшарыр, атасына карата да фикере үзгәрер.

— Хуш, шулай булсын. Кәтиб, яз фәрман. Сәне һиҗри белән 573 нче, милади белән 1177 елда Бөек Болгар ханы Сәлим ханның атаулы карары белән Кара Иделгә Казан елгасы койган төбәктә зур вә кәттә базар-кала салырга. Сәлим хан.

— Иншалла, барысы да әйбәт булыр, җиде саны изге сандыр,— диде вәзир Камай.

— Игелек сезгә, барчагызга да. Ташчыларга җиткер, вәзир, акчасыннан тормам, Хаҗи угланнан күбрәк түләрмен. Каланы Дәүран кияү күтәрер...

Сәлим хан барчасын да карашы белән озатып калды, күңеле белән ул ханбикәнең калуын теләгән иде, әллә нишләп тегесе әйләнеп тә карамый чыгып китте. Әйе, үткән гомер үтә. Ә бит аның бер карашыннан дер селкенеп торырлар иде, шул ук вәзир дә, ханбикә дә, гәрчә ханбикәгә гомер буенча кычкырып дәшкәне булмаса да, тегесе аның мәҗлесләрендә сүз каткалап утыргаласа да. Сәлим хан үкенми иде, үз гомерендә ул Болгарда бик күп кала-кирмәннәр салдырды, әмма монысы иң кәттәсе булыр, чөнки урыс кенәзе Всеволодның Ибраһим каласына күзе төшкән. Урыс — эрсез, ул каланы алыр, ә болгарлар яңа базар-кала салган булырлар. Калада зур-зур кәрвансарайлар булыр, йөзләрчә илләрдән сәүдәгәрләр агылыр. Ә сәүдә ул — ил байлыгы.

* * *

Яңа каланы күтәрергә кияве белән ташчыларны озаткач, каты сырхаулап киткән Сәлим хан тәмам урынга калды. Ахыр тәхет ягына бөтенләй чыгалмас булды, ятак ягында гына вәзирен вә якыннарын кабул итте. Ул көннәр шулай яткач, хәле һаман яманлана баруын сизеп, ятак ягына кәтибе Хафизны чакыртып алды һәм аңа шагыйрь Әбдел-

галәүне дәштерергә кушты. Моңа кадәр сараена китерергә рөхсәт биргән булса да, шагыйрь гадәттә шәкертләр вә хатын-кыз ягында югалыр иде, Сәлим хан, гомумән, шагыйрь белән кызыксынмады. Бүген исә уяныл китүгә, әллә нигә шул шагыйрьне күрәсе, аның язган шигырьләрен тыңлыйсы килеп китте. Көдрә чәчле, көдрә җирән сакаллы, кирәкмәгән чандыр гәүдәле, кылыч борынлы шагыйрь Әбделгаләү ятак ягына килеп кергәч, Сәлим хан яткан урыныннан торып утырды, шагыйрьдән сәлам алгач, бертын дәшми-тынмый такмак чыгаручыга карап торды, ягъни ил чичәнենә. Шагыйрьнең йөз-чыраенда һични күрмәде Салим хан, ә менә яшел күзләрендә нindidер яну, кызыксыну бар иде. Ханны беренче тапкыр күрүеме, дәшеп алуга аптыравымы? дип уйлады Сәлим хан һәм сүлпән генә кул изәп, якындагы түмәрдә урын күрсәтте.

Әбделгаләү ике-өч адәм читтәрәк басып торган кәтиб Хафизга күз ташлап алды һәм хан күрсәткән түмәргә утырды, дога кылды, янә сәламен кабатлады.

Сәлим хан урынына ятты һәм сабыр гына:

— Шигырьләрең укыр идең, Әбделгаләү,— диде.

— Ни турында укыйм, хан, мәхәббәт турындамы, табигатькә багышлаганнарынмы, дөньяви хәлләргә караганнарынмы?

— Мәхәббәтен күрдем, беләм, үтүчән вә сагышлы икән, биргән бәхетне суга салган балдай эретә, юкка чыгара икән. Табигатен гиздем, күреп вә сокланып туя алмадым; язын көтеп алдым, усал кышын теләп уздырдым, кояшлы яз килгәнне күрүгә, илаһи бәхетем шулдыр дип куандым. Хәят күгемне, сандугач сайравын яңадан ишетә алуыма шикләнәм, алдагысын бер алла белә, хыялым ирексез яши, җәннәткә дәшә торган догаларымны укыйм, караңгы каберем күз алдыма килеп баса. Әмма, шагыйрь, дөньяви хәлләрдән шушы хәлемдә дә аерыла алмый изаланам. Шөкер итәм, рухым яшь, йөрәгем тибә, димәк, шигырь тыңлар гына хәлем бар. Гомерне адәм баласына ниһаясез бирмәгән, барыбыз да беләбез, әмма әллә нигә караңгы гүргә керәсе генә килми. Хәятемнең киләчәге сүнгән, кара гүр мине көтә һәм мин анда барырга мәҗбүрмен. Нинди шигырең укыр идең шундый адәм баласына, шагыйрь?

— Олуг хан, минем кулыма оныгыгыз Кол Гали язган шигырьләр килеп керде. Укыдым да мин аларны, таң калдым. Олуг шагыйрь икән сезнең оныгыгыз. Тик аны...

Сәлим хан кулын күтәрде, Әбделгаләүгә туктарга кушты.

— Шагыйрь, ары таба сөйләмәсәң дә була. Оныгымның Өргәнечтә икәнен бер синең авызыңнан гына ишетүем түгел. Ил гайбәттән, җир айдан кача алмас, диләр. Иншалла, шигырь язса-язмаса да, туган туфрагына кайтыр ул. Аллаһы тәгаләнең кодрәте зурдыр, йа раббем, кичерә күр колыңны. Күрәсең булса, күркә булырсың, ди. Күрәсе булгандыр...

Сәлим хан кинәт эчен тотып, куырылып китте, йөзенә тимгел-тимгел кызыл таплар кунды. Әбделгаләү бу хәлне күреп, торып китәргә иткән иде, Сәлим хан кулын күтәреп, аңа сабыр итәргә кушты.

— Үтә ул, үтә, шагыйрь. Әллә ни шунда, дулкын-дулкын булып килә дә бөтерә дә ала.

Чынлап та ул арада ханның йөзе алсуланып китте, тимгелләре югалды, чыраена табигый төс керде.

— Укы, укы, Әбделгаләү,— диде моңа кадәр дәшми торган кәтиб Хафиз.

— Мин басып укырмын, ханиям.

— Ихтыярың, ихтыярың...

Илаһым, мин сорыйм синнән,
Шул дүрт чараны бүләк ит:
Берсе — җәннәт, берсе — хөрмәт,
Берсе — нигъмәт, берсе — иман.

Телимен синнән, и раббым,
Шул дүрт чараны юлдаш ит:
Берсе — гыйлем, берсе — гамәл,
Берсе — иминлек, берсе — иман...

Сәлим хан кулын күтәрде, бер мизгел шагыйрьгә карап утырды.

— Сөбханалла, Әбделгаләү, сина гакылны аллаһы тәгалә үзе биргәндер. Йә, хәзер золым-җәбер кылган кешеләр турында бирәр нәрсәңне укы.

Каза килсә берәүгә, димә: килсен,
Берәүгә килсә сырхау, димә, үлсен.
Бу сүзләрең аңа һични кылмас,
Зарар килер үзеңә, файда булмас...

Сәлим хан кисәк кенә түшәккә ятты, сизелер-сизелмәс кенә Әбделгаләүгә кул селтәде. Кәтиб Хафиз шагыйрьне ятак ягыннан алып чыгып китте. Әмма алар сарай бусагасы аша үтәргә дә өлгермәделәр, артларыннан бусагабаш йөгереп чыкты.

— Хафиз, Хафиз, сезне ханиям дәшә!

Ятак ягына әйләнеп керделәр. Сәлим хан сүзсез генә икесенә дә якынрак килеп утырырга кушты.

— Кәтибем, язып бар. Миннән соң Болгар тәхетенә утырган углан-ханнарга васыятем булыр. Онытмасыннар иде: ходай тәгалә адәм баласына да, хайван вә җанварларга да көч-гайрәтне биргәндер. Ат хайваны адәм баласыннан күп тапкыр көчлерәктер, үгез вә арыслан турында әйтеп тә торасы юк. Мәгәр ходай тәгалә адәм баласындагы гакылны бер генә хайван вә җанварга да бирмәгәндер. Адәм баласының көч вә гайрәте аның гакылындадыр. Бүген мин бер чарага инандым: агачка сандугач җитмәгән кебек, хан сараена шагыйрь җитмәгән икән. Кәтиб Хафиз, минем васыятьне язып ал һәм углан-оныкларыма җиткер. Сарайда һәрчак ике-өч шагыйрь булсын. Мин күп чакта үз акылым белән генә яшәргә тырыштым, шуның аша шактый гөнаһлар кылдым: акыллыларны кудым, ялагайларга ышандым. Бик ихтимал, Болгарга яман хәлләр шулар аша да килгәндер.

Сәлим хан ыңгыраша-тартыша кырын ятты. Авыз эченнән генә, китегез, диде.

Кәтиб Хафиз шагыйрь Әбдәлгаләүнең терсәгеннән алды һәм ишеккә әйдәде. Хан ятагы ягыннан чыгуга, аларга ханбикә очрады.

— Ханның хәле ничек, кәтиб?

— Ханның хәле авыр, ханбикә. Миңа калса, угланнарны дәшәргә кирәктер.

— Хәзер табиб килә. Ишкул шәех вафат,— диде ханбикә һәм хан ятагы ягына кереп китте.

Алар янына вәзир Камай килде.

— Кәтиб Хафиз, калага шәех Игәнәй кайткан, ханны күрәсе килә. Ни кылыйм?

— Күрәсе килсә, күрсен, вәзир. Бәлкем әйтер сүзе бардыр.

— Бардыр анысы. Ишеттеңме, Ишкул шәех вафат. Бәлкем, мин әйтәм, Ишкулны...

— Хан ни әйтер, шул булыр, вәзир. Мин тәгаен каршы түгел.

— Ә ханбикә?

— Менә анысын әйтә алмыйм, вәзир.

— Син аның белән сөйләшеп кара әле, кәтиб. Синең ханбикәгә телең үтә. Дөресен генә әйткәндә, Ишкул шәех түгел иде, кәтиб Хафиз, шәех түгел иде. Игәнәй — белекле, гакыллы, ил имамы булырдай адәм,— диде вәзир Камай һәм ханбикә артыннан хан ятагына кереп китте.

— Табиб Хәсән дә кайтты микән?— дип сорады кәтиб Хафиз шагыйрь Әбделгаләүдән.

— Менә анысы миңа караңгыдыр, кәтиб Хафиз. Кичә мин ханбикәгә шигырьләр укыдым, шул вакытта безнең янга баһадир Таймас килеп керде һәм ханбикәгә: табиб Хәсән юк, диде. Бу хәлдән мин шуны аңладым, табиб Хәсән илгә кайтмаган. Ә менә шәех Ишкул белән хан оныгы Кол Гали Болгардадыр.

— Анысын анык беләсеңме?

— Кешедән ишеттем, кәтиб Хафиз.

* * *

— Су бир, ханбикәм, су,— диде Сәлим хан, ятагына ханбикә килеп керүгә.

Ханбикә тышы тирләп торган чүлмәктән ханга чишмә суы салып бирде. Сәлим хан акрын гына күтәрелде, калтыранган куллары белән җиз чүмечне алды.

— Көмеш чүмечемне кая илттеләр?— дип сорады Сәлим хан су эчеп куйгач.— Асрау кызларны да кертми башладың.

— Асрау кызларны үзең кертмәскә куштың ич, ханиям. Имеш, яхшысынмыйм кыз балалар алдында ыңгырашырга.

— Һич югы бусагабаш янымда торсын иде.

— Хәзер табиб кайта. Ишкул шәех вафат булды, ханиям.

— Ишкул вафат!— диде Сәлим хан.— Миңа да нәүбәт житте. Кияү киттеме? Ә бит ул миңа без бер көндә...

— Сөйләмә тузга язмаганны, ханиям. Ул аны болай гына сөйләп йөргән булгандыр, исән калу өчен.

— Һә, бу хакта аңа Чәчкә Ана әйтте диделәр түгелме соң?

— Чәчкә Ана үзе дә гүр иясе булган икән инде.

— Кем әйтте?

— Таймас баһадир.

— Бит ул, мәрхүмә, мәңге яшәр кебек иде. Мин үскәндә үк карчык иде инде ул Чәчкә Ана. Хәерле булсын, язмыштан узмыш юктыр. Дәштер угланнарны, ханбикә. Чаптарлар җибәр.

— Бүген үк җибәрермен, ханиям. Ханиям,— диде Зөбәрҗәт ханбикә авыруның кулыннан алып.— Калага шәех Игәнәй кайткан. Сине күрергә тели. Сабырланган, үкенепләр бетә алмый, диделәр.

— Үкенүләр белән генә кылган языгын юа алса икән ул. Шушы чиркәү аркасында күпме зыян-зәүрәт күрде Болгар. Йә хуш, кабул итәрмен.

— Син аны...

— Мин аны кичерермен, ханбикә, кичерермен. Аллаһы тәгалә алдында барыбыз да бертигездер.

* * *

Көтмәгәндә урынга калган һәм ике-өч көн эчендә вакыт-вакыт янында торган кешеләрне танымый башлаган, саташа-саташа кем беләндер орышкан Сәлим хан янына гарәп табибе белән ханбикә берәүне дә кертмәделәр. Ханның хәле авырая төшкәч үк дәвалый башлаган гарәп табибе ханбикәгә әйтте: «Хан озак яшәмәс». Шул хәлдән соң табиб кулыннан килгәнен барысын да эшләде кебек. Дарулар эчерде, сөлек салды, әмма бер дә алга китү булмады. Ахыр мәрхүм Ишкул мәчетеннән шәехнең бер мөриден китерделәр, ул ханга ясин чыга гына башлаган иде, кинәт кенә исенә килгән вә зиһене ачылып киткән Сәлим хан аны ятак ягыннан куып чыгарды.

Шуннан соң ханбикә вәзир Камай белән киңәшеп, Шайтан каласында яшәүче Болгар картны ничек тә китерергә дигән карарга килде. Икенче көнне иртән-иртүк килеп житкән угланнары, Хажи белән Илһам, аналарының бу эшен ошатмыйча, ниндидер сихерче картны чакыруга каршы төштеләр. Әмма ханбикә аларны тыңламады. Болгар карт артыннан ышанычлы жансакчысын жибәрде. Шуннан угланнар аталары янына керергә киттеләр, мәгәр монда да ханбикә Зөбәржәт угланнарга аркылы төште.

— Хәле арулангач үзе дәштерер, сабыр итегез!— диде.

Агалы-энеле Хажи белән Илһам кояш өйләгә житкәнче көттеләр дә, сабырлыклары төкәнеп, вәзирне чакырып алдылар. Әмма вәзир дә ханбикә яклы булды.

— Сабыр итегез, сабыр. Берәүне дә кертергә кушмады,— диде вәзир Камай уйчан-житди рәвештә.

Шәех Игәнәй дә килгән, ул да бер читтә йөренә, угланнары янына килми, чөнки дөнья күргән кеше буларак, ике углан арасына керәсе килми иде. Кайсы угланның тәхеткә утырасы хакында белү хәтта аңа да караңгы иде. Шуның өчен шәех угланнардан ераграк торуны мәслихәт күрде. Вәзир аңа әйтте, хан ясин чыгучы мөридне куып чыгарды, диде. Өмете бар иде әле шәехнең, ханның кинәт кенә аны чакыруы бар иде — ясин чыгарга. Шунда ул хан колагына киңәшен салыр, тәхетне кемгә калдырырга кирәклеген әйтер. Шул ук вакытта бу хәлнең яман бетүе дә бар иде: ханның ул теләгән кешене тәхетенә утыртырга теләмәве — шәехнең киләчәген чабып ташлаячак иде. Шуның өчен уйлана торгач, ул ханга да, угланнарга да бер сүз дә әйтмәскә булды. Ахыр чиктә аның үз хәле дә хәл иде — хан ни әйтә бит әле. Авыру вә гакылы камил үк булып житмәгән ханның аны илдән кудыруы, йә булмаса зинданга утыртуы да бар. Әйе, авырып урында ятса да, хан кулыннан барысы да килә, ул әйткәнне һич югы ханбикә Зөбәржәт тормышка ашырыр. Сәлим хан горур вә тәккәббер, тәвәккәл, шул ук вакытта үзсүзле кеше, кем-кем — шәех Игәнәй ханның холкын әйбәт белә иде. Дөрес, ханга ул рәнжеми, ахыр чиктә әнә кабул итәргә булды ич. Ә бит ераккарак китеп карасаң, шәех Игәнәй Сәлим ханга бер дә алай яманлык кылмады. Ил халкына коткы тараткан ярым шымчы, ярым төрки, ярым болгар (епископ Дунай болгарларыннан иде) адәм Игәнәй тарафыннан үлемгә дучар ителде. Әмма шул вакыйгадан соң илдән китми дә мөмкин түгел иде. Кияү санында йөргән Андрей кенәзгә ярарга тырышып, Сәлим ханның аны зинданга яптыруы бар иде, ул гынамы, хәтта башын да кистерер иде. Аллага шөкер кыла шәех Игәнәй, ходай саклады, вакытында качып котылды. Хак анысы, ул юк чакта яшь хатыны бер жилбәзәккә ябышып китеп барган, әмма шәех Игәнәй ул хатынны нә яраткан булса да әллә ни уфтанмады: хатын — мал түгел, таш — алтын түгел, берсе китсә, янә ике хатыны калган.

Кемгә дә сер түгел, шәех Игәнәй бары тик Сәлим хан гайрәтеннән Болгарга кайтмый ятты, гәрчә хатыннары Өргәнечкә килгән сәүдәгәрләр аша илгә чакырып хат арты хат язсалар да. Ахыр килеп монголлар Хәрәземшаһ калаларын басып ала башлагач кына юл чыгарга мәжбүр булды. Беткән баш беткән, дип кайтса да, илгә аяк баскач, айдан артык кеше-кара күзенә күренергә куркып йөрде. Бары тик Ишкул шәех каты авырып, Сәлим хан урынга калганны ишеткәч кенә, йөзен ачып йөри башлады. Һәм беренче булып, кайчандыр үзенең дошманы булган ханбикә Зөбәржәткә мөрәжәгать итте. Ни өчен нәкъ менә Зөбәржәт ханбикәгә? Сорасалар, үзе дә әйтә алмас иде, әмма күңеле нигәдер шулай теләде. Һәм ялгышмаган булып чыкты — ханбикә аны сарайга дәштерде, ханга күрсәтергә булды. Бәлкем, Өргәнеч ягында булган хәл дә бу адымны ясарга бер сәбәп булгандыр. Хәрәземшаһ Олуг Мөхәммәт монгол-татар илчеләрен яклап чыккан олуг шәех Пәһлеван Мәхмүткә кул күтәрә — башын кистертә. Шуның белән зур хата кыла Хәрәземшаһ.

Калаларны дошман камагач, аңа каршы халыкны күтәрү урынына рухани аталар Чыңгыз хан гаскәрен яклыйлар, аларга илне биләргә ярдәм итәләр. Рухани атакайларны, ягъни имамнарның бу «изге адымын» Чыңгыз хан да онытмый, калаларны алган сугышчыларына: «Һөнәрчеләргә, руханиларга тимәскә!»— дип әмер бирә. Әйе, Олуг Мөхәммәт халкы күңелендәге иманга кул күтәрә һәм дәүләтен югалта. Чөнки иманы юкның — кыйбласы да юктыр. Шул турыда да сөйләр ул ханга.

* * *

...Шәех Игәнәйне килеп каршы алган ханзада Гали каршылаган иде. Сәлам юллауга ук:

— Вәгаләйкем әссәлам, олуг шәех!— диде. Нәкъ менә шулай диде, «олуг шәех» дип әйтте. Бу хәлгә шәех Игәнәй тәмам аптырауга калып, ни әйтергә белми торган иде. Адәм теле кешенең хиссиятеннән күп тапкыр ярлы икән бит. Гаҗизләнеп тору бер хәл, ә менә хан онытын күрү, бәлигъ кешене очрату, әллә кайчан тереләй кабергә күмелгән адәми затлар табу — сусаган кешегә салкын чишмә суы бирү белән бер иде.

Шәех Игәнәй башта хан сәүдәгәре Бикколга бакты, ахыр тагын хан оныгы Галигә. Әйе, хан оныгы иде — Гали.

Тиз арада ашъяулык җәйделәр, табын хәстәрләделәр. Шәех Игәнәй бөкләнеп тез асты мендәренә утырды, дога кылды. Ул арада янә бер көтелмәгән тамаша булды: түр яктан казый Нисбах килеп чыкты.

— Исәнме-саумы, шәех,— диде ул нәкъ болгарларча, гарәпләштермичә генә.

— Сөбханалла, казый Нисбах, син дә мондамыни!— диде шәех Игәнәй.

— Хәтерең коелып калмаган булса, син мине хан оныгына аталык итеп билгеләгән идең. Мин үз вазифамны, аллага шөкер, тугры үтәп киләм. Нишләмәк кирәк, гомер үтә, сакалга чал кунды инде. Ә күңел яшь, яшь, шәех. Менә алланың рәхмәте белән Хаҗга барырга ният итеп торам әле. Биккол да, Кол Гали олан да ризалаштылар. Йөрәк тибүдән, кан йөрүдән туктамый торып, казый Нисбах илаһи илләрне күрү вә гизүдән туктамас. Инде көч вә куәтем җитмәгән тәкъдирдә — илгә кайтып, туган туфрагыма егылырмын. Туган туфракка кайтып егылырлык көч вә гайрәтне аллаһы тәгалә үзе бирер, иншалла, адәм баласына түгел, җанварга да каты бәгырьле була алмадым. Илне сагынам, шәех, һәммәсе дә сагындыра, чирәме дә, куе урманы да, елга-күлләре дә, гүзәл хатын-кызлары да, гәрчә илдә күз салырга йөзе ермачланган карчыгым булмаса да, күңел туган илдә, шәех. Синең әнә икеме, өчме хатының калды бугай. Аларны сагынмаганнардыр дип беләсеңме, шәех. Адәм баласының җаны гына түгел, тәне дә сөйгәненә зарыгыр, ди.

— Күр әле, күр, казый Нисбах, сине тыңлау бик тә рәхәт икән бит. Күңел дигәнең әллә кая ашкына башлады.

— Туган илгә, шәех, туган илгә. Адәм баласына җанга рәхәтлекне, тәнгә сихәтлекне туган як бирә. Яшь хатының ниндидер бер яшь җилбәзәккә тагылып китеп барган, дип әйтеп әйттеләр. Хакмы шул, шәех?

— Син, казый Нисбах, элек тә әче телле идең, әле дә шул гадәтең ташламагансың икән,— диде шәех Биккол, үрелеп йөзем каба-каба.

— Тел китәр, гадәт калыр, диләр бит, шәех хәзрәт. Минем телем, аллага шөкер, адәм балаларына бер дә алай зыян китермәде шикелле. Ә менә син, шәех, хөрмәткә ия кеше, дүрт хатының ташлап, Олуг Мөхәммәт кәрвансараен саклап ятасың.

— Ни бит, Нисбахеттин, җыенам дип әйтеп әйттем түгелме. Әйе, Нисбахеттин, куеп тор әле үпкәләреңне.

— Әйе, казый абзый, шәех бездә кунакта. Кунак барында кан түкермәскә куша иде кебек безнең болгар халкы,— диде, ниһаять, хан оныгы.

— Кол Гали, мин иртәгә булмаса, бер атнадан Хаҗга китәм. Һәм әйтер сүзем әйтеп каласым килә. Туган илгә кайчан кайтырмын, бер ходай белә, ә шәех бүген-иртәгә юлга чыгачак. Белеп китсен дим, казый Нисбах исән, белгән-күргәннәргә җиткерсен. Һәм кайтыр ул туган туфрагына, аллаһы тәгалә боерган итсә, кайтыр. Менә шунда шәех Игәнәй халыкны миңа каршы котыртмасын иде дим. Чит илдә без барыбыз да бертигездер, тик менә туган илдә әллә нигә дошманлашабыздыр, ходайның хикмәте, шуңа төшенеп житә алганым юк. Әйтик, Сәлим хан табиб вә галим Хәсәнне Олуг Мөхәммәткә җибәреп ни отты?... Үзе табибсез калды. Хәзер әнә муенына тавык тәпие таккан адәмне табиб итеп алган, ди.

— Киткән инде ул, Всеволод кенәз соратып алган,— диде хан сәүдәгәре Биккол.

— Тәмам каным кыздырдың бит әле син, Нисбахеттин. Әллә чынлап та җыенасы да китәсе инде?

— Дөрес кылырсың, шәех. Биредә дә мәхшәр. Ата — улны, ана — кызны белми. Чыңгыз ханның илчеләрен үтергәннән соң шаһ сараеның, гүя, асты-өскә килде. Кыскасы, монда безгә дә җай калмады, шәех. Ил тарафына без дә җыенырга булдык. Бу юлы хан Кол Гали дә кайтыр. Дөрес, хан аны колач җәеп каршы алмас. Әмма нишләмәк кирәк, монда безгә дә башка чара калмады бугай,— диде Биккол.— Сине чакыруым да бары тик шуның өчен иде, шәех. Миңа ишеттерделәр, Чыңгыз хан атлы илтабар Олуг Мөхәммәткә яу чыкмакчы икән. Өн биргәнгә, иншалла, им бирер әле. Аннары халык, туган якның чыпчыгы да сандугач булып сайрар, ди.

Әнә шулай шәех Игәнәй илгә кайтып китәргә ният итте. Ике ай дигәндә ул Болгар җиренә аяк басты. Бәхете аягына уралган икән, хатыннары өй-каралтыларын, мал-туарын саклаганнар, таратмаганнар. Дөрес, яшь хатыны киткән. Иллә йөгән кигереп атны гына тотып була. Хатын-кыз, ип-җайга ятучан булса да, тыйганны яратмый. Хәерле булсын. Ат белән хатын табылыр, туган илең югалтма, дигән борынгылар. Аннары мөридләре дә онытмаганнар икән, кайтып төшүе булды, ябырылып килделәр, бар булган илдәге яңалыкларны сөйләделәр. Ул хәзер Болгардагы күп нәрсәдән хәбәрдар иде.

Шәех Игәнәй угланнарга янә күз төшереп алды һәм янә арлы-бирле йөренергә кереште. Өргәнечтә яшәгән мәлдә ул бернәрсәгә инанды: Коръән шәрифне төрки телгә аударырга кирәк. Халык гарәп телен аңлап җиткерми, ятлап, сүзгә вә гарәп моңына мөкиббән китеп иман кыла. Ә кеше дингә үз ана теле аша инанырга тиеш.

Кайберәүләр моңа каршы төшәр, мәгәр шәех Игәнәй барыбер үз дигәненә ирешер — Коръән төрки телдә дөнья күрергә тиеш. Халык аны аңлар, изге китапның асыл хакыйкатенә үз ана теле аша төшенер. Тәрҗемә эшенә ул Хафизны да алыр. Хактыр, Коръәнне гарәп телендә уку үзе бер могҗизадыр — моңы, аһәңе сихерлидер. Әмма эш бер монда гына түгел, эш мәгънәдә. Әйе, каян килә соң ул гарәп телендәге адәм баласын сихерли алган моңлы тылсым? Бертапкыр ул кәтиб Хафизга әнә шул сорауны биргән иде, теге шәехне шаккатырып: «Шәех, дөнья кавемнәрен төрле халык төрлечә яулый. Гарәпләр моңлы вә сихри телләре белән адәми затларның күңелләрен яуласа, яваннар ихтыяри ихласлыклары белән, урыс корал белән яуларга тырыша».

— Шәех, шәех, сезне хан дәшә!— диде бусагабаш чыгып.

Шәех Игәнәй бу сүзләрне ишетүгә, дерт итеп китте һәм ни сәбәпледер як-ягына каранып алды. Янында угланнар юк иде. Шәех Игәнәй бераз каударланыбрак бусагабашка иярде.

— Әссаламегаләйкем, ханиям!— диде шәех Игәнәй бусаганы атлап керүгә.— Һәм ишек ягында торган түмәргә утырды да дога кылды, сакалын сыпырып алды.

— Вәгаләйкем әссәлам, шәех!— диде хан зәгыйфь кенә тавыш белән.

Ханбикә аңа ишарә белән генә хан янынарак күчеп утырырга кушты, шәех Игәнәй түргә узды, сәке янындагы түмәргә утырды, янә дога кылды.

— Йә!— диде хан башын күтәрми генә.— Йомышың әйт, шәех!

— Кыен булды миңа анда, хан. Чит җирләрдә солтан булганчы, илеңдә олтан булсаңчы икән.

— Менә-менә шуны әйттерәсем килгән иде дә минем синнән. Хәер, син барыбер качкын, шәех, качкын, илемне рисвай итеп киттең.

— Минем аллаһы тәгалә алдында гөнаһым юктыр, ханиям. Калган гомеремдә ил-халкыма игелек бирүне ниятләп кайттым, ханиям. Кичер мине, кичерә алсаң...

— Хуш, син дигәнчә булсын. Әнә ханбикә дә бик сорады: шәехне кичер, диде. Ишеткәнсеңдер, Ишкул шәех вафат, авыр туфрагы җиңел булсын, үлем казык башыннан йөрми, нишләмәк кирәк, менә мин дә урынга калдым бит әле. Кыскасы, кәтиб Хафиз, яз: шәех Ишкул урынын Игәнәй биләр. Мәхәллә картларына җиткер, вәзир. Вәзир Камай дим, Сөрәнчеләреңне бүген үк чыгарып җибәр. Ил — солтансыз, мәчет-мәхәллә имансыз булмас, диләр. Инде сине тыңлыйм, нинди яңалыклар алып кайттың?

— Олуг Мөхәммәт үзе белән сәүдә итәргә теләгән Чыңгыз хан атлы илтабарның илчеләрен үлтертә. Шуннан ике арада ызгыш китте, диләр. Әтрәр каласын яуларга җыена, диделәр. Ул ханның гаскәре яман көчле икән, саннары да бихисап. Унбиш яшьтән алып җитмеш яшькә кадәр барлык ир-ат яуга барырга тиешле.

— Ходавәндә, бу ни хәл тагын, ахырзаман киләдер, бер дә бүтән түгел. Ничек инде җитмеш яшьлек картларны атка атландырып сугыштырмак кирәк. Адәм баласы түгелдер, дию пәрие затыннандыр ул Чыңгыз хан дигәннәре. Йа Алла Мөхәммәдерәсүлулла! Минем Биккол нишләп ята анда? Ул яман хан, Әтрәргә килсә, Өргәнечне дә читләтеп узмас.

— Иншалла, Олуг Мөхәммәт шаһ туктатыр аны, туктатыр, ханбикә. Өргәнеч каласы мөселман дөньясында иң нык кирмәннәрнең берседер.

— Биккол сәүдәгәр, ханиям, оныгың Кол Гали белән юлга чыгабыз, дип калды.

— Ничек-ничек?!— дип урыныннан күтәрелә төште Сәлим хан.— Кол Гали оныгым да кайтамыни?! Кол Гали. Нинди кушамат тагын ул... Хан оныгы кол буламы?

— Аллаһы тәгалә алдында без барыбыз да колдыр, ханиям.

— Хуш-хуш. Бирсен ходай, бирсен, кайта күрсен. Шуны күрсәм, ханбикәм, үлсәм дә үкенмәс идем. Әллә нигә шул баладан бәхиллек аласым килә. Тик белмим, язганмыдыр, юкмыдыр. Танырлык та түгел инде?..

— Танырлык буламы, ханиям. Мин аны гелән танымадым. Сакаллы, мәһабәт сынлы, гакыллы, галим вә шагыйрь, шаһ мәдрәсәсендә мөгаллим икән.

— Йа Алла, Мөхәммәдерәсүлулла, сабый булып югалды, сакал җибәреп кайта. Акбикә киленне күрмәдеңме? Ул да андамы?

— Юк, ханиям, аларны күрмәдем. Казый Нисбах кына күземә чалынды. Халык ыру-ыру олаулар белән Сәкъсин каласына күчә, безнең якларга. Һаман да шул бер Чыңгыз хан явыннан куркалар.

— Олуг Мөхәммәт нә карый икән соң, дөньяда бер гаскәре, нигә үзе каршы чыкмый. Яуны яу туктатыр, диләр.

Сәлим хан шулай диде дә ыңгыраша башлады, эчен тотып йөзен чытты. Ханбикә барысына да чыгып китәргә ишарә ясады.

Ул арада Сәлим хан, ярга чыгарып ташланган балык кебек, авызын зур итеп ача-ача сулыш ала башлады, табиб аңа ярдәмгә ташланды, ханбикә исә йөгереп чыкты да шәехне чакырып алды. Ясин чыгу кирәк иде. Шәех ханның баш очына утырды, ясин укырга кереште. Нindidер

бер мәлдә Сәлим хан күзләрен ачты, йөзенә кеше төсе керде, ул мендәр астыннан кәгазь төргәге чыгарды һәм шаехкә сузды.

— Васыятемдер, шаех,— диде ул ишетелер-ишетелмәс кенә һәм шундук күзләрен йомды. Ләкин алай озак тыныч тора алмады. Янә йөзе күк-күмгәк булды, янә авыру тартышка башлады, янә табиб әле ханга канат белән йөз-битенә, ә кайчан иреннәренә зәм-зәм суы тигезеп алды, әле йөрәк тирәсен уды.

Әмма хан соңгы мәлләрен яшәгән, күрәсәң, күп тә үтми аякларын сузып җибәргәндәй итте, күзләрен зур ачып түшәмгә текәлде.

Зөбәрҗәт, тик бермәлгә генә тораташтай катып торды да, ир-канатының күкрәгенә капланып елап җибәрде.

## 12

Сәлим хан васыятен олуг мәҗлестә укыдылар. Аксакаллар янында аталарын күрми калган угланнар да бар иде. Васыятьне шаех Игәнәй укыды. Бөек Болгар иле ханы Сәлим тәхетне икенче угланы Илһамга васыять иткән иде. Васыятьне укыгач, мәҗлескә җыелган халык бер мәл тик утырды, һәркем үз уенда иде. Шуннан шаех Игәнәй торды да: «Фатиха бирик, җәмәгать, хан сүзе — аткан уктыр. Төрки Болгары тәхетенә мәрхүм ханның икенче угланы Илһам утыра. Игелек сиңа, углан. Авыр аягың җиңел булсын! Амин!»

Әнә шулай көтмәгәндә Сәлим ханның икенче угланы олуг хан булды һәм тәхеткә утырды. Илһам углан үзе моны көтмәгән иде бугай, бермәлгә каушый калды. Әйе, өмет иткән булса да, ул да хәтта атасы тәхетне өлкән угланы Хаҗига васыять иткәндер, дип уйлаган иде, шуның өчен каушавы, дулкынлануы йөзенә үк бәреп чыкты. Иллә тәхеткә таба ике-өч адым ясауга, тәүге каушавы үтте, башын күтәрә төшеп, түр якка узды, тәхеткә утырды, терсәкләрен җайлабрак терәккә куйды. Шуннан соң гына күтәрелеп мәҗлескә килгән аксакалларга, куштаннарга карады. Чынын гына әйткәндә, моңа ышануы кыен иде, вәзир вә аксакаллар түгел, бу хакта, тәхетне кемгә, кайсы угланы вә онысына васыять итүе турында хәтта ханбикә дә белмәгән иде, хәтта ханбикә Зөбәрҗәт тә тәхетне аталары өлкән угланы Хаҗига васыять иткән дип уйлаган иде. Ә ул, мәрхүм, әнә ничек хәл иткән. Ана кеше буларак аңа ике угланы да якын, бертигез иде. Ләкин баш бала дигән нәрсә бар бит!..

— Атаң соңгы сулышына кадәр Гали онытын көтте, балам. Аны исән диләр, хакмы шул?

— Миңа алтмыш яшь, аңа кырык тулып узгандыр инде, анам. Ул бала, исән-имин булса, бер кайтмаса, бер кайтыр, иншалла. Тик күңел әллә нигә ышанып җитми.

— Кайберәүләр кайткан дип тә сөйлиләр.

— Кеше ни сөйләмәс, гайбәткә гает укытмыйлар.

— Хат язырдай, хәбәр җибәрердәй итмәде шул атаң, балакай. Килен дә, углымны эзләргә киттем, дип юкка чыкты.

— Киленең Акбикә Бачман баһадирга тагылып китте, анам,— диде әмир Хаҗи кырысрак итеп.— Миңа ул хакта сөйләмәс идең, анам. Минем ишем бар, хатыным.

— Ягкуб бәк кызымы?.. Бик яшь түгелме соң?

— Тай түгел, биле сынмас, анам. Ул үзе риза булып килде.

— Йа алла, мөхәммәдерәсүлулла, балакай, исән-имин яши күрәңез, мин бик шат. Ир-ат өчен күңел тынычлыгы, ил тынычлыгы ул. Тәүге хатыныңа артык йомшак булдың шул, балакай...

— Ярый, анам, кешеләр игътибар итә. Бакчы әнә Илһамына, ни тамаша кукыраеп утыра.

— Тәхет ләүкә түгел, балакай, утырсын. Игелек бир энеңә. Изгелек илдә калыр, диләр.

— Игелекне изгелек кылып ала торганнар иде, анам. Хәер, мин разыймын, утыра бирсен. Тик миңа гына комачауламасын, минем хәятемә генә тыкшынмасын. Аның үз биләмәләре, минем үз биләмәләрем.

— Ул олуг хан, балакай.

— Олуглыкны акыл белән яулыйлар, анам. Утырып карасын, күз күрер. Олуг хан атына лаек икән, лаек, диярбез, юк икән, кичерә күрсен, алла тарафыннан алган тәхете түгел.

— Ачу — ачуга, үч — үчкә китерер, балакай. Игелек теләэ энеңә. Иңиңгә килсә генә тиң-тиңгә килер, диләр.

— Атам Болгарның уникенче ханы иде. Кырык елга якын тәхеттә утырды. Аның кебек Болгар тәхетендә озак утырган хан булмаган, анам. Инде атам вафаттыр. Өлкән угланына алтмыш тирәсе, бүген тәхеткә утырган олуг хан Илһам илледән өстә. Картая Болгар, анам. Кеше түгел, дәүләт тә картаюны яратмый, умыртка сөяге ката башлый.

— Сине Үлдәмир кенәзе белән бәхәскә кергәнсең икән, дип ишеттем, ярамас иде алай, балакай,— диде ханбикә Зөбәрҗәт.

— Ул кенәз минем сәүдәгәрләремне талады.

— Үзе түгелдер бит?

— Аның юлбасарлары, аның илендә. Болгарда сәүдәгәрләрне таламыйлар. Мөрем юлбасарлары. Мин моннан кайтам да...

— Урыска яу чабасыңмы?

— Урыска түгел, Мөрем юлбасарларына. Мөрем баһадиры оештырган эш, шымчыларым тәгаен ачыклады.

— Әйткәнемчә, үч-үчкә китермәсен тагын, балакай.

— Кайчак, анакай, үч алмау дошманга канат үстерә, үзен синнән өстен күрә башлый, әрсезләнә, талымсызлана. Явызлык елан кебек бит ул, коерыгын чапсаң башы кала, башын чапсаң коерыгы кала.

— Миннән фатиха юк, балакай. Әүвәл энең белән киңәшер идең. Киңәшле эш таркалмас, дигәннәр,— диде ханбикә Зөбәрҗәт һәм урынына барып утырды.

* * *

Әмир Хаҗи һәркөнне диярлек Ага-Базарга чыкты, халык вә сәүдәгәрләр арасында йөрде, халыкның ни сөйләгәненә колак салды. Халык телендә Илһам хан иде.

Мәйдан уртасындагы түмәргә мосафир менеп баскан. Кара сакаллы, киң маңгайлы, башында әрмән кәләпүше, яшел җиләне җилбәгәй киткән. Бу кем дип сорамады әмир Хаҗи, туктады, мосафирны тыңламакчы итте.

— Аллаһы тәгалә кешене нигә дип яраткан? Менә син, син әйт әле, ни өчен яраткан аллаһы тәгалә адәм баласын? — дип мөрәҗәгать итте мосафир күркәм йөзле, яман юан гәүдәле сәүдәгәргә. Сәүдәгәр каушый калды, тирә-ягына каранды, иңнәрен җыерды.

— Ашау-эчү өчен, хатын-кызны ярату өчен.

— Хайван да, эт тә ашый. Ә ул — адәм баласы.

— Хушлашу өчен, урман-болыннарның хозурлыгын күреп, шатлану өчен.

— Атлар-сыерлар да болында яшиләр, үлән ашыйлар, чәчкә арасында йоклыйлар.

— Бу кем? — дип сорады җансакчысыннан әмир Хаҗи.

— Берәү дә белми, әмирем. Беренче күрүем.

— Ни өчен ошбу дөньяда кеше яши, ни җитми аңа? — дип кабатлады мосафир.— Менә син, син бу юлы җавап бир. Ни өчен яши адәм баласы?

Бу юлы кечкенә гәүдәле, түбәтәй кигән, ертык сырмалы йөк ташучыга мөрәҗәгать итте. Теге тәмам ни әйтергә белми артка чигенгәндәй тәпенләде.

— Куй, куй, каян белим мин,— диде ул.

— Ә-ә,— диде мосафир ерактан ук берәүгә кычкырып.— Мал чалучы. Менә син әйт: ни өчен яши ошбу якты дөньяда адәм баласы?

— Аллаһы тәгалә аны адәм итеп яратканга, җан биргәнгә.

— Ә син ат-сыерларда җан юк дип беләсеңмени, чебен-черкинең йөрәге типми дип беләсеңмени? Аллаһы тәгалә аларны да җан иясе итеп яраткан.

— Алар... Халаяк, нәрсә кирәк моңа?! Кем син?! — дип кычкырырга тотынды мал суючы. Аның киндер алъяпкычында кан эзләре, йөзен куе сакал-мыек баскан, кызыл чырайлы, зур борынлы.

— Бик күп белсәң, үзең әйт! — дип кычкырды мал суючы.

— Тыңлагыз, җәмәгать, тыңлагыз. Аллаһы тәгалә кешене калалар салу, затлы әйберләр ясау өчен яраткан. Калаларын, ишек алларын гөлбакча итсен өчен, көттә биналар, алтышар манаралы мәчетләр, яшәү өчен уңай булган өйләр салу өчен яраткан. Әнә шуларны ясый алмаган, бары тик тамак өчен генә яшәгән җаннарны ул хайваннар дип әйткән. Алтын янсә асылташ ни ул? Җирдә аунаган җисем. Ә кеше аңардан таңкә ясаган, таштан төймәләр эшләгән. Тауларны җимереп, мәрмәр чыгарган, алардан ханнарга сарайлар торгызган. Кеше җансыз җисемне җанлы иткән. Шуңа кеше дип атала ул, бары тик шуңа!

— Хак әйтә,— диеште халык.

Әмма халыкның мосафирны күбесе аңламады, нәкъ менә аңламау аларда кызыксыну уятты, мосафирны ураткан бөҗра зурайганнан-зурая барды.

— Казан базарында да мондый акыл сатучылар бармы? — дип сорады җансакчысыннан әмир Хаҗи.

— Ил түрәсез булмаган кебек, базар кәмитсез булмый, әмир.

Әмир Хаҗи бер сүз дә әйтмәде. Аны биредә берәү дә танымый иде, ул һәрчак нинди дә булса һөнәр иясе сурәтенә кереп киенә белде, җансакчылары исә, гүяки, хезмәтчеләре иде.

— Ни өчен мин сездән болай дип сорадым?.. Инде җавабын тыңлагыз. Ата-бабалары, халкы ясаган затлы әйберләрне, мәһабәт биналарны саклый алганда гына кеше кеше булып кала. Калган очракта ул — хайван. Әйтик, кемдер килеп Болгар каласын җимерде, ди. Кем була ул безгә? Дошман. Чөнки ул безнең ата-бабаларыбызның истәлеген, ягъни алар төзегән калаларны, мәһабәт биналарны җимерә, яндыра, хатын-кызларыбызны әсир итеп алып китә. Без бабаларыбыз салган калаларны, яраткан сөекле хатын-кызларыбызны якларга ташланабыз. Кан коела. Яшәү белән үлем арасында көрәш башлана. Ләкин ни өчен тегеләр үлә дә, ни барәбәренә без үләбез. Үлем алдында барыбыз да бертигез ич! Алар безнең бабаларыбыз вә үзебез корганны җимерә, ә без аларны саклап калырга тырышабыз. Кайсысында моның күбрәк кешелек? Яуга килгәннәрдәме, үз байлыкларын саклаучылардамы? Үз истәлекләрен саклаучыларда, үз байлыкларын яклаучыларда. Чөнки берәүләре — җимерүчеләр, икенчеләре төзүчеләр. Берәүләре чәчәкләр үстерүчеләр, икенчеләре аларны таптаучылар. Кайсылары шуларның батыр була ала? Яклаучылармы, яулаучылармы? Яклаучылар. Чөнки яулаучы каһарманлык кыла алмый, чөнки ул кеше төзегән байлыкны җимерергә килгән, ә менә аны саклап калырга аңа каршы чыккан кеше — чын мәгънәсендә каһарман ул! Чөнки ул халык-ил байлыгын сакларга, Җәбраил фәрештә утыннан саклап алып калырга тырыша. Кайсын адәми зат итеп кабул итәр иде аллаһы тәгалә? Тегесен дә, монысын да. Әмма без сезнең белән бары тик үз илләрен, үз җирләрен, үз байлыкларын, үз хатын-кызларын якларга ташлаганнарны гына кеше дип әйтә алабыз. Бары тик аларның гына ит ашарга, чәчкәләр үстерергә, хатын-кызларны сөяргә хаклары бар. Димәк, кеше каһарманлык кылырга яратылган икән, халаяк! Онытмасагыз иде шул хакта! Мин күрәм, сезнең арада хатын-кызлар да бар. Үпкәли күрмәсеннәр иде миңа ул фәрештәләр. Чөнки ир-ат ул иң әүвәл

әнә гүзәл затларны дошман кулына бирмәс өчен көрәшергә, чын мәгънәсендә ир-ат булырга тиеш. Кем ул ир-ат? Сакал-мыек тагып йөргән өчен генә ходай тәгалә аңа бу исемне биргәнме? Юк! Сакал үстерү белән генә ир-ат түгел әле ул, хатын-кызны сөюче дә ир-ат түгел әле, ир-ат иң әүвәл күкрәге, йөрәге белән ил-халкын, анасын-сеңлесен, сөйгәнен якларга ташланучы кешедер. Ир-ат — ил тәрәге ул! Күптән түгел Мөрим юлбасарлары безнең сәүдәгәрләрне талады. Урыс кенәзе Юркәй бу хакта ишеткәч, шаркылдап көлгән генә. Юлбасарларга үлем!

— Бу кешенең кем икәнен белегез, булдыра алсагыз, миңа тотып китерегез! — диде җансакчыларына әмир Хаҗи.— Мәгәр әле түгел, кич белән, караңгы төшкәч.

Халык шаулый башлады, ул арада мосафир кай яккадыр шылды, әмма базардагы халык ул югалгач та бик озак кычкырышты, бәхәсләште.

Кайтыр юлда да, кайткач та, үз ягына кереп яткач та уйлаудан туктый алмады Хаҗи. Икенче көнне аңа бер уй килде: Ага-Базар халкын Казан базарына дәшәргә. Ул гынамы, Болгардагы оста һөнәрчеләрне котыртырга: күчеп килсеннәр Яңа Калага. Бар шартлар да булдырылачак.

Әнә шул уй белән ул Ага-Базарга чыкты. Бик озак кичәге кешене эзләде, ләкин таба алмады. Җансакчылары исә кичә көн буена эшләп тә аны таба алмый кайтканнар иде. Әмир Хаҗи җансакчыларын чакырып сөйләште һәм, билгесез кешене эзләп маташмагыз, диде. Чөнки аңа кайтып китәргә вакыт җиткән иде инде. Аталарының җидесен уздыргач, ул яшь ханга әйтте: «Иртәгә мин китәрмен инде, олуг хан».

Кече Чирмешән елгасына җитүгә, Илһам хан атын туктатты һәм кичүне чыгарга теләмәвен аңлатып, арттан килгән атларына тукгарга дип кулын күтәрде. Хәтта бу хәлне күрсә дә, әмир Хаҗи туктап тормады, аты белән суга кереп китте. Аңа җансакчылары иярде. Шунда гына, әмир Хаҗиның аты елгага керә башлагач кына яшь хан:

— Абам, әйтергә онытып торам, яңа елдан соң Шайтан каласын миңа бирерсең! — дип кычкырды. Ул моны тамак ертып кычкырып әйтмәде, әмма әмир Хаҗи ишетте, атын туктатты, каерылып артка карады.

— Шайтан каласын?! — дип сорады ул мыскыллы кабатлап.

— Әйе, абам, Шайтан каласын,— диде Илһам хан бер дә исе китмәгәндәй.

Әмир Хаҗи елганы кичеп баручы җансакчыларына күз ташлады, Илһам хан азатларына карап алды. Орышу килешмәс. Халык: «Аталарының җидесен уздырырга өлгермәделәр ике туган тәхет бүлешә башлады»,— дип уйларга мөмкин иде. Шул ук вакытта дәшми калу да ярамастай хәлдер. Бүген Шайтан каласын сорый, иртәгә Кашанны, аннары Җүкәтауны, ахыр килеп Тубылгытауны, тора-бара Казанга кул суза башлар бу яшь хан.

— Ашыкмасаң иде, олуг хан, мин әле үләргә җыенмыйм! — диде әмир Хаҗи һәм атын камчылый-камчылый елганы кичте, чаптырып китеп барды.

— Мин — хан, син — әмир, абам. Бирерсең, бирми хәлең юк! — дип үзалдына сөйләгәндәй калды Илһам хан.— Аннары, абам, син качкын Җик Мәргәнне баһадирың иткәнсең. Ә аны абасы Тубыкай эзли. Мин баһадирыңны да абасы кулына тапшырырмын. АннарыНазлыгөл белән Дәүранны Болгарга кайтарырмын. Казан каласына Булат угланымны утыртырмын. Болай килешмәсәң, гаскәр белән килермен. Тик анда инде берәүне дә кызганмам, чөнки очкан ук корбан сайламый, аткан ук үз корбанын үзе таба.

Илһам хан бик озак тузан туздырып Чирмешән елгасыннан, гомумән, башкаладан ерагая барган әмир Хаҗиның җайдакларына карап торды. Кичә аңа һич көтмәгәндә абасы әйтеп куйды: «Бәхет — тәхет түгел, тәхет — бәхет түгел»,— диде. Илһам хан, моңа аптырый калган

иде. Чынлап та, бәхетне тәхеткә салып үлчәмиләр. Гомумән, боларның икесен дә бизмәндә үлчәп булмый. Олуг Мөхәммәт илендә каты орышлар бара икән, шул тарафлардан Болгарга халык агыла. Каты яулар килгәндә төрки дөньясында була торган хәл. Тик Булат угланга дигән шаһ кызын атап җибәргән сәүдәгәр алып чыга алдымы икән? Алып чыккандыр, китүенә байтак бит инде. Булачак киленне Рабига атлы, диделәр. Исән-имин китереп җиткерсәләр, зурлап туй итәрбез, боерган булса, туйга Назлыгөл белән Дәүранны да дәштерермен, әмир Хаҗины да. Әйе, аны да чакырыр яшь хатыны белән. Туйга килгәч, бабалары Ибраһим хан кыпчак ханы Әюпне... Әйе, бер казанга ике тәкә башы сыймый, дигәннәр борынгылар, абам әмир Хаҗи белән яши алмам дигән фикергә килде 1219 елда Бөек Болгар тәхетенә утырган Илһам хан.

## 13

Олы мәҗлестән соң шуны аңлады ханбикә Зөбәрҗәт: кайбер аксакаллар, куштаннар, тарханнар угланы Илһам ханның алдына тезләнергә торалар. Күренеп тора, шәех Игәнәй дә хан аягына төшәргә тора. Килешми, килешми олы кешегә болай кылану. Илһам хан атасы Сәлим ханга йөз тоткан меңбашларны алыштырды, кайберләрен хәтта йөзбаш дәрәҗәсенә төшерде. Дөрес, бәкләргә тимәде. Аның каравы вәзир Камай ягына кырын карый башлады. Сарайда булган хәлләрне энә күзеннән үткәреп килгән ханбикә Зөбәрҗәт күрде — нәүбәт вәзир Камайга житте. Кемне вәзире итеп күрергә тели углан — ханбикә Зөбәрҗәт белми иде, әмма ханның үзеннән сорарга кыймый иде. Ә теге анасы белән ник бер киңәшсен! Әйтерсең, ул аның анасы да түгел иде. Әйе, әллә бар иде мәҗлестә ханбикә Зөбәрҗәт, әллә юк. Киңәш-сабак кылмый гына сарайда әллә ниткән үзгәрешләр кертүенә Илһам угланына үпкәсе булса да, ханбикә Зөбәрҗәт сабыр итәргә булды. Ләкин күрше Всеволод кенәздән баһадир Баянны сараена күпмедер алтын түләп кайтаруы хакында ишеткәч, түземе җуелды, мәҗлеснең икенче көнендә тәхет ягына кереп:

— Бу ни хәл инде, углан, нигә кирәк булды ул баһадир сиңа! Нинди кяфер баһадир җыю ди ул! Яу килгәндә бер тапкыр да кылычын кынысыннан чыгармаган баһадирны нигә дип сараеңа алырга булдың?! — дип, өнәмәвен белдерде.

— Атама ярагаң миңа да ярар, анам.

— Атаңа да ярамады ул. Качып китте. Ә син аны алтын түләп кайтарасың! Шымчы ул, икейөзле адәм!

— Хәтерем ялгышмаса, Баян баһадирны иленә атам илче итеп җибәргән иде кебек?

— Әйе, җибәрде. Чарасыздан җибәрде. Юркәй кенәзне тыныч кына кире җибәрә алмасмы дип. Ә ул, мөртәт, аңа барып елышты. Кем була инде ул шуннан соң?! Хөкем итәргә кирәк аны, хөкем!..

Шулай диде дә анасы пырлап чыгып китте.

Илһам хан тәхетеннән купты, арлы-бирле йөренергә тотынды.

Кышкы салкын көннәр, күлләр шартлый, агачлар чатнап ярыла, ә тәхет ягында җылы, тыныч, хәтта кәтиб Хафиз да юк, илаһи уйларга чумып утырганда гына әнисе керде дә бөтен уй-хисләрен астын-өскә китереп чыгып китте. Ни эше бар анасының хан эшендә?.. Житәрдер, атасын да бармак очында биетте. Мин — Бөек Болгарның олуг ханы. Минем үз башым бар. Иртәгә үк Всеволод кенәзгә илчеләр җибәрәм: язын Казанга яу килсен, мин ярдәмгә барырмын. Абам биләмәләре минем кул астыма күчәргә тиеш. Шунсыз дәүләт юк. Тик кемне Всеволод кенәзгә илче итеп җибәрергә? Әйе, Булат углан кулайрак булыр иде, әмма ул Җаек буенда кәләш көтеп ята. Тик кәләшен тиз генә көтеп ала алмас. Татарлар кулына эләккән, диделәр. Ә бәлкем әле бөтенләй дә килмәве бар. Эт авызыннан сөяк алып буламы — шаһ кызы Чыңгыз хан

угланнары кулына эләксә, кайсы гына баш тартыр икән! Олуг Мөхәммәт кызы Рабига ул угланга Хәрәземшаһ иле белән идарә итәргә мөмкинлек бирәчәк. Бөтенләй үк тиле беткән булмасалар, нәкъ шулай кылырлар да. Әллә соң илчеләр белән язга кадәр сабыр итәргәме? Әйе, сәүдәгәр кайтсын, хәлнең асылын белик, шуннан күз күрер.

Анам әче телләнә башлады. Шәех Игәнәй минем яклы. Шәех атамның исемен дә телгә алмый, гәрчә атам бахырны кичергән булса да. Анам исә шәехнең күптәнге дошманы. Ахыр чиктә анам аны кичерер кичерүен, әмма күңел түренә кереп калган җан үпкәсе тиз генә җуеламыни!

Иң мөһиме — аңа бүген сарай куштаннары арасында абруй казану. Урыс кенәзләре әнә, халкы канәгатьсезлек белдерә башласа, йә аларны күрше кенәзләргә каршы котырта («имеш, алар гына безне ярлы яшәргә дучар итүчеләр»), йә рухи атакайларны да җигеп, мөселманнарны, аларның илләрен, гореф-гадәтләрен кыргыйга санап, «бусурманны» үтергәч сәвап аласын искәртеп, яу чабарга өнди башлыйлар. Нигә, әйтик, аңа да шул ысулны кулланмаска? Шайтан каласы аныкы, Казан янә Болгарныкы. Шайтан каласында чуен-тимер житештерелә, Казан каласы дөнья базарына әверелеп килә. Әйе, сәбәбе дә бар. Ә Болгарда тимер җитми. Халык арасында да канәгатьсезлек туачак. Тимер кемдә? Әмир Хаҗида. Әмир Хаҗи тимерне иржәләргә, чирмешләргә сата, ә Болгар тимерчеләре тимергә интегә. Әйе, бар яктан да халыкта канәгатьсезлек тудырырга. Ахыр халыкның түземе җуелыр, шунда мәйданга Илһам ханның сөрәнчеләре чыгар — халыкны яуга өндәр. Әмир Хаҗи абасы аңа карусыз буйсынырга тиеш. Илһам ханга башка чара юктыр.

## 14

Яз көтмәгәндә килде. Башта өй кыекларыннан тамчылар тама башлады, көлтә-салам белән япкан түбәләрдән боз сөңгеләре сузылды. Шуннан ун-унбиш көн дә үтми, көтмәгәндә күңелләргә шом салып, кара болыт күренде һәм котны алып күк күкрәде. Картлар бу хәлне яманга юрады, бала-чага, яшь-җилбәзәк: «Яз килә! Яз килә!» — дип шатланып туймады. Чынлап та, сәер хәл булды. Тагын атна-ун көн дигәндә очар кошлар-каргалар, алар артыннан сыерчыклар күренде. Урамнарда кар бетте, кыр-басулар ала-тиләләнеп калды. Мондый иртә язга күнекмәгән мал-туар дымлы туфрак исен тансыклап, болын-тауларга тартылды.

Халык моны янә яманга юрады.

Юньлегә булмас бу, мондый язның булганы юк әле, диештеләр.

Кичкә таба ханбикә колагына янә бер яман хәбәр килеп ирешге. Угланы Илһам хан әмир Хаҗиның кече угланын сарай мәдрәсәсеннән куып җибәргән. Бусына һич тә ышанмалы түгел иде, әмма төн житүгә, бу хәл дә раслангач, ханбикә Зөбәрҗәт тәмам чарасыз калды. Ичмасам кинәшер кешесе дә юк, һич югы Назлыгөле янында булсын иде. Нигә, әйтик, ул каты маңгайга баласын алып анасы янына кунакка булса да килеп китмәскә икән! Абасы җибәрмиме? Аны тагын Мөрим каласына яу чапкан, юлбасар сәүдәгәрләрдән үч алган, дип сөйлиләр. Ни хәл бу, нигә орыш вә кан коюдан туймый бу ир-ат?!

Ир канаты Туйбикә, дип бик авызы суын корыта башлагач, Зөбәрҗәт ханбикә, оста Алпарны күрергә барган иде. Алпар тиңе булмаган оста, алтын куллы кеше иде. Ләкин хатын-кыз күзе төшүне, өзелепләр яратуны бер осталыкка гына кайтарып калдырсак, ханнарны, бәкләрне, баһадирларны, гади халыкны кем ни өчен яратырга тиеш булыр иде икән?

Ханбикә Зөбәрҗәт колчура Алпарны күрде дә хатын-кыз буларак бөтен җаны-тәне белән тойды: кысыр Туйбикә түгел, җиде иргә тап булып бала тапмаган хатын да авырга узачак бу ирдән, дигән нәтиҗә-

гә килде. Юк, ир-зат ут тиклем тамаша олпат гәүдәле, күзгә ташланырлык матур да түгел иде. Әмма бер хода белә: ни беләндер үзенә җәлеп итә. Күз-карашында идеме бу гайрәт, йөз-кыяфәтендә идеме — ханбикә Зөбәрҗәт төшенеп бетермәде. Ләкин бернәрсәгә ышанды: хатын-кыз яратырлык иде оста. Туйбикә ябышып ятырлык иде. Углы Дәүран да әнә атасына суеп каплагандай охшаган, гәрчә күз-кыяфәтендә Туйбикә чалымнары булса да. Назлыгөл аны үсмер чакта ук күрде. Күрде дә шашып гашыйк булды, күрәсең, балакай. Юкса, җәннәттә яшәгән җирдән, үзе өчен үлепләр торган ата-анасыннан качып, шушы ир-егеткә барып капланыр идеме? Тәгаен алласы, пәйгамбәре иткән ич балакай шул колчура останы. Ярый, хәерле булсын, бәхете вә язмышы шуннан булгандыр. Юл — адәмнән, язмыш — алладан, диләр бит.

Яз килеп, җир чишенеп яткан бер вакытта ханбикәгә бигрәк тә кыен иде. Табиб Антонийга булган рәнҗүсез үпкәсе, ахыр килеп угланы Илһам ханга булган җан ачуы аны тәмам гасага салды. Менә ничә көн инде ханбикә Зөбәрҗәтнең угланы Илһам белән сөйләшәсе килә, ә ул мең төрле сәбәп табып, анасын кабул итмәскә тырыша иде.

Тәхет ягына кәтиб Хафиз килеп керде һәм ханбикәне күреп сискәнеп китте.

— Саумысез, ханбикә! — диде ул бераз дәшми торгач.

— Аллага шөкер, кәтиб! Үт, уз.

— Ханбикә, рөхсәт итсәгез, мин иртәгә Ага-Базарга барып килер идем. Табиб Антоний кайткан, диделәр.

Нәкъ менә шул кеше турында уйланып утырганда аның Болгарга килеп төшүен ишеткәч, ханбикә Зөбәрҗәт, язмыш кошын тоткандай, торып басты. Ханбикәнең бит очлары алсуланып киткән, күзләрендә кызыксыну галәмәтләре уйный иде.

— Хафизҗан, мин дә барсам икән?

— Рәхим итә күрегез, ханбикә. Үзем кереп дәшәрмен.

— Йә, үзең генә чыгарсың инде, Хафизҗан. Күрсәң-нитсәң сәлам юлларсың үзенә. Онытмагандыр әле ханбикәне.

— Оныта буламы, ханбикә! — диде кәтиб Хафиз ашыга төшеп, ләкин икенче мәлдә инде оялып, күзләрен түбән төшерде.

— Онытмагандыр, — диде ханбикә Зөбәрҗәт. — Ничәмә ел сарайда табиб булып торды.

Ханбикә Зөбәрҗәт тагын нидер әйтергә теләгән иде, тыелып калды, кәлтәсеннән бер янчык акча чыгарып, кәтиб Хафизга ташлады.

— Мохтаҗлыгы булса, Антонийга бирерсең. Ханбикә бирде, дип әйтерсең.

* * *

Ниһаять, ханбикә Зөбәрҗәт тәхет ягында утыручы Илһам ханның ялгызак чагына туры килде. Илһам хан анасын күрде дә:

— Инәй, мин казнабаш Варданны көтә идем, — дигән булды, әмма аны Зөбәрҗәт ханбикә гүя ишетмәде дә, утырды, дога кылды.

— Инәй, — дип кабатлады Илһам хан. — Сиңа әйтәм.

— Абаң йортына яу чабарга җыенасың дип ишеттем, бәхиллегем юк, — диде ханбикә Зөбәрҗәт угланының күзенә карамый гына, башка берәүгә сөйләгән кебек.

— Абам миңа Шайтан каласын бирергә тиеш иде! Әмир Хаҗи казнага бер тиен ясак түләми, бәйсез рәвештә мөстәкыйль көн күтә. Ә миңа гаскәремне ишәйтергә кирәк.

— Һәм абаңа яу чабаргамы? Абаң җүләр түгел, моны кылмас. Ул синең яу чабарга җыенуыңны белмидер дип беләсеңме?!

— Белсен! Ул миңа — олуг ханга бер тиен дә ясак түләми!

— Абаңа яу чабырга жыенасың, миңа инәй дип дәшә башладың. Баккан анага әйтә торган исем ул, балакай, тапкан-баккан анаңа түгел. Ә мин сине үз күкрәгем имезеп үстердем...

— Кичер, анам. Тик нә кылыйм! Абам баш бирми. Болгардан Казан ягына һөнәрчеләр, чүлмәкчеләр, бай сәүдәгәрләр китә.

— Казан каласын атаң салдыра башлаган иде. Дәвам итүең хәерлегә кыл, балакай.

— Житәр, анам, «балакай да балакай». Мин сиңа үсмер бала түгел, олуг хан.

— Ил йөге синең иңеңдә, балакай,— диде ханбикә ирен чите белән генә көлемсерәп.— Казнабашыңны Яңа Калага җибәрмә, бәхиллегем юк.

Илһам хан тәхетеннән төште, арлы-бирле йөренергә кереште.

— Шундаен олы кешегә кул күтәрерләр дип уйлавыңмы?

— Абаң ясак түләмәс, ә казнабашыңны мыскыл итәрләр.

— Мин аны азатларым белән озаттырам.

— Азатларыңны әсир итәрләр. Ә казнабашыңны, сакалын кисеп, корсагы җиргә тигән бияга атландырып җибәрерләр. Кияүкала кенәзләре Әндрәй кенәзнең йомышчыларын мыскыл иткән кебек итсәләр?..

— Юкны сөйләмә әле, анам. Кяферләрме әллә без.

— Кеше ихтыярын кимсеткәндә иман тикшермиләр. Казнабашыңны кәҗәгә атландырып, сакалын кисеп җибәрсәләр, кая керер тишек тапмассың.

— Миңа акча җитми, миңа гаскәр җыярга кирәк. Акчасыз азат тотып буламы?!

— Нәфесеңне тый, уй-ниятеңне изгегә юнәлт. Абаңа баш иеп бар,— диде ханбикә кузгала башлап.

— Мин аңа баш иеп түгел, яу белән барачакмын, яу белән! Тик, анам, син генә миңа комачаулама. Аннары Мәрьямбикәне рәнҗетмә!

Мәрьямбикә исемен ишетүгә, ханбикә Зөбәрҗәт туктады, каерылып, угланына карады. Күзләре кысыла башлап, кашлары җимерелүдән үк күрде Илһам хан, Мәрьямбикә сүзе анасы йөрәгенә ук булып кадалды.

— Әстәгъфирулла, бу ни дигән сүз тагын?! Ни дип дәшәргә тиеш мин аңа — Марҗа дипме?!

— Мария аның исеме, Мария, анам!

— Аларда Мариядер, шикләнмим, әмма бездә Марҗа. Сиңа Мария, миңа Марҗабикә.

— Ул хәзер ханбикә, анам, ишетәсеңме, ханбикә!

— Алды бикәдер, шикләнмим, арты Марҗадыр ич! Инде ханбикә! Булмый торсын әле! Кем өйрәтте сиңа моны?!

— Гөнаһлы булма, анам. Берәү дә өйрәтмәде. Мин — хан, ә ул — ханбикә.

— Син олуг хан, ә ул бикә, бары тик бикә! — диде ханбикә Зөбәрҗәт һәм шундый иттереп угланына карады, тегe чактан гына тәпен-тәпен артка чигә башламады.— Җый мәҗлес. Бөтен аксакалларыңны дәштер. Алар хәл итсен!

Анасы пырлап чыгып киткәч, Илһам хан бусагабашны чакырып алды һәм казнабаш Варданны тизрәк табып китерергә кушты. Бусагабаш эленке-сәленке генә килеп керде, керде дә туктап калды, таптанып тора башлады.

— Кая казнабаш Вардан агай?!

— Килеп ята, хан иям.

— Ә синең нигә кәефең юк? Кем янына килеп кердең син, бозау ялаган нәмәстә. Бар, йомышчыларга әйт, берсекөнгә бөтен аксакалларны, куштаннарны мәҗлескә дәшсеннәр. Берәүсе дә килми калмасын.

— Баш өсте, шөһрәтлем.

Бусагабаш чыгып кына киткән иде, вәзир Камай килеп керде.

— Хәерле иртә, хан иям,— диде вәзир, мичкәдәй гәүдәсен тәхеткә таба тәгәрәтеп.
— Казнабаш Вардан агай кайда?
— Килеп ята,— диде вәзир Камай.
— Нәрсә сез, тутый кош сыман һаман бер сүзне кабатлыйсыз? Бусагабаш «килеп ята» диде, инде син.
— Минем сезгә әйтер сүзем бар, хан иям.
— Йә-йә,— диде Илһам хан, тәхеткә төшебрәк утырды.
— Мәрьямбикә белән очрашкан кенәз тиуны Митәй атлы булып чыкты, сәүдәгәр Яким Күчтемнең оныгы икән.
— Әнә ничек икән. Таймас баһадир кайда?
— Ул хәзер килер. Казнабаш Варданны Казанга җибәрү килешерме икән, хан иям?
— Минем казна буш, азатларыма түләргә акча житми. Казнабаш Вардан абама барсын, акча сорасын. Бирми икән, атам кала салырга биргән акчаны кайтарсын.
— Халык бай да бит ул, хан иям. Ничек кеше кулыннан тимәгән акчаны тартып алмак кирәк. Кара халык — кара сарык бит ул. Фетнә күтәрүе бар. Хәер, фетнәдән куркасы юк, азатлар да, корал да житәрлек. Мине, хан иям, Мәрьямбикә белән сөйләшеп торган кенәз тиуны борчый.
— Моннан соң, вәзирем, Мәрьямбикә синең өчен дә, башкалар өчен дә — ханбикә. Мин — олуг хан, ә ул ханбикә.
— Баш өсте, шөһрәтлем.
— Юркәй кенәздән хәбәр юкмы әле?
— Юк, хан иям, ул вәгъдәсендә торыр. Сабан туйлары үткәч тә кузгалырмын дигән иде. Үтә корылык анда, хан. Чәчкән икмәкләре чыкмаган, басуларында ком бураны. Юркәй кенәз Казанга ук килергә курка, Ибраһим каласын яуламакчы.
— Ул Ибраһим каласын, без Казанны кулга төшерербез.
— Бирсен ходай,— диде вәзир Камай баш иеп.
— Бусагабаш,— диде Илһам хан.— Ханбикәне дәш!
— Зөбәрҗәт анагызнымы, шөһрәтлем?
— Мәрьям ханбикәне! — дип җикерде Илһам хан.— Тиз бул, бер аягың монда, бер аягың анда булсын!
Күп тә үтми тәхет янына Мәрьям ханбикә килеп керде. Тыенкы, сак кына ир-канаты янына килде. Килде дә ханның күкрәгенә башын төртте.
— Ни булды? — дип сорады Илһам хан, вәзире белән бусагабашына чыгып китәргә дип ым кагып.
— Берни дә булмады, Илгамым, яраттым,— диде Мәрьям ханбикә.
— Сагындым, диген.
— Яраттым да, сагындым да,— диде Мәрьям ханбикә башын күтәреп, ир-канатының күзләренә карады.

## 15

Ханны күрергә килгән Яким Күчтемне Илһам хан бик озак кабул итми торды. Урыс кенәзенең бай сәүдәгәре Яким Күчтем мәрхүм Всеволод кенәздә илче вазифасын үтәгән иде, бүген әнә Юркәй кенәз тарафыннан оныгы Митәй белән Болгарга тиреләр алып килгән, диләр. Яңа сәүдәгәрлек эшенә керешкәнме? Ә бит Андрей кенәздән ук илче булып йөрер иде, гәрчә соңра кенәзне үтерүдә катнашса да, ни сәбәпледер мәрхүм Всеволод кенәз дә аны чит итмәде — янында калдырды. Ул гынамы, бүген әнә Юркәй кенәзгә дә хезмәт итә. Ләкин кем булып? Илче булып түгелдер, юкса хәбәр итәр иде. Димәк, Болгарга сәүдәгәр йөзендә генә килгән. Илчеме, сәүдәгәрме — Илһам хан аны кабул итәр. Хәтере ялгышмаса, атасы мәрхүм әйтер иде: Яким Күчтем беркайчан да Болгарга тикмәгә генә килмәс.

Илһам хан кәтиб Хафизга карап алды, Яким Күчтем кергәндә кәтибнең урынында булуы зарур иде. Ошбу кешене кәтиб Хафиз да бик әйбәт белә. Яким Күчтем турында аңа нәкъ менә кәтиб Хафиз: «Телгә җор, аяклы тарих»,— дип әйтеп әйткән иде.

Атасы Сәлим хан белән Яким Күчтем илче бик тату яшәгәннәр иде. Илченең ханнан, ханның илчедән сере булмады, ахрысы, чөнки яу-талаулар хакында Сәлим хан алдан ук белеп торыр иде. Ул да якын итеп кабул итсә кенәз илчесен?.. Бөтен уй-теләген, эч серен белсә?..

Илһам хан кенәз илчесен дәшәргә кушты.

Яким Күчтем бусага аша үтте, тәхеткә якынаюга баш иде, ханга сәлам юллады.

— Сәламең алдык, әйдә-әйдә, түрдән уз, утыр,— диде яшь хан һәм шуның белән илченең күңелен янә тынычландырып куйды.

— Олы Оя Всеволод угланы кенәз Юркәй сиңа сәлам юллады, олуг хан.

— Сәламен алдык, Якимкә агай,— диде Илһам хан елмая-елмая.

— Бездә корылык, хан. Базарларда кыйммәтчелек. Олуг кенәз борчуда — Болгардан икмәк килми башлады.

— Мөрем юлбасарларын абам акылга утыртты бугай инде. Юлбасарларын тыйсын кенәз, илче агай. Болгарда әнә бер сәүдәгәрне дә талаганнары юк. Саклыйбыз.

— Ачлык, олуг хан, ачлык шул көнгә калдырды. Ач кешенең ачуы яман булыр, диләр бит.

— Икенчедән күпме ясак җыя кенәз?

— Биш өлештән берен, олуг хан.

— Ә мин, кадерле илче, ун өлештән берен җыям. Салымны сала белмәсәң, чынлап та ач калуың бар. Аннары кенәз бик күп гаскәр тота, ә гаскәриләрне ашатырга кирәк, һәммәсенә акчалата бирергә.

— Киңәшең өчен, рәхмәт, олуг хан. Ләкин мин Владимир тәхетендә утырмыйм шул.

— Ачулану түгел бу, Якимкә агай, үртәү дә түгел, мин үзем дә салымны биш өлештән җыярга җыенам әле. Керем аз. Сәүдәгәрләр дә узынды, товарларын яшереп саталар, тарханнарым моңа күз йома, йә булмаса кул очына ала. Ә бу хәл казнага бик күп зыян китерә. Хакмы, түгелме, Якимгә агай, Казанга да күз салгансың икән дип ишеттем. Имеш, урам суктыра башлагансың, әмир Хаҗи ризалыгын биргән.

— Күз салырга картайдым инде мин, олуг хан. Казанга күз салучы энем Афанасий. Булдым мин ул калада. Урыны уңай, җиде су, җиде юл чатында дияргә була. Мәрхүм Сәлим ханның югалган кызы да анда икән. Кала остасында кияүдә. Малайкасы бар. Гүзәл, гүзәл, баласы белән күрдем дә үзен, Мәрьям анага охшатып куйдым. Ходай бирсә бирер икән гүзәллекне кешегә, атна-ун көн буена йөз-кыяфәте күз алдымнан китмәде. Кызлар чибәрлеге адәмнән, хатыннар гүзәллеге ходайдан, диләр бит, хак икән.

— Язмыш, язмыш, Якимкә агай. Әнә шулай колчурага кияүгә чыкты да куйды.

— Бер дә колчура катынына охшамаган ул, олуг хан. Бәхете йөзенә үк бәреп чыккан, шат, елмая. Ни, мин ул Дәүран останың атасы белән таныш идем бит. Владимиргә килеп чиркәү салып киткән иде. Алтын куллы иде мәрхүм, улы да әнә тиңе булмаган кала салып ята. Әмир Хаҗиның сарае бер дә олуг ханныкыннан ким түгел. Барысын да килештереп эшли. Кәрвансарай суктырырга сызымнарны аңа эшләргә бирдем әле.

— Йә, дөнья хәлләрен куеп торыйк, Якимкә агай. Үзең нинди йомыш белән килдең?

— Һэ, иң әүвәл, олуг хан, сиңа кенәз бүләкләрен тапшырырга рөхсәт ит.— Яким Күчтем бармак шартлатты, шундук ишек артында торган хезмәтчеләре кенәз бүләкләрен күтәреп, тәхет ягына кәрә башладылар.— Олуг кенәз бүләкләре, олуг хан.

Хан алдына кеш тиреләре, затлы туннар, ике-өч тәпән бал, күзне камаштырырлык ак киндер тукыма төргәкләре өелде.

— Рәхмәт, рәхмәт яусын, илче,— диде Илһам хан һәм ялчыларына бүләкләрне алып китәргә кушты.— Болгар да буш итмәс, илче. Иртәгә үк утыз-кырык көймә икмәк Владимиргә юл алыр.

— Аллаһы тәгалә ярлыка гына күрсен, олуг хан,— дип, илче Яким Кучтем ханга баш ия-ия чукынып алды.

Илһам хан әмере белән түр яктан агач тәпән белән кымыз күтәреп керделәр. Илче Якимгә кымызны хан үзе салып бирде.

— Синең белән күптән очрашасым килгән иде, Якимкә агай,— диде ул кечкенә өстәл янына кунагын дәшеп.— Син күпне күргән кеше. Болгарга юл башың Казаннан башлаган өчен дә үпкә тотмыйм. Житеш әйдә, эч һәм сөйлә. Шул гынамы йомышың, икмәк кирәк булдымы?..

— Күрше күршегә килми, йомышы төшми торамы, хан. Йомышсыз ялкау гына йөрер, ди. Илләә иң олы йомышым — икмәктер, хан. Икмәктә — хикмәт, диләрме әле.

— Икмәкне борын-борыннан болгарлар игә, аллага шөкер, ач калганыбыз булмады диярлек. Ләкин бүген аны куеп торыйк әле, Якимкә агай. Минем урысларның борыннан килгән кенәзләренең тормышын беләсем килә. Шул хакта сөйләсәң иде. Китан кенәздән башка минем бер кенәзне дә күргәнем булмады. Ә ул батыр кеше иде. Атасы Юркәй Долгарук та хикмәтле кенәз булган, диләр. Аны син дә күргәнсең икән. Нindиерәк кеше иде?..

— Минем атамның башына житүче кенәз шул инде, хан иям.

— Ничек-ничек булды ул хәл?— дип Илһам хан жайлабрак утырды, ишек төбендәге бусагабашка «чыгып кит» дип кул селтәде.

— Хикмәтле кеше булган, күрәсең. Әле дә күз алдымда тора. Олпат гәүдәле, ак чырайлы, зур булмаган күзле, кәкрәебрәк торган озын борынлы, кечкенә сакаллы кеше иде. Тавышы калын, карашы усал да, ягымлы да. Ягымлыга — ягымлы, усалга — усал булгандыр инде. Бермәлне дружинасы белән Мәскәүтин утарына килеп төште бу. Берәүләр: Кияүкалага яу барыр юлда күңел ачарга туктаган, диделәр, икенчеләре кенәз, анама гашыйк икән, диделәр. Минем анам жырга оста, ак йөзле, чибәр хатын иде. Бай нәселдән. Хак, атам да төшеп калганнардан түгел, бай сәүдәгәр, Болгардан күчеп килгән булган. Кенәз килгәч тә Черниговтагы туганына чаптарын жибәргән, имеш, Мәскәүтин урманнарына ауга килсен, имеш, урман мәчесен дә ала килсен. Чернигов кенәзе ауга өйрәтелгән урман мәчесе йөрткән. Аннары Юрий кенәзне хатын-кызга хирес икән, диделәр. Мин ул чакта моның ни икәнен белми идем әле, бу хакта атамның хезмәтчеләре сөйләр иде, ә мин инде үсмер егет, гелән колак салып йөрим. Чөнки күрәм, кенәз килеп төшүгә, атам кара коелып йөри башлады. Күрәсең, эче сизгәндер, бичараның. Кенәз табынны ишегалдына хәстәрләтте. Ни өчен дисәң, Чернигов кенәзе алып килгән урман мәчесе бу көнне пошн тоткан, аны тунап, таганга астылар, ут яктылар. Атам бал шәрабе китерде. Берме, икеме мичкә эчтеләр, хәтерләмим. Безгә ни, без шат. Ыгы-зыгы, шау-шу, жырлыйлар, биилар, көрәшәләр. Шактый салып алгач, Юрий Долгарук кенәз торды да анама таба китте, атам ялт итеп шул якка күз атып алды. Ошатмады кенәзнең кыланышын. Әмма тыймады, дәшмәде. Кенәз үзенә таба килә башлагач, анам йөзенә кызыл комач жәйгәндәй кызарынып китте, бит-йөзләре гөлт итеп чәчкә аткандай булды.

— Жырла әле, жырла әле, лебедушка-аккошым,— диде кенәз. Шулай диде дә анамның алдына тезләнде, күтәрелеп күзләренә карады. Анам ни кылырга белми аның чәченә кагылып алды.

— Жырлармын, сокол мой, жырлармын,— диде анам.

Атама анамның бу кыланышы килешмәде, күрәсең, шартлатып кулындагы камчы сабын сындырды, әмма миннән башка моңа хәтта игътибар итүче дә булмады, бары тик анам гына йөрәге белән иштепме.

— Жырлармын, кенәз, жырлармын, бар урныңа утыр,— диде.

Юрий кенәз урынына барып утырмады, шул жирдә терәлеп калды һәм анамның жырлавын көтә башлады. Шул мәлдә, башка чарасы калмагачтыр инде, анам жырлап жибәрде. Әй, ул моңны ишетсәң иде син, олуг хан, менә тәннәр чемер-чемер итә, билләһи, сандугачлар сайраудан туктагандыр. Сурәт шундыйрак: анам жырлый, ә кенәз Юрий анамның аяк астында диярге була. Барысы да мөккибән китеп, таң калып тынлый, кенәз дә ачкан авызын ябарга онытып, жырчының авызына төбәлгән, сихерләнгәнмени.

Жыр бетте. Анам тирән итеп сулыш алып куйды. Шул мәлдә кенәз сикереп торды да анамны кулына күтәреп, өйгә таба алып китте.

Атам Степан Кучтем төптән юан саллы гәүдәле кеше иде, ачуы килгәндә ике яшьлек үгезнең ике мөгезеннән алыр иде дә егар иде, әле дә көр вә усал тавыш белән:

— Кенәз, куй минем катынны, тимә аңа!—дип кычкырды һәм кынысыннан кылычын суырып чыгарды да кенәзгә таба китте. Юрий кенәз анамны төшермәде, борылды да атама карады һәм аның кулында ялангач кылыч күреп, әллә бер-бер жансакчысына ым какты, әллә тегесе ашыгыбрак атамны укка алды. Аркасына ук кадалуга, атам артына әйләнеп карасы итте, илла өлгерә алмады, йөзтүбән капланды. Анам чырыйлап кычкырып жибәрде, ыгы-зыгы купты. Юрий кенәз анамны жиргә куйды да кылычны чыгарып, атамны укка алган жансакчысына таба китте. Һәм ул аны урталай чапкан булыр иде, әллә каян атасы алдында Андрей кенәз пәйда булды, атасына аркылы төште. «Атам, койма кан, ул синең жаныңны саклап калды»,— диде. Юрий кенәз әле берсенә, әле икенчесенә күз ташлады да, кылычын кынысына тыгып, бераз башын иеп торды, аннары:

«Югал күз алдымнан, Петр!» — диде.

Бу фажига 1147 елның апрель аенда булды, ә ун елдан кияүкалалылар Юрий кенәзнең үзенең дә башына життеләр. Ләкин безнең ара моның белән генә бетмәде. Юрий кенәз, анам алдында гаебен жуярга теләпме, апабыз Улитаны өлкән улы Андрейга сорады. Анам каршы килмәде. Әнә шулай Андрей кенәз безнең жизнәй булып китте. Бераздан жизнәй кеше энем Афанасий белән мине сараена алды — киңәшчеләре итте.

— Нигә соң Андрей кенәзгә кул күтәрергә иттегез?

— Үчле идек без долгарукларга, нык үчле. Апам Улита да бер дә яратып тормады үзен, бәлкем шуңа аны аерып сезнең Болгардан өйләнгәндер. Улитаны кууы, Болгардан өйләнүе янә безнең йөрәккә ут өстәде. Һәм без аннан котылырга булдык. Хәер, Андрей кенәздән бик күпләр канәгать түгелләр иде инде: рухи атакайлар да, баярлар да, безнең турыда әйтеп тә торасы юк.

— Андрей кенәзне үлтерүдә Всеволод кенәз дә катнашкан, диләр, хакмы шул, Якимкә агай?

— Гөнаһлы буласым килми, үлтерүдә катнашмады, әмма котыртуы хак. Ә нигә, ул да Юрий Долгарук угланы, анасы башка булса да, кенәз булырга хакы бер. Тизрәк техеткә утырасы килгәндер.

— Хәтерем ялгышмаса, Андрей кенәз ислам динен кабул иткән өчен энең Апанайны зинданга утырта, иртән бөтен халык алдында дар агачына асмакчы була. Аны кем коткарды?

— Петр кияү. Ул коткарды. Бусурман динен кабул итүенә без дә риза түгел идек, әмма ул минем туганым. Владимирга килгән Афанасий турында кемдер кенәзгә житкергән. Имеш, сәүдәгәр Афанасий бусурман диненә күчкән, башына чалма киеп йөри. Андрей кенәзнең Кияүкалага яу барганнан соң күп югалтуларга дучар булып кайткан көннәре. Халык кенәзгә ачулы, баярлар турында әйтеп тә торасы юк. Андрей кенәз бу тамаша белән халыкның ачуын бусурманнарга күчермәкче иде, ягъни Болгарга. Әйе, энем Афанасий аша.

— Өлгерә алмый калдымы?

— Өлгерә алмый калды, хан иям.

— Апанай Болгарда. Башында чалма, шәех кызына өйләнде, никах укытты.

— Тиле ул, җүләр беткән. Җитмәсә мәчеткә намазга йөри икән.

— Бу начармы, Якимкә агай?

— Дин ташлау яман түгел, иман алыштыру яман, хан иям. Мин аңа ачуланмыйм. Яңадан Владимирга кайта алмас кына диюем. Безнең урыс халкы, гомумән, башка диндәге кешеләргә көн күрсәтми. Аллаһы тәгалә ярлыкасын. Ышану төрле булса да, Алла бер диләр бит.

— Хуш, Якимкә агай, хуш. Ә син җитешеп утыр әле. Балны да авыз ит, кымызны да читкә куйма. Кымыз канны кузгатыр, диләр.

Яким Күчтем барысыннан да җитешеп утырды, ул бернәрсәдән дә тартынмады. Гомумән, болгарларны бик яхшы белә иде ул, ошбу тырыш һәм сәүдә итәргә хирес булган халыкка ихтирамы зур иде. Кыскасы, күчтемлеләр Болгарда исемле, дәрәҗәле кешеләр иде. Яким Күчтемнең энесе Афанасий мөселман диненә күчкәч, шәех кызына өйләнеп, кала уртасына диярлек хан сараедай өй салдыргач, бу нәселгә болгарларның ихтирамы тагы да артты. Чөнки Болгарда Яким Күчтемнең бик күп товар ишләре бар иде. Әмма Яким Күчтем энесе Афанасий түгел, беркайчан да динен алыштырмас. Аның уенча, бүрекне алыштырырга мөмкин, ат-исемне, хатыннар турында әйтеп тә торасы юк, хәтта илне, ә менә табынган динне?! Юк, тагын бер тапкыр юк!

Кымыз эчә-эчә уйланып утыра торгач, Яким Күчтем Болгар ханы Илһамга кызы турында әйтергә булды. Дүнәшә атлы ул кызга Шайтан каласындагы чуен коючы оста өйләнгән икән, кенәз кушкан йомышны үтәү өчен җайлы юл үзе табылды түгелме соң?!

— Олуг хан,— диде Яким Күчтем бик озак уйлана торгач.— Заманында мин бик зур бер яманлык кылдым: үз баламны товар ишем Әхмәткә китереп бирдем. Асрау хатын тапкан балам иде. Китереп бирергә мәҗбүр булдым. Бер яктан хатынны кияүгә биргәннән соң үги атасы баланы кыерсыта башлады, икенче яктан үз хатыным тинтерәтте. Имеш, асравыңа сөйрәлеп йөри-йөри бала таптырдың да, уфтанасын да уфтанасың. Кыл бер-бер хәл үзе белән, юкса көннәрдән бер көнне ул бала суга батып үләр, диде. Ничарадан бичара кылдым бу яман эшне, олуг хан. Хәзер әнә шул баланы күрәсем килә. Җан тартмаса да кан тартыр, диләрме әле? Инде төшләремә керә башлады сабый.

— Шайтан каласына керергә ярамастыр, Якимкә агай.

— Ярлык бирсәң ярар, олуг хан. Бала бит.

— Шайтан каласына керергә ярлык,— диде Илһам хан һәм бертын уйланып торды.— Кала, беләсеңдер, Якимкә агай, әмир Хаҗи кулында. Илләә ниятең явызлыкта булмаса, бирербез аны, нигә бирмәскә...

— Аллам сакласын, олуг хан. Нинди яманлык булсын, ди?! Болгарлыларның күчтемлеләргә рәнҗегәннәре булмаган иде кебек, иншалла, моннан соң да булмас.

— Мин барысыннан да хәбәрдар, Якимкә агай. Мәрьям ханбикә миңа барысын да сөйләп тора. Тиун Митәйне икенче көнне үк Үлдәмиргә кайтарып җибәрүеңне дә беләм.

— Буталып йөрмәсен дидем. Сәүдәгәр түгел ул. Мәрьям ханбикә туганнары турында сорашкан. Бары тик.

— Ул миңа барысын да сөйләде, Якимкә агай.

— Син хаклы, хан, хатын-кызга ышану кирәктер. Кайбер ир-ат ялгыша, хатын-кызга ил-җирен алыштыру берни тормый, дип бара, ялгышадыр ул. Андрей кенәзнең кенәгинәсе Екатерина ирен үлтерергә җыенуыбыз турында һични белми кала. Белгән булса, безгә яман булган булыр иде. Ә кайберәүләр белгән дип баралар. Хак анысы, кенәгинә, минем кебек үк, Болгарга яу чабуга һәрчак каршы булды. Эш талашуга кадәр җитәр иде. Болгарга юнәлгән соңгы яуга Андрей кенәзнең катнашмавы да хатыны үтенечен җиргә салып таптамаудан иде. Кенәзнең бу

кыланышын рухи атакайлар, баярлар бер дә ошатмады, халыкка: «Кенәзне үлтерергә хатыны котыртты»,— дигән гайбәт тараттылар. Шушы хәлдән соң бичара кенәгинә, кече угланы Юрийны алып, Сәкъсин каласына китәргә мәҗбүр булды. Мин моны бер дә хупламадым, хан. Әмма нишләмәк кирәк, башны ташка орып булмый, безнең христиан халкы башка диндәге кешене эттән дә яман күрә.

— Миңа бу хәлләр таныш, Якимкә агай. Хуш, сиңа ярлык булыр,— диде Илһам хан тора башлап. Яким Күчтем дә күтәрелде һәм барысы өчен дә рәхмәт әйтеп, тәхет ягыннан чыгып китте.

## 16

Кунак өенә кайткач, Яким Күчтем ашыкмый гына юынды, ашадыэчте дә мендәр-түшәкләр җәйгән сәкегә кырын төште. Хак анысы, ул манарага кергән кешеләрне икенче көнне елга буеннан табып алгалаганнар. Хәрәземшаһ илчесе Садак та Шайтан манарасына кереп һәлак була, аны да шул язмыш көтсә?.. Чынлап та, Шайтан бармы ул манарада, әллә болгарлар бер-бер хәйлә корганнармы?.. Әйе, чуен коюның серен башка халыкларга бирмәс өчен корылган хәйләдер. Яким Күчтем анда керер. Үзе белән Тимушаны да алыр. Хезмәтчеләрен үзе белән алмас, йөрмәсеннәр комачаулап. Тәвәккәл — таш ярыр, дигәннәр.

Икенче көнне таң беленер-беленмәс Яким Күчтем юл чыкты. Аты җилле генә юыртып бара, Тимуша кала төшебрәк теркелти. Ул арада кояш чыкты, ниндидер инеш буена туктап ял итеп алдылар, атларны эчереп, утларга җибәргән Тимуша иясе янына килеп ятты.

— Ни кирәк безгә анда, ул манарада, Яким Степанович? — диде ул теш арасындагы үләнне кимерә-кимерә.— Анда кергән кешене елга буеннан табып алалар, ди.

— Син каян беләсең?

— Мин монда үскән кеше бит, Яким Степанович. Атам тимерче Әхмәт алачыгында эшләгән иде. Син дә минем кебек бөкерең чыгарырсың, дип, атам мине бер Владимир сәүдәгәренә ияртеп җибәрде. Шуннан әнә сиңа тап булдым.

Яким Күчтем терсәгенә таянып тора иде, торып ук утырды.

— Күр әле моны, нигә аны әллә кайчан шулай дип әйтмисең. Минем анда кызым тора, тимерче Әхмәт угланында кияүдә — Дүнәшәм.

— Үз кызыңмы?! — дип тәмам аптырый калды Тимуша.

— Үз кызым булмый. Анастасья тапкан иде. Соңыннан ул ат караучыга кияүгә чыкты — Даниилга. Ә ул, тиле беткән, эшне сизеп кыз баланы күралмас булды. «Өч айлык бала буламыни?» — дип Анастасьяны кыйнаштыра башлады. Шуннан мин аны бире алып килдем. Әнә нишләтә адәм баласын язмыш дигән нәрсә, Тимуша.

— Кызыңны алып китәргә исәбең юктыр бит, Яким Степанович?

— Кем бирсен аны миңа. Әйтәм бит, кияүдә, дип. Мин үзем бу халыкны яратам, Тимуша. Безгә алар белән сәүдә итә-итә тату гына яшәргә иде дә бит, иманнар башка,— диде Яким Күчтем.

— Афанасий энең әнә чалма киеп, мәчеткә йөри икән.

— Йөри, кеше ат түгел, авызлыклап булмый. Ә мин аны авызлыкларга да теләмим. Җаны теләгән — җылан ите ашаган. Аңа яхшы, миңа да начар түгел. Без хәзер энем Афанасий белән ике тау кебек, бер-беребез янына күчә дә алмыйбыз, бер-беребездән китә дә алмыйбыз. Болгардагы бөтен сәүдә эшләрен ул алып бара, ә Владимирдагы эшләрне мин.

— Ә мин сине, Яким Степанович, башка йомыш белән йөрисең дип беләм.

— Нинди йомыш тагын?!

— Һы, яшергән була тагын. Чуен кою серен белергә кирәк сиңа, Яким Степанович, бернинди дә Дүнәшкә кирәкми.

— Кит, дивана, юкны сөйләп торма, кеше ишетүе бар! — диде Яким Кучтем һәм сикереп торды да атына таба китте.
— Танымас та әле ул сине, Яким Степанович! — дип кычкырып калды Тимуша һәм эленке-салынкы гына ул да атына таба кузгалды.
Яким Кучтем юл буена җансакчысы Тимушага дәшмәде, теге дә иясенә арттырып җибәрүен аңлапмы, сөйләшмибаруны кулайрак күрде бугай. Кирәкмәгән олпат гәүдәле, мичкәдән чыккандай калын тавышлы Тимуша кушканны һәрчак тыңлады, аны карусыз саклады, аз сөйләште. Бу адәмгә күп кирәкми, тамагы тук, өсте бөтен булса җитә, дип уйлый иде Яким Кучтем, ә ул әнә нинди икән, кенәз белән күзгә-күз карашып сөйләшкән хикмәтне белә. Ә бит илдән киткәндә генә шушы тилегә Анфиса атлы хезмәтче кызын бирергә иткән иде. Хәзер ни уйлый икән?..
Яким Кучтем хәтәр уйларын куу өченме, күк йөзенә күз төшереп алды. Чалт аяз көн иде. Көз. Үләннәр саргая башлаган, әмма инеш буйларында ямь-яшел курпы тора иде әле.
— Яким агай, чуен коючы янына Шайтан манарасы аша гына узып була, диләр. Халык сөйләгән хак булса, нишләрбез?
— Керербез, Тимуша, керербез. Бернинди дә Шайтан юк анда, барысы да уйдырма.
— Уйдырма түгелдер, Яким Степанович. Уйдырма булса бөтен кеше шул хакта ипи тотып сөйләмәс иде.
— Сиңа кем әйтте ул турыда?
— Хан ясавылы әйтте. Анда кергән кеше кире әйләнеп чыкмый, йә бахырны елга буеннан табып алалар, йә судан калыккач. Шайтан каласы әмир Хаҗи кулында, Яким Степанович. Хан ярлыгы белән безне анда кертмәсләр.
— Ә син каян беләсең бу хакта, дивана баш?
— Мин бу якта үскән кеше бит, Яким Степанович. Миңа монда барысы да таныш,— диде Тимуша итек кунычына камчысы белән суга-суга.
— Нинди юллар белән Владимирга килеп эләктең соң?
— Баян баһадир дружинасында идем. Аның белән киттем һәм әнә сиңа тап булдым. Әмир Хаҗины азатларына әйбәт түли, диләр.
— Мин сиңа аз түлимме?
— Аз түләмисең, Яким Степанович, аз түләмисең. Ләкин минем монда туган ягым. Таныш инешне узгач, күңелләр әллә нишләп китте. Балачакларыма әйләнеп кайткан кебек булдым.
— Тимуша, Тимуша, кемнәр алар, безне куа киләләр түгелме! — диде куркынып Яким Кучтем, артларыннан килүче азатларны күреп.
— Хан багучылары,— диде Тимуша бер дә исе китмәгәндәй.
— Ни калган аларга монда?.. Безгә таба киләләр. Йа ходаа, үзең сакла,— диде Яким Кучтем һәм тиз-тиз генә чукынып алды.
Ул арада ханның ертавыл азатлары аларны куып та җиттеләр. Очлымына ике кауриый куйган йөзбаш аларның алдына чыкты, туктарга боерды.
Яким Кучтем аңа хан ярлыгын чыгарып күрсәтте.
— Барыбер сабыр итегез, хан үзе килә,— диде йөзбаш, ярлыкка исе китмәгәндәй йөзен читкә борды.
Ул арада тузан туздырып, хан һәм аның җансакчылары килеп туктадылар.
— Олуг хан, үзегез ярлык бирдегез, үзегез туктатасыз,— дип, Яким Кучтем Илһам ханга үпкәсен белдергәндәй итте.
Илһам хан тимер-күк туры айгырда, йөгән-өзәңге, иярләренә кадәр алтын-көмештән. Ханның очлым башында дүрт кауриый җилферди, янында баһадиры, баһадиры башындагы очлымда өч кауриый. Хан җиләне алтын җепләр белән тукылган, кеш тиресе белән каелган, баһадир өстендә көмеш белән тукылган җилән. Аякларында болгари итекләр.

— Ярлыкны бирдем, Яким агай, үзем пошаманга калдым. Беләсең булса кирәк, Шайтан каласы абам әмир Хаҗи кулында. Аның, беләсеңдер, талканы коры. Әйе, кертмәүләре бар, дип уйладым да менә үзем куа чыктым. Аллага шөкер життек. Калага мин сине, Якимкә агай, үзем кертеп җибәрермен, йә үзем белән алып керермен. Кыскасы, мин каланы үз кулыма төшерергә килдем, Якимкә агай.

— Бирсен ходай, бирсен ходай,— диде Яким Күчтем ашыгыбрак һәм, хан шаяртмыймы дип, як-ягына карап алды.

— Мин әмир Хаҗиның мөстәкыйльлегенә чик куярга булдым, Якимкә агай. Урыс белән сәүдә итү өчен миңа чуен кирәк. Чуен ул каты корыч. Корычтан бөтен коралны да ясап була. Казанны да үземнеке итәрмен дә Юркәй кенәз белән бабаларыбызча солых төзермен.

— Йа аллам, бирсен ходай, бирә күрсен,— диде Яким Күчтем.

— Йә, кузгалыйк. Кичкә кадәр кала минем кулда булырга тиеш.

Хан атын калага таба борган гына иде, кала ягыннан атта чабып килүче берәүне күреп, туктап калдылар. Илһам хан жансакчыларына чаптарны камап алырга дип боерды. Килеп житәр-житмәс чаптар ханны таныды булса кирәк, атын кире бормак итте, әмма аңа качарга бирмәделәр, йөгәненнән эләктереп хан янына китерделәр.

— Син кем, кем җибәрде?— дип сорады Илһам хан төксе итеп.

— Унбаш Чупай булам, олуг хан.

— Бәең, бәең кемдә?

— Бәем меңбаш Туранда, олуг хан. Кемнәр икән дип белеп кенә килермен дигән идем,— диде унбаш Чупай һәм Тимушкага карап, ияк каккандай итте. Бу хәлгә барысыннан да бигрәк Яким Күчтем аптырый калды. Ләкин ияк кагучыларны хан да күргән икән.

— Танышлармы әллә?

— Баян баһадирда хезмәт иткән идек,— диде унбаш Чупай.

— Безнең урыс ул, биредә туып-үскән кеше. Хәлләр ничек, Тимуша?

— Ару болай,— дигән булды Тимуша теләр-теләмәс кенә. Ахыр сындырылып атыннан төште, Чупайны килеп кочаклады.

— Исәнме-саумы, Чупайжан. Син һаман монда икәнсең, мин янә Яким Степановичка хезмәт итәм, жансакчысы итеп алды.

— Унбашка коралларын кайтарыгыз!— дип боерды хан.

— Рәхмәт, олуг хан, игелегегезне онытмам,— дип бер аягы белән җиргә тезләнде унбаш Чупай.

— Онытмасаң менә нәрсә, унбаш. Хәзер үк атыңа атлан һәм меңбаш Туранга элдерт. Әйт: капкаларны ачып, асма күперне төшереп торсын— олуг хан килә диген.

— Баш өстем, олуг хан.

Шулай диде дә унбаш Чупай коралларын киеп, сикереп атына атланды һәм калага таба чапты. Илһам хан барысына да калага таба кузгалырга боерды, ләкин берара киткәч, баһадирына калырга кушты, үзе белән жансакчыларын гына алды.

— Калада әмир Хаҗи булса?— дип сорады илче Яким Күчтем.

— Булса нә кыласың, Якимкә агай. Орышырга туры килер. Әмма Шайтан каласын мин барыбер үземнеке итәрмен.

— Гаскәреңне дә алырга иде, хан иям. Туган туганның башын ашаган, диләр.

— Якимкә агай, сездә шулай диләрдер дә, бездә алай түгел, туган туганның, хан ханның башын ашар, диләр.

Шайтан каласы кирмәненең асма күпере төшерелеп, капкалары ачылып куелган иде. Илһам ханның жансакчылары, илче Яким Күчтем җилле генә юырттырып, килгән жайдан кирмән эченә керделәр. Илһам хан эчкә керүгә, атын туктатты, капка сакчысыннан:

— Әмир Хаҗи мондамы?— дип сорады.

— Юк, олуг хан, әмир Хаҗи Кашанда!— диде кычкырыбрак сакчы.

— Туран меңбаш кайда?

— Әнә ул, килә! — диде сакчы һәм тураебрак басты, сөнгесен кысыбрак тотты.

Ул арада меңбаш Туран килеп житте, баш иеп кенә Илһам хан белән һәм илче Яким Күчтем белән исәнләште.

— Меңбаш Туран, безгә Шайтан манарасына керергә кирәк булыр,— диде Илһам хан атыннан төшә-төшә.— Кем алып керер икән?

— Үзегез керсәгез генә инде, олуг хан. Мин анда керергә батырчылык итмим.

— Якшы,— диде Илһам хан, Яким Күчтемгә күз төшереп алды.— Без монда кунарбыз, аннары күз күрер.

— Рәхим итегез, олуг хан. Кәрвансарай өе буш, урын житәрлек.

Илһам хан ат тезгенен жансакчысына ташлады да кәрвансарай кунакханәсенә таба китте. Туран меңбаш аңа иярде.

— Әйт әле, меңбаш Туран, чуен коючылар янына ничек кереп була?

— Шайтан манарасы аша гына, олуг хан.

Илһам хан биек манараны күздән кичерде, авыз чите белән генә елмаеп куйды.

— Шунда керергә куркамы халык?

— Курка, олуг хан.

— Ә синең кергәнең бармы?

— Аллам сакласын, олуг хан. Минем башыма тай типмәгән.

— Ә чуен коючылар каян йөри?

— Бер хода беләдер, олуг хан. Мин монда чуен коючыларны түгел, кирмәнне саклыйм, олуг хан,— диде меңбаш Туран.

Илһам ханны илче Яким Күчтем куып житте.

— Манарага кергән бер кешене Шайтан ала, диләр икән бит, ханиям,— диде ул кабаланыбрак һәм каушабрак. Илченең йөзендә чынлап та курку күреп, Илһам хан аның жилкәсенә кулын куйды.

— Ялган, барысы да ялган. Менә иртәгә без анда икәү керербез.

— Йа хода, хан иям, мин Тимушкамнан башка беркая да кермим. Ат башы хәтле бүләк вәгъдә итсәләр дә.

— Сиңа ат башы хәтле алтын кирәкми, Якимкә агай, сиңа чуен коючыларның алачыкларын күрү кирәк. Миңа да кирәк ул чуен коючыларны күрү. Абам әмир Хажи миннән барысын да ишерә. Мин олуг хан, мин атам түгел, аңа башбаштакланырга бирмәм!

— Олуг хан,— диде меңбаш Туран.— Алай да мин анда сезгә керергә киңәш итмәс идем. Анда кергән кеше кире чыкмый.

— Уйдырма, пәри яшиме әллә анда, Шайтан үземе?!

— Кем яшәгәнен бер хода беләдер, олуг хан, әмма кергән кешенең кире әйләнеп чыкканын күргәнем булмады. Аларның күбесен елга буеннан табып алдык.

Илһам хан күгелжем кара төстәге манарага янә күз ташлап алды, төсе белән үк шом салып тора иде манара. Ханның ни турында уйлаганын белгәндәй, илче Яким Күчтем:

— Биек, төссез, шыксыз,— диде.

— Манараны тергезүче оста Дәүран, шулаймы, меңбаш Туран? — диде Илһам хан.— Хәзер ул Казан каласын күтәрә, мәһабәт биналар сала. Манараны тергезгәч, ул аның серен дә беләдер, меңбаш, ә? — дип сорады аңа карамый гына Илһам хан.

— Беләдер, олуг хан. Ләкин оста Дәүранның биргә килмәвенә шактый инде.

— Аның каравы чуен коючы оста Бәкернең киткәне дә юк, шулаймы? Яшь хатыны белән монда яши, шулаймы? Ул кай тарафта тора инде?

— Кашан каласында, олуг хан. Хатыны да Кашанда яши. Дөрес, монда да өйләре бар. Мин аның тәгаен генә кая торганын белмим, олуг хан. Серле кеше ул.

— Чуен коючылар янына каян керә?

— Анысын күргәнем булмады, олуг хан. Әйтәм бит, сер тубалы ул, әле монда, әле анда. Ниндидер бер яван белән әллә ниләр корып яталар шунда.

— Әмир Хаҗи да алар янында булгалыймы?

— Еш була, кайчак көннәр буена югала.

— Иртәгә мин синең белән чуен коючылар янына керермен, меңбаш. Саклык йөзеннән ике җансакчым, илчене һәм аның Тимушкасын алырбыз.

— Мин анда кермәмдер, олуг хан.

— Нигә?

— Яшисем килә, олуг хан.

— Минем яшисем килмиме?

— Мин алай дип әйтмәдем кебек, олуг хан. Минем яшисем килә, ә анда кергән кешенең кире чыкканы булмады әле.

— Сәбәбе нидә инде, меңбаш Туран?

— Бер хода беләдер, олуг хан.

— Ярый, меңбаш, алып бар безне кунак өенә. Иртә кичтән хәерлерәк, күз күрер,— диде Илһам хан.

— Мин кызымны күрә алырмынмы икән соң, хан иям?

— Меңбаш Туран,— диде бераз кинаяләп Илһам хан.— Үлдәмирдән килгән илченең кызын күрәсе килә, ә аның кызы оста Бәкердә кияүдә. Иблис аларны да саклыймы, әллә алар да иблискә әверелделәрме?

— Олуг хан,— диде пышылдабрак меңбаш Туран.— Кирәкмәс иде алай, көлмәгез, зинһар, Шайтанның ишетүе бар. Аннан кычкырып көлгән кешеләр дә биредән югалгалады, мәетләрен дә тапмадык.

— Һы,— диде Илһам хан чынлап та бераз шомлана калып.— Хәтерем ялгышмаса, Шайтан манарасына атам мәрхүм кергән иде бугай бит. Исән-имин калага әйләнеп кайтты, алай-болай бер дә зарланмаган кебек иде.

— Булды андый хәл, олуг хан. Керде хан. Ләкин ничек котылганын үзе генә белгәндер, берәүгә дә сөйләмәде, сезгә дә әйтмәгән әнә. Мин анда үзем дә булдым, олуг хан, ләкин манарага кермәдем. Атаң мәрхүм, урынысы оҗмахта булгыры, бик күп кешенең башына җитте ул көнне, бер гөнаһсыз кешеләрне кылычтан уздырды. Абаң әмир Хаҗи булышты, атаңыз манарадан чыга алмаган булыр иде.

— Хан, кабат әйтәм, мин анда Тимушкасыз кермим, тәрем белән ант итәм.

— Тимушканы алдан кертербез, илче Яким агай, аның артыннан син керерсең.

— Йа хода, йа хода, сакла, ходаем, бахырың,— дип илче Яким Күчтем уңлы-суллы чукынырга тотынды, җансакчысы Тимушка аңа көлемсерәп карап тора иде.

## 17

Илһам хан белем-сабакны кәтиб Хафиздан алды. Чорына күрә белекле кеше буларак, мөгаллиме аңа убырлы карчыкларга, сихерчеләргә, йорт ияләренә, төрле имеш-мимешләргә ышанмагыз, барысы да Аллаһы Тәгалә кулында, дип әйтер иде. Чөнки алар юктыр, дияр иде. Әмма кешенең күз буу сәләтенә мөгаллим үзе дә ышаныр һәм укучыларына да ышанырга кушар иде. Шәкертләрен ул үзе моңа ышандырды, берничә балага күз буып күрсәтте. Кайсына алма дип суган ашатты, кайсын дивар буена башын аска куеп бастырды. Соңыннан бу әкәмәттә катнашкан шәкертләрдән сорашкач, шуны аңлаган иде Илһам хан: мөгаллимнәре ошбу кодрәтне Аллаһы Тәгаләнең үзеннән ала, Мөхәммәт пәйгамбәр кебек. Аның да бит янына еш кына Җәбраил фәрештә килә торган булган һәм Мөхәммәткә киңәш-сабаклар биргән, хәтта укырга өйрәткән.

Иртән кояш чыгар-чыкмас уянгач, Илһам хан баш астына кулын куеп шул турыда уйланып ятты. Йокысының рәте-җае булмады, әллә ниткән яман төшләр күрде, әле манарадан очып суга төште, әле су өстеннән очып барды. Һәм шуңа шатланып бетә алмады — оча ала икән бит ул!

Ләкин уянып киткәч, моның бары тик төштә булуына бермәлгә ачыргаланып ятты. Чынлап та, нигә оча алмый икән адәм баласы, әйтик, очар кошлар кебек, теләгән җиренә күтәрелеп очып китсә? Адәм баласын күтәрә алырдай канатлар ясасаң?..

Илһам хан торды, шул мәлдә үк бүлмәгә комган-таз тоткан, иңе аша сөлге ташлаган хезмәтче кыз керде.

— Хәерле иртә, олуг хан! — диде ул тыйнак кына елмаеп, баш игәндәй, әллә ничек чүгеп куйгандай итте.

— Хәерле булсын, гүзәлкәй! — диде Илһам хан һәм җинен сызганып, юынып алды, кыз иңеннән чигүле сөлгене алып, битен-кулын сөртте.

— Күптән биредәме?

— Ике ел була инде, олуг хан.

— Хезмәтең зарыктырмадымы соң?

— Юк, олуг хан. Тагын бер елдан мине әмир Хаҗи чуен коючыларына кияүгә бирәчәк. Әмир Хаҗи чуен коючыларына һәрберсенә өй салдыра. Өйләнгәч.

— Яраткан кешең дә бармы, егетең дим?

— Бар, олуг хан. Аты Батталдыр.

— Ул синең яныңа ничек килеп йөри соң?

— Белмим. Ләкин атнага бер булса да килә. Күрешәбез.

— Чуен коючылар янына кергәнең юкмы соң?

— Ходаем, олуг хан, мөмкинме! Анда берәүнең дә кергәне булмады. Шайтан манарасы аша кергәннәрне елга буеннан табып алдылар, калган юлын бер алла беләдер.

— Ярый-ярый, рәхмәт сиңа,— диде Илһам хан, кызның иңенә сөлгесен куйды да киенә башлады.

Кыскасы, уйланырлык иде Илһам ханга. Сәер, оста Бәкер каян кереп-чыгып йөри чуен коючылар янына? Ихлас кыланамыдыр, меңбаш Туран белми, бу хезмәтче кыз да әллә ни әйтә алмады. Ләкин ни генә булмасын, чуен коючылар янына керү юлы булырга тиеш. Манара аша булса, манара аша, болай булса, болай. Илһам хан белә иде, Шайтан манарасын Кубрат хан угланнары салдыра, үзе салдырган, дип сөйләүчеләр дә бар. Кайчандыр бабалары салган бу хәрәбә калага бабалары Ибраһим хан игътибар итә. Бирегә килә, көнозын әйләнә-тулгана йөри, җимерек кәрвансарайны күрә һәм торгызырга дигән нияткә килә. Ни өчен? Ибраһим хан шуны белә: борынгы болгарлар монда бакыр кайнатканнар. Ибраһим хан кирмәннең диварларын торгыздыра, кәрвансарайны тергезә, әмма манарага чират җитми, вафат була. Сәлим хан атасының бу эше белән бөтенләй кызыксынмый, җимереклектән тергезелә башлаган каланы әмир Хаҗи угланына бирә. Манараны һәм асма күпер белән капкаларны әмир Хаҗи куйдырта, каладан оста Дәүранны китертеп, ел буена шунда эшләтә. Оста кул астына меңләгән ташчы бирә. Ниһаять, әмир Хаҗи бакыр кайната башлый, ул да түгел, яван остасы ярдәме белән дип сөйлиләр, чуен коя башлый. Әмма әллә ни зур нәтиҗәгә ирешә алмый, аның каравы оста Бәкер чын мәгънәсендә чуен коюга ирешә. Әмир Хаҗи аңа бөтен шартларны булдыра, алачыкларны кеше күзеннән яшерә, кирмәнгә берәүне дә кертми, алай белән меңбашын куя. Эрү ташны Урал якларыннан китерәләр, ә чуенны монда коялар. Эрү таш ташуда меңнәрчә кеше эшли. Кыскасы, абасы әмир Хаҗи тора-бара атасы өчен сер тубалына әверелә, шуннан ул бу хакта белергә тели, иллә бернәрсә дә килеп чыкмый. Әмир Хаҗиның моңа ачуы килә һәм ул манараны, кирмән диварларын янә күтәрттерә, күренгән-багыл-

ган бар нәрсәне кеше күзеннән яшерә. Җир астыннан яшерен юллар салдыра, юлларны салган кешеләргә бик күп акча биреп, илдән китәргә тәкъдим итә. Китмәгәннәрен бер атнадан юк итәләр. Осталардан һәм ташчылардан бары тик ике кеше исән кала: оста Дәүран һәм яван Драгил. Тагын кемнәрдер калдырыла, әмма аларны берәүнең дә күргәне юктыр. Илһам хан өчен бердәнбер кеше бар — оста Дәүран. Ахыр чиктә ул аны бирегә тотып китерер һәм төньюлларын күрсәтергә мәҗбүр итәр. Төньюлларын, манараны серләп эшләгән өчен әмир Хаҗи абасы оста Дәүранга ирек бирә, коллыктан азат итә. Атасына бу ошамый, Казанга яу чаба диярлек, әмма һични кыра алмый, кире борылып кайтырга мәҗбүр була. Менә хәзер яңа хан Шайтан каласының серен белергә кереште — Илһам хан. Һәм ул аны белер!

Әмир Хаҗины күп кенә кешеләр Шайтанның үзе белән тиңлиләр. Моңа кадәр Илһам хан моңа ышанмыйча, көлеп кенә йөргән иде, хәзер исә тәхеткә үзе утыргач, бөтенләй башкача уйлый башлады. Шайтан! Нинди Шайтан?! Булган хәлдә нигә аны берәүнең дә күргәне юк?..

Ашарга-эчәргә керттеләр, Илһам хан ашыкмый гына, уйлана-уйлана ашады, амин тотып, авыз эченнән генә бисмилласын әйтеп, торып, киенеп бетеп кенә килә иде, ишек шакыдылар.

— Кереңез, кереңез! — диде Илһам хан.

Меңбаш Туран керде, ишек катында туктады, сәлам юллады да тынып калды. Меңбаш дәү гәүдәле, кирәкмәгән зур куллы иде. Сакалы очлаеп килгән, кашлары киң, кушылып тора, яшел күзләрендә киная елмаю сыман чалым.

— Олуг хан, чынлап та Шайтан манарасына керергә исәп тотасызмы?

Шушындый эре гәүдәле, көрәк хәтле куллы, бер сукса үгезне егардай кешенең курка калып, кичә сөйләшкән һәм ниятләгән уйны шиккә калдыруы ким куйганда көлке иде, әмма Илһам хан көлмәде, елмаеп кына куйды.

— Исәп тотам гына түгел, мин анда керәчәкмен, меңбаш. Әйт әле, меңбаш, шайтан манарасына синең чынлап та кергәнең юкмы?

— Ипи тотсам ышанмассыз инде, олуг хан,— дип тәгаен уңайсызлана калды меңбаш Туран.

— Исемеңә карасаң — син төрки халкының баһадиры булырга тиеш идең.

— Мин болай да төрки халкының баһадиры, олуг хан. Һичнидән курыкмыйм.

— Шайтанның үзеннәндәме?!

— Шайтанның үзеннән дә, олуг хан. Чөнки ул юк. Ә менә манарага кергән бер кешене елга буеннан табып алабыз. Менә нәрсә мине аптырашка калдыра.

— Чуен коючылар янына әмир Хаҗи каян керә соң?

— Менә анысын күргәнем булмады, олуг хан. Әмир Хаҗи үзе сер тубалы ул. Ләкин әмир гаҗәеп гадел кешедер, олуг хан. Һичкайчан кешене бинаһакка рәнҗетмәс, кычкырып сөйләшмәс, ясак-салымны уннан бер өлештән ары җыймас. Халык әмирдән канәгать, мин аның меңбашы, тугры кешегә тугры хезмәт итәсем килә.

— Әмир Хаҗины манарага кергәч, әфсен укый, диләр. Шуннан, имеш, ниндидер ишекләр ачыла, әкәмәтләр күренә.

— Белмим, олуг хан. Кеше ни сөйләмәс, кеше сүзе кеше үтерер, ди халык. Мин сезгә белгәнем, күргәнемне сөйлим. Әмир Хаҗи беркайчан да безнең алда манарага кермәде, олуг хан. Чуен коючылар янына керергә бәлкем бер-бер аерым төньюлы бардыр. Ләкин мин биредә ничәмә ел менбаш булып торам инде, нә чуен коючыларны, нә төньюлларын күргәнем булмады. Дөрес, манарага Бачман баһадир белән Акбикә керделәр, әмма алар...

— Нәрсә алар?..

— Бикә чыкты, Бачман баһадир елга буеннан кайтып төште. Шуны гына беләм. Баһадир: адаштым, әллә кая барып чыкканмын, гына диде. Өс-башы юеш иде дә бит, мин сорарга кыймадым.

— Меңбаш Туран, оста Бәкерне монда чакыртып алып буламы?

— Ул миңа буйсынмый, олуг хан. Оста Бәкер нинди юлдан чуен коючылар янына керәдер, моны бер хода үзе беләдер. Ул, гомумән, безгә сирәк күренә.

— Оста Бәкер миңа да буйсынмасмы?

— Шәһрәтлем, аны каян тапмак кирәк. Аның үз дөньясы, безнең үзебезнеке, дигәндәй.

— Меңбаш,— диде Илһам хан чыга башлап.— Син бүгеннән меңбаш түгел, баһадир. Мин сине баһадир итәм. Синең кулыңда олуг ханның кирмәне дип уйла — бөтен чуен коючылар, оста Бәкер дә, биредәге һәммә нәрсә дә.

— Булмастыр, олуг хан. Зинһар, кычкырып сөйләшмәгез. Әйтәм бит, Шайтанның ишетүе бар.

Илһам хан чак кына көлеп җибәрмәде, ул янә ошбу кешенең куркуына гаҗәпләнгән иде, әмма дәшми калуны кулайрак күрде.

## 18

Илһам хан Чулман елгасы буйлап атын акырын гына юырттырып бара. Манарага кергәч булган хәлгә ышанды да ул, ышанмады да. Бер уйлаганда таң калмалы иде.

Алар манарага дүртәү керделәр. Үзе белән ул Туран меңбашны да алырга булды. Җансакчыларын ияртмәде. Янә илче Якимне һәм аның җансакчысын Тимушканы алырга булды.

— Әйдә-әйдә, кыюрак,— диде хан юлдашларына.— Күрдегезме инде, бернинди дә Шайтан юк.

— Хан иям,— диде Яким Күчтем.— Сабыр ит әле, сабыр ит. Мин ары таба менмим.

Илһам хан туктады, әйләнеп карады. Яким Күчтемнең кулында шәм, ә шәм калтырый, менә-менә төшеп китәр сыман.

— Тимуша, хуҗаң кулындагы шәмне алчы,— диде Илһам хан.

Шунда: «А-а-а!»— дигән тавыш ишетелде һәм кинәт барысы да тынып калды. Күкрәкне тишеп чыгардай булып йөрәк тибә, колаклар чыңлый.

— Меңбаш Туран, меңбаш Туран! — дип кычкырды Илһам хан һәм шундук алар өстенә ком-таш коела башлады.

— Тимуша, әйдә алдан,— диде Илһам хан.

Илченең җансакчысы карусыз алга атлады, ул өч-дүрт баскыч күтәрелгәч кенә Илһам хан белән илче Яким кузгалдылар. Илче Яким Илһам ханның җиңенә ябышты.

— Ары таба бармыйкмы әллә, хан иям?

Илһам хан туктады, акырын гына өченче катка күтәрелә башлаган Тимушкага карап торды.

— Бу ни инде тагын? — диде ул үз-үзенә сорау биргәндәй.— Меңбаш кайда?

— Тимуша, ни бар анда, әллә соң төшәсеңме! — диде Яким Күчтем. Ләкин ул соңгы сүзен әйтеп сулыш алырга да өлгермәде, янә: «А-а-а!» тавыш колак пәрдәсен ярып керде һәм янә тирә-юнь тынып калды. Яким Күчтем ашыга-кабалана түбән төшә башлады, теләсә-теләмәсә дә Илһам хан аңа иярде. Искитмәле хәл иде, меңбаш та, җансакчысы да тәгаен юкка чыктылар. Гүя, җир йота иде үзләрен. Ләкин җир аста, алар манарага менәләр иде.

Тышка чыгып, ишекне япкач кына Яким Күчтем кара ташка тезләнде дә янә чукынып алды.

— Кызым да кирәкми, хан, чуен коючыларың да үзеңә булсын, Тимушка кадәр Тимушканы юк иткәч, мин ни аларга, житмәсә, динем, илем башка. Китик моннан, хан иям, алла хакы өчен!

— Тор, Якимкә агай, тор! Әйдә, китәбез!

Капка янына житкәч, Илһам хан йөзбаш Чупайны дәшергә кушты, жансакчылары йөзбаш артыннан чаптылар. Илһам хан исә капка янындагы баганага сөялде дә манарага карап тора башлады.

Нинди хәл инде бу! Әзмәвердәй гәүдәле ике кеше күз алдында юкка чыксын әле...

— Инде нишлибез, хан? — диде илче Яким Күчтем.

— Нишлибез, китәбез,— диде Илһам хан гасабилана төшеп. Илче Яким Күчтем аның ачуын китерә башлаган иде. Ул арада йөзбаш Чупай килеп житте.

— Мин сезне тыңлыйм, шөһрәтлем.

— Син шушы минуттан йөзбаш түгел, меңбаш! Әйе, меңбаш Чупай. Мин сиңа, меңбаш Чупай... Хәер, сабыр итеп торыйк әле, Якимкә агай, шулай бит.

Илһам хан атына атланды, тезгенен тарта төшеп, янә манара ягына күз ташлады. Ул бернәрсәгә ачык төшенде: моннан китәргә кирәк. Кемдер аларны күзәтә, алар күзәтү астында. Ул моннан киткән булыр, аннары... Юк, меңбашны үзе белән алып китәр, кирмәнгә үз гаскәрен кертеп калдырыр. Берәүне дә кертмәсеннәр дә, чыгармасыннар да. Ләкин моны бүген түгел, иртәгә эшләр ул. Әллә соң бүген үкме?.. Иртәгә соң булып куюы бармы?

— Меңбаш Чупай, азатларыңа атларына атланырга боер, коралланган килеш капка янына жыелсыннар.

Меңбаш Чупай кычкыра-кычкыра азатларын жыя башлады, Илһам хан Яким Күчтемнең атка атланганын көтеп торды да:

— Мин гаскәремне бирегә кертеп калдырырга булдым, Якимкә агай. Ә әмир Хажи азатларын үзем белән алып китәм.

Илче Яким Күчтем аңламый торды, дөресрәге, ул барысын да аңлады, әмир Хажи азатларының ханга карусыз буйсынуларына бераз гажәпләнә калуы иде бугай. Аңа һаман да әле кем дә булса аларның кылган хәлләрен күзәтеп торалар иде кебек һәм ханның бу әмере көтелмәгән афәт китереп чыгарыр дип куркуы иде. Ләкин Илһам ханның коры вә житез, куркусыз әмер бирүен күреп, тынычлана төште, алай да капкадан чыкканда Тимушкасын пышан гына телгә алып, чукынып куюны кирәк тапты. Аллаһы Тәгалә саклаганны саклармын, дигәнне истә тотып, кылычын да кул тирәсенәрәк китерде.

Капкадан чыга башлаганнар иде инде, яңа гына меңбаш дәрәжәсенә күтәрелгән Чупай Илһам ханнан:

— Олуг хан, меңбаш Ҭуран кайда соң? — дип сорады.

— Аны Шайтан алды,— диде Илһам хан һәм жилле генә атын юыртырып алып китте. Меңбаш Чупай хан артыннан чапты.

Елга буенда калдырган азатларына житкәч, Илһам хан атыннан төште һәм ышанычлы Актай меңбашны бер читкә чакырып алды. Ул аңа бик озак нидер аңлатты, үгетләде, боерды хәтта, соңра теге вак-вак аяк кагып торгач кына, алар кире әйләнеп килделәр.

— Чупай меңбаш миндә калыр, ә кирмәнне сакларга мин гаскәре белән меңбаш Актайны жибәрәм,— диде Илһам хан һәм илче Яким Күчтемгә: — Илче каршы түгелдер бит,— дип киная уйнатып алды.

Меңбаш Актай гаскәренә кузгалырга дип боерды һәм алар кирмәнгә таба киттеләр. Илһам хан жиңел сулап куйды. Кирмәнгә кереп урнашулары белән меңбаш Актай аңа чаптар жибәрәчәк, барысы да жай гына бетсә, кан коюсыз гына Шайтан каласын кулына төшерәчәк. Ул бүген биредән китмәс, төнлә белән кала тирәсендә йөрер, елга буена төшәр. Югалган кешеләрне елга буеннан табып алалар. «Димәк,— дип

уйлады Илһам хан,— елга буена каяндыр тоньюлы төшә. Ул аны табар. Табар да Шайтан каласының серен ачар.»

— Хәзер ни кылырга исәбегез инде, олуг хан? — диде меңбаш Чупай.

— Менә шунда кунарбыз, меңбаш. Син минем меңбашым, кул астында йөздән артык азат, сакла ханыңны. Башкалага кайткач, мин сина тагын азатлар беркетермен.

— Баш өсте! — диде меңбаш Чупай.

— Бар, минем җансакчыларым белән таныш,— диде Илһам хан, ә үзе елга ярына утырып, уйга калган илче Яким Күчтем янына килде.

— Нәрсә уйга калдың, Якимкә агай?

— Уйланмаслыкмы, хан. Мондый әкәмәтне минем күргәнем юк иде әле, ниндидер манарага дүртәү кердек, икебез чыктык, икебез анда калды. Исәннәрме ул бахырлар, юкмы. Исән булмаган хәлдә, нинди хикмәтле манара ул?! Билләһи дип әйтәм, үзем кереп карамасам, үз күзем белән күрмәсәм, кем сөйләсә дә, ышанмас идем. Мин, хан, аллага ышанам, әмма көпә-көндез Шайтан алган кешене күргәнем юк иде әле. Китик моннан тизрәк, хан!

— Юк, Якимкә агай, без бүген монда кунабыз. Мин бу хикмәтле могҗизаның серен белеп китәргә тиешмен. Караңгы төшү белән манара янына барам, аннары яр астына төшеп торам. Тимушка белән меңбаш Туранның югалуына ышанмыйм мин. Йә алар алдан сөйләшеп бездән качтылар, йә...

— Нәстә, хан, нәстә йә?..

— Йә чынлап та Шайтан кулына эләктеләр. Ләкин нинди Шайтан ул, ике аяклы, ике куллымы? Ике аяклы, ике куллы булса, ул бер дә Шайтан түгел, адәм баласы, адәм баласы икән, мин аны тотармын.

Яким Күчтем чукынып алды.

— Куй, куй, хан. Яшь икән яшь барсең. Шайтан икән, син аны тота алмассың.

— Шайтан юк ул, Якимкә агай. Күрүче булганмы соң аны?! Юк! Шулай булгач, хәйлә бу, бары тик хәйлә! Чуенны бит Шайтан коя димәделәр, адәм балалары коя, диделәр.

— Хактыр, Якимкә агай, чуенны адәм баласы коядыр. Миңа монда бернәрсә мәгълүм булды, Якимкә агай, чуенны адәм баласы койгач, Шайтаны да адәм баласыдыр. Иллә мәгәр ул кем? Кем шулай куркыта халыкны?.. Кирмән — әмир Хаҗиныкы, бүгенге көннән ул минеке булыр.

— Әмир Хаҗи кирмәнгә алаең кертү турында белми, ахры, югыйсә күренер иде. Димәк, ул Шайтан дигәне абан була алмый.

— Белмим, Якимкә агай, белмим, ләкин мин аны белермен. Миңа калса, монда бернинди дә Шайтан юк. Мин шуны гына беләм, Болгар ханнары борын заманнан ук Шайтан каласына чит халыкны кертмәгәннәр, борын заманнан ук бу кала сер булып калган. Хәтта әнә мин дә белмим...

— Китик моннан, хан, ходай хакы өчен,— диде илче Яким.

— Киявеңне дә күрәсең килмимме, Якимкә агай? Кем белә, бәлкем Шайтан дигәне синең киявеңдер?..

— Йа хода, авызыңнан җилләр алсын, тәүбә диген, хан. Мөмкин хәлме! Минем кызым үз акылында иде, мин аны камил акыллы килеш тимерче товар ишем Әхмәткә үзем килтереп бирдем,— диде илче Яким һәм тиз-тиз янә чукынып алды.

— Ә шулай да мин анда барырмын, Якимкә агай. Яр астына да төшәрмен.

Бавырчылар ашарга дәштеләр. Илһам хан белән илче Яким елга буена төшеп, кул-битләрен юып мендәләр, ашарга утырдылар. Күп тә үтми караңгы төште, Илһам хан меңбаш Чупайны чакырып алды.

— Минем белән барасыңмы, меңбаш?

— Барам, олуг хан,— диде тәвәккәл төстә меңбаш Чупай.

Илһам хан аңа атларны китерергә кушты, үзе коралларын барлады. Ике ягына ике хәнҗәр такты, кылычын җайлабрак куйды. Атлар килгәч, илче Яким тагын хан янына килде.

— Бәлкем йөрмәссең, хан — диде.

— Күп сөйләнмә, Якимкә агай. Хан ике сөйләми.

— Догаң укы, аллага тапшыр,— дип калды чын-чынлап үзе өчен дә, хан өчен дә куркып илче Яким.

Ләкин Илһам хан аңа җавап биреп тормады, сикереп атына атланды да кузгатмас борын тыпырдарга тотынган кара айгырга ирек бирде: әйдә, ат юлын таба ул, кая илтә, шул булыр язмышы.

Илһам хан су кырындагы ташка утырды. Елга тын гына ага, балыклар сикерә, ярга елышып үскән агачлар арасында тынып-тынып һаман шул бер байгыш кычкыра бугай, гүя, кемгәдер зарлана, кемнедер дәшә сыман. Юк, сагышлана, моңлана.

Чаптырып килгән ат аягы тавышы ишетелде. Илһам хан сикереп урыныннан купты, кылычына кулын салды. Ат өстендәге азат яр астына чабып төште, нигәдер янәдән кире борылды. Туктады. Бертын күзәтте, тыңлады. Күзләре караңгыга өйрәнгән Илһам хан йөрәк кагуын колак янында тоеп, көтеп торды.

— Олуг хан,— дип тыенкы гына дәште, ниһаять, азат.

Ул аны тавышыннан таныды, җансакчысы Күгеш иде.

— Ни булды, Күгеш?

— Олуг хан, олуг хан, илче Якимне урладылар.

Илһам хан сикереп атына атланды, аның камчылый-камчылый ыстан туктаган җиргә чапты. Ул ыстанга житкәндә ясавыл азатлар кисәү агачлары кабызып, арлы-бирле чабышалар иде инде. Илһам хан чабып килгән җайдан диярлек атыннан сикереп төште, ясавыл азатлар арасында илче Яким Күчтемне күреп, җиңел сулап куйды, ыра-ера Яким Күчтем янына узды.

— Исән! — диде ул Яким Күчтемне тоткалап карап.

— Исән, аллага шөкер, хан, исән! — диде Яким Күчтем.

— Без аны көчкә алып калдык,— диде унбаш Садыйк.— Куып житеп алып калдык.

— Кем куып житте, кем коткарды илчене?

— Меңбаш Чупай,— диде азатларның берсе.

— Ходай бар икән әле, хан,— диде илче Яким.— Бар икән әле.

— Кем алып китте соң, кая иден? — дип сорады Илһам хан.

— Кая идем. Яр кырында ятып тора идем.

— Шуннан?

Илче Яким Күчтем чукынып алды, кисәвен бик якын китергән азатны этебрәк җибәрде.

— Чукынырга да бирмиләр. Мине урлый яздылар. Кемгә кирәк мин. Йокыга китеп кенә ята идем, кемдер күтәреп кенә алган кебек. Җиңел генә күтәрә бу мине, әйтерсең нәни бала мин. Башта, бәрәкалла, төшемдә дип торам. Рәхәт шулай, күтәреп алып баралар. Кемдер манарага алып менә, имеш. Шуннан кинәт тәмам уянып киттем. Мине күтәреп алып баручы мышный. Нык мышный. Тәмам өнсез калдым. Кычкырырга итәм, тавышым чыкмый. Алай да, аллаһы тәгалә кодрәт бирде, кинәт тамагым ачылып китте — разбой салдым. Мин разбой салганга азатларың уянды, безне куа киттеләр. Мин чәбәләнә башладым. Азатлар якынайды. Кемдер килеп житеп, тегене бәреп екты, теге «аһ!» итте дә юкка чыкты, әйтерсең җир упты үзен. Баксам, янәшәмдә меңбаш Чулпай басып тора.

— Әйе, мин аны кайтарып җибәргән идем.

— Ә бит ул синең белән киткән иде, хан иям. Ай калкып килә иде инде, күренмәслек түгел. Таныдым мин аны — меңбаш Чупай. Ә теге, гүя, күккә ашты.

Илһам хан илчене ары таба тыңламады, ат иярен салдырды да:

— Барыгызга да йокларга, ыстан тирәли сак куярга, дип китеп барды. Яким Күчтем аның янына килеп ятты, бик озак дәшми торгач кына:

— Хикмәтле хәл, олуг хан. Ул адәмне мин үземнең Тимушкама охшаттым. Ул да шулай мышный иде, бичара,— диде.

Илһам хан җавап бирмәде. Ул уйланды. Бик озак йолдызлар белән чуарланган, урак хәтле генә булып күк йөзендә йөзгән айга карап ятты. Алар тирәли сакчы азатлар йөренә. Олуг ханнарын һәм кенәз илчесен саклыйлар. Кемнән?.. Шаккатмалы хәл иде. Шулай ук чынлап та ул Шайтан дигәннәре бар микәнни?..

Бары тик таң атыр алдыннан гына Илһам хан онытылып йокыга китә алды. Дога укып ятты-ятты да, алласы саклар әле дип тынычланды булса кирәк. Йокыга талу белән күз алдына хатыны Мәрьям килде; каядыр бара, угланнары Габдулланы җитәкләгән. Илһам хан аңа нидер әйтергә теләи, әмма авызын ачса да, ни сәбәпледер тавышы чыкмый, имеш. Мәрьямы каядыр юкка чыга, аның урынына әзмәвердәй гәүдәле шыксыз вә ямьсез, бөтен тәнен йон баскан, аяклары тояклы, маймыл йөзле, озын бармаклы бер әкәмәт пәйдә булды. Ул әкрен генә Илһамга таба килә. Илһам хан кычкырмакчы итә, әмма янә тавышы чыкмый...

Илһам хан торып утырды, ияргә ятып каерылган муенын боргалады. Азатлар учак асканнар, аш хәзерлиләр, беришесе елга буеннан юынып менә, кайберләре яр өстенә намазлыкларын җәеп намаз укыйлар. Ниһаять, илче Яким Күчтем дә күзләрен ачты, торып утырды да кояшка күз төшереп, чукынып куйды.

— Әйдә, юынып менәбез, Якимкә агай.

— Ярый торган эш.— Илче торды, каткан сөякләрен язгалады. Җансакчысы аларга сөлгеләр китереп бирде. Юынып менеп килгәндә кала яклап чабып килүче берәү күренде.— Нидер булган, кычкыра,— диде илче Яким Күчтем.

Чаптар килеп җитте, сикереп атыннан төште, бер тезенә тезләнде.

— Олуг хан, яр буенда меңбаш Туранның мәетен таптылар.

Илһам ханга атын китерделәр, ул сикереп атланды да артына да әйләнеп карамый яр буена чапты, үткән кичтәге сөзәклек аша су буена төште. Азат дөрес әйткән: иртәнге салкынча җилгә дулкынланып торган елга читендә чалкан килеш меңбаш Туран мәете ята иде. Ул арада хан янына илче Яким Күчтем килеп җитте һәм ярты гәүдәсе ташлыкта яткан Туран гәүдәсен күрде дә чукынып алды, як-ягына күз ташлагач кына:

— Йа ходай, йа аллам, бу ни хәл инде, хан? Минем Тимушка да кая булса шулай аунап ята микән? Алар бергә киттеләр ич,— диде дә атына атлана башлады.— Безгә моннан тизрәк китәргә кирәк.

— Меңбаш Туранны яр өстенә менгезеп күмегез,— диде Илһам хан һәм ат тезгенен сул кулына алып, уң кулы белән ияр башына тотынды, текә ярга ябышып үскән куе карамаларга күз ташлап алды.

* * *

Курку дигән нәрсә Илһам ханга кайтыр юлга чыккач килде. Кирмәндә калдырган меңбашын да шушы язмыш көтсә? Ә бит меңбаш Туранның мәетен үз күзе белән күргәнче, алар икәүләп ияләреннән качтылар, дип уйлап йөри иде. Хәзер исә мәетне үз күзе белән күргәч, моның алай түгеллегенә инанды һәм тәгаен шиккә калды. Әллә соң чынлап та бу манарада Шайтан бармы?.. Шайтан хакында Коръәндә һәм башка әдәби вә үгет-нәсихәткә көйләнгән китапларда укыса да, Илһам хан беркайчан да моңа житди җисем итеп карамаган иде. Ә бит ул Шайтан каласын үземнеке итәм дип барган иде, хәзер исә моңа шикләнә калды. Хәтта азатларын һәм меңбашын анда калдыруына үкенү кебек бер нәрсә тойды.

Илһам хан илче Яким Күчтемгә күз төшереп алды. Атларын атлатып кына баралар. Алда Болгар каласы да күренә башлады инде, алдан да, арттан да ясавыл азатлар бара. Үлдәмир илчесе белән Болгар ханы алар уртасында. Кемнән куркалар? Илһам хан кемгә дә явызлык кылмады кебек. Алар илчене саклыйлар. Илчегә үлем юк, дәүләттә нинди хикмәтле хәлләр, фаҗигале вакыйгалар гына булмасын, илче исән-имин булырга тиеш. Азатларына Илһам хан илчене үзе күз карасы кебек сакларга кушты. Илченең кәефе юк — җансакчысы Тимушканы югалтты. Илче Яким Күчтем җансакчысының үле гәүдәсен дә күрә алмады. Кенәз Юрий коткысы белән Болгарга килеп, чуен кою серен белергә йөргән илче Яким максатына ирешә алмады. Моның өстенә жанына гонаһ алды.

Басу капкасын үттеләр, тышкы кирмән капкаларын ачкан арада Илһам хан Яким Күчтемгә бүген кич аксакалларын мәҗлескә җыясы, киңәшәсе килүе хакында әйтте. Аннан миңа нинди җинеллек килер икән дигәндәй, ханга күңелсез генә күз төшереп алды һәм кул селтәде, янәсе, теләсәң нә кыл.

Эчке кирмәннең асма күперен үтеп, сарай капкасына якынлашуга, Илһам хан каршына Мәрьям бикә йөгереп чыкты.

— Илһам, Илһам, Булат угланның кәләше — Олуг Мөхәммәт шаһ кызы Рабиганы алып кайтучы кәрванны мәңгелләр талаган, шаһ кызын әсир иткәннәр, әмма без җибәргән Ярулла сәүдәгәр аны коткара алган...

— Иплэп кенә сөйлә әле, шаһ кызы Рабига кайда соң хәзер?

— Сәкъсин каласыннан чыкканнар, дип әйтеп әйттеләр.

— Чаптар житкердеме сөенчене?

— Әйе.

— Үзе кайда?

— Кунак ятагында ял итә.

— Булат угланга хәбәр итәргә булыр,— диде Илһам хан һәм сараена узды. Ишекне узуга, аңа Зөбәрҗәт ханбикә каршы төште.

— Саумы, инәй дим! Без кайттык. Шайтан каласы минем кулда.

— Абаң белән орыштыңмы? — дип коры гына сорады ханбикә Зөбәрҗәт. Илһам ханның анасында мондый усал карашны беркайчан да күргәне юк иде әле.— Имансыз! Бәдбәхет! Анаңнан каргыш аласың киләме әллә!? Дәүран кияүне атаң азат итте түгелме?!

Ханбикә Зөбәрҗәт аяк тибеп куйды, әмма Илһам ханның моңа бер дә исе китмәде, бары тик ирен чите белән елмаеп кына алды һәм янәшәсенә килеп баскан бусагабашына:

— Илче Яким Күчтемне тәхет ягына алып кер,— диде һәм бөтенләй анасы юктай кыланыш белән тәхет ягына узды. Илче Яким тәхет ягына кергәндә ул тынычлаган иде инде. Анасының чәперенүенә аның әллә ни исе китмәде, әмма шактый гасабиланган, ачуланган иде. Илһам хан кәтиб Хафиз ягына күз төшереп алды.

— Чыгып торыр идең, кәтиб,— диде. Шуннан соң гына Яким Күчтемгә янәшәсеннән урын күрсәтте. Илһам хан ишек катына карап алды һәм бусагабашына да «чыгып кит» дип кул селтәде.

— Минем синең белән күзгә-күз сөйләшәсем килә Якимкә агай. Миңа әлегә шул нәрсә билгеле: ике туган Константин белән Юрий кенәзләр әле булса тәхет бүлешәләр. Гәрчә Юрий кенәз өскә чыкса да, халкы алдында ул хәтле абруе юктыр, ишетеп торам. Ә син, Якимгә агай, Юрий кенәз исеменнән Болгарга килдеңме?.. Хакмы?.. Хак. Шулай булгач, әйт әле, Якимгә агай кемгә өмет итә, кайсы кенәзгә урыс халкы?..

— Нәрсә бу, хан иям, үтенечме, боерыкмы? — диде Яким Күчтем канәгатьсезлеген сиздермәскә тырышып.

— Үтенеч тә, боерык та дип уйла, Якимгә агай. Минем синнән серем юктыр. Үзең күреп кайттың, бездә дә шул ук хәлдер. Абам баш бирми, гаскәр тотарга хәлем чамалы. Ашлы каласына әнә кече угланы Җаббарны илтеп утырткан. Ә ул кала Иделнең уң ягында, урысларның күзенә

карап тора, гәрчә кала борын-борын заманнан Болгар шәһәре булса да. Мин кенәздән ярдәм сорамыйм, ярдәмгә мохтаҗ түгелмендер, миңа абамны үземә буйсындыру кирәк. Кер хәлемә, Якимкә агай, минем абам белән орышасым килми.

— Кичә генә хәбәр алдым, хан, бүгенге көндә Юрий кенәз Городец каласында утыра, Константин кенәз аны шунда куган. Минем дә хәлемә кер, хан, йомышымны Юрий кенәздән алган идем, ә мин киткән арада Владимирдә әнә ниләр булып беткән. Миңа калса, Юрий кенәздә минем кайгы калмагандыр, хан, аның үз кайгысы үзенә бик җиткән шикелле.

— Ибраһим хан бабабыз салдырган каланы урыслар Городец дип атый башладылармы, Якимкә агай?

— Калалар гына түгел, илләр бер ханнан икенче ханга, бер кенәздән икенче кенәзгә күчә, хан. Әнә шундый заманда яшибез хәзер. Мин монда Юрий кенәз йомышы белән килдем, хәзер әнә Константин кенәз аягына кайтып егылырга тиеш булам. Илче, хөрмәтле хан, кенәз вә ханнар фикерен йөртүче генәдер.

— Илче фикереннән күп нәрсә тора, Якимкә агай. Әйтик, син Юрий кенәзгә килеп төштең, ди. Үлдәмиргә түгел, Городец каласына. Кем җырын җырларга тиеш буласың инде?

— Юрий алдында Юрий кенәзнең, Константин алдында Константин кенәзнең, хан. Әйткәнемчә, илче бары тик кенәз йомышчысыдыр.

— Минем сиңа киңәшем шул булыр, Якимкә агай. Син башта Юрий кенәз аягына егыл. Миңа ул кенәз якынрак. Иншалла, дружинасы үзе белән дер. Ул килсен Ашлыга. Җаббар углан кулында гаскәр юк хәлендә, миннән ярдәм булмас. Абам сизми калыр.

Яким Күчтем Болгар ханнарын үтә күрәм дип мактанса да, Илһам ханның тәкъдименә шикләнеп карады, ул бик озак дәшми торды. Илһам хан гадәттәгечә дисбе тарта, ирен чите белән генә елмаеп, аннан җавап көтә иде. Ни әйтә ала ул? Әлегә һични! Ул башта Юрий кенәз белән хәбәрләшергә тиеш. Аннары Болгар ханы аны җәтмәгә алырга теләмиме?.. Булмас димә. Ләкин күңеле белән тоя иде күпне күргән илче Яким, Болгар ханы Илһам аны алдамый.

— Мин сиңа кем кирәген беләм, Якимкә агай,— диде Илһам хан дисбесен бер читкә куеп.— Беләм...

— Ул кеше минем кулымда булырмы соң хан?

— Барысы да аллаһы тәгалә кулында, Якимкә агай.

— Һәм синең кулыңда, хан, синең кулыңда...

Илһам хан тураебрак утырды, моны илче Яким күрми калмады, яшь ханны да мин-минлек чире читләтеп үтмәгән икән. Хәер, кайсыбызда юк ул чир, аллаһы тәгалә аны барыбызга да биргән, берәүне дә кимсетмәгән. Гади халык аны кешегә күрсәтергә куркыбрак йөрсә, ханнарның исә бу чир йөзләренә үк бәреп чыга.

— Шөһрәтлем Илһам хан, абаң әмир Хаҗига кылыч күтәрергә теләмәвеңне хуплыйм, пәйгамбәрләргә тиң акыл белән эш итәсең. Әмма Юрий кенәз мине аңлармы! Нә бәрабәренә килергә тиеш ул Ашлыга яу белән?.. Яу булгач яу булыр инде ул, кан-җан коймыйча булмас...

— Чуен коючы синең кулда булыр, Якимкә агай.

Илче Яким ачкан авызын ябалмый бермәл ханга карап торды, ул Илһам хан әйткән сүзләргә ышанырга да, ышанмаска да белми торды, күрәсең. Ахыр килеп тәвәккәлләде: ышанырга булды.

— Мин риза, хан. Кайчан телисең, шул вакыт Юрий кенәз дружинасы белән Ашлыда булыр.

Илче Яким Күчтем урыныннан купты, Илһам ханга түбәнчелек белән баш иде һәм ханга көмеш балдак сузды. Илһам хан балдакны үрелеп алды, учына кысты һәм янәдән учын ачты. Зөбәрҗәт кашлы, көмеш балдак, бәясе күп булса биш-алты алтындыр.

— Эш бәядә түгел, хан,— диде ханның гаҗәпләнә калуын күреп илче Яким.— Эш вәгъдәдәдер. Нәкъ менә шундый икенче бер балдакны күрсәткән кешегә чуен коючыны биреп җибәрерсең...

Илһам хан балдакны алды, дәшмәде, авыз эченнән генә: «Әлхәмделиллига мәгънә бир,» — дип урыныннан купты һәм илче Якимгә кул суузды.

## 19

Яким Күчтем хезмәтчеләре һәм үзен озатучы җансакчылары белән Бөек Каладан иртән-иртүк чыгып китте. Кәефе шәптән түгел иде. Теләгенә ирешә алмады, әмма бөтенләй үк буш кул белән дә кайтмый иде. Яким Күчтемнең әле булса хәтерендә, кияүләре Андрей Боголюб ун ел эчендә ун тапкыр яу чапты: ике тапкыр Киевкә, ике тапкыр Болгарга, ике тапкыр Новгородка. Җәмгысе тоташ өч ел буена сугышты, өч ел кан-җан койды, өч ел халыкны рәнҗетте, шул ук вакытта бусурман болгарларны гына түгел, христианнарны да — үзе табынган диндәге халыкны да. Аклап буламы аның бу яуларын? Юк. Болгарга яу чабуын акларга булыр да иде әле, ә менә Киев белән Новгородка яу чабуын Яким Күчтемнең аклыйсы килми. Димәк, Юрий кенәзнең Ашлыга яу килүе хәерлегә булыр, урыс халкы рәнҗемәс, ә хуплар. Бит хуплый Яким Күчтем Илһам ханның теләген, чөнки Яким Күчтем — урыс халкы вәкиле, димәк, халык та нәкъ аныңча уйларга тиештер. Дөрес анысы, Яким Күчтем беркайчан да кенәз вә ханнарга ышанып житмәде. Ә бит ул аларга һәрчак игелек теләде, әмма кадерен белмәделәр, теге яктан да, бу яктан да сәүдәгәрләргә кул салдылар, таладылар, рәнҗеттеләр. Ә бит илне баетучы халык — сәүдәгәрләрдер.

Константин кенәз — Владимирда... Димәк, олуг кенәз вазифасын да ул үти, ә Яким Күчтем Болгарга олуг кенәз йомышы белән килгән иде. Константин кенәз беләме аның Болгарга юнәлүен — Яким Күчтем өчен караңгы иде. Шуның өчен Юрий кенәзгә юл алуына янә бер тапкыр инанды Яким Күчтем. Шул ук вакытта ул белә иде, Константин кенәз Владимир-Суздәл тәхетенә утыруга, аның шәхесе белән кызыксыныр. Яким Күчтем Владимир каласында, ягъни кенәз сараенда вак кеше түгел. Константин кенәз аның кай тарафларда булуы белән дә кызыксыныр. Бәлкем әле артыннан да җибәрер, чөнки киңәшәсе эше булуы ихтимал. Константин кенәз каршына кайтса, аны барысының да беләсе килер. Болгарга китеп, муенындагы тәресен өзеп атып, бусурман динен кабул иткән Афанасий энесе турында сөйләргә туры килер. Ул гынамы, чуен коючы турындагы хәл-әхвәлләр калкып чыгуы да бик ихтимал. Юк инде, Яким Күчтем туры Городец каласына юнәлеп дөрес эшләде. Башта ул кенәзне Ашлы каласына яу чабарга котыртыр. Яу уңышлы чыкса, Яким Күчтем иманы камил иде, ул яшь кенәзне үзе үк Владимир тәхетенә утыртыр.

Шулай дип уйласа да, Яким Күчтем бу хакта боерык бирергә ашыкмый. Ул, гомумән, юлда йөргәндә эчү ягында түгел. Менә Сүрә елгасына житәрләр, кичәрләр, урыс җирләренә аяк басарлар, шунда исән-имин ил-җиргә аяк басу сөенеченнән...

Салмак кына искән җилгә ияреп, аш исе килеп, тамакны кытыклап куя. Шул чак Яким Күчтем ашчыны дәшеп алды.

— Син дим, монда кил әле!

Ашчы кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә Яким Күчтемгә таба кузгалды, учак ягучы шундук аларга төбәлде.

— Моңа кадәр кемгә хезмәт иткән идең?

— Андрей кенәзгә, Яким Степанович.

«Менә тагын, үзе мине белә икән!»

— Мине каян беләсең? Атын ничек?..

— Егорка мин, Яким Степанович, Егорка, ашчы, болгарлар әйтмешли, бавырчы.
— Кенәзгә дә аш пешерденме?
— Әйе, аш пешердем, Яким Степанович. Ашны күп ашый иде, мәрхүм.
— Мин дә ачыкканда аз ашамыйм аны.
— Шуның өчен мин күп итеп ит салдым да, Яким Степанович.
— Кулыңа кылыч та тотканың булгаладымы?
— Булды, Яким Степанович, булды. Андрей кенәз үлгәч, мине Всеволод кенәз үзенә алды. Аннары угланы Изяславка җансакчы итеп бирде. Ул Болгарга яу чапканда һәлак булгач, Юрий кенәз үзенә алды. Аннары ул әнә сиңа биреп җибәрде.
— Колчурамы әллә үзең?
— Христиан мин, Яким Степанович!
Шулай диде дә Егорка чукынып алды.
— Минем җансакчым булыр идеңме?
— Йа хода, Яким Степанович, булмый буламы! Хактыр ки, мәнә минем бер дә Константин кенәзгә хезмәт итәсем килми, Яким Степанович...
— Юрий кенәзне Владимир каласына алып кайтсак? Ә!?
Егорка як-ягына каранды, янә чукынып алды.
— Константин кенәз килмешәк, барыбер аннан китәр, Яким Степанович.
— Тиз генә китмәс, каланы яулап алды, кул салмаса да, Юрий кенәзне өтек бер калага куган.
— Юрий кенәз йомшак табигатьле, кеше кадерен белә, мин аны якын иткән идем, Яким Степанович.
— Димәк, син ашчы түгел, җансакчы... Ә Юрий кенәз сине бавырчы итеп минем белән җибәргән... Тиккә генәме, Егорка?!
Яким Күчтем ак сакалын сыпыртып, торып утырды, кылыч сабын җайлабрак куйды.
— Без кая барабыз соң, Яким Степанович,— диде Егорка Яким Күчтемнең хәрәкәтенә мыскал да игътибар итмичә, кирессенчә якынрак килеп.— Минем Владимирга кайтасым килми. Константин кенәз Владимир каласына ут салды, христиан халкын тиккә рәнҗетте.
— Син холопка нигә кирәк бу? Ә?! Сиңа нигә кирәк булды кенәзләр ызгышы! Син хәзер минем җансакчым. Ишетмәдеңмени ни әйткәнемне?!
Егорка кинәт йөзгә алышынды, әкрен генә артка чигенде.
— Мин, Яким Степанович, хезмәт иткән кешемә һәрчак тугры булдым. Шундый кеше инде мин, изгелекне онытмыйм, биргәнгә канәгать калып, көчемнән килгән кадәр ярдәм итәм.
— Димәк, һәр иягә тугры хезмәт иттен?— дип кинаяләбрәк сорады Яким Күчтем.
— Тугры хезмәт иттем, Яким Степанович. Аллаһы тәгалә алдында җаным тыныч.— Егорка иясенә якын ук килде.— Ханның бер җансакчысы миңа әйтте, Яким Степанович, сезне бернинди дә Шайтан алып китмәгән. Кһм, ни, ул кешене хан җансакчысы үзе күргән. Таныган.
— Мине күтәреп алып киткән кешенеме таныган?— дип торыбрак утырды Яким Күчтем.— Мине Шайтан күтәреп алып китмәгәнмени?!
Егорка кеткелдәп көлеп алды, әмма бу кыланышы белән Яким Күчтемнең ачуын гына чыгарды.
— Син, эт ялаган нәмәстә, минем башымны катырма, минем баш болай да каткан,— дип, Яким Күчтем Егорканың изүеннән эләктереп алды да йөзенә якын китерде.— Кем мине күтәреп алып киткән булган? Ни диде хан җансакчысы?!
— Әүвәл җибәр, Яким Степанович, тыным кысыла...
Яким Күчтем ашчының изүеннән җибәрде, тегенә янәшәсеннән урын күрсәтте.

— Дөресен әйт, кем мине күтәреп алып китте? Иясен күтәреп алып китәргә Тимушка җуләр түгел иде. Тимушкага мин үземә ышанган кебек ышана идем. Башына җиттеләр аның, әнә шул Шайтан дигәннәре җитте, бер дә бүтән түгел.

— Телисең ас, телисең кис, Яким Степанович, сине күтәреп алып китүче Тимушка була.

— Йә-йә, узынма, Тимушканы нахакка рәнҗетмә. Башын җуләргә салыбрак йөрсә дә, үз акылы үзенә бик житкән аның.

— Тимушка элек ул якларда яшәгән, шунда туган, шунда үскән кеше, Яким Степанович.

— Кем кайда тумас! Кем кайда туса да, аның торган җире, инанган иманы була. Тимушканың инанган иманы сиңа билгеледер — христианин иде ул! Минем атам, урыны оҗмахта булгыры, Болгарда туа, ә торыр җире Мәскәүтиндә иде, утар тотты. Хәзер әнә ул утарга Владимир кенәз баш булып ята... Дөнья ул, Егорушка, дөнья, диләр аны.

Егорка елганың аръягына карап тора иде. Кояш баеп килә, анда ниндидер хәрәкәт бар сыман иде. Ат менгән халык, ихлас! Егорушка сикереп торды һәм:

— Дружина! — дип кычкырды.

Яким Күчтем дә сикереп торды, кулын маңгай өстенә куеп, елганың аръягына карады, әмма һични күрмәде.

— Саташма, тиле беткән, нинди дружина булсын, ди. Юлбасарлар булуы ихтимал. Һәй, йөзбаш, кая син! дип кычкырды Яким Күчтем.— Багып кил әле, нинди халык аръякта тулгана?..

— Алар безне күрә, ә без аларны күрмибез,— диде янәшәсендә басып торган Егорка.

— Ни өчен алар безне күрә, без аларны күрмибез? — дип сорады Яким Күчтем соңге тотып торучы ашчыдан.

— Алар кояшбаеш ягында, Яким Степанович, ә без кояшчыгыш ягында. Нәрсә инде бу, Яким Степанович, төне буена без аларны, алар безне шулай каравыллап чыгарбызмы? Рөхсәт ит, Яким Степанович, аръякка чыгып белеп килим, кемнәр икән үзләре?..

Шулвакыт атыннан төшми генә йөзбаш кычкырды:

— Кем бакмага бара, ихтыяри барган кешегә йөз акча вәгъдә итәм! — диде.

— Мин, мин барам! — дип алга чыкты ашчы.

— Син! — дип гаҗәпләнде йөзбаштан бигрәк Яким Күчтем.— Син! Нигә син?..

— Миңа тылмач кирәкми, мин дүрт-биш тел беләм.

— Башта син безне ашатып кит, һич югы тулы корсак белән үләрбез,— диде көлемсерәп Яким Күчтем.

Бавырчы Егорка сөңгесен җиргә кадады да савыт-саба сорап алды, зур агач кашык белән ашны болгатты һәм тары өйрәсен өләшә башлады. Иң әүвәл ул Яким Күчтем белән йөзбашка илтергә кушты, аннары сугышчыларны ашатты, шуннан соң гына олаучыларга дәште.

— Бавырчыны аръякка чыгару килешер микән? — диде Яким.

— Килешер,— диде йөзбаш гамьсез генә.— Үзе теләде ич!

— Теләвен теләде анысы,— дигән булды Яким Күчтем, әмма яңадан бу хакта сүз кузгатырга кыймады. Бавырчыны җибәрмә дип әйтер иде, үзе үк аны сынап карарга булды, җибәр дип тә әйтергә соң иде инде, йөзбаш барысы белән дә килешкән иде.

Халыкны ашатып-эчергәч, Егорка йөзбаштан килеп корал-кием алды, җентекләп киенде, ике ягына ике хәнҗәр такты, кылычын җайлады.

— Кечү тирән, ат корсагына житә,— диде йөзбаш.— Аннары аръякта сине көтеп торулары бар. Болгарлар булса, уктан җилле алалар.

— Мин түбәннәнрәк чыгырмын, йөзбаш. Түбәндәрәк тагын бер кичү бар.

— Вазифаңны беләсең, Егорушка,— диде Яким Кучтем Егорканы чукындырып.— Сак бул. Иң мөһиме, кемнәр икәнен ачыкла. Шуны белү белән кире борыл.

Егорка сикереп атына атланды һәм җилле генә юырттырып, елга буйлап түбән таба төшеп китте.

Караңгы кинәтрәк төште сыман. Яким Күчтем барчасына да түгәрәкләнеп куелган олау уртасына җыелырга кушты. Алай да олау тирәли сакчылар бастырды. Алар алышына торып, төне буена сакта торырга тиеш булдылар. Яким Күчтем ут алырга кушмады, кисәү агачларын әзерләгән олаучыларга арбаларын ташламаска боерды. Олаучыларның күбесе Городец каласы ягына юл алулары хакында белмиләр иде әле, әмма Яким Күчтем бу хакта яшерергә дә уйламады. Белсеннәр. Константин кенәз кул астына кайтып керүләре аларга да җай түгел, чөнки Ростов кенәзе, гомумән, Владимир сәүдәгәрләрен яратмый иде.

— Хан азатлары булса, Егорка сөйләшә белер,— дигән булды Яким Күчтем олаучылардан битәр үз-үзен тынычлындырырга теләп. Ул һәрчактагы кебек Болгардан бик күп товар алып кайта иде, булган малтоварны юлбасарлар алсалар, ул Юрий кенәз алдына буш кул белән кайтып төшәчәк, ә байлыкның күбесе кенәз исәбенә алынган иде.

Яким Күчтем яр кырына ук килде, бертын колак салып тыңлап торды. Шулчак колак түренә атта чапкан берәүнең тавышы ишетелде, Яким Күчтем кылыч сабына кулын куйды, әмма олаучыларга кычкырмады. Гаҗәбе шул булды, ат менгән кеше туп-туры аңа таба килә иде, әйтерсең, ул аны күрә. Ат менгән кеше якыная башлауга, Яким Күчтем кычкырып дәште:

— Кем бу?!

— Бу — мин, Яким Степанович, мин Егорка!

— Егорушка, син! — диде Яким Күчтем күңеле тулышудан чак кына елап җибәрми калды.— Син, исән, Егорушка?!

Егор аның янына килеп җитте, сикереп атыннан төште, чукынып алды, бер аягы белән Яким Күчтем алдына тезләнде.

— Йә-йә, тор, килешмәгәнне. Мин сине җансакчым итәм. Бүген үк. Йә, сөйлә, кемнәр анда?

— Өскөйләр Казан сәүдәгәрләрен талаган. Әмир азатлары, шуларны көтә. Безнең кем икәнне беләләр, багучылары күреп киткән.

— Ә без сизмәдек тә,— диде Яким Күчтем.— Өскөйләр имансыз, аларга урыс сәүдәгәре ни дә, болгар сәүдәгәре ни. Бер сүз белән — юлбасарлар.

— Әлегә алар түбән таба төшеп киткәннәр, шул арада күтәрелергә тиешләр икән — болгарлар аларны көтә.

— Безгә дә сак булырга кирәк, Егорка. Сакланганны саклармын дигән аллаһы тәгалә дә.

— Әллә соң ашап тормыйча кузгалабызмы, Яким Степанович?

— Хак, Егорушка, кузгалырга кирәк. Тамак тәмугка кертер, диләр. Бераз баргач, туктап ашарбыз әле.

— Мин бернәрсә ишеттем әле, Яким Степанович. Әмир азаты әйтте: Константин кенәз вафат икән бит!

— Юк сүз, Егорушка, юк сүз! Кенәз Константин Владимирда утыра. Коткы бу. Безне туры Владимиргә кайтарырга телиләр. Анда безне Константин азатлары көтәдер. Сәүдә итү өчен алтынны мин Юрий Всеволодович кулыннан алып киткән идем, аңа кайтарып та бирермен. Тугрылык шул инде ул, Егорушка, иянә тугры хезмәт итү йөзгә оят китермәү дигән сүздер.

— Без Городец каласына юл алдык диден, Яким Степанович, анда безгә чирмешләр иленнән үтәргә туры киләчәк.

— Чирмешләр безгә тимәс, иншалла. Ә әмир азатлары уңайлы җиргә килеп туктаган. Түбән төшеп киткән өскөйләргә башка кайтыр юл юк.

— Өскөйләр Юрий кенәзгә буйсыналар бугай, Яким Степанович?
— Юлбасар беркемгә дә буйсынмый, аның аты-иманы юктыр. Юрий Всеволодович монда бармас, мөмкин түгел, Егорка.
Шул мәлдә томан эченнән көймә күренде, аның артыннан икенчесе, өченчесе, Яким Күчтем Егорканың кулын кысты.
— Бар, чап болгарларга. Юлбасарлар Яким агай олавын талыйлар диген.
— Юлбасарлар христианнардыр бит, Яким Степанович.
— Мин сиңа әйттем ич, юлбасарга талау хәерле, кем ул христианмы, бусурманмы барыбер. Бар, тиз йөр!
Егорка атына атланды, кайткан юлыннан кире чапты. Яким Күчтем чукынып алды да, авызына ике бармагын кабып, әче итеп сызгырып җибәрде. Шундук аның янына берничә сугышчы белән йөзбаш килеп җитте.
— Ни булды, Яким Степанович?
— Әнә елгага кара. Кемнәр менә...
— Өскөйләр, юлбасарлар! — дип кычкырды йөзбаш.
Олау тирәсендә ыгы-зыгы купты, барысы да коралланырга кереште. Яр өстендәге олауны күреп, өскөйләр ярга таба ишә башладылар.
— Туганнар! — дип кычкырды өскөйләр көймәләрдән төшә башлагач.— Туганнар, без урыслар, христианнар, православные...
Ләкин аңа игътибар итүче булмады, яр кырына инде утызлап көймә туктаган, алардан коралланган кешеләр коелалар иде инде. Бу хәлне күреп, Яким Күчтем олау арбалары белән уратып алынган боҗрага таба йөгерде һәм килеп керүгә, арба менде дә янә кычкырырга тотынды:
— Туганнар!.. Акылыгызга килегез. Мин Юрий Всеволодович кенәзнең илчесе. Туганнар, православные.
Арбалардан корылган боҗрага таба килүче юлбасарлар аны, гүя, ишетмәделәр дә, кылыч-корадларын күтәргән килеш, акыра-бакыра арбалар янына якынайдылар.
— Акылыгызга килегез, өскөйләр, мин олуг кенәз илчесе! Мин Яким Күчтем, Андрей Боголюбта хезмәт иткән кеше! — дип кычкыруын дәвам итте Яким Күчтем. Артык якыная башлагач, саклау чарасын йөзбаш үз кулына алды, ул укчыларына юлбасарларны уктан алырга боерды. Берничә юлбасар егылып калды, калганнары тагы да котырынып арбалардан корылган боҗрага якынлаштылар. Юлбасарларның исәбе-хисабе юк кебек иде, алар һаман яр астыннан күтәреләләр һәм акыра-бакыра олауларга таба ябырылалар иде. Яким Күчтемнең оста сугышчылары шактый юлбасарны кырып салсалар да, арттагылары котырынып, үлгән ишләре аша сикерә-атлый боҗраны камап алдылар. Ул арада иң кыюлары һөҗүмгә ташланды. Алар ничектер бердәм ташкын булып ябырылдылар һәм эһ дигәнче ике-өч арбаны аударып, уртага керделәр. Китте суеш-кырыш, кадаш-чәнчеш. Ахыр Яким Күчтем кычкырды:
— Без бирeләбез, без сугышмыйбыз! Атаман, атаманыгыз кем, без бирeләбез!..
Яким Күчтем үз кешеләрен урта төбәккә җыйды, күкрәген киерә төшеп, алга чыгып басты.
— Атаманыгыз кая, без бирeләбез!..
Берничә юлбасар аңа ташланганнар иде, арттанрак килүче озын сакаллы юлбасар, атаманнары булса кирәк, алга чыкты, кулын күтәрде.
— Кем сәүдәгәре?
— Олуг кенәз Юрий Всеволодовичныкы — Яким Күчтем — илче!
— Илче олау белән йөриме! — диде атаман, сул кулындагы кылычын, уң кулындагы хәнҗәрен кыналарына тыкты да Яким Күчтемгә якын ук килде.
— Ә син, картлач, мич башында яту урнына нигә илче булып йөрисең?.. Илче, имеш. Ә Юрий кенәз турында менә ни әйтәм мин сиңа, картлач, аның үзен дә куачакбыз ошбу яклардан. Ул безнең шәһәрчеккә

килеп үз тәртипләрен урнаштырмакчы итте. Булмас ул! — Атаман юлбасарларына таба борылды.

— Булмас ул!

— Булмас, булмас, булмас! — дип акырышты юлбасарлар.

— Сугышкан өчен сине шәрә калдырам, кенәз эте. Әйбер-товарларың алам. Ничә кешемнең башына житте сугышчыларың?.. Карт эт, синнән сорыйм?! Сал чапаныңны! Сал-сал! Юкса корсагың тишәм...

Атаман кылычын суырып чыгарды, әмма яңадан тыкты, чөнки Яким Күчтем чапанын салып, аның аяк астына ташлаган иде инде. Атаман чапанны алды да иңенә салды. Аннары юлбасарларына борылды да:

— Талагыз, ирек! — диде.

— Тәре юктыр синдә, тәрең булса, христианнардан көлмәс иден.

— Килешми, килешми, кенәз илчесе.— Атаман юлбасарлар талаган йөкләргә күз төшереп алды.— Сиңа нәрсәгә товар. Син илче. Илченең үз вазифасы бардыр инде аның. Ә син товар төяп йөрисең. Димәк, син илче түгел...

— Атаман, бер олауда мичкәләр белән шәраб,— дип кычкырды бер юлбасар.

— Мичкәнең берсен монда ачабыз, калганнарын минем көймәгә! — дип боерды атаман. Кирәкмәгән таза гәүдәле, жирән сакаллы, кыпкызыл йөзле яшел бәбәкле атаман кет-кет көлеп алды.— Илче мичкәмичкә шәраб йөртәмени?! Сине дә, әсир ителгән кешеләрең дә без суярбыз. Син минем утыз кешемнең башына житкәнсең, илче. Сездән дә шул чама ятып калды. Баш өчен баш булыр. Бигайбә, илче?..

— Товар Юрий кенәзнеке, атаман. Хажитарханнан кайта.

— Димәк, кипкән балык, шибрәт, шәраб юллыйсың. Илче дигән була бит әле.

Ул арада бер мичкәне атаман каршына китереп куйдылар. Атаман мичкәгә күз төшереп алды да ым белән генә ачарга кушты.

— Кенәзгә ярагач, безгә дә ярар, шулаймы, илче, ә?!

Яким Күчтем дәшмәде. Аңа элек тә юлбасарлар очраштыргалаганнар иде, әмма берсе дә аны бу чиккә житкереп кимсетмәде, кан-жан коймады. Бу атаман иптән чыккан, моңа ни алла, ни бәндә чик түгел иде, күрәсең.

Мичкәнең бөкесен ала алмагач, берәүсе кылыч белән орды, бөке сынып очты. Кит, булдыксыз, ача белмисең, дип, әзмәвер гәүдәле юлбасар кулындагы сөңге сабы белән бөкегә төртте. Бөке мичкә эченә төшеп китте. Юлбасарларның һәрберсендә каешларына таккан агач кружкалары бар икән — чиратка тезелделәр. Берәүсе аларга сала торды. Атаманга да бирделәр, ни арададыр кипкән чабак китерделәр. Атаман Яким Күчтемгә кулындагы шәраблы савытын бирде.

— Эч, илче! Эч-эч, сиңа барыбер үләсе.

— Үлем ул синнән дә ерак йөрмидер, атаман.

— Йөрмидер, хак. Ләкин мин синең үлемеңне күрәм, ә син минекен күрмисең...

— Үлем ул ходa кулында, атаман.

— Хода кулында,— диде икенче савыт шәрабны эчкән атаман.— Хак әйтәсең, хода кулында. Тик хода әлегә мина ул үлемне жибәрми торырга булган, илче. Ә синең баш очында кылычым эленеп тора. Еллар буена кенәз сараенда илче вазифасын үтәдем, дисең. Димәк, гонаһны да күп кылгансыңдыр. Андрей кенәзнең дә әнә кылган гонаһлары өчен хода яман итеп жанын ала.

— Син ул турыда каян беләсең? — дип сорады Яким Күчтем.

— Сүз-хәбәр очар кош ул, илче. Ишеттем. Бaйлары үтергәннәр, аннары хатынына япканнар. Нахак сөйлимме?

— Үтермәгәннәр аны, үзен-үзе үлемгә хөкем итте ул. Хода тәгаләне рәнжеткәне өчен, халкыннан йөз чөергәне өчен жәза алды кенәз...

Атаман башын артка ташлап шаркылдап көлеп җибәрде. Яким Кучтем тирә-ягына күз төшереп алды. Юлбасарлар исән калган сугышчыларны һәм олаучыларны бер тирәгә җыйганнар да аркан белән уратып, бәйләп куйганнар. Арада яралылары да бар, күрәсең, шул яктан ыңгырашкан тавышлар ишетелә.

— Минем йөзгә якын көймәм бар, кенәз илчесе. Йөзгә якын! һәр көймәдә дүрт-биш кешем. Бүген аларның күбесе һәлак булды, бушаган көймәләргә синең товарларың тәяргә туры килер. Ә син минем кешеләргә каршы сугыштың. Килешми христиан кешегә алай, хурлык! Менә бу чүмеч шәрабны мин синең үлемең өчен эчәм, илче!

Шулай диде дә атаман тулы бер чүмеч шәрабны эчеп бетерде һәм баш аша чүмечен ташлады. Ялагай ярдәмчесе булса кирәк, шундук чүмечне йөгереп барып алып килде, янә шәраб тутырып атаман кулына тоттырды.

— Кенәз илчесен эчер,— диде исерә башлаган атаман.— Барысын да эчерегез. Христиан кешесе эчеп үләргә тиеш. Шәраб эчү христиан өчен савап, бусурман өчен гөнаһ. Шулаймы, кенәз илчесе? Исемең әйтмә, барыбер исемдә калмас. Миңа исемең кирәкми. Алла белер исемеңне. Эчер илчене, эчмәсә, авызын каерып сал. Барысына да, барысына да эчерегез!

Шулчак юлбасарлар шау-гөр килеп әсирләрне эчерергә керештеләр, бер мичкә беткәч, икенчесен тәгәрәтеп китерделәр. Яким Кучтем бертуктаусыз чукынды, аллаһы тәгаләдән мәрхәмәт сорады, ә күңеле белән Егорканы көтте. Ул кайтып җитәргә тиеш иде инде. Яким Кучтем исереп аунаган юлбасарларны күрмәс өчен күзен йомды, аңа чүмеч артыннан чүмеч шәраб эчерделәр, ниһаять, ул исерде, тәгәрәп китте. Карт илче чуалган зиһене аша көлгән тавышлар ишетте, кемдер аның янына ятты, кочаклады, ялагайланды кебек. Всеволод Юрьевич бик еш яу чаба башлагач, игътибарын артыгы белән хәрбиләргә җәлеп иткәч, тәҗрибәле олы кеше буларак, аңа әйткән иде: «Олуг кенәз, дәүләт башында утырсаң үзең утыр, хәрбиләргә ирек бирмә, юкса алар яу-талау турында гына уйлый башлаячаклар, ә дәүләт сәүдә иткәндә генә дәүләт исемен йөртәчәк». Ләкин кенәз аны тыңламады. Яу артыннан яу чапты, сугыш кәсепкә әверелде. Кайчак отты, кайчак оттырды. Тик моннан барыбер ил тәненә ит кунмады. Чөнки яу-талауга йөз тоткан дәүләт даирәләре хезмәттән ваз кичкән булалар инде. Бу атаман да кайчандыр кенәз дружинасында йөргәндер. Кенәз белән килешмичә качкандыр, хәзер әнә Всеволод җыйган дәүләтнең дәрәҗәсен төшереп, күрше халыкларга ышанычын югалттырып, юлбасарлык кылып йөри. Әйе, кенәзләрнең барысы да акыллы була алмый. Күбесе ахмакларча гомер итә. Әйтик, Владимир тәхетенә Ростов кенәзе Ростислав утыргач, халык кинәнгән иде. Тик шатланулары юкка булда, Ростислав та, Всеволод кебек үк, хәрбиләргә таянды. Тәхеткә кенәз Михаил утыргач та халыкка җиңеллек килмәде, ул да сугыш-орыш дип авыз суын корытты.

Яким Кучтем, аңын җуйгандай, зиһенен җыя алмый изаланып ятты. Кая ул, кемнәр кычкырыша. Ул көч-хәл белән күзләрен ачты, авырлык белән торып утырды. Кинәт башы әйләнеп китте. Күзләрен йомып, бераз тынып торды. Тагын күзләрен ачты һәм үз күзләренә үзе ышанмады: аның янына Егорка тезләнеп тора иде.

— Яким Степанович, бу мин, Егорка!

Яким аңа кулын бирде, торгызырга кушты, әмма аякларына басса да, һични аңламый торды. Бөтен олауны, атаман юлбасарларын камап алып, әмир Хаҗи азатлары тора иде. Алар барысы да ат өстендә, аннан ерак түгел атаман аунап ята, аның корсагына сөңге кадалган. Олаучыларны чишкәннәр, алар ни кылырга белми аптырап калганнар иде.

— Мин әмир Хаҗи меңбашы Җик Мәргәнне алып килдем. Ул коткарды безне, Яким Степанович,— диде Егорка.

— Кая ул, кая меңбаш Җик Мәргән! — диде Яким Кучтем.

— Әнә ул, килә. Юлбасарларның барысын да сөңгегә алдылар. Без исән калдык, Яким Степанович.

Яким Күчтем очлым очына тутый кош кауры кадаган баһадирга таба атлады, әмма чак кына егылып китмәде, Егорка аны тотып калды.

— Рәхмәт сиңа, баһадир. Мең рәхмәт. Безне үлемнән коткардың. Хода тәгалә сиңа игелек итсен.

Яким Күчтем ике тезенә төште, баһадирга җиргә кадәр баш иде. Атыннан да төшмәгән Җик Мәргән:

— Мәетләрне күмәргә! Юлбасарларны бүреләргә калдырырга! — дип боерды.

Ул арада унлап юлбасарны әсир итеп китерделәр. Көймәләрдә калганнар икән. Баһадир әсирләрнең кулларына богау салырга әмер бирде һәм атыннан төште, Яким Күчтем янына килде.

— Мин Юрий кенәз илчесе Яким Күчтем, баһадир. Бөек Каладан кайтып килә идем.

— Апанай сәүдәгәр абасымы?! — дип сорады Җик Мәргән.

— Мин ашыгам, баһадир. Миңа юлда булырга кирәк.

— Юл кешесенең юлда булуы хәерле,— диде баһадир Җик Мәргән һәм сугышчыларына олауны озатырга булышыгыз, дип боерды.

Яким Күчтем Егоркага таба борылды.

— Бүгеннән син минем җансакчым, Егорка. Сакла иясңне, ким-хур итмәм. Ишетәсеңме, Егорка!

Егорка аның алдына тезләнде, Яким Күчтем аны чукындырып алды.

— Мин сиңа, баһадир, алладан кодрәт бирүен сорамын. Ул мине ишетер, чөнки минем кешегә яманлык кылганым булмады.

— Син илче, Якимкә агай, ә бездә илчегә үлем юк, диләр. Аннары син Болгар җирендә. Кайсы илдән генә килмәсеннәр, сәүдәгәрләрне безнең илдә таларга бирмәбез. Ак юл сиңа, илче!

Җик Мәргән баһадир сикереп атланды.

Болгарлар әсир төшкән юлбасарларны алып китеп баралар. Юлбасарларның күбесенең муйнында тәре. Димәк, христианнар. Ә бит Изге Гайсә һәр христианны: «Якын кешеңә кул күтәрмә. Якының ярат!» — дигән. Ә монда алар кеше талый, кан коя!..

Яким Күчтем, айнып киткәндәй, тирә-юньгә күз ташлады. Олаучылары ыгы-зыгы килеп ат җигә, калган берничә сугышчы болгарлар белән бергә һәлак булган ишләрен күмәләр. Болгар баһадиры китеп бара. Яким Күчтем, ике динне бергә кушарга теләгәндәй, җиргә тезләнде, маңгаен җиргә бәрә-бәрә аллаһы тәгаләдән болгарларга игелек теләде. Һәм беренче тапкыр диярго мөмкин, ихлас күңелдән Афанасий энесен телгә алды.

*Ахыры киләсе санда.*

# ШИГЪРИЯТ



## Мөдәррис Әгъләм

ШИГЫРЬЛӘР

### Мин гаепле түгел

Халык «Кара урман» икән,
Кереп китте күңел...—
Ул гаепле,
Тик ул гына,
Мин гаепле түгел.

Мунча салып, абзар салып,
Бер һәйбәт йорт салып,
Ятсам «салып»...
Йөрмәс идем
Болай борсаланып.

Сыер асрап, дуңгыз асрап,
Хатын асрап кына
Ятасы иде Ходайдан
Саулык сорап кына.

Көлкегә калган чакларым
Булса алай-болай —
Йомры сүзләр төртер идем
Авыл агаедай.

Председатель булмасам да —
Йөрмәс идем эшләп:

---

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ (1946) — *шагыйрь, «Учак урыннары», «Киләчәккә кайту», «Мин әйттем» һ. б. китаплар авторы. Ул — Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты. Казанда яши.*

Гомерем һәйбәт узар иде
Эшләгәнне «тешләп»...

Шуңа диеп ятарылган
Бөтен «данныйлар»ым.
Орден-медальле итте ил
Шундыйларның барын.

Һәм аларга бирде бит ул
Чикләнмәгән «влач» —
Ил белән бергә барасың,
Илең шундый булгач...

Андый якты киләчәккә
Мин дә барыр идем.
Көн-төн йокламый уңышны
Мин дә алыр идем.

Мин дә тартыр идем йөкне
Каберлеккә тикле.
Кире кайтмак булсам, хәзер
Капкалары бикле.

...«Кара урман» җырына дип
Кереп киткән күңел.
...Ул гаепле,
Тик ул гына,
Мин гаепле түгел.

## Китеп баргандыр ул

«Болдырдагы каен ауды» —
дип язгансың. Ялган!
Ул бит минем балачакта
Мәңгелеккә калган.

Болдыр идәненнән чыгып
кәрнизгә сыенган:
көндез — кояш,
төннәрен — ай
нурына коенган.

Каен — кайгы... Әнкәм китте,
озатып калды ул да.
Бергә-бергә әзерләдек
аны соңгы юлга.

«Болдырдагы каен ауды...»
«Инде аумагае»,—
дияр чакларым күп булды,
тик аумады кайгы.

Каен — кайгы... әткәм китте
сугыш ярасыннан —
каен аның белән бергә
китеп бара сыман.

Безнең халык кайгысыннан
инде арып-талып,
китеп баргандыр ул, сеңлем,
үзе аякланып.

Без кичергәнне кичерсәң,
тамырың аяк булыр.
җиргә береккәнлегең дә
кинәт онытылыр.

...Рәхмәт, сеңлем, хатың өчен,
тик ышана алмам:
«Каен ауды» — дигән сүзең
шагыйрәнә ялган.—
Әнкәм китте...
Әткәм китте...
Ул да китеп барган.

## Кичер, әнкәй

Әти-әниләргә җырлар яздык,
күпме яздык —
әти-әни була алмадык:
тырышлыклар китте бары юкка —
манкортлыкка
каршылыклар кыла алмадык.

Яңа заман, дигән кием киеп,
ӘНИ, диеп
калдык җыр язарлык көннәргә.

...Алтын тәре күрсәк абынабыз,
табынабыз
ил хуҗасы — әллә кемнәргә.

Ярым-йорты инде телебез дә,
көнебез дә —
ярым-йорты инде хәлебез.
Җырыбызда «кичер, әнкәй!» дибез,
үлмәгәнбез,
үлмәгәнбез, димәк, әле без.

Әнкәйләрне күптән җирләсәк тә,
үрләсәк тә
ул төшләрдә күргән үрләргә,
каннан кучеп килгән сөйгән ярны —
хыялларны
үзебезгә калды җирләргә.

...Милләт, бәргәләнеп, йокы аша
ыңгыраша —
көтә әле, димәк, уяну.
Бер кайчан да таң атачак түгел,
уятачак түгел,
уятмаса әгәр бу яну.

...Башны җиргә иясе кала,
«кичер, әнкәй!» диясе кала.

## Язгы исәрлек

Нигә абындың, кыз бала?
Бу язларны күп күргән
Картлар сөйләшә үзара:
— Ерак калмый ташуларга,
Кар астына ут кергән!
— Ут кергән!

Уйлыйсыңдыр: — И бу халык,
Кемнәр генә җиткергән?
Сүзләреннән мәгънә табып,
И атлыйсың каударланып:
— Кар астына ут кергән,
Ут кергән.

Син генәме курка-курка
Беренче кат үптергән.
Абынырсың, чапма юкка,
Син бәхетле бу минутта:
Йөрәгеңә ут кергән.
Ут кергән.

Син бит гаепле түгел лә,
Ничә еллар көттергән
Сөю килгән. Язгы көндә
Әйтерсең лә синең генә
Йөрәгеңә ут кергән?!

## «Бар» катыш

Абына-сөртенә
узып ла бара кыш...
Яңгырлар сүтелә,
сүтелә кар катыш.
Еллар да үтелә
сүтелә-сүтелә...
Һәр яңа елыннан
яңалык көтелә...
Яктылык телибез,
телибез һаман да.
Ә еллар әйләнә
яхшыдан яманга...
Һәм «юк»лар сүтелә,
сүтелә «бар» катыш.
Яңгырлар явалар,
явалар кар катыш.

## Барыбер

Син һаман, максатым, биектә,
Атадым Ак болыт, диеп тә.

Кайчакта каплагач кояшны,
Сөйлиләр, дидем, мин,
булмасны!

Кайчакта күмелеп ай калды.
Кемнеңдер күңеле айкалды.
Калыгыз, дидем мин,
ак булып.
Каплады бары тик
ак болыт.

Кайчакта каплады йолдызын,
Каплады йолдызлы күк йөзен.
Кычкырдым: көтегез, юлчылар!
Ачылыр, бераздан җил чыгар.

Җил чыкты, ажунны[1] каплады,
Агымдай ишелде ак кары...
...Ак карлар, саф карлар, пакь карлар,
Төшегез, барыбер таптарлар.

## Үз-үзең белән әңгәмә

— Шигърият ул йә бар, йә юк кына,
анда булмый үрә катып кына...
Төче аш та түгел,
Әчеләтеп
булмый аны катык катып кына.

— Соң ул алай гына булмый әле,
әйләндерик әле тәлинкәне —
җиңеллек тә кирәк күңелләргә,
дөньяларның бигрәк авыр мәле.

...әйләндердек.
Дәште еллар гына:
«Шигърият ул йә юк, йә бар гына».

---

[1] Дөнья мәгънәсендә. Борынгы төрки сүз.



# Кадыйр Сибгат

ШИГЫРЬЛӘР

## Тынлык

Төн уртасы. Кошлары да
таңнарга кадәр киткән.
Күкләре күкрәп, яшенләп
яңгыры яуса икән.

Узмый никтер егетләр дә
шау килеп, гөрләп кенә.
Бер тавыш юк. Шушы тынлык
колакны ярып керә.

Тынган дөнья. Ник бер яфрак
селкенсен ялгыш кына!
Миләрне кыса бу тынлык,
уйларны ялгыштыра.

Таш булып ята күкрәккә.
Сулышны, тынны кыса.
Шомландыра, дөньялары
бик артык тыныч булса.

Төннәр озын. Төннәр авыр:
күземне йоммый чыгам.
Чыдый алмас, кинәт кенә
бу тынлык шартлар сыман.

## Уй

Яши алмый икән шунсыз кеше —
уйлау икән аның иң төп эше.
Киләчәген айкый кабат-кабат,
бүгенгесен уйлап, артка карап.

— Миндә генә уй,— ди,— миндә генә...
Төкерә ул кайчак синдәгенә.

---

Кадыйр СИБГАТ (1942)—*шагыйрь, «Әманәт», «Гамь», «Авазлар» һ. б. татар һәм рус телләрендә басылган унга якын китап авторы. Чаллыда яши.*

Бетерәсе килә уйны уйлап.
Бер генә бит үтә гомер буйлап.

Уйлый кеше, уйлый гомер буе.
Үзеннән соң кала шул ук уе.
Бер гомерен яшәп кеше китә...
Калган уе мең гомергә җитә.

* * *

Ява да ява шушы кар...
Юрганың итеп ябын.
Искә төшереп ява ул
гомернең бала чагын.

Ява да ява шушы кар...
Сагынсаң инде сагын:
хәтерләтә гомерләрнең
кызлар озаткан чагын.

Ява да ява шушы кар...
Уйлата уйның агын:
кулыннан тотып улымның,
кар ерып үткән чагын.

Ява да ява шушы кар...
Нәрсә дип ява тагын?
Каршылагыз, ди, гомернең
моңлы-сагышлы чагын...

Ява да ява шушы кар...

## Шүрәле

Төрле халык монда.
Төрле милләт.
Төрле телләр.
Хисләр төрледән.
Ник зал өнсез? — дисәм...
чыгып килә
шүрәлебез сәхнә түреннән.
Гомер итте урманнарда яшәп,
халыкларда бала куркытып.
Урманнардан Тукай алып чыкты,
арык җилкәсенә утыртып.
Күрә торып шуны,
ничек итеп,
гаҗәп могҗиза бит,— димисең?!
Дөнья буйлап йөртеп кара әле
гастрольләрдә урман иблисен.
Тагын бер кат карап утырдым мин
халкым, үзем өчен шатланып.
Тукай белән әчтән мактанып.

Чыдый алмас иде Тукай жаны,
үзе монда булса ул әгәр.
Алкышлардан һава кызды залда,
жилфердәшеп торды пәрдәләр.
Халыкларның изелгәне дә бар.
Бар халыкның түрәлесе дә.
Дөнья сәхнәләрен тота ала
бу халыкның шүрәлесе дә.

## Һәвәскәр астроном

Чормасыннан төшми,
күккә карап,
күз дә йоммый төннәр үткәрде.
Һәр карышын капшап, барлап чыкты
күз карашы житмәс күкләрнең.
Кызыктырмый аны бу йолдызлар.
Бардыр, диде,
бардыр яңасы.
Иске йолдызларда бер тапкыр да
тукталмады аның карашы.
Санамады,
ничә төне үтеп,
күпме йолдыз күктән атылган.
Яңа йолдыз кирәк иде аңа,
аның чормасыннан ачылган.
Табылмады күпме эзләсә дә.
Тумагандыр.
Туар бер заман...
Яңа йолдыз инде эзләми ул.
Чормасында ләкин ул һаман.
Бөтен күкне күрә.
Бернәрсә дә
читтә калмый инде күзеннән.
Иске йолдызларга карый-карый
аерыла алмый күгеннән.

* * *

Життеләр китәсе көннәр дә.
Әле сез бәхилләп калмагыз.
Кызарып кояшлар баеганда
без киткән якларга карагыз.

Житәр ул сагыныр вакытлар,
хисләргә бирәү дә баш түгел:
килер бер әйләнеп кайтасы,
безнең дә йөрәкләр таш түгел.

Утларын сүндереп китмибез.
Йөрәкләр калсыннар кабынып.
Калдырып китәбез сагышын,
көтегез безне дә сагынып.

* * *

Мөстәкыйль һәм үзебезгә үзебез
хужа кебек булып йөрибез.
Кемнәргәдер нидер аңлатабыз,
акыл сата-сата йөрибез.

Әллә нәрсә генә йөртә безне.
Алып китәр икән кайларга?
Юк!
Кешегә ирек бирелмәгән,
хокукы юк аның сайларга...

Аңлыймы соң кеше үзен-үзе?
Үзен-үзе кеше күрәме?
Мең бәлагә,
мең хәсрәткә тарып,
үзен-үзе белми үләме?

Мин: беләм, дим.
Аңлыйм, дигән булам.
Гомер буе шулай алдашам...
Инде күптән даһи булыр идем
мин үземне-үзем аңласам.

* * *

Яратмаган безне тигез итеп,
яратмаган безне тиң итеп.
Бирелгәне яки бераз артык,
йә бирелгән бераз ким итеп.

Мин үземне синдә таба алмам.
Син үзеңне миндә тапмассың.
Кереп кара,
әгәр керә алсаң,
ачып куям күңелем капкасын.

Син йөрерсең аның тирәсендә.
Үтә алмассың ачык булса да.
Сак астында һаман,
синдә, миндә —
ике җанда ике бусага.

Беләбез дә,
күрәбез дә кебек.
Без кешене, гүя, таныйбыз.
Җаннарына аның
үз күзебез,
үз җаныбыз аша карыйбыз.

Кем танысын?
Кем аңласын сине?
Таный алмас, хәтта, үз анаң.
...Игез бала көн дә туа тора,
игез җаннар әле тумаган.



## Барлас Камалов

# АДАШКАН АДӘМНӘР

ПОВЕСТЬ-ХРОНИКА

### I

Иртән көн шундый матур иде, эшкә барганда Әнвәр сокланып туймады. «Август елмаеп туды. Иртән чык күп төште, көн эссе булыр»,— дип уйлады.

Көн, чыннан да, нык кыздырды һәм өйлә авышып күпмедер үткәч, иләмсез болытлар кабарды, җилләп-давыллап яңгыр килде. Шул тикле яшенләде ки, күзләр камашты. Әнвәр үзләренең подъездына кайтып җитәрәк яшел озын чыбыркысын дуамалланып болгады да очын җиргә салды. Шул мизгелдә үк баш өстендә көчле шартлау булды. Дәһшәтле шартлау! Егет хәтта тетрәнеп китте.

Җебенә-төгенә кадәр чыланып бусагадан атлаганда, аны хафага төшкән Ханифә түти каршылады.

— Лычма булдыңмы, улым? Бигрәк каты ява. Әйләнеп-тулганып килә. Котны алып яшен ата... Чишен, алыштыр киемнәреңне...

— Зыян юк, әнкәй. Тоз түгел, эремәбез, диләрме? Ә яшен шәһәрдә куркыныч түгел бит ул, яшен кайтаргычлар адым саен...

Үз бүлмәсендәге өстәлдә конверт күрү белән, Әнвәр яңгырны да, дөбер-шатырын да онытты кандай булды, елмаеп куйды: бик тә таныш кулъязу! Егетнең каратут йөзенә көләчлек җәелде, кара күзләрендә рәхмәт белдерергә теләгәндә генә кабына торган җылы нур-очкын күренде. Җанында үтә татлы ләззәт уянуын тоеп, ул таза иңбашларын уйнаклатып алды, учларын уды, тумра кара чәч бөдрәләрен кушучлап артка сыпырды.

Аның күз алдына Гөлнара килде. Зур зәңгәр күзләре, нурлы керфекләре, чәчәк таҗыдай иреннәре, дөнья кайгыларын оныттырырдай мөгамәләсе...

— Очрашуны да көтмәгән, кызыйның сабыр канатлары сынган,— дип сөйләнде ул, сөенечле хәбәр өметләнеп.— И-их, Гөлнарам!

Барлас КАМАЛОВ (1930) — *прозаик «Өметең өзелмәсен», «Җир кочәре» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Конвертны ачты, чәмләнеп кереште. Шунда... тагын яшен аткандай булды. Төз, озын гәүдәсе чүкте, әйтерсең лә эченнән сулышын чыгарып бетерделәр. Чыраена көл төсе йөгерде, аскы иренен тешләштергәли башлады, сулышы тигезсезгә әйләнде, чигә тамырлары ярсып тибенде. Хат юллары биешәләр иде кебек.

Хат, татарның күркәм йоласын сакламыйча, сәлам-тәбриксез башланган иде.

*«Әнвәр! Хыянәтче син! Мин моны карбыз шартлап ярылгач язам. Син җае чыккан саен: «Кеше — карбыз түгел, аны кисеп карап булмый»,— диярга ярата идең. Инде менә үзең пычаксыз ярылдың.*

*Партиядән чыгу-чыкмау турында фикер йөртеп, сүз кузгаткалаганда, шул рәвешле мине сынап каравың түгел микән, дип кенә уйлый идем. Син акрынлап әнә нинди карарга хәстәрләнгәнсең. Шәһәр газетасыннан төзелеш идарәсе парткомыгыз секретаре язганны укымасам, үзең килеп әйтсәң дә бу хәбәргә тиз генә ышанмас идем.*

*Партиядән чыгарга дип гариза биргәндә уйладыңмы икән, син бит шәһәр Советына халык депутатлыгына кандидат итеп күрсәтелгәч, читтән торып төзүче инженерлар институтын тәмамлап килүче үңган прораб буларак кына түгел, коммунист буларак та сайлаучыларның яклавын таптың. Егерме биш яшеңдә «Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе» дигән исемне биргәндә дә партия солдаты булуыңны хәтердә тотканнардыр дип беләм. Барсына да төкердең булып чыгамы?*

*Партиянең хәле авыр чакта, аңа һәрьяклап һөҗүм көчәйгәндә, аңа булышлык зарур көннәрдә, давыл ботарлаган корабтан качкан күсе кебек, аның сафларыннан чыгуны ни дип әйтергә кушар идең?*

*Акылым ирешмәгәч, үземне синең урынга куеп карадым. Югары белемле педагог, комсомол райкомында секретарь булып эшләгән укытучы-тәрбияче, партиядән ихтыяри чыгып китсәм, бүгенге укучыларым миңа ни дияр иде? ВЛКСМ райкомы бюросында партиягә керү өчен минем кулдан рекомендация алган егетләр, кызлар күзенә нинди намус белән күренер идем? Мондый адым идеалларга хилаф кылу, үз капкаңа үзең дегет сылау булыр иде ләбаса!*

*Бер шәһәрдә, бер урамда үссәк тә, бер мәктәптә укысак та, бик аз белгәнмен икән сине. Ә бит мин сине үңган-булган, кешелекле, олы йөрәкле, тотрыклы ир-ат дип хөрмәтләдем.*

*Качкынлыгың белән мине рухи йокыдан уяттың, аңымны сискәндереп чаң суктың. «Парлы тормыш корсак, арка таянычым, яшәешем терәге була алырмы соң ул?» — дигән соравыма җавапны бөтенләй бүтән яктан эзләүгә этәрдең. Инде әйтим: сиңа ышанычым бетте.*

*Казан сабан туенда булган вәгъдәләшүне юк дип сана. Бүгеннән соң күрешүнең, аңлашу-мазар дип очрашуның һич кирәге юк. Бу — минем соңгы сүзем.*

*Гөлнара. Июль, 28».*

Әнвәр фәһеменә дә китерә алмаган бу сүзләрдән күкерт кебек кабынды, бизгәк кызулыгы белән хатны йомарлап атканын тоймый да калды. Беравыктан акылы өстенлек алды, ярсуы кими төште, вәсвәсәгә биреләмәскә, каушап калмаска тырышты. Ул кәгазь битен идәннән күтәреп, өстәлгә җәеп салды, хаттагы җыерчыкларны язмак булып азаплады. Кәгазь игә килмәгәч, аны шул килеш пинҗәгенең куен кесәсенә тыкты да ашыгып киенә башлады. Аның борчулы-сәер кыяфәтен берәү дә күрмәде. Әнисе кибеткәфәләнгә чыгып киткән иде бугай (әллә ничә төрле талоннарын учлап йөгерәдер бичара!), тимер юл вокзалында эшләүче энесе хезмәтеннән кайтып җитмәгән.

Әнвәр атлыгып урамга чыкты. Асфальтта күләвекләр ялтырый иде. Талгын гына җил исә. Күк йөзе болытлардан арынып бара, үзе дә юылып, чистарынып калган төсле.

Мәрҗани мәчете урамы шәһәрнең үзәк урамнарына караганда тынычрак бит ул. Җомгаларда, гаетләрдә генә гөрләп ала да гадәти көннәрдә әллә ни кайнамый.

Әнвәр Каюм Насыйри урамының аргы башына юнәлде. Хатында араны шартлатып өзүне язуына карамастан, Гөлнара белән күзгә-күз карап сөйләшүне кичектергесез вә котылгысыз эш дип саный иде ул. Ни гомер җайланган, еллар буе дәвам иткән, югары ноктасына — максатка якынлашкан мөнәсәбәтләрне юкка чыгарырга маташуны — хет үтерсеннәр! — егет аңлый алмады, аңларга теләмәде дә.

Әтисе каны күчкән тамырларына, дип фикер йөртте Әнвәр Гөлнара турында. Гыйззәт агай коммунистлар партиясендә кырык елга якын бит, утыз сигез ел. Шагыйрьләрнең берсе сыман, җиһан йолдызларсыз булмаган кебек, коммунистларсыз яшәү мөмкин түгел, дип санаучы зат. Иманы шундый. Бер исәпләсәң, шул тикле нык инанулы була алуга сокланырга гына кирәк. Иманы хакына утка да, суга да кергәннәрнең әшен дәвам итәм дип белә ул. Илдәге көйсезлекләрнең, йөрәк әрнеткеч хәлләрнең күбесе өчен җаваплылыкны да бүлешергә әзер бугай Гыйззәт абзый. «Мин — рядовой коммунист, партия башлыкларының кылганнары өчен хөкем каршына басарга теләмим»,— дип тормый. Күрәсең, барча җиңүләребезне оештыручы көч партия булды һәм булып кала дигән ышанычы какшамаслыктыр. Кем генә ни нәрсә димәсен, Гөлнарага тормыш биргән кешеләрнең берсе — көне өчен генә түгел, дене өчен дә яшәгән ир — гомере буе диярлек партиянең район һәм шәһәр комитетларында төрле урыннар биләгән агай бормакай булмаган...

## II

Алтмыш ике яшен тутырып килүче Гыйззәт Зарипов моннан ярты гасырга якын элек булган бер хәлне һич оныта алмый. Ул хәл армиядә хезмәт иткәндә дә төшләренә кереп йөдәтте, институтта укыганда да әледән-әле исенә төшә торды. Гаилә башлыгы булып, кызларын үстергәндә дә онытылмады. Үзәгенә үткәнгә шулайдыр.

... Сугыш вакыты. Кырык икенче ел. Кырлач ае суыклары.

Колхозның нәсел айгырын җигеп, Казаннан килгән ниндидер бер башлыкны Канашка, поездга илтеп куярга җибәрделәр Гыйззәтне. Ир-ат затыннан анда барырлык бүтән кеше булмагандыр инде, күрәсең. Начальник ир-атны озата барырга олаучы итеп хатын-кызны җибәрмәсләр бит инде.

Яртугай авылының Канаш станциясен илле чакрым исәплиләр. Авыл картлары кайчак: «Атың начар булса, алтмышка да җыела яза»,— диләр иде. Ул елны Ташбуа районы аша чуен юл узмый иде әле. Кышларын Казанга юл Канаш аша гына, җәйләрдә исә Тәтешкә пароходка чыгу мөмкинлеге дә бар иде...

Ни җитте ат белән тиз генә урап кайтырга бирәү дә кыймый торган юлны Гыйззәт көнендә әйләнергә ниятләде. Колхоз рәисе Кәлимулла карт: «Айгырны өшәндерәсе булма, матри, юлда туктап төн кичәрсең!» — дип төрпе генә кисәтеп калса да, малай (үзенә егет инде!) колагына элмәде. Айгыр шәп иде, шуның дәртенә ышангандыр инде.

Кайтуын да кайткан булыр иде, ярты юлны үтүгә, коточкыч буран купты. Айгыр юлдан сапты. «Адашсаң, гел бер тирәдә әйләнеп йөрисең»,— дигәнне ишеткәне бар иде Гыйззәтнең. Чыннан да шулаймы икән дип, чанасыннан бер култык салам ташлап калдырды. Бата-чума байтак йөргәч, күземә генә күренәме әллә дисә, ат шул саламга килеп чыкты. Тәмам аптырады егет. Юлдан килгәндә җил уңнан бәргәнен абайлап алганнан соң туры айгырны ул үз иркенә куйды, дилбегәне тотмады, аның очын чана мөгезенә бәйләде. Туктап калса, атның да, үзенең дә туңып үләсен белә иде. Күпме баргандыр — ул минутлар тәүлек булып тоелды — каршыда бер кара нәрсә күренде. «Авыл! Кырый йорт бугай!» — дип куанды Гыйззәт. Юртак каралты-кура буена килеп туктады да шикелле. Чанадан төшсә... каралтымы дигәне салам эскерте булып чыкты. Юлаучының бүтән бер генә

чарасы да калмаган иде, айгырның аркалыгын бушатты да чанага менеп, толыбына төренеп ятты. Ат салам йолкыштыра башлады, аннары кыштыр-кыштыр чәйнәргә кереште. Бу тавыш берничә җәяүленең каты кар өстеннән атлап килүе төсле тоелды. Гыйззәт белә торып сискәнде, коты кимеп калды, күңел кыллары шөмрәйде. Сикереп торды, толыбын салып, салам күченә килде. «Кешеләр йөрмәс тә йөрмәс бу гарасатта, ә минә бүреләр килеп чыкса ни хәл итәрмен? Айгырны бугазлап ташласалар?» Шушы дәһшәтле уй аны дер-дер калтырата башлады. Ул бармаклары туңып, аннары уттай кызышып, суелып беткәнче салам йолкыды. Бер шырпы сызды — сүнде, икенчесеннән, өченчесеннән дә рәт чыкмады. Әйтерсең, җил аңа юри үчегә, мыскыллап көлә, юлбасарларча сызгыра һәм сызган бер шырпысын сүндерә бара иде. Куллары тәмам савылып төште дигәндә, каптагы соңгы шырпыдан көч-хәл белән ут үрләп китте. Байтак саламны яндырды ул. Колхоз башлыклары килеп чыксалар, гарипләндергәнче кыйныйсыларын, аннары судка тарттырасыларын белә торып яндырды. Бәгыренә — суык, күңеленә бүреләрдән курку үткән иде. Азаплана торгач, учак җылысына алданып йокыга киткәнен тоймый да калды.

Җилегенә кереп оялаган өшүдән уянып китсә, кышкы таң капкасын ачкан, иртәнге эңгер-меңгер җиткән. Яктырып килә. Буран басылган, күк йөзе болытлардан арынган. Гыйззәт бик кыенлык белән генә аягына басты, әллә ни гомер маташкач кына буыннары язылды. Айгырны да калтырау алган иде. Аның өстен ап-ак бәс сарган. Ул, күзләрен чагырайтып, үзен юлга җигеп чыккан адәмгә карап тора. Толып исә малкайга да, хуҗасына да файдасыз килеш чанада төн кичкән.

Уңны-сулны чамаларлык булып яктыргач, Гыйззәт бер-ике чакрымдагы авылны шәйләп алды. Як-ягына салам маяклар утыртылган юл да якында гына булып чыкты. Тик аны төн караңгысында, бөтен дөньяны буран дулатканда күрәсеңмени?!

Юл катысына чыгу белән, Гыйззәт чөңгереп җибәрде, айгырны ашыктырды, үзе тәртәгә ябышып янәшәдән чапты. Тәмам тынына капканчы йөгерде, алай да җылына алмады шикелле. Чанага аугач, йөрәге чәнчешкән төсле булды. Бер мәлгә сулыш алалмый торды. Аннары гына күкрәк читлеге эчендә ниндидер әлмәк-бик ычкынганга охшап, сулыш алу иркенлеге килде.

Кайту ягына айгыр аерата кәефле юыртты, ә егетнең бәгыренә үткән суык тешләрен-тешкә бәрдереп тинтерәтә иде. Ул янә тәртәгә ябышып, айгыр белән узышырга теләгәндәй чапты, хәлдән тайгач, тагын чанага барып ауды...

Ялан басуда төн кичүнең азагы шул булды: Гыйззәтнең дәһшәт имгән организмы йомшады, егет ике-өч атна урын өстендә хаста ятты. Үпкәсе шешер дип әнисенең коты алынган иде, анысы ук булмый калды. Нервылары чыгырдан чыгып какшаганлыгы исә күз алдында иде. Йокысыннан: «Бүреләр!» — дип кычкырып уянулары, төннәрен әлләниләр сөйләнеп саташулары тиз генә бетмәде. Кыскасы, гомере буена шом булып оялады бу вакыйга аның җанына. Коңгырт күзләрендә мәңге эремәс хәсрәт күмере катып калды шикелле.

Монысы — табигать зилзиләсенә, Канашка сәфәренә бәйле шом, үсмер чакта котын алган хәл. Ә менә соңгы араларда чукрак-сукырлар утравында көн итә диярсең, ярым елак, томан-су, кар тыны бәреп торган яшәешендә ул аңлатуы кыен төстә шомлана башлады. Тынычланмаммы дип атнадан артык бакчада яшәп бакты. Юк! Анда да үз-үзе белән бәхәсләште, төшендә генә түгел, өнендә дә торымнан-торымга кычкырынкы сүзләр белән сөйләште. Ничә төн рәттән «Бүреләр!» дип ярсынып уянды. Кемнәрне ерткычларга тиңләве булгандыр. Ярый әле, казна эшендә чагы түгел, пенсиядә. Күп кенә сәерлекләренә хатыны Сәкинә белән авылдан килгәләп торучы апасы Гөлфирә генә шаһит булып калалар. Бәхеткә каршы, гомер иткән хәләл җефете дә, карындаш туганы да өйдән сүз чыгаручылар түгел иде...

Бакчадан кайтуга газеталар җыелган иде. Гыйззәт көн буе шуларны укыды, тынып торды. Аннары күкерт сыман кабынып китте дә, читлектәге яралы юлбарыс кебек ыңгыраша-сызлана, өй түрендә йөренә башлады.

— Халыкка әйтер сүз, имеш! — дип сыкранды ул, кулына «Советская Россия» газетасының июль азагындагы бер санын бөкләп тоткан килеш.— Кул куючылары кемнәр бит югыйсә, иллә-көндә абруйлы дия торганнар. Шулар хагын-нахагын бергә укмаштырганнар. Кая чакыралар? Нәрсәгә өндиләр, ә?

Гыйззәт Зарипов йөрүеннән шып туктап, язу өстәле артына барып утырды, кулындагы газетаны җәеп салды, кечкенә вазадан юан кызыл карандаш алып, мәкалә юллары астына тырышып-тырышып сыза башлады.

«... Без коммунистлар партиясенә мөрәҗәгать итәбез. Үткән җитмеш елдагы җиңүләр һәм уңышсызлыкка дучар булулар өчен генә түгел, соңгы алты фаҗигале ел өчен дә барлык җаваплылык аның өстендә. Фаҗигале елларда ул башта илне җитәкләде, аннары хакимияттән баш тартты, хакимиятне җиңел акыллы һәм булдыксыз, безне бер-беребез белән низаглаштырган, үле туган меңнәрчә законнар үрчеткән парламентарийларга бирде. Ул законнарның фәкать халыкны кабалага сала, илнең җәфаланып беткән гәүдәсен кисәкләргә бүлә торганнары гына исән. Коммунистлар партиясен үзенең юлбашчылары җимерә, алар, партбилетларын ташлап, берсе артыннан икенчесе каршы як лагерына качалар — саталар, хыянәт итәләр, әле күптән түгел генә иптәшләре булган кешеләр өчен дар агачы таләп итәләр. Коммунистлар безнең чакыру авазын ишетсеннәр!»

— Дөресме соң бу? Шулаймы соң? — Гыйззәт бу сүзләрне башта авыз эченнән генә пышылдап диярлек әйтте, аннары кеше ишетерлек дәрәҗәгә җиткерде, тора-бара, үзе-дә куймый тәкрарлагач, өй күтәреп кычкырып җибәрде:

— Шулаймы соң?

Тавышка аш-су ягында матавыкланучы хатыны Сәкинә йөгереп килде. Алъяпмасының читләрен бөтерә-бөтерә, бусагада килеш сорады:

— Ни булды инде тагын? Дөнья күтәреп кемне тиргисең?

Гыйззәт җыелышта рәислек иткән кыяфәттә торып басты, ике кулы белән дә өстәлгә таянып, залга төбәлгән кыяфәттә хатынына карады һәм:

— Менә болар белән даулашам! — диде. Тезелеп киткән имзаларны күрсәтим дигәндә, газетаны сыпырып төшерде. Иренмәде, аны иелеп идәннән күтәреп алганда йөзе кызарып-бүртеп чыкты.

— Мә, укы! Фикереңне әйтерсең...

— Туктасана, Гыйззәт,— диде Сәкинәсе, зур зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп.— Бимазаламачы. Аш өлгертеп йөрим ләбаса!..

Песи кебек кенә басып, ул өстәл янына килде һәм газетаны куйды.

— Һы-ы! — дип калды аның артыннан ире.— Һы-ы! Ә менә Виктор Астафьев булдырган! — Ул газеталар өеменнән тагын берсен тартып алды.— «Бер сүзләренә дә ышанмагыз!» — дип каршы чыккан. Бер сүзләренә дә!.. Соң шулай булмый! Кулларны ни язганны акыллары тикшерми микәнни? Мондый чакыруга кул куйган ике генерал — Громов белән Варенников ни уйладылар икән? Мондый өндәүгә кушылыр өчен алар иң әүвәле отставкага китәргә тиешләр ич! Үзләре бик җаваплы постларда утыралар бит. Кемгә зарланалар? Үзләре бөек державага хезмәт итәләр... Һәрберсенең сәясиләшүе хәтәр икәнлекне дә бик белә торган затлар... Байтак прогрессив сәясәтчеләргә мондый хәтәрлекне бәяләп җиткермәү кыйммәткә төште: аның чылбыры утызынчы еллардагы Испания республикасыннан алып Сальвадор Альендега кадәр сузыла...

Сәкинә тагын йөгереп килде.

— Гыйззәт дим, кулларым камырлы, ишектә — звонок, үзең барсаңчы...

## III

Зариповлар фатиры ишегенең кыңгыравына басканчы, Әнвәр байтак уйланырга өлгергән иде инде.

Әтисе ысланып беткән партаппарат кешесе булса да, дип фикер йөртте ул, кызы Гөлнара бит яшь кеше, заманага бүгенчәрәк карый алырга тиеш иде. Ярый, институтның өченче курсында ук партиягә кергән кыз вузда комсомол эшендә, хәтта соңгы курста укыганда партком члены да булган, ди. Мәктәптә укыта башлаган көзендә үк комсомолның район комитеты секретаре итеп сайлаганнар. Анда да, мәгълүм инде, әтисенең кызы булып кала биргән. Яңадан мәктәпкә кайткач та үз кырыгын кырык иткән. Соңгы еллар аңа бөтенләй дә тәэсир итә алмаганнармыни соң?

Гөлнара туташ — яшәешнең җил-давылларына бирешми торган кыяташ да, ди. Моңа аркаланып, дөньяга карашы өчен кешене битәрләргә ярамый. Хокукый дәүләт төзибез, дип талпынганда бигрәк тә. Әмма мәхәббәтгыйшыкны, гаилә коруны, җенем дә бер кушмагае, егет белән кызның, ир белән хатынның интим дөньясын шәрә политикага, киләчәктә җир җәннәте вәгъдәләгән якты идеяләргә бәйләп салып, бер казанда кайнатырга ярамыйдыр лабаса! Чагыштырып, үлчәп бакса, гыйбрәт күз алдында: ата коммунистларның берсе — Гыйззәт абзый партия турында уйлап та карамаган гап-гади биология укытучысы Сәкинә апа белән бик әйбәт гомер иткән ич. Әле дә булса яшь гашыйклардай чукердәшеп яшиләр. Баг алмасы кебек кызлар үстергәннәр. Гөлнара минем партиядән үзем теләп китүемне гафу итә алмый гына түгел, киләчәккә бергә барасы юлларны бикли.

Әгәр мин партия сафында торган килеш кызыл билетсыз иптәшләрдән бер ни белән дә аерылмыйм икән, алай гына дип тә әйтмик, партия үз эченә оялаган комсызлардан, карьеристлардан, алдакчы, күз буяучылардан арына алмый икән, ни дип әле мин ул партиядә тора бирим һәм каһәрләнгән бәндәләрнең языгын уртаклашыйм? Шуның өстенә, бүген миңа партия киләчәгебезне анык күрсәтә алмый икән, ни өчен мин иш янында куш адәм булып йөрергә тиешмен? Партиясез намуслы гражданин, хәләл хезмәт кешесе булып, үз көчем белән көн күреп яшәү начармыни?

«Партиягә кергәндә ни карадың?» — диючеләр дә хаклы булыр. Партиягә мин Совет Армиясендә хезмәт иткәндә кердем. Яшь егет идем. Коммунистларга ихластан ышана идем. Партия җитәкчелегендәге хөкүмәтнең яраксыз эшләре дә ил-көн каршына бу тикле бүселеп чыкмаган иде. Аннан соң сукыр да күрерлек вакыйгалар кичте бит ил башыннан. Эчкечелеккә каршы көрәш дип Указ чыгару, бәяләр күтәрү, йөзем җимеше плантацияләрен кыру нәтиҗәсендә җилгә очырган ике йөз миллиардка якын байлык, яраксыз эчемлекләрдән дөнья куйганнарның гомерләре... Самогончылык котырынуы... Әфганстан фаҗигасе: өзелгән гомерләр, гарипләнгән яшьләр, ата-аналар йөрәгендәге мәңге уңалмас яралар... Тыныч елларда үз илебездә хәрби хезмәт үткәндә һәлак булган дистәләрчә мең яшьләр... Сумгаит, Тбилиси, Баку, Фирганә, Ош, Көньяк Осетиядәге, Балтыйк буе республикаларындагы канлы вакыйгаларга кем гаепле? Ачлык, ялангачлык, торaксызлык, хәттин ашкан җинаятьчелек, мафияләр азынуны кем ничек аклар? Дөньяда иң зур армия асрауны, үзеңә юк, муллага чүп дигәндәй, чит мәмләкәтләргә ярдәм дип мал түгүне ни дип бәяләргә? Инде дә килеп, таянычсыз-терәксез картларның, гарип фронтовикларның үлемтекләренә дип җыйган илле, йөз сумлыкларына һөҗүм дәүләт башы агайларының денсезлеге түгелме? Бичара карт-коры, хәерче мескеннәр почтада, саклык банклары янында шыкыр суык көннәрдә күпме чират тордылар? Аракы чиратлары, тәмәке чиратлары гына җитмәгән иде. Акча алмаштыру чиратларында «күләгәдәге экономика» миллионерлары юк иде ич әнә...

Шуларның барсын күрә торып, әмма алардан арыну әмәлләрен тоймаган хәлдә партиядә калу әхлаклылыкмы?

Шәһәр Советына халык депутаты итеп сайлаучыларга килгәндә, мине яклап тавыш бирүчеләр белән очрашуларда үз карарымны аларга ирештерә

килдем. Берәүнең дә чыраема бәреп: «Син — ренегат!» — дигәне булмады. Мондый фикерне гомерлек өметем, килер көннәрем бәхете дип йөргән Гөлнарадан башлап ишеттем.

Икенче катка күтәрелеп, аз гына сулу алгач, Әнвәр кыңгырау төймәсенә басты. Ишеккә елт итеп өстенә — пижама, аякларына артлары тапталган киез туфлилар кигән Гыйззәт абзый килде. Керү уңаендагы лампочканы кабызып җибәргәч, иң әүвәле аның чебен таеп егылырдай баш түбәсе ялтырады. Карт, гадәтенчә, бик ягымлы булырга теләп исәнләште, җыерчык баса башлаган йөзенә елмаю кунгандай булды, әмма барыбер кабагыннан кар яудырганы ачык иде. Бүтән чаклардагыдан аермалы буларак, йорт башы Әнвәрне өйгә өндәмәде, ым кагып коридорга әйдәде. Ул ике ут арасында иде. Әнвәрнең җиңенә сак кына орынып әйтте Гыйззәт абзый:

— Гөлнара бик кәефсез,— диде.— Өч-дүрт көн инде авырута сабып йөри. Син килә калсаң, өйдә юк, дип әйтергә кушты. Тик мин алдаша алмыйм, хакым юк, намусым рөхсәт итми. Сиңа аның янына кермәскә киңәш итәм. Сөйләшмәячәк. Артыгын тәмсезләнерсез генә. Соңрактыр бәлки, көннәр үткәч... Мин дә әйтим, бик ямьсез эш кылгансыз. Алай позиция алыштыруларны башыма китерә алмыйм...

Әнвәр, коры гына саубуллашып, китәргә мәҗбүр булды.

## IV

Гыйззәт үзенең рухи халәтенә үзе аптырый. Аның сәбәпләрен ачыкларга дип җан атканда, хәтерен киереп, солдат елларындагы хәлләрне искә төшерә, аннары педагогия институтының тарих-филология факультетында, тел-әдәбият бүлегендә укыган елларына әйләнеп кайта.

Шулай була бит ул, кеше үзе узган сукмакның аргы очы күренә башлагач кына артта калган юлына күз сала. Еш кына соңгарган да була. Алай да адәм баласы тормыштан үзен бимазалаган сорауларга җавап тапмый китмәскә тиеш дип чутлый. Кем ул? Кем иде, кем булды? Фани дөньяда ниләр майтарды? Аны рәхмәт белән хәтергә алырлармы, каһәрләпме? Иманы ни иде? Кыйбланы бутамадымы? Иманына хилафлык кылмадымы? Тоткан мәсләге хак идеме? Ялганга табынып, алданганын тоймыйсызмичә, бүтәннәрне тайгак юлга этәрмәдеме? Ил-көнгә зыян китермәдеме?

Институтта уку Гыйззәткә буй җитмәс, ирешеп булмас хыял булып тоела иде. Укый алмам дип хәвефләнүдән түгел. Һич юк! Гыйззәт Зарипов немец фашистларына каршы сугыш беткәннең өченче җәендә туган авылы Яртугай урта мәктәбен шәп тәмамлады. Өлгергәнлек аттестатына бер генә «өчле» дә кертмәгән иде. Шик-шөбһәгә төшүнең бердәнбер сәбәбе — хәерчелек.

Әтисе Габит Зарипов, «Кызыл Яртугай» колхозының гына димик, районның мактаулы тракторчысы, сугышның беренче аенда ук үзе теләп фронтка китте һәм кырык беренче елның декабрендә Мәскәү янында һәлак булды. МТСтан бирелгән броньнан баш тартып, ут эченә ашкынуы чит туфрак тартудан булгандыр күрәсең. Утыз алты яшендә генә иде.

Әниләре Бибинур (ул иреннән бер яшькә кече иде) кырык дүртенче елның мартында дөнья куйды. Урман кисәргә җибәргәч, агач басты. Ябалак урманыннан алып кайтып җирләделәр.

Уналтыр яше тулар-тулмас үзеннән дүрт яшькә өлкән апасы Гөлфирә белән шыр ятим калды. Апасы, җиде класс укыгач, мәктәпкә бармады, колхозда эшли иде инде. Йорт алып бару дигән нужаның юан башы аның ябык иңнәренә төште. Энекәше өчен ул әтисе белән әнисен дә алыштырырга тырышты. Үзенә ни тикле көчкә килмәсен, Гыйззәтнең урта мәктәпне тәмамлап чыгуын теләде. «Укыйсың, энем, ике сөйләшмибез!» — дип кырт кисте.

Йорт-җирләре, каралты-куралары кешенекеннән кайтыш-ким түгел иде. Габит сугыш алдыннан гына үзенең кендек каны тамган нигезгә алты почмаклы яңа йорт өлгерткән иде. Түбәсен, бу яклардагыча әйтсәк, шатрун итеп, тутыя калай белән япты.Урам якка өч зур тәрәзә карап тора. Аларның йөзлекләре шулкадәр килештереп бизәлгән, агач челтәр дими хәлең юк. Урыс капкага төшерелгән бизәкләргә дә сокланмаган кеше калмый. Болар һәммәсе Габитның үз кулы белән ясалган. Үзенә һәйкәл дисәң дә җирендә. Тимер-томыр, машина дөньясында гына түгел, балта-пычкы тотса да кулында нур балкыта иде мәрхүм. Каннан күчкәндер, җаннан ирешкәндер, Гыйззәтнең дә белмәгән эше юк...

Йорт-җир төзеклеге куаныч иде, билгеле. Әмма коймасы биек булса да өйрәсе сыек иде шул ул елларда. Ашамаган үлән-яфрак калмады: кычыткан дисеңме, чөгендер яфрагымы, кузгалакны әйтәсеңме, юанымы. Басуда кыш чыккан бәрәңгедән пешергән кәлҗемә хан сые булып тоела иде. Күрше авылда әнә, Каенлыда, ачтан шешенеп үлүчеләр утыздан артты, диделәр.

Шул тәкъдирдә дә халыкта уен-көлке хисе үлмәвенә исең китәрлек! «Сербияночка моя»! Кычыткан шулпасы эчеп симергәнски моя»,— дип такмаклыйлар иде...

Унынчыны бетергәннең икенче көзендә Гыйззәтне армиягә алдылар. Апасы ялгыз калды. Иртәгә военкоматка чыгып китәсе дигән көнне, сентябрьның җылы кичендә, ике туган аулакта калып, эч серләрен уртаклаштылар.

— Апа,— диде Гыйззәт ихластан, бик үз итеп, сүзләренә җан җылысын кушып,— мин кайтканны көтеп утырма, чык кияүгә. Болай да мин синең аягыңа — тышау, җаныңа богау булдым шикелле. Минем аркада ялгыз кала күрмә берүк. Күңелең үз итәрдәй кеше очраса, чакыр үзебезнең йортка. Мин, кем белсен, хезмәтемне тутырып кайткач, бәлки институтка китәрмен. Анда дүрт-биш ел узар. Югары белем алсам, эше дә, торыр җире дә табылыр... Утырып кала күрмә. Мәңге рәнҗерсең аннары. Мин синең бәхетле булуыңны телим. Болай да мин дип, үзеңне онытып яшәдең. Барсы өчен дә мең рәхмәт сиңа. Беркайчан онытмам изгелекләреңне...

Гөлфирә туган йортыннан озакка аерылып китәсе энесенең сүзләрен бүлдерми тыңлады. Гыйззәт күңелендәге мәрхәмәт аның җанын йомшатты, күзләре яшьләнде.

— Яхшы сүзеңә рәхмәт, энем,— диде ул.— Бер-беребезгә миһербанлы булсак, икебезгә дә җиңелгәрәк килер... Кияүгә чыгарга кыставың гына кирәкми. Чыкмыйм! Йортка кертү дигәнне гупчи ишетәсем килми!...— Апасы куе зәңгәр җирлеккә ак борчаклар төшкән күлмәге өстеннән бәйләп куйган алъяпмасын чишеп атты, күкрәгенә төшкән калын толымын гасабиланып артка ташлады, әйтерсең лә шул ярсу-кискен хәрәкәтләре белән җанына ятышсыз уй-фикерләрне дә читкә селтәп ыргыта иде.

— Ник алай дисең әле, апа? Ник? Гомереңбуе ялгыз яшәрсеңме?— Гыйззәт Гөлфирәгә чекерәеп карады.

— Яшәрмен! Чыгасым юк! — Гөлфирәнең тавышына сәер төсмер калкып чыкты.— Җирдә ямьсезләр үрчетәсем килми. Шөкәтсезләр болай да җитәрлек. Шуларның берсе — мин мескен. Ходайга рәнҗүдән генә куркам...

Үзенә карата соңгы чиккә җиткән аяусыз хөкем чыгарырлык көчне, аеклыкны кайдан ничек тапкандыр, Гөлфирә катгый карарын ташка баскандай әйтеп салды. Моның шушы минутта гына туган фикер түгеллеге ачык иде.

Чыннан да, гәүдәсе, буе-сыны килешле генә булса да, төскә-биткә барып чыкмаган зат иде ул. Әтисенә охшаган, тач Габит: тар гына маңгай, җәенке бит, зур борын, ә яшькелт-соры күзләре орчык белән төртеп тишкәндәй генә. Авызны да кызганмаган ходай. Тешләр сирәк, бармак буынындай эреләр...

Энесе әнисенә охшап чибәр. Ни хәл итәсең, табигатьнең үз кануннары, кемне нинди итүе үз ихтыярында. Аңа әмер бирер хәл дә, караламадагы иҗатын акламага үзгәртеп күчертер чара да юк.

Апасының кистереп әйткән сүзләреннән тынып калган Гыйззәт сүз барышында туган шыксыз тәэсирне бераз гына булса да йомшартырга теләп:

— Хикмәт тышкы чибәрлектәмени соң?! — диде. — Кешенең җаны матур булсын аның. Менә шул кыйммәт тормышта. Әткәй дә өзелеп төшкән матур түгел иде, әмма дөнья бәясе кеше иде. Чын адәм булганга чыккандыр аңа әнкәй дә...

Энесенең бу сүзләреннән соң Гөлфирә, сагая калгандай, як-ягына каранып алды һәм пышылдап диярлек әйтте:

— Алай гына түгел ул, энем. Түгел. Әнкәйнең тутасы Бәдерниса түтинең сөйләгәне булды миңа, матурларны һәр чатта сагалыйлар бит, Бибинурның да үтә чибәрлеге харап итте. Ярый, бәхетенә Габит килеп очрады, диде. Аңа чыкмый хәле юк иде инде, югыйсә кулдан-кулга йөреп гомерен чиклисе иде, диде. Нык алданган булган ул әнкәй бичаракаем, шуңа гына чыккан әткәйгә...

Сүз шунда өзелде. Туганнарның һәр икесенә бик кыен булып китте. Сөйләшә торгач, әнә кая барып чыктылар лабаса. Инде күптән гүр иясе булган ата-аналарын каберләрендә әйләнеп ятардай итеп искә төшерделәр. Иң якын кешеләренә болай кагылу, шул рәвешле хәтергә алу — үзе гонаһтыр ул...

Гөлфирәнең газиз эти-әнисенә карата бер бөртек тә рәнҗүе, үпкәсе, кинәсе юк бит үзе болай. Әлеге ачылып китеп сөйләп ташлавы да үзе эченнән көеп йөргәннәргә тигәч булды бугай инде. Үзенең кияүгә чыгуыннан ваз кичүен энесе алдында нигезләргә азаплануыннан килеп чыкты бугай. Тере адәм баласына хас табигый ихтыяҗлардан, гадәт-йолалардан ваз кичүләре бик ансат кына булмыйдыр шул ул!

Гыйззәтнең күңел эчкәресендә мәрхүмә Бәдерниса түтиенә рәнҗү баш калкытты: сеңлесе хакында ни дип аның баласына шулай сөйләп калдырды икән? Егет халкыннан сак йөрсен, гыйффәтлелекнең кадерен белсен дип, кыз аңына ирештерергә теләгән фикерен аның газиз әнисе мисалында шәрәләндереп сеңдерергә теләдеме икән? Шулайдыр, мөгаен. Бүтәнчә булмас. Әнкәләрен дә, Гөлфирә белән Гыйззәтне дә бик ярата, этиләренә дә «Кияү!» дип кенә тора иде. Үтә диндар иде. Сигез-тугыз яшьлек Гыйззәткә дә: «Иманлы булу болай ул, балам,— дип тезеп китәр һәм Гыйззәтнең кул бармакларын бөкләтә-бөкләтә санатыр иде.— Алланың барлыгын, берлеген, бердәнберлеген тану, Коръәнгә ышану; Мәккәгә барып хаҗ кылу...» Гомере буе Хак тәгаләгә һич икеләнүсез табынган кеше, начарны-яхшыны анык белгән хатын-кыз балага анасы хакында дөресен сөйләүне языклы эшкә санамаган булып чыга.

Гыйззәт клубтан әйләнеп кайтасы итте. Гөлфирә аны:

— Бар, энем, бар,— дип озатып калды.— Саубуллашасы кешеләреңне күр...

Үзе энесенең капкадан чыгып китүен көтте дә түр тәрәзәгә килде, иң якын кешесе артыннан күз нурын түгеп калды. «Егет булып җитте бәгырькәем, ходай бәхетен түгәрәк итсен!»

Чыгарылыш кичәсенә тектергән костюмын киеп алгач, Гыйззәтнең буе-сыны бигрәк тә сылуланып кала. Каратутлы кешегә кара кием бик килешә. Кардай ак күлмәк белән аерата. Егетнең мөлаем йөзендә нур арта сыман. Куе кашлар астындагы зур коңгырт күзләрендә очкыннар шаярыша башлый кебек. Җиңелчә генә дулкынланып торган чәчләрен дә тарапкүпертеп җибәрсәме?!

Энесе гомерендә беренче мәртәбә гәүдәсенә улчәп тектергән бу костюмлыкны эзләп, Гөлфирә аяк табаннарыннан ут чыкканчы чапкан иде. Казанга барып алды. Район үзәгендә тектерделәр. Хәзер әйтүе ансат, аның акчасын ничекләр итеп юнәткәнен Гөлфирә үзе генә белә. Күпме атлан май, күпме күкәй сатып, базарга ничаклы бәрәңге ташып җыйган иде ул аны. Үзенә плащ алуны да кичектереп торды. Каян барсына да бер юлы төткәзәсең? Налоглары күпме иде бит әле аның?! Заемы тагын...

Аның каравы Гыйззәт энәдән-җептән генә төшкән костюмын киеп күзгә каршына килгәндә, апасы үзен җәннәт бакчасында итеп сизде, билләһи! Менә бүген дә туганы киенеп-ясанып клубка юнәлгәндә шул горурлану тойгысын кабат кичерде.

«Саубуллашасы кешеләреңне күр...» — дигәндә Гөлфирә, барыннан да битәр, колхоз рәисенең кызын, энесенең классташы Мөсфирәне күз алдында тотты. Матур, акыллы, әдәпле кыз. Гыйззәт белән сигезенче класстан бирле дуслашып йөриләр. Калага ары укырга китмәде, мәктәптә өлкән пионервожатый итеп калдырдылар...

Армиядә Гыйззәт Зарипов хыялына да китермәгән җирдә хезмәт итте. Мәскәү янында. Шелково дигән җирдә.

Унтугызга җиткәнче аның ил башкаласын күрү мөмкинлеге бөтенләй булмады (аның гына түгел инде, бик күп авыл балаларының шулай!). Хәтта Казанга да ике тапкыр барып кайткан килеш китте ул хәрби хезмәткә. Мәскәүгә кайчан, кем белән, нинди акчага барып чыга алсын ди? Баргач кайда тукталсын, кемнәрдә яшәсен?

Солдатка килгәч, юк дигәндә дә ике айга бер тапкыр Мәскәүдә булу җае чыкты. Махсус экскурсияләрне бик яратты ул. Килеп чыккан саен Кызыл мәйданда булырга, Кремльне күрергә тырышты.

Гыйззәт әйбәт хезмәт итте. Авылда үскән егет бит. Сәламәтлеге шәп, кул-аяк нык. Баш түгәрәк, өлгер эшли. Иркәләнеп-назланып үсмәгән. Тамагы тәм-том гына даулап интектерми, йокысы ястык-түшәк сорап аптыратмый. Физик эш өркетми, кулына ни алса, шул ятышып тора. Хаксызга кырыс караш та күрсәтмәс, үзен кыерсытырга да юл куймас, кирәге калса, сдачаны тутырып бирүчеләрдән. Җитмәсә ротада татар егетләре байтак. Алар белән шаярырга ярамаганны бүтәннәр тиз арада муекларына урап куйдылар.

Татар егетләренең бик күбесе солдат вазифаларын җиренә җиткереп үтәүчән. Шуңа командирлары бик яраталар аларны.

Бер ел дигәндә Зарипов кече сержант булды. Комсомол оешмасының рота бюросына әгъза итеп сайладылар. Тагын бер ягы белән хөрмәт иттеләр аны. Авыл мәктәбендә укыганда район газетасына мәкаләләр язудан башланган һәвәслеге солдат булгач тагын да арта төште. Ул округ газетасына да, «Красная звезда»га да язгалый торды.

Армиягә чакырылуына ел ярым дигәндә, аның белән замполит бик иркенләп, ачыктан-ачык сөйләшәсе итте.

— Миңа, Зарипов,— диде ул,— синең сугышчан һәм политик әзерлек отличнигы булуың ошый. Комсомол эшендә дә ихластан тырышасың. Минем белүемчә, син институтка керергә җыенасың, дөресме?

Шулай диде дә, сержантның җавабын да көтмичә өстәп куйды:

— Бер генә ягың кәефкә тия: җыелышларда еш сөйлисең, газеталарга күп язасың. Дәртеңне баса төшсәң, үзеңне партия сафына кабул итәрбез...

Мәскәү округы газетасының һәм «Красная звезда»ның штаттан тыш хәрби хәбәрчесенә замполит шундый шарт куйды. Бу хәл сержантны тетрәндерде, өнсез итте. Гыйззәт Зариповның күзләре дөньяга шар булып ачылды. Малайлык чоры белән саубуллашу сәгате шул көнне сукты шикелле. Аның миендә байтак сораулар яралды. Партиягә чукрак-телсезләр кирәк миканни соң? Дөреслекне күзгә бәреп әйтүчеләр, тәнкыйть хәбәре язучылар (хәер, хезмәттәшләрен бик хаклы мактап та аз язмады ул) коммунистлар сафында булырга тиеш түгелме? Замполит тикле замполит, Совет Армиясенең кадровый офицеры нигә мондый киңәш бирә әле? Мин партия сафына институтка «льготный шартларда» узу өчен керергә җыенаммыни? Мондый әрсезлекнең ике ятып бер төшемә кергәне дә юк лабаса...

Бу әңгәмә вакытында Гыйззәт Зарипов замполитка бернәрсә дә вәгъдә итмәде. Ай чамасы гомер уздымы икән, әллә артыгракмы, капитан аны янә чакырып алды, партиягә кабул итүне сорап гариза язарга кушты, Уставны өйрәнергә кирәклеген әйтте һәм сержантның кулына кечкенә китапчык

тоттырды. Рекомендацияләрнең берсен взвод командирыннан сорарга киңәш итте, икенчесен үзем бирермен, диде. Өченче рекомендацияне комсомол оешмасыннан алырга туры киләчәк иде.

Аңлашыла инде, Гыйззәт зур җаваплылык сизеп, борчылып, дулкынланып хәстәрлек күрә башлады. Взвод командиры рекомендацияне бер дә кыенсынмыйча бирергә булды. Комсомолдагы егетләр дә Зариповны бер тавыштан партия әгъзалыгына кандидатлыкка тәкъдим итте.

Арттырып-күпертебрәк әйтсәк, Зарипов Уставны яттан белә иде инде. Буш сәгатьләрендә Ленин бүлмәсеннән, китапханәдән чыкмады, көндәлек матбугатны тоташтан укып барды. Партҗыелышта илнең эчке һәм тышкы хәлләренә кагылышлы сорауларны күп бирәләр, диделәр. Сынатырга ярамый иде. Сугышчан һәм сәяси хәзерлек отличнигының көймәсе комга терәлде диярлек булмасын!

Иртәгә партоешмада җыелыш буласы дигән көнне Зариповның редакция өстәлендә айдан артык яткан мәкаләсе «Красная звезда»да басылып чыкты. «Онытылган традицияләр» дип атала иде ул. Частьта аны укымаган кеше калмады диярлек. Ул мәкаләдә яшь сержант гаскәрдә элеккеге күркәм традицияләрнең онытылып баруы турында язган иде. Гыйззәт моның бомба шартлагандай тәэсир ясаячагын фәһеменә дә кертеп карамаган иде.

Замполит сержантны тыңлап та тормастан ук әйтте:

— Синең мәсьәлә ачык, Зарипов. Үз коллективы өстенә лаканы белән юынтык су койган кешенең коммунист булырга хакы юк. Мин үз рекомендациямне кире алам, — диде.

Җыелышны Гыйззәт буталчык төш сыман гына хәтерли, әмма хәтерли. Оешмадагы коммунистларның тавышлары ярты-лаш диярлек икегә бүленде. Яклаучылар яшь офицерлар һәм сержантлар иде, кадровый өлкән хәрбиләр каршы чыкты. Шактый озак бәхәсләштеләр, кызып-кызып китүчеләр дә булды, ләкин сержант Зариповны партия әгъзалыгына кандидатлыкка кабул итмәделәр.

Рухи суйдылар егетне. Нахакка суйдылар. Алай гына дию дә аз, күпләр аңардан читләштеләр, әйтерсең лә Гыйззәт Зарипов махау чиренә дучар булган иде. Взвод командирына рәхмәт, читләшмәде, суынмады, егетнең хәленә керә белде, төчеләнеп түгел, ирләрчә юатты, тынычландырырга тырышты.

Бәла ялгыз йөрми, диләр. Хактыр. Мөсфирәдән икенче ай инде хат юк иде. Гыйззәт моңа эчтән көя, бик борсалана иде. Юкка үрсәләнмәгән икән. Апасыннан килгән хат авылданиләр булганын ачыклады.

«Гыйззәт туганым! — дип язган иде Гөлфирә. — Сиңа күп сәламнар юллыйм, имин хезмәт итеп, сау-сәламәт туган илләргә кайтырга язсын.

Үзем, шөкер, бүгенгә сау-сәламәт, бер җайга гына яшим.

Бик кыен булса да сиңа күңелсез хәбәр язарга туры килә. Мин язмасам да хәбәр итми калмаслар иде.

Мөсфирә иргә чыкты. Киявен Казан егете диделәр. Ниндидер министерствода эшләүче түрә малае, имеш. Узган җәйдә танышкан булганнар, ди. Авылга кайтып алып китте Мөсфирәне. Үзем укытам мин аны дип әйтә, ди. Бу минем йөрәккә пычак кадаганнан ким булмады. Сиңа бигрәк тә авырга килер. Шулай да артыгын бетеренмә, энем. Нишләмәк кирәк? Шулай язгандыр. Син кыз таба алмаслык егет түгел, насыйбы чыгар.

Мөсфирәнең вәгъдәсендә тормавы, сине көтмәве бик начар. Шулай да, алла үзе генә белә, бәлки хәерлегәдер әле. Вәгъдәсез хатын-кызның ирне бәхетсез итәсен көт тә тор, диләр бит.

Кызының сине ташлап кияүгә чыгуы бер хәл, атасының бик эреләнеп әйткәнен дә ирештерделәр. «Чибәр Габит малаен көтеп утырырга минем кызның башына тай типмәгән лә!» — дигән. Ичмаса мәрхүм әткәйне кушаматы белән телгә алмасын иде. Коммунист председатель бит ул, кеше хурлап, үзен зурлап йөрергә ни хакы бар аның?...»

## V

Эшендә дә Әнвәрнең хәлен сизми калмадылар. Идарә башлыгы туп-туры сорады:

— Авырмыйсыңдыр бит, Әнвәр дус? Килеш-килбәтең балтасы суга төшкән татарныкы кебек. Әниеңнән наз-нигъмәт җитмиме, әллә сөйгән ярың салкын сөйләшә башладымы? — диде.

— Тавышсыз мылтыктан аттылар, шуңадыр,— дип җавап бирде егет.

Әнвәрнең сүзләре беренче ишетүгә тиз генә аңлашылмаслык тоелса да, идарә җитәкчесе төшенеп алды.

— Астыртын кешегә юлыктыңмыни? — дип сорады.— Бирешмә, нык тор. Унҗиде яшең түгел, башыңны ирләрчә югары тот! — дип тә өстәде.

Ана йөрәге — җир йөзендә иң сизгер прибор. Күпне күргән, иреннән яшьли калып ике бала үстергән, мехкомбинаттан хезмәт ялына чыккан Ханифә түти өлкән улының ут йотып йөрүен көне-сәгате белән сизде. Башта ул Әнвәргә бу хакта телләнеп әйтмәде, соңрак чыдамады, күңеле имрәнеп, хәл белеште.

— Эшеңдә берәр чатаклык бармы, бала? Әллә Гөлнара белән арагыздан кара мәче үтмеме? Нигәдер бик бәргәләнәсең бит син,— дип хафалана калды.

Әнвәр аңа һәммәсен туп-туры сөйләп бирде. Ана улының сыңар сүзен дә колагыннан ычкындырмый тыңлады да, хәсрәткә уралып, уйга калды. Аннары гына, улыннан битәр, үзенә сөйләгән төсле әйтә куйды:

— Язмыш, тәкъдир дибез. Ходайның әмере шулайдыр инде дип килешәбез. Инде килеп, тәкъдиреңне сурәтлисе каурый каләмне теләсә кем кулына тоттырсаң, язып күрсәтерләр, улым, язмышыңны...

Әнвәр әнисенә томырылып карап торды, бер сүз дә катмады. Газиз кешесенең мәгънәле сүзләрен күңел әчкәресенә салып куйды.

Иртәгәсен, шимбәдә иртүк, Гөлнара мәктәпкә кузгалганчы барып өлгерү нияте белән Әнвәр янә кызның өенә китте. Алай да соңлаган булып чыкты. Капка төбендә педагог туташның бертуган сеңелесе Гөлзаданы очратты. Институтка укырга китеп барышы иде.

Гөлзада Әнвәр белән бик ихтирамлы исәнләште, апасының караңгылыяктылы ук мәктәпкә китүен әйтте. Егетнең кайтыр якка борылып, берара студентка туташ белән янәшә атлаудан гайре чарасы калмады. Аерылышып китәр алдыннан Гөлзада Әнвәрне токка бастыргандай сүз әйтте:

— Чынлыкны белмичә тәмуг газаплары кичерәсең бит, Әнвәр абый! Күзеңне ачыбрак карар идең дөньяга!

— Аңлат соң, акыллым, миңа шул чынлыкны, ач күземне!..

— Мине дөрес аңласаң, бүген ачар идем мин синең күзеңне...— Шулай диде дә, Гөлзада үтә ваемлы кыяфәттә китеп тә барды.

Әнвәр аңа тагын нидер әйтмәкче иде, сүзләре авыз эчендә бөялеп калды. Ул вак-вак атлап ерагаючы кызга озак карап торды.

— Чибәр дә соң Гыйззәт абзыйның кызлары! Апалы-сеңелле бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаганнар җитмәсә. Гөлзада сабыррак булуы белән генә аерыла бугай. Юк, сүзгә дә саранрак. Матурлыкны әниләреннән түкми-чәчми алганнар. Сәкинә апа әле дә чибәрләр ярышына чакырырлык димәсәң...

Кызларның дөньяга хәйран калып карauчы зәңгәр күзләре язгы аяз күк сыман. Нурлы-балкышлы зәңгәрлек бар аларда. Озын куе кара керфекләр белән каймаланганга, зифа камышлар тирәләгән зәңгәр күлгә дә охшыйлар ул күзләр. Оста рәссам сызгандай кара кыйгач кашлары да йөзләренә илаһи бизәк булып тора. Татар зәукынча әйтсәк, кашы-күзе кыелган туташлар. Нәфис төз борын, пешкән чия төсендәге чәчәк таҗыдай иреннәр. Каймактай ак тигез тешләрен күрсәтеп елмаюлары һушны алырлык. Безнең заманда сирәк очрый торган чәч толымнарын инде әйткән дә юк. Андый хәзинәне хәзер «Алтынчәч» спектакле куелганда атаклы җырчы ханымда гына күрергә мөмкин. Нечкә билләреннән узып киткән алтынсу калын толымнар туташларның урта буйларын, йомры гәүдәләрен ямьле итә.

Шулай да матурлыкларына була һаваланмый Гөлнара белән Гөлзада. Моның казанып алган хәзинә булмыйча, табигать бүләге икәнен аңлыйлар булса кирәк.

Әнвәр Гыйззәт картның «көннәр үткәч»ен сынап карады, атна буе Гөлнаралар тарафына аяк атламады. Мәгәр каңгырап йөрү аны сыта, изә иде.

Капка төбендә очрашудан соң ике көн узгач, кичке сәгать җиденчедә Әнвәрнең өенә Гөлзада шалтыратты. «Мин республика китапханәсендә утырам. Теләгең булса, килеп чык. Синең өчен кызык булырдай нәрсәләр күрсәтә алам»,— диде.

Егет китапханәгә килеп, Гөлзада янәшәсенә утыргач, туташ аның алдына өч хат салды. Укыйсың да, мин аларны урынына куям, диде. Әнвәр килеште. Галәм серләре бәян ителгән китапка ябырылган төсле, йотлыгып укый башлады. Укыган саен сәерсенде, гаҗәпләнде, йөдәде, аптырады, дөньяда үзенең күзле сукыр булып яшәвенә гарьләнде, үкәләнде.

*«Гөлнарам! Институт тәмамлап туган якка кайтканнан бирле өченче уку елы тәмамланып килә. Директор өчен булмаса да (аның ял итәрлек җае бөтенләй юк диярлек), җәйге каникуллар якынлаша. Эшем әйбәт бара кебек, урта мәктәп директорлары арасында иң яше булуыма карамастан, яман яктан телгә кергәнем юк. Коллектив тату, тырыш. Гаиләдә дә тышкы яктан тәртип хөкем сөрә. Малай туды. Хатын шуның белән мәшгуль әле, укытмый.*

*Тик... йөрәк дигәнең тынгы белми, канәгатьләнү тоймый. Саҗидә урынында син булсаң, мин үземне җәннәтнең дә фирдәвесендә сизәр идем.*

*Еллар үткән саен торымнан-торымга нигә бик үкенәм дисеңме? Соңгы курста укыганда, 8 март мәҗелесеннән соң безнең бүлмәгә аулакка кайткач, мин сине үземнекс итә ала идем бит. Син инде кочагымда һәм карышусыз идең. Юкка әдәп саклап маташканмын. Әгәр кыюрак эш иткән булсам, сиңа: «Авылга китмим!» — дип чәбәләнергә урын калмаячак иде. Әйе, бит?*

*Кыюсызлыкның азагы шул булды: сиңа уч итеп яратмаган кешегә өйләндем, чамасыз ахмаклык эшләдем. Ирләрчә булмады, кыскасы. Кем белә, бәлки бу юлларны сиңа язуым да бик үк акыллы гамәл түгелдер, тик йөрәккә әмер биреп буламыни?!»*

Икенче хаттан.

*«...Июньнең унбишендә язган хатымны җавапсыз калдырдың. Ике атнага якын җавап көттем, юкка гына булды. Заманында кыюлык күрсәтмәвем турындагы фикерем кәефеңне китәргәндер дип уйлыйм. Үткәнне үзгәртеп булмый бит инде, Гөлнарам, дөресен генә хәтерләвем иде.*

*Инде мөнә яңа әрсезләнергә булдым. Конкрет бер тәкъдим белән соңгы тапкыр әрсезләнеп каравым. Сиңа кагылышлы рәвештә соңгы тапкыр бәхет сынавым.*

*Мәгариф министрлыгы җитәкчеләренең, Гөлнарам, мине республикабыз башкаласына, Чабаксарга күчерү турында фикерләре бар. Өч-дүрт көн элгәре генә министр урынбасарында булдым. Һәрьяклап уйларга кушты. Уйланам менә. Синең белән дә киңәшүем. Синең өзеп әйткән фикерең минем ныклы бер карарга килүемә нигез булачак.*

*Эш җиңелдән төгелми. Июльдә мәктәп-интернатны кабул итәргә, диләр. Анда хәлләрнең хөрти икәнлеген ишетә тора идем. Хәер, министр урынбасары үзе дә туп-туры әйтте, авыр участокка җибәрәбез сине, эшне яхшыртуыңа өметебез бөтен, диде.*

*Әгәр мин шул тәкъдимгә ризалашсам, киләсеңме минем яныма? Бөтенләйгә. Гомерлеккә. Тулы нагрузка белән эш булачак. Торак мәсьәләсе бүгеннән хәл кылынган. Мәктәп-интернатның үзендә педагоглар өчен квартиралар бар. Әгәр бик теләсәң, шәһәр Советыннан квартира алуда булышырбыз, дип ышандыралар.*

*Саҗидә авылда, һәммә шартлары булган квартирада кала. Мин киемнәрем һәм китапларымнан башка берни дә алмыйм.*

*Аннары, мәгълүм инде, Гаделҗан Истиев — алиментчы дигән яманатка чыдарга тиеш булам. Ничшим, миннән генә калмаган. Үз балаңны тәрбияләүгә өлеш кертү — котылгысыз бурыч, аннан авырсынырга кирәкми дә, ярамый да.*

*Мин югарыдагы иптәшләргә карарымны бик тиз ирештерергә тиешмен. Шунлыктан синнән дә ашыгыч җавап көтәм. Уйла, уйла, улчә дә хәл ит. Синнән хәбәр алуга, министрлыкка сүземне әйтәм һәм Саҗидә белән никахны юкка чыгару хакында хөкем эше кузгатам. Барсы да законлы булырга тиеш...»*

Өченче хаттан.

*«... Бу хатны Чабаксардан язам. Мин, төшенәсеңдер, яңа эштә. Монда миңа элегрәк уйлаганнан да авыррак буласы икән. Әмма чыдармын, түзәрмен. Үз дигәнемә ирешеп, мәктәп-интернатны алдынгылар рәтенә кертермен дип ышанам. Син миңа канат куйдың, Гөлнарам! Күңелемдә тантана, ахры гына хәерле булсын!*

*Инде безнең башкалага бернечә көнгә килеп чыгу әмәлен таба күр. Безгә мөнәсәбәтләребезне ЗАГС белән көйләү кирәк. Озын-озакка сузмыйча дигәнем. Торыр почмагыбызны, эшләр урыныбызны күреп киту дә бик файдалы булыр. Башта — хәбәреңне, аннары үзеңне көтеп калам.*

*Сәлам, ихтирам, сөю һәм рәхмәт белән: Гаделҗан».*

Хатлар тәэсире Әнвәрне әйтеп бетергесез игәүли иде. Һич кенә дә шигырь тансыклар мәл булмаса да, егет Нәваи сүзләрен хәтерләде:

Дус кешенең яшерен энәсеннән
Дошманның күрсәтеп аткан угы артык.

Соңгы арада Гөлнара белән килешү эзләп өтәләнүе өчен үз-үзен эт итеп сүгү белән генә калмады ул, аяусызланып үзенә: «Адәм актыгы! — диде. — Кемгә дигән, кемгә ялвармак булып йөргәнмен!.. Ике көймә койрыгын тотарга исәп иткән яшерен җанга лабаса! Ышан икән син аның судан пакь, сөттән ак фикер иясе булып сөйләгән борчактай түгәрәк сүзләренә! Үзе итәк астыннан ут уйнатырга тартынмаган туташ дөньяга мөстәкыйль күзлектән карый башлаган кешене хыянәтчегә чутласын әле! Үз мәнфәгате хакына йолдызларга кармак атарга әзер җан икән ич! Монысы, күрәсең, аныңча, вөгъдәгә хилаф та, хыянәт тә түгел... Сүзеңдә тора алмыйсың икән, ихтыяр көчең шуңа да җитми икән, димәк, син әле шәхес булып өлгереп җитмәгәнсең, ди бит әнә сүз рәссамнарыннан олпат бер агай. Кесәдә партбилет булу гына кәефенә ярамаганнарга ярлык чәпәп йөрергә хак та, хокук та бирми ул. Минем партиядән чыгуымны әшәке гаепләвенең сере бик тиз ачылды. Юкәдә икән чикләвек! Телдә Туры Тукай булу гына җитми шул... Ярый әле, кәртләрнең ачылып китүе тиз булды. Беркайчан да үз вөҗданың, үз рухың белән ялган килешүгә күнәргә ярамаганлыгын бу очрак янә бер кат искәртмимени? Андый килешүгә барган кеше ялган идеяләр савытына әйләнеп кала да кала...»

Чебен-черки өередәй ябырылган уйларыннан арына алмыйча, кайту юлында үзе белән янәшә атлаган Гөлзадага да илтифаты җитмәде аның. Аңа ни уңайдан, ни тискәредән сүз әйтмәде. Бу рәвешле атлау кызны да мең дә бер төрле уйга ураган иде.

— Син кайтып җиттең, Әнвәр абый, — диде Гөлзада, мәчеткә якынлашкач.

Егет мәртәкә киткән җиреннән уяндымыни! Аңа үтә кыен булып китте.

— Гафу итә күр, Гөлзада акыллым, дөньядан үткән кеше сыман кайтам бугай. Әйдә, озатып куйыйм үзеңне, — дип акланырга кереште.

— Юк, Әнвәр абый, озатмыйсың, үзем генә кайтам. Принципиально шулай кирәк. Саубуллашканда мин сиңа тагын бер хат калдырам. Монысы — үземнән. Тынычлангач укырсың. Кире җавап бирердәй булсаң, миңа әйтеп тә тормассың, һәммәсенә сүзсез генә нокта куярсың, яме? Шулай дөрес булыр... Хуш! Хәерле төн телим!..

Әйтәсе ансат! Әнвәр Сафинны металлдан койганнар дип уйлыймы әллә ул кызый? Тынычлану кайчан булыр? Ихтимал, гомеренә дә килмәс ул халәт. Азмы дәвага бирешмәстәй җәрәхәткә юлыкканнар?

Ишекне әнисе ачты. Гаҗәпсенүе чыраена чыккан иде.

— Ачкычыңны югалттыңмыни соң, бала? — дип борчылды Ханифә түти.

Улы, аракы махмырыннан кинәт айнып киткән адәм сыман, тиз-тиз җавап бирергә, әнисен тынычландырырга ашыкты.

— Югалтмадым, әнкәй, кесәмдә. — Ул плащ кесәсен учы белән шапылдатып алды. — Әллә нигә онытылып бастым звонокка.

Ханифә улын эчкә уздырды, кабаланмый гына ишекне бикләде, үзе иштелер-ишетелмәс кенә сукрана куйды:

— И-и аллам! Су сөренеп юл таба дигәннәр, синең дә эшләрең бер җайланыр әле... Ниләр дип кенә зиһенең чуалганчы исәптә йөрисең, бала? Ялкыннан котылам дип упкынга төшә күрмә берүк... Аш кайнарлатам, соңладың бит, озакладың...

Җаны тәгам теләмәсә дә, Әнвәр, әнисен рәнҗетәсе килмичә, юыныптаранып өстәл янына утырды. Үзен мәҗбүр итеп, көчләп аш ашады, бер генә чынаяк чәй эчте дә, рәхмәт укып, бүлмәсенә узды. Әлбәттә инде, аны Гөлзада бирсп калдырган хат борчый һәм кызыксындыра иде...

## VI

Гыйззәтнең хатирәләре дулкын-дулкын.

...Өлкән сержант Зариповның институтка керергә җыенып, кабул итү имтиханнарына җибәрүләрен сорап командование исеменә язган рапортына колак салдылар. Тагын икс ай хезмәт итәсе калган булса да, Казанга кайтырга рөхсәт бирделәр. Егетнең башы күккә тиде, шатлык-куанычына чик булмады. Татарстан башкаласына кайтып төшкәч, мин туган җирдә микән, дип ышанмый торды хәтта.

Июльнең егерме тугызы иде. Педагогия институтына документларын тапшырырга да чак өлгерде димәсәң.

«Бу институтны сайлавыңа сине ни нәрсә этәрде?» — дигән сорау куйсаң, Гыйззәт икеләнеп тормастан: «Укытучыларыма ихтирам!» — дип бик кыска җавап бирер иде. Чыны шулай. Яртугай мәктәбендәге бердәм педагогик коллективтагы укытучыларның барчасы диярлек — өлкәннәре дә, яшьләре дә — аның өчен өлге иде. Мәктәп елларында ул шуларга охшарга, алар кебек белемле, акыллы, булдыклы, мәдәниятле һәм әдәпле булырга теләп яшәде. Өлкән классларда исә гап-гади охшарга омтылу чиген узды, педагогның изге вазифасын төшенә башлады, укытучы дигән гали затның яшь буынның биографиясен язышучы шәхес икәнен аңлады. Балаларны яратуы йөзенә чыккан иде.

Кабул итү комиссиясе сәркатибе хәрби формадан килеп кергән мәһабәт буй-сынлы егетне бик җылы каршылады, документларын дикъкать белән күздән кичерде. Гыйззәтнең хәрби частьтан алып кайткан характеристикасын ошатты булса кирәк, комсомол комитетына шылтыратып, институт оешмасы сәркатибенең кабул итү комиссиясенә кереп чыгуын үтенде.

— Демобилизацияләнеп кайткан бер иптәш белән таныштырам үзегезне, комсомол активисты, — диде. Аннары Зариповтан имтиханнар чорына тулай торак кирәкме-юкмы дип сорады. Кирәкмәгән кая инде ул!

Институтның комсомол комитеты секретаре да татар егете икән. Аспирант-физик. Бик тиз танышып киттеләр.

Зур Матур урамындагы элекке монастырьда икән институт тулай торакларының берсе. Шунда урнашкач, Гыйззәт тәүге эше итеп апасына хат язып салды. Кесәсе бик сай икәнлеген яшермәде, азрак акча сорады. Имтиханнарын беренче айдан ук стипендия алырлык итеп бирә алмаса, читтән торып укырга туры киләчәген язды.

Августның егерме икесендә эленгән исемлекләрнең берсендә институтның беренче курсына кабул ителгәннәр арасында «Зарипов Г. Г.» дигән фамилия дә бар иде.

Институт елларында Гыйззәт, гыйлем эстәүнең төмен-ләззәтен белеп, бик яхшы укуы белән бергә, җәмәгать эшләренең дә уртасында кайнады. Беренче курста аны комсомолның рус бюросы секретаре, икенчедә — факультет бюросы әгъзасы итеп сайладылар. Студентларның фәнни җәмгыятенә дә теләп йөрде. Факультетта да, институт җәмәгатьчелеге хозурында да үрнәк студентларның берсе булып китте. Икенче курста аңа Горький исемендәге стипендия бирелде.

Шул курста аңа «Татарстан тарихы»ннан лекцияләр укучы доцент белән бәхәскә керергә, шуның аркасында күңелсезлеккә тарырга да насыйп икән.

Зарипов бөтен группа алдында доцентның «Иван Грозныйның Казан ханлыгын алуы Россияне ныгыту өчен зарур иде. Бу — заманы өчен прогрессив күренеш булды», — дип раславына каршы төшеп сорау бирде. «Мөстәкыйль дәүләтне канга батыру, аның халкын иркеннән мәхрүм итү, коллыкка салу прогрессив күренеш була аламы? Сезнең логиканы дәвам иткәндә, немец фашистларының безнең илгә басып керүләрен дә акларга мөмкин була түгелме соң? — диде.

Доцент агай анасы карынында ук куркып яралган татар иде бугай. Зариповның чагыштыруыннан коелып төште, тотлыга башлады.

— Комсомол члены дыр әле үзегез... Совет мәк-к-ктәбендә белем алган кеше бит сез... Т-т-телегез нәрсә сөйләгәнне колагыгыз ишетмиме әллә?!

Студент белән доцент иптәшнең фикри бәрелешүе Зариповны институтның комсомол комитетында агарту белән очланды. Нинди миһербанлык булгандыр, хисап карточкасына язып шелтә бирмәделәр, оялттылар, интернационалист булырга вәгазьләделәр. Комитет утырышында институтның партком секретаре үзе катнашты. Ул бу сөйләшүнең Зарипов өчен гомерлек сабак булырга тиешлеген әйтте, без бит сезне, иптәш Зарипов, үзебезнең резервтагы студентлардан берсе дип беләбез. Алама фикерләрегезне башыгыздан чыгарып ташлагыз. Сез бит киләчәктә яшь буынга коммунистик тәрбия бирәчәк кеше. Болай үзбелдекләнүнең ахыры хәерле булмавы бар дип үгетләде.

Резерв дигәне дөрескә чыкты. Кышкы каникулдан килгәч, Гыйззәтне факультет партбюросы секретаре, рус әдәбияты тарихын укытучы абзый чакырып сөйләште, партия әгъзалыгына кандидатлыкка әзерләнергә кирәклеген төшендерде. Шунда, йә нигә хаҗәт иде инде, Гыйззәт, сертотмас үрдәк сыман, армиядә партиягә керергә талпынып та теләгенә ирешә алмавын сөйләде. Партбюро секретаре аңа сокланыпмы, егетне аңлый алмыйча кәефе китепме, бик озак карап торды, аннары ярым аптырап әйтә куйды: «Булгандыр... Бездә туры сүзлелекне кайчак өнәп бетермиләр. Минем уемча, сез сөйләгәннәр кабат партия сафына басу теләгегезгә каршы килми. Аннары булган-беткән хәлләрнең баш калкытмавы хәерлерәк...» — диде.

Бу юлы Гыйззәт Зарипов партбюро секретарен кирәгенчә аңлады шикелле. Тик аның күңелендә барыбер: «Шулай кирәк микәнни соң? Дөресен әйтмәү дөрес була микәнни?» — дигән сызлавык торып калды.

Кыскасы шул: халыкларның сөекле бөек юлбашчысы вафатыннан соң туган Гыйззәт Зариповны апрельдә — кандидатлыкка, ә бер елдан, өченче курста белем алганда, коммунистлар партиясенә әгъза итеп кабул күрделәр. Ул елны аны Сталин стипендиаты иттеләр. Икенче курс, алда бәян кылынганнардан кала, Гыйззәт өчен тагын бер ягы белән истәлекле булды. Бу курста ул, бер тапкыр авызы пешеп, кызларга шактый битараф йөргәннән соң, үз дигәнен тапты. Моның өчен илләр гизәргә дә, диңгезләр кичәргә дә туры килмәде. Насыйбы үзе укый торган институтта бер үк курста фән нигезләрен өйрәнә икән ич. Биология укытучысы булачак кыз. Яшәвен дә бер тулай торакта яшиләр, бүлмәләре генә төрле катларда. Сәкинә — икенчедә, Гыйззәт өченче каттa. Кайтканда-барганда күрешкәләп, исәнләшеп йөриләр иде.

Дуслашып китүләренә Сәкинәнең тәвәккәллеге сәбәп булды дисәк, хаталанмабыз. Ул парткомда техник секретарь булып эшләүче якташ кыз

белән ахири иде (ул кыз шушы институтта читтән торып укый). Икесе дә — Балтач кызлары.

Сүз иярә сүз үрелеп, гәпләшеп торганда, районадашы Сәкинәгә «Бүген җыелышта Гыйззәт Зариповны партиягә алалар. Сезнең общежитиедә тора ул, беләсеңме аны? Истфилфакта укый. Горький стипендиаты»,— дигән иде.

Сәкинә көлеп җибәрде.

— Аны кызлар белми димени?! Безнең торакта яшь бит ул...

Секретарь кыз егеткә битараф түгел иде, ахрысы, гел көтелмәгән тәкъдим әйтте:

— Әйдә җыелыштан соң тәбриклибез үзен! Чәчәкләр алабыз, шәп бер китап бүләк итәбез...

Кызлар җыелыш тәмамланганны көтеп алдылар һәм, чыннан да, егетне тормышындагы җитди зур яңалык белән котлап, китап бүләк иттеләр.

Әйтерең бармы, егетнең кәефе килде. Мондый хәлне һич көтмәгән иде бит. Тугашларга ул ихластан рәхмәт әйтте һәм урталарына кереп култыклады да Матбугат йорты каршындагы мороженое кафесына туңдырма белән сыйларга алып китте. Анда кеше әйтүле күп түгел иде. Тоньк ут яктысында, сыйлана-сыйлана, салмак агылган музыка тыңладылар.

Кафедан чыккач, секретарь кыз теләр-теләмәс кенә аерылып, үз квартирасына китте, Сәкинә белән Гыйззәт тулай торакка юл алдылар.

Бу кичтә алар бер-берсенә сыңар гына мәхәббәт сүзе дә әйтмәделәр. Күңелләрен күзгә күренмәс нинди сихри җепләр бәйләп өлгергәндер, шул апрель кичennән башлап гел бергә булдылар һәм дүртенче курста, эшкә билгеләү башланыр алдыннан, студент туе иттеләр.

Ирле-хатынлы Зариповлар авыл мәктәбенә китәргә дигән анык карарда иделәр. Гыйззәт үз районына, бәлки әле үз авылына ук кайту турында исәп йөртә иде. Көтмәгәндә хәлләр бүтән борылыш алды. Өченче-дүртенче курсларда Гыйззәт педагогик практика узган база мәктәбенең директоры юллап-җайлап йөри торгач, Зариповны үз мәктәбенә билгеләтүгә ирешге. Әнә кайда — җебе шунда. Сәкинәгә дә күрше мәктәптән эш таптылар. Яшь педагоглар, шул рәвешле, кала укытучылары булып киттеләр. Әмма пычаксыз суя, баусыз аса торган бер проблема җилекләренә үтте. Торак дигәнең иде ул.

Кеше почмагында өч ел уздырдылар. Гыйззәтне партия райкомына пропаганда бүлеге мөдире итеп алгач кына иске йорттан ташка үлчим дия торган бер квартира бирделәр. Суы тышта, бәдрәф тышта. Әйдә газ бар. Әүвәле утын яккан мич тә газга көйләнгән. Бар уңайлылык шул... Хәзерге квартираларын алар Зарипов партиянең шәһәр комитетында бүлек мөдире урынбасары булып эшләгәндә алдылар. Гөлнара әле иске йортта яшәгәндә доньяга килгән кыз...

## VII

Булды шундый бер мизгел, Әнвәр, язу өстәле янында утырганы хәлендә, конвертны ачарга имәнеп калды. Әйтерсең лә аны ерта башлауга гайре табигый шартлау буласы. Ул гөрселдек көч әҗәл китермәячәк, яралап кан да агызмаячак, мәгәр кешенең җанын сыеклаячак, уйлау сәләтен тарткатачак, матурлыкка соклану тойгысын үтерәчәк, ирнең — ирлеген, хатын-кызның үзенә хас якларын юкка чыгарачак. Аннан соң яшәдең ни дә, яшәмәдең ни! Бары тик җан асрау, бушка икмәк черетү генә кала... Килсә килә бит адәм баласы уена шундый тузга язмаган уйлар. Бөтен бер бәйләм булып...

Егет үзенең шомлана калуына чын-чынлап аптырады. «Чепуха! — дип нервыланды ул.— Ни дип мәлҗерәп утырам әле? Кулымда гап-гади кызлар хаты лабаса! Шулай да гап-гадиме соң?»

Хатта исә мондый юллар бар иде.

*«Әнвәр абый!*

*Бу хатны язарга каләм алганга кадәр мин Идел буе уйлар уйладым. Ник дисәң, язмыш минем алдыма бастырган таш кыяның ике ягында да миңа якын кешеләр тора. Берсе аның — бертуган апам. Икенчесе — син. Моңа тикле сүз белән дип әйтммим, күз карашым белән генә дә сиңа сиздермәгән серемне ачам: син апаны ярата башлаганчы ук мин сиңа гашыйк кызчык идем инде. Апа белән сез унынчы класста укый идегез, мин — алтынчыда. Космонавтика көненә багышланган концертта мин мәктәп сәхнәсендә «Җырлыйм әнием турында» дигән җырны башкардым. Баянда миңа син уйнап тордың. Сәхнәгә чыкканчы ике-өч репетиция уздырдык. Синең уйнавыңа кушылып җырлавы шулкадәр рәхәт иде, мин үземне бик бәхетле хис иттем, ләкин миңа баласытып каравыңа, «үскәнем» дип эндәшүеңә бик ачуым килде. Менә шул көннән бирле йөрәгемнән үземнеке иттем мин сине.*

*Мәктәптә ни карагансыздыр, кайсыгыз кем белән мавыккандыр, белмим, сез бит апам икенче курста укыганда гына дуслашып киттегез шикелле. Сирәк булса да өйгә килгәли башлавың шул чакта дип истә калган. Синең безгә килүләрең миңа дар агачына менәргә боеру белән бер була иде, рас әгәре!*

*Апам — иң якын кешем, аңардан көнләшергә, аның бәхетен күпсенергә минем хакым юк иде. Ә син күңелемә фәрештә булып кергән идең инде.*

*Тора-бара мин апаның үз факультетларындагы Гаделҗан абый белән якыналарын тойдым. Бертуган апамның яшерен «көндәше» буларак, моңа сөенергә кирәк булгандыр югыйсә, сиңа якынлашу әмәлен эзләргә кирәк булгандыр? Мин алай уйламадым, мин сине кызгандым. Апаның сине алдап йөрүенә җен ачуларым чыкты. Инде аларның эшләре гаилә коруга килеп терәлгәч, мин синең күзеңне ачарга булдым.*

*Карындаш туганыма хыянәтме бу? Сиңа булган хисләрем өчен гаепләме мин?*

*Син, Әнвәр абый, зинһарлап сорыйм, шул сорауларга ачык җавап бир. Әгәр мине сатлык җанга санап каһәрләмәсәң, хисләремне кабул итә алсаң, миңа рухи коткару кулыңны суз.*

*Аңлыйм, кызларның башлап сүз кушуы бик үк гадәти күренеш түгел. Бигрәк тә минем башка төшкән шартларда. Зинһар, тыйнаксызлыкта гаепли күрмә: минем һәр адымым — сине чиксез яратуым галәмәте.*

*Гөлзада».*

Хатны бер уку белән генә канәгатьләнмәде Әнвәр. Кат-кат кулына алды. Шулай да аңына андагы сорауларга җавап түгел, кызның саубуллашып киткәндә әйткән сүзләре килде: «Хәерле төн телим».

Моннан да хәерлерәк төннең булуы мөмкинме? Гөлзадага уңай сүз әйтә калганда, кыз туганнарны, булуы ихтимал кодайгыйларны, Гөлзаданы һәм үзен ниләр көтә?

Бу сәгатьләрдә Әнвәр тоташ билгесезлек эчендә калды. Әмма ул күңел томанын куып таратырлык көч-кодрәт табарга тиешлеген белә иде. Юл югалтып озак йөрәргә ярамый. Фани дөньяның адашкан адәмнәре аңардан гайре дә җитәрлек.

Гөлнара белән бернинди мөнәсәбәттә дә булмаган очракта, дип фикер йөртә башлады егет, Гөлзаданың башлап сүз кушуын һич гаепкә-кыекка алмастан, парлы тормыш сукмагына бергә керик дип кул бирер идем. Сеңелне беләм, ихтирам итәм. Күңеле саф, нияте изгедә. Ялганны, икейөзлелекне күрә дә, кичерә дә алмавын менә шушы хаты белән раслап тора... Әгәр кайнар башлылык күрсәтеп, тәвәккәлләп аңа өйләнсәм, дус-ишләр, хезмәттәшләр, күргән-белгәннәр ни әйтер? «Апасыннан гүзәл сеңелесе дип йөргән идеңмени соң? Балдызларга гашыйклык, җизнине сөю борын-борыннан була килгән хәл. Балдыз яшьрәк, ә яшьлек — үзе гүзәллек инде. Балдыз — табышмак, ачылмаган йолдыз», дигән булып тел шомартырлармы? Йә булмаса «Апасы дигәнең — «йөзем җимешләре пешмәгән» булып чыктымы? Шуннан балдыз белән канәгатьләндеңме?» — дип төрттерерләрме?

Чит кешеләрдән битәр, килеп туган хәлне әнигә ничек аңлатырмын? Менә шундый четерекле эштә — өйләнү мәсьәләсендә әни белән сөйләшәсе булмасын иде! Җайсыз, читен, кыен, оят та сыман. Тик ничек инде сөйләшмисең? Әни бит ул!..

Гыйззәт абый белән Сәкинәападан рөхсәт гозерләргә ничек барырмын? Алар моны башларына сыйдыра алырлармы? Тормышта гайре табигый хәлләр булмый тормый, мәгәр бу тикле дә парадокс теләсә кемне сискәндерәчәк бит. Гайбәт китәчәк инде, ил авызын томаларга илле яулык та җитмәс...

Әикенчеләй уйлап баксаң? Бүредән шүрлисең икән, урманга бармыйсың. Шул гына! Сөйләгәннән сүтелер чагым узган. Тагын ничә ел бүйдаклыкта йөрергә мөмкин?

Ошбу мәсьәлә Әнвәргә менә-менә хәл кылынгандай күренә, ул да булмый күңелнең әллә кайсы бер читендә авыр, бәйләнчек бүтән уйлар борынлый, өем-өем бәхет-сәгадәт вәгъдә иткән туар көннәр артка, бик еракка чигенгәндәй тоела башлый. Беравыктан янә тәвәккәллек баш калкыта...

Җан тире түгә торгач, ул иртәгәсен Гөлзаданы күрергә дип ният беркетте. Уртага салып сөйләшәселәр азмыни? Һәр икесенә кагылачакларны өр-яңа баштан фикер иләгеннән уздыру — котылгысыз.

## VIII

Дүшәмбе көнне, уникенче августта, өйгә партия райкомыннан «варисы», Гыйззәт пенсиягә чыккач идеология бүлеге мөдире булып калган иптәш шылтыратты. Сүз җилеме итеп хәл-әхвәл сорашкач, үтенеч барын, бюро исеменнән гозерләвен әйтте.

— Йорт идарәләрендә учетта торучы коммунистларның берләштерелгән җыелышы буласы, Гыйззәт Габитович,— диде яшь мөдир.— Башлыча, мөхтәрәм пенсионерларыбыз инде анда, беләсез. Көн тәртибендә КПСС-ның яңа Программасы турында фикер алышу. Район комитеты сездән, Гыйззәт Габитович, шул җыелышта кереш сүз әйтүегезне, сорауларга җаваплар биреп, йомгак ясавыгызны үтенә. Бүгенгене дә кертеп, җыелыш көнен дә санап, дүрт көн вакыт бар. Сезгә, әзерлекле ветераныбызга, кайбер хәстәрлекләрне күрер өчен бик җитәр дип беләм. Ярдәмегездән ташламасагыз икән, Гыйззәт Габитович...

Зарипов, турысын әйтик, бу тәкъдимгә сөенде. Югыйсә соңгы айларда үзен кирәкмәгән китек балтага чутлый башлап изалана иде. Кәефе китүгә, нервылары шаяруга моның да тәэсире булмый калмагандыр. Шулай да ветеран Гыйззәт яшь мөдир алдында ләббәйкәләнеп төшмәде.

— Алданрак әйтерләр аны, кем, энем,— диде телефон трубкасына.— Темасы үтә мөһим, архиәһәмиятле, орды-бәрде килеп, илаһи-уптым сөйләшә торган түгел. Сүз бит партиябез Программасы турында бара. Хәзерге шартларда...

Бүлек мөдире, Гыйззәтнең үз тәрбиясен дә татырга, аның эш ысулларын өйрәнергә өлгергән иптәш, Зарипов агасының үз сые белән үк сыйлый башлады.

— Архимөһим булганга да сезгә ялынычыбыз төште бит инде, Гыйззәт Габитович. Мондый эшне теләсә кемгә тапшырып булмаганга сезгә, идеология фронтының гвардиячесенә инәлүебез.

Артыгын төчетү Гыйззәткә ошап бетмәде.

— Эш кушканда шундый эпитетлар кулланып сөйләү бар инде ул, кем, энем,— дип бүлдерде. Шулай да мөдирнең гайрәтен чигереп җибәрүдән сакланды.— Ничегрәк иторбез икән соң, әй? Үзәк матбугатта башланган дискуссия материалларын карап өлгерермеме икән? Татарстан газеталарында да байтак фикерләр әйтелде инде,— диде.

Мөдир картның тел төбен чамалады һәм бераз былагайланып, кәефенә ярарга теләп, бераз борчак шыттырып:

— Өлгерерсез, Гыйззәт Габитович,— диде.— Аннан соң сез алар белән даими һәм җентекләп танышып барасыз ич! Төнлә йокыгыздан уятып сорасалар да, һич ялгышмыйча җавап бирерлек ич сезнең хәтер. Килештек-

ме, Гыйззәт Габитович? Килешик инде, килешик. Райкомның таяныр талы бит инде сез...

«Таяныр тал» дигәне Гыйззәтнең җанына ятты, аны мәс итте.

— Ярый, килештек, энем. Унбишендә кичке алтыда, димәк,— дип вәгъдә бирде.

— Кем булды ул, бик озаклап сөйләшәсез? — дип янына килгән Сәкинәсенә исә эре генә аңлатасы итте.

— Райкомнан. Районлагы пенсионер коммунистларның берләштерелгән җыелышы буласы икән. Шунда мин партиябезнең яңа Программасы проекты турында доклад сөйләргә тиеш булам. Бюро поручениесе. Өч көн вакыт... Бакчага минсез генә барып кайтырсың инде, Гөлзада белән,— диде.

Шул сәгатьтән Гыйззәт Габитович үз бүлмәсенә бикләнде. Сәкинәсе ашарга да чакырып кына ала иде.

Җыелыш көнне ул иртәдән үк әсәренде, дулкынланды. Халык каршына беренче чыгуы диярсең. Тотасы нотыгының тезисларын кат-кат күздән кичерде, газеталардан җыеп барган кисентеләрне барлап, папкасына салды. Китәренә ике сәгать чамасы калгач, костюм, күлмәк, галстук сайларга керешге.

Киенеп-җыенып көзге каршына килгәч, үзеннән канәгать булды: «Менә, менә, менә! Бакчада өсте-башына иске-москы киеп йөргән Гыйззәт Зарипов түгел инде, түгел! Пенсиягә киттем, тиражга чыктым дип бер дә туарыласы түгел шул, түгел! Үз-үзеңне картлыкта карый белергә кирәк, яшь чакта кем дә чибәр ул, кем дә җилле...»

Иренең көзге хозурында гадәттәгедән озаграк туктавын абайлап алган Сәкинә дә ишек катына килде һәм Гыйззәте янына басты. Янәшә торып төшкән фоторәсемдәге кебек, көзгедә парлашып сурәтләнделәр. Гыйззәт карашын хатынының йөзенә күчерде. Эченнән генә: «Сәкинә дә биреште. Алай да чибәр килеш картая»,— дип уйлап куйды.

Хәләл җефете Гыйззәтне хәерле юл теләп озатып калды.

Өч сәгатьтән артык торып кайтты Гыйззәт. Бәйрәмчә кәеф белән чыгып киткән ветеран фатиры бусагасын кабердән качкан адәм кыяфәтендә атлап керде. Сөмсере тәмам коелып, хәлдән тайган иде. Сәкинәнең дә коты очып калган иде.

— Ни булды? Әллә кан басымың күтәрелдеме? Йә булмаса, йөрәгең җәфалыймы?

Гыйззәт башта ачыргаланып кул селтәде, шуннан соң сүзсез генә чишенде, өс-башын алыштырды, йомшак кәнәфигә барып ишелгәч, үз алдына сөйләнде:

— Кан басымы түгел, җан басымы... Үлем хәле...— диде һәм хатыныннан урын җәюен сорады.

Кичке чәйгә тормады. Йөрәге беркадәр тынычланган кебек булса да уйлары мыжгудан туктамаган иде.

...Кереш сүзен игътибар белән тыңладылар аның. Берничә кеше үз тәкъдимнәрен әйткәндә дә җил-яңгырсыз булды. Менә берзаман сорау яудыра башладылар. Эндәшүләре үтергеч, «Сез инде гомерлек партократ кеше, бу мәсьәләгә ничек карыйсыз?» — дип җибәрәләр бит! Шулчак инде Гыйззәт Габитович җанында давыл купты. Боз болыты алып килгән давыл. Сораулар көн тәртибендәге мәсьәлә буенча гына түгел иде. Аларны Гыйззәтнең шәхси намусына тукынганнан да яманрак итеп бирделәр. Шулай китереп куялар. Гыйззәт Зарипов аларга җавап биргәндә холкында тамырланган инануларыннан ваз кичәргә тиештер кебек. Усалланды халык, телчәнләнде, хәбәрдарлык, сүз иреге дигәч, чыгырдан чыгарга ярый дип беләләр бугай...

— Илдәге кризиска, Коммунистлар партиясеннән кала, кем гаепле?

— Совет хөкүмәте башындагы коммунистлардан кем Әфганстанга басып керергә хәер-фатиха бирде? Әлеге кан коюң совет халкына алтмыш миллиард сумга төште, диләр. Андагы хөкүмәтне асрауга әле һаман да ел

саен өч-дүрт миллиард байлык түгәбез. Җинаятьчел әрәм-шәрәмне бетерү буенча партия башлыклары ни уйлый?

— Илнең еллык оборона чыгымы чынында күпме? Җитмеш миллиард, диләр. Артыграк түгелме? Халык хәерчелектә интеккәндә, шул расходларны киметүдә компартия нинди чаралар күрә?

— КПССтан йөз чөереп, партиядән чыккан миллионнарча кешеләрнең төп дәлиле нәрсә, сезнеңчә? Бу партия әҗәл түшәгендә түгелме? Аны яңа программа белән генә саклап калу мөмкинме? Киресенчә, куып таратырга вакыт җитмәгәнме аны?

— Партия җитәкчелегенең партвзнослардан һәм бүтән матди чыганаклардан тупланган миллиардларча сум акчаны чит ил банкларына салуы хакмы? Хак булса, ник алай эшләнә?

— Егерменче еллар башында, ачлыктан файдаланып, изге храмнарны таларга кушып политбюрога яшерен хатлар язган Ленинга бүген карашыгыз ничек? Унтугызынчы елда кабул иткән программада мондый вәхшилек кылу каралган идеме әллә? — әнә шулай дип киттеләр тезеп, киттеләр тезеп!..

Гыйззәт Габитович алай итте, болай итте, хәл — хәленчә җавап бирергә тырышты, әмма залдагыларны канәгатьләндерә алмады. Шул рәвешле, кыеннан-кыен хәлгә тарды, алҗыды, йөрәге кага башлады. Ярый әле кафедра артында сыгылып төшмәде. Троллейбуска кадәр аны райком инструкторы озата килде.

Шушы ятуыннан ничә көн түшәк-мендәр җылытты ул. Илдә фетнә купканын ишетсә дә тернәкләнә алмады. Бу хәл аны тетрәндерде. Егерме өченче августта кичен Форостагы әсирлектән котылып кайткан партия башлыгының Рәсәй депутатлары белән очрашуын күрсәтәләр дигәч кенә караватыннан кәнәфигә күчәсе итте. Сәкинәдән иске пижамасын сорап алды. Пижама өстеннән мамык шәлгә уранып, телевизор каршына утырды.

Бу очрашуда ил башлыгына, партиянең беренче җитәкчесенә биргән сораулар да бик усал иде.

— Президент Советлар Союзы Коммунистлар партиясен, җинаятьчел оешма буларак, таратылырга тиеш дип санамыйммы?

— Юк, юк, КПССны җинаятьче оешмага санап тыярга ярамый! — диде партиянең беренче җитәкчесе. — ...Бигрәк тә партия программасын тикшерергә чыгарган вакытта...

Менә бу җавапка Гыйззәт Габитович бик сөенде, куанычыннан кулларын уып куйды. «Һай, рәхмәт! Мең рәхмәт!» — диде ул ихластан. Ветеранның кәефе дөррәү әйбәт якка авышты. Күңел күгендәге соры болытлар тарала башлаган кебек булды. Йөрәк тибеше хәерле хәленә кайтты. Баш әйләнүе бетте. Тавышына дәрман керде. Өйдәгеләргә дә рәхәт булып китте. Ләкин...

Ләкин Гыйззәт аганың шатлыгы үтә кыска гомерлегә чыкты.

Иртәгәсен үк партия башлыгының бүтәнчәрәк белдерүе пәйда булды. Анда партия Үзәк Комитеты Секретариатының, Политбюроның дәүләт фетнәсенә каршы килмәүләре, Үзәк Комитетның хәлкылгыч позиция биләмәве, коммунистларны конституцион законлыкны бозуга каршы көрәшкә күтәрмәве, фетнәчеләр арасында партия җитәкчелеге әгъзаларының да булганлыгы әйтелде, бу шартларда генсекның үз вазифасын үтәү мөмкинлеге юклыгы һәм аның вәкаләтләрне иңеннән төшерүе белдерелде. Партиянең беренче дәрәҗәле җитәкчесе Үзәк Комитет, партиянең үз-үзен таратуы турында карар кабул итәргә тиеш дип, туп-туры әйтте.

Мондый хәбәр бер мәлгә Гыйззәт Габитовичның аңына барып җитми торды. Сүзләренең асылын аңлагач, аның йөрәге тотты. Җанын-тәнен дәрмансызлык биләде. Күңелендә кыерсытылу, үпкә, имәнү укмашкан иде.

Хәләле, ирем җан тәслим кыла ахры, дип, коелып төште. Гөлнара агарып калды. Булачак табип Гөлзада гына артыгын хафаланмады, бик тиз телефонга килеп, ашыгыч ярдәм машинасын чакыртты.

Тән хәленнән битәр җан хәле авыр иде гаилә башлыгының. «Бәлки, мин чын ахмакмындыр. Дөньяга мәгълүм лидер фикерендә тәүлек эчендә шундый үзгәреш була алуны аңлар чамам юк»,— дип сукранды.

— Алла хакы өчен ташла шул сәясәтеңне! — Гомере буе ни сабыр Сәкинә түзем чуаны тулып тишелгәч, шундый сүзләр әйтте.— Ходайдан саулык сора, үз хәлеңне кайгырт! Партия урынына партия бетмәс, тәхеткә үрмәләүчеләр бетмәс. Яңгырлы көндә мәйдандагы митингны күр: ничә зонтик булса, шул хәтле партия анда!.. Гөл тамыры туфракта, диләр, туфракта... Сезнең фиркагез химикатлы чүлмәктә үскән булган, күрәсең...

Гыйззәт Габитович Сәкинәсенә күзләрен зур ачып, гаҗәпләнеп тә, тилмереп тә карады. «Мондый сүзләрне гомер иткән хатыным әйтәме? Хәләлем булып хәләлем җаныма хәнҗәр кадыймы? Бигрәк тә партиягә кагылышлы рәвештә...» — ди иде аның күзләре. Ул шулай мөлдерәп карау белән чикләнде. Аннары кул хәрәкәтләре белән укол кадарга кирәген аңлатты.

Гөлзада кулына шприц алды. Ашыгыч ярдәм машинасы ашыкмый иде... Кыз аны каршылыйсы итте.

Августның соңгы якшәмбесе туды. Өйдә әтисе белән әнисе икәү генә калгач, Гөлнара, әнисен әтисе караваты янына утыртып, үзенең карарын бәян итте.

— Мин бүген, менә хәзер, Чабаксарга китәм. Без Гаделҗан белән өйләнешергә булдык. Анда язылышачакбыз. Эштә шунда калам. Хәзергә бер нәрсәмне дә алмыйм. Әйберләрне алырга парлап кайтырбыз. Мондагы мәктәптә барсын да хәл иттем,— диде.

Кызның җөмләләре мылтыктан аткан сыман кыска, өзек-төтек иде. Өлкәннәр алдында мәлҗерәп тормаска теләп булса кирәк, тиз-тиз сөйләде ул. Сорауларга урын калдырмаска дип ашыкты. Кияүгә чыгу тикле җитди мәсьәләне телеграф теле белән әйтеп бирүеннән уңайсызланса да, шул кадәресен шул рәвешле ирештерүне кулайрак күрде. Вөҗдан газабына артык минутлар сарыф итәсе килмәде аның.

Картлар да нидер буласын беләләр иде. Алай гына да димик, көтәләр иде. Сагаеп, хәвефләнеп, имәнеп көтәләр иде. Тик болай ук тиз килеп чыгар дип уйламыйлар иде. Гыйззәт тә, Сәкинә дә ак димәделәр, кара димәделәр. Сүз катарга өлгермәделәр дә. Ихтимал, нидер әйтеп тыңлата алмаячакларын да аңлаганнардыр. Аннары бит инде бу — өлкән кызларының ата-ананы олылап, уртага салып киңәшүе түгел, әйтми булдыра алмавы гына иде.

Итәк-чабуларын алдан ук җыештырып куйган булгандыр, күрәсең, Гөлнара чирек сәгать эчендә чыгып та китте.

— Сау яшәгез. Без сентябрьдә кайтып китәрбез,— диде ул әтисе белән әнисенә. Сеңлесенең исемен телгә дә алмады. Нидер сизенә, фараз кыла иде булса кирәк...

## IX

Көннәр уза торды.

Гыйззәт Габитович белән Сәкинә ханым чыгып китәргә торалар иде, ишектә кыңгырау чыңы ишетелде.

— Озакладык, әнкәләре, озакладык. Әнә тагын чакыра килделәр булса кирәк,— дип сөйләнде Гыйззәт.— Алмага килүләредер, тизрәк маташ инде, зинһар...

Ишекне Сәкинә барып ачты. Бусагада аларны ашыктыручылар түгел, кызлары Гөлнара басып тора иде. Әнисе, сәерсенепме, сагаепмы, артка чөйкәлгәндәй булды, өлкән кыз өйгә узды. Аңа ияреп коридордан ноябрь киченең суыгы да керде төсле. Әллә ул җан суыгы идеме соң?

— Исәнмесез! — Гөлнара тавышын көр итәргә тырышты.— Исәнме, әти! Әни, саумы?

Ул чемоданын аяк киемнәре янына куйды.

— Исәнме, кызым! — Сәкинәнең сәлам бирүеннән Гөлнараның көтмәгәндә-уйламаганда кайтып төшүен хуплыймы, юкмы икәнен аңлап булмый иде.

— Исәнме, Гөлнара! — Гыйззәт туфли бауларын бәйләргә иелгән җиреннән торайды. — Исән-имин кайтып җиттеңме?

— Кайттым. — Гөлнара өс-башын чишенергә дә онытып, кухняга керү юлында торган табуретканы алып утырды. — Бөтенләйгә...

Сүзсез манзара булып алды.

Бөтенләйгә? — Гыйззәт шаяртма без картларны, ансыз да нервылар скрипка кылыдай тартылган дигәндәй сорады.

— Әйе, әйе, бөтенләйгә. Яшәр хәлем калмады. Гаделҗанның беренче хатыны имчәк баласын китереп ташлады. Шул хатынның Чабаксарда яшәүче энесе «Гомерлек гарип итәм мин сине!» — дип көн-төн яный. Террор... Сез кая җыендыгыз болай? — Гөлнараның күптән инде әти-әнисен киенгән-төзәнгән килеш күргәне юк иде.

— Туйга, кызым... — Әтисе шулай диде.

— Гөлзада белән Әнвәр туена... — Телен кызган тимергә куйгандагы газап белән монысын әнисе әйтергә мәҗбүр иде.

Сүзсез манзара янә кабатланды.

Ә димәде, җә димәде, Гөлнара күләгә сыман өнсез булып әлек үзе яшәгән бүлмәгә кереп китте.

Ишек кыңгыравына тагын ярсынып бастылар.

Бу юлы ишекне Гыйззәт ачып җибәргән иде, бусагада янәшә подъезддагы күршеләре — урам себерүче Сәхи-Сашка күренде. Аюдай таза гәүдәле ир. Бите тулган ай табагыдай. Һәрчак кәефле йөри. Икенче шөгыле бик төшемле — шинкар. Көмешкә куучы, аракы алыпсатары. Үзенә хәмер сорап килгәннәрнең акчасын гына умырып калмый, өлешкә керергә дә маһир. — Әле дә Гыйззәтне корсагы белән төртеп дигәндәй кереп басты. Ишек катына аракы аралаш сырамсак исе җәелде.

— Исәнме, бывший! — диде ул үзен өнәми торган Гыйззәткә. — Янасызмы, партия әтәчләре? Халык җилкәсеннән кимергәннәрегезне косар сәгать суктымы? Мир талаганыгыз өчен җавап тотачаксыз!..

Гыйззәт, ни хәлгә калдым соң әле мин дигән төсле, керфекләрен еш-еш йомгалап, Гөлнара торып киткән урындыкка утырды, учларын тез күмәчләренә куеп, атныкы сыман эре тешләрен ыржайтып торган Сәхигә карады.

— Ни йомышың төште миңа, бәлабаш? — дип сорады.

— Йомыш! — дип мыгырданды Сәхи-Сашка. — Йомыш түгел, әйтеп куюю: сезнең юл — дар агачына! Җитмеш елдан артык илгә майда кыздырылган боз хәстәрләдегез, салават күперенә менәргә азапландыгыз, шуның җазасын алырга тиешсез! — Урам себерүче чалыш елмайды һәм көрәктәй кулларын йодрыклап, алга сөрлекте.

Гыйззәт картның күз алды караңгыланды һәм ул нәрсәгәдер тотынырга теләгән хәрәкәт ясады. Куллары һавада асылынып калды.

Бүлмәдән һәммәсен ишетеп торган булса кирәк, әле генә шәүләдәй кереп киткән Гөлнара өермәләнеп килеп чыкты һәм кулындагы чебен шапалагы белән Сәхине уңлы-суллы яңаклый башлады.

— Вон, идиот! — Гөлнараның тавышы яшелле-күкле иде. — Әзең булмасын, исерекбаш! Сиңамы кешеләр язмышын хәл итәргә? Вон!

Ни гаҗәп! Әзмәвердәй ир, тычканнан коты алынган фил кебек, хатынкыз давылына чыдый алмыйча чыгып качты.

Ишекне бикләгәч, Гөлнара, җирәнгеч нәрсәдән арынырга теләгәндәй, шапалагын ташлады да кул юарга юнәлде.

Иренең хәлен җәһәт аңышып алган Сәкинә аш-су ягындагы котыйчыктан йөрәк даруы алып килде.

Туй кайгысы артка чигенде. Шулай да Гыйззәт урынга ятмады.

— Хәзер, хәзер үтәр... — диде ул, әллә ничә төрле ут эчендә калган хатынын юатырга теләп. — Аз гына сабыр...

Туфлиләрен, пальтосын, эшләпәсен салып, Гыйззәт түргә керде, кәнәфигә теркәлде. Дару тәэсире булдымы, тынычланганга охшап калды. Хәтта йокыга да тарта иде шикелле.

«Мир талаганыгыз өчен җавап тотачаксыз»,— диме алкаш? — Гыйззәт дворник әйткәннәрне хәтерендә яңарта башлады.— Булды инде ул партиягә аркаланып балда-майда йөзүчеләр. Ришвәтчеләре дә булмады түгел. Кеше башыннан йөрүчеләрне дә күрдек. Гаделсезлек кылучылар да бар иде кызыл билетлылар арасында... Югарыда хәлләр яманрак та дип сөйли тордылар. Иллә мәгәр шәхсән мин үзем соң, гомерем буе диярлек партаппаратта эшләп, кемнең дә булса энәсенә кагылганым булдымы? Нахакка кеше рәнҗеттемме? Юк бит, юк! Кара диңгез буенда да нибары бер ял иттем мин. Туган авылымда үткәрә идем отпускыларымны... Туры Тукайлыгым өчен ничә тапкыр эшемнән куыла яздым. Тырышканга, кушканны карусыз үтәгәнгә генә кул якмадылар. Инде менә ышандырып кара син кешеләрне! Мине дә мир талаучысына санап, дар агачы юраучы бер Сәхи генәдерме?! Хәзер генә бит әле дөньяда сыйнфый көрәштән, идеолόгик көндәшлектән күпкә мөһимрәк кыйммәтләр барын таный башладык, югыйсә барлык гамәлләребезне бердәнбер хак саналган тәгълимат күзлегеннән чыгып кылдык һәм бәяләдек. Күрәсең, гөнаһлы җирдә яши башлаганга хәйран гомер үткән булса да, догма чәйнәп салынган имезлекне ташлаганга санаулы вакыт кына узу галәмәтедер бу. Артта — караңгы, суык, үткән гомер капкасы ачылмаска ябылган. Алда — томан, киләчәккә китәр җай күренми. Аннары бит киләчәк ул нидер алып килгәнне көтә, ә без — хәзинәсезләр. Хәерчеләр генә түгел, каты сырхаулар да. Шундый минут җитә икән, иң түзем, иң чыдам авыру да стенага борылып ята...»

Гыйззәт Габитовичка куркыныч булып калды. Дәһшәт тойгысы, артына чәнечкәндәй, аны урыныннан торгызды. Кызы бүлмәсенә керәсе килмәде, уртак язмышлы адәмнәр булсалар да, аның белән ике арада җан берлеге калмаган иде. Хатыны янына кузгалды.

Түр як ишегеннән чыгып барганда, аның аягына ничектер шунда яткан кер бавы эләкте. Гыйззәт аны кулына алды, ныклыгын сынагандай тартып карады һәм... башына суккан коточкыч уйдан тораташ төсле катып калды...

*1991 ел, сентябрь*
*Казан*



# ШИГЪРИЯТ



## Рөстәм Сүлти

ШИГЫРЬЛӘР

### Сусау

Зыңлап куйды кое чүлекмәсе[1]
Тиеп китте йолдыз тәлгәшенә,
Шыбыр-шыбыр коелышты йолдыз
Күпер башындагы кое эченә...—
Бик сусадым, зинһар, суың бир!
Илаһият!
Суын авыз итсәң,
Эрерсең күк төннең карасында,
Күпме гомер шуны күрмәгәнмен,
Белмәгәнмен күпме яшәп шунда...—
Бик сусадым, зинһар, суың бир!

Күпер башындагы кое...
Төштән
Төшкә күчеп йөдәтүче коем,
Дымык сулыш белән дәшәдер күк:
«Үзең киттең ләсә, балакаем!».
Бик сусадым, зинһар, суың бир!

Төнге асман...
Авылым тарафында
Шыбыр гына шыбыр...
Йолдыз, йолдыз...

---

Рөстәм СҮЛТИ (1969) — *шагыйрь, «Мин — шигырьдән» исемле китап авторы. Казанда яши.*

[1] Чүлекмә — кое сиртмәсе

Кемдер сулар ала коелардан,
Кайсыгыз ул анда, әй, кайсыгыз?

...Бик сусадым, зинһар, суың бир!

## Болан әни

Аһ-зар булып, аерылуны көтә
Яшь боланнар — Сак-Сок... Ике туган,
Әнкә сүзен санламыйча,
уйнап
Сөзешүләр инде онытылган:
Берегешкән мөгез солтаннары,
Башлар түбән...
Башлар әрни-әрни,
Хәлдән таеп тезләнгәннәр җиргә,
Иңрәшәләр һәрдәм:
— Әни, әни!..
Таш кыялар кайтавазы өнне
Ирештерә кат-кат:
«Бу ни?»
«Бу ни?»
Таш кыялар тетрәр мәгърур бу сын,
Болытларны айкап ташлар мөгез
Ничарадан гаҗиз...
Газизләрен
Коткаралмас микән берәрегез?..
Кинәт...
— Ерткыч!..
Теләсәгез ничек
Олагыгыз,— диде болан-әни.—
Таш кыядан
түбән
ташланыгыз —
Яуда аста калсам
Әгәр дә мин...
Чал кайтаваз шунда гына өнне
Отып, шәрран ярды:
— Әни, әни!..

## Тулай торак

Олуг кырмыскалык!
Кеше! Кеше!
Уңда, сулда, югарыда, түбән...
Кем идәне минем өчен түшәм,
Берәүләргә түшәм — минем идән.

Гомер яшә, гомер күңел ятмас,
Чикерткәсе дә юк, мич арасы...
Бармы икән? Кайда, ичмасам, шул
Тулай торагының бичурасы.

Хозыр Ильяс керә алмас монда,
Беркем йөгереп чыкмас каршыларга.
...Зар-интизар булып, тәрәзәмнән
Карап тора, бахыр, кара юрга.

## Ятим

Яз иде... Кисәк өзелде
Болай да зәгыйфь жыру.
Тәгәри китте ярыкка
Сабый кулыннан дару.

— Күбәләк булып кайтырмын
Елама, балам,— диде.
Җәй житте... Сабый һәрвакыт
Нәрсәдер эзли иде.

Көз инде... Шыксыз зиратның
Почмагына чүгәләп,
Кайнар тынын өрә сабый —
Учларында күбәләк.

Канат жилпегәндәй була,
Егыла салкын ташка.
Яшь аралаш дәшә сабый:
— Һай, гомер бигрәк кыска!

## Пәрванә

Ай, пәрванә, вай, пәрванә[1]
Бәргәләнә, бәргәләнә...
Өзгәләнә-өзгәләнә
Эзли, эзли даһи мәгънә:
— Төннәр озын, гомер кыска...
Гомер озын, төннәр кыска...

Белми туктау, алны-ялны
Үти утлы ритуалны
Зыр-зыр, зыр-зыр...
Әй пәрванә,
Бәгырьләрең телгәләнә...

— Янам инде, бәхил — йола...
Мин тапмадым,
ә син уйла!..
Сезнең йола, и пәрванә,
Шагыйранә, шагыйранә.

Бәргәләнә-бәргәләнә
Эзлим, эзлим бөек мәгънә:
— Гомер озын, төннәр кыска...
Төннәр озын, гомер кыска...

---

[1] Пәрванә — төн күбәләге.

## Йолдыз-кеше

*Янәсе, күктә дә, җир өстендә дә кешеләр яши. Күктәге адәмнәр җирдәгеләргә йолдыз булып күренгән кебек, җирдәгеләр дә аларга йолдыз булып күренә.*

Балачак әкиятеннән.

Мин кеше — әлегә җир өстендә,
Күккә бәйле ләкин тумышымнан:
Кендегемне кискән йолдыз яна,
Дәртләп китәр булып сулышымнан.

Синдер ләүхелмәхфүз дигәннәре,
Бар вөҗүдем бәйле, йолдыз, сиңа... Юра:
Син юраган язмыш — кичер, утлы
Төер булып килә бугазыма.

Мин — йолдыз, әлегә җир өстендә,
Өсләремдә яна минем кешем.
Мин җаваплы аның язмышына,
Мин җаваплы аның гомере өчен.—
Утлы газап ла бу, шуңа — сиңа
Йолдыз булып күренәмдер, кешем!

## Тагын яна!..

Өстәлдә мине күзәтеп,
Ут яна.
— Тагын яна!..
«Сүндер» диләр, һаман шулай,
«Җүләр диләр,— төн саклый».
Мине уйлар җәфаласа,
Аларны ут газаплый.

Илһамга тулган йөрәккә
Янар өчен көн җитми.
Хәтта кайчак үз-үзеңне
Аңлар өчен төн җитми.
Йоклар өчен генәме төн,
Ул бит уйлар өчен дә.
Ярый әле бу җанымны
Дустым каләм төшенә.
— Тагын яна!.. Уй-көймәмне
Давыл күтәреп каплый...
«Сүндер» диләр, һәрчак шулай,
Аларны ут газаплый.
Өстәлдә мине күзәтеп
Ут яна.
— Тагын яна!..
Сүндермәгез, ул барыбер
Итәчәк бер тантана!

## Алиһә

Нидер тырный җанны? Ни икән? —
Сиңа бөтен ир-ат мөкиббән.
Табыналар синең күзләргә,
Табыналар синең тезләргә,
Табыналар синең эзеңә...—
Ым гына сал — барын биһуш итеп
Каратырсың шундук үзеңә.
Ул чагында ләкин мин булмам:
Мин, алиһәм,
сиңа табынмам!

## Илһам

Менә җиттем, менә җиттем дигәндә
Кабат төшеп китәм инде мин бәндә.
Өстә кала Илһамият һәм Җаннар,
Өстә кала ак болытлар, томаннар...
Кайсыгыз ул? Фәрештәме, шайтанмы?
Коткарыгыз — тагын шунда кайтаммы?
Һәр төн шулай... Очышта мин төнозын,
А-шы-гыр-га...
Төн кыска вә бик озын...
Аһ, таң ата...
Якынаям дигәндә —
Сак-Сокларның кауменнән шул мин — бәндә,—
Гөлле тәмуг, утлы оҗмах түбәндә...

## Сак-кош мин...

— СОКлан — Сөю! — дидем мин,
— САКлан — Сөю! — дидең син.
Сокландык та, сакландык без,
СОКландык та, САКландык...
Инде мин — САК, син — СОК,
Кавышулар тансык...

Аккош түгел, каракош та,
СОК-кош син, ә мин — САК-кош,
Язны сары күзләр итәр
Сагыш без, бәгырь, Сагыш.

Аһ, кабаттан бергә булСАК,
Аһ, әгәр кавышалСАК,
САК, бәгырем, син кайда, САК,
САК!
САК!!
САК!!!

* * *

Миңле бала идем — миң беткән,
Моңлы бала идем — моң калган.
Бәләкәйдән бәгърем парчаланган,
Кечкенәдән җаным айкалган.
И әткәй!
И әнкәй!
Миң калсачы шунда —
Моң калган...

## Билал Мамбет,

кырымтатар шагыйре.

* *
*

Көндез дә сискәнеп китәрлек төннәр
Күрдем мин — янымда син булмаганда.
Кара урманда яу,
Үтәр юлым урау —
Мин шуның эчендә айкалам һаман да.

Янамын,
Көямен
Аңларга телимен —
Тотыныр өчен дә эзләп тик терәк...
Төштә дә,
Өндә дә
Бер максатым, димен:
Азат Ватан өчен
Янарга кирәк!

* *
*

...Алар бу җиһанны алмак булдылар.
Океаннан океангача —
Аларга булсын.
Халыкның иркенә тозак кордылар —
Һәммәсе аларга
Кол булып торсын.

Теләкләре ачык,
Хакыйкать ябык...
Илләрне нәкъ шулай ябып булырмы?
Мәзлүмдә нәфрәт күп,
Мәзлүмнәр — гарык...
Бәйдәге халык — халык булырмы?

---

Билал МАМБЕТ (1935) — *танылган кырымтатар шагыйре, күп китаплар авторы. Бөтендөнья татар конгрессында катнашты.*

* *
*

Дөньялык онытыла
Гомер кичкәннән соң;
Су юлында үзенчә салып куя Вакыт.
Табигать тә тоя җимеш авырлыгын,
Үзенә ияртеп
Ала сине картлык.

Дөньялык онытыла.
Хикмәтле сырлары,
Урман күк безне дә чал каплап ала.
Арада чайкала санаусыз еллары,
Хәтерсез хәтер дә
Җилләргә кала.

* *
*

Ватан — бу көндә эңгер дә томан,
Урман, тау, кырданмы сәбәбе аның?
Торса иде ул — туган туфрактан,
Сизәр идең бит гайрәтең барын...

Һәммәсе әнә җәелеп ага —
Бакча рәтләре,
Иркен җәйрасы.
Кырлар киңлеге күзләргә бага —
Аларны эчеп күзләр туймасмы?

Таш юллары да дәшә еракка,
Дуслар күңеле дә бирә инеллек...
Килгән мосафир — иленә кайта...
без — кайсы жирне — Ватан ул, — дидек?!

*Мөдәррис ӘГЪЛӘМ тәрҗемәләре*

# Виктор Федоров

## Чишмә

Шомлы кышлар буе көттем
Мин бу көнне зарыгып;
Хәвеф-хәтәрдән сакладым
Кара-туры атымны.

Сәгать сукты:
Мин — иярдә,
Әйтерсең, япь-яшь егет;
Урман суын эзләп киләм,
Җилләрдән җиңел кебек.

Очып килдем,
Башым идем,
Куанудан — дер дә дер...
Ак урманга
Изге йортка
Кергән кебек керәмдер.

Биек-биек каеннарның
Кытыршы билләреннән
Күз яшедәй сулар ага —
Сафтыр энҗеләреңнән.

Тама алар терек суы,
Мәңгелек су — чишмәгә;
Мин иеләм шул чишмәдән
Терек суы эчмәгә.

Мәңгелек агымнарның мин
Туган сеңелесе белән
Серләшкәннәрен ишетәм...
Сеңлесе — кипкән үлән.

Ә аннары учларымнан
Эчердем мин атымны:
Рәхмәтле иде атымның
Сулышы — җылы тыны.

Ике куз савытыма мин
Терек суы тутырдым.
Язга баш ордым янә бер,
Гүя яңадан тудым.

* * *

Гашыйклар төнгә атлыйлар...
Тупыл мамык очыра...
Ягымлы җәй пышылдыйдыр:
Торналар киткәнче әле,
Ямансу иткәнче әле
Бик күп төннәр, таңнар бар.

Таң атканда гашыйкларны
Юындырып — эчереп,
Челтерәде чишмә суы,
Исләренә төшереп:
Торналар киткәнче әле,
Ямансу иткәнче әле
Бик күп төннәр, таңнар бар.

Кыз назының тәмен тапкан
Егет әйтте кызына:
Күзләреңдә — йолдыз гына,
Куеның шундый кайнар...
Торналар киткәнче генә,
Ямансу иткәнче генә
Җитмәс безгә төн-таңнар.

*1987*

* * *

Саратовта — бозлавык,
Казаннарда ишә кар.
Очар юл — бер сәгатьлек:
Сөйләрлек соң нәрсә бар?

Бусагаңнан тын атлап,
Сыеныйм яңагыңа.
Буран, йөз саескандай,
Кычкырсын чарлагыңда.

Сорарсың: кайда болай
Югалып тордың әле?
Пышылдармын: мин көттем
Әүвәлге назларыңны.

Саратовта — бозлавык.
Казаннарда ишә кар.
Очар юл — бер сәгатьлек:
Сөйләрлек соң нәрсә бар?

*1986*

* * *

Чиркәү фрескаларын чистарткандай,
Кубып төшә уйлар кутыры...
Чынга аша бара хыялларым —
Барыбер кыен, каһәр суккыры!

Тынчып беткән буа суларына
Килеп кушылсалар чишмәләр,
Игелекле гамәл кылганнарын
Ул чишмәләр алмый искә дә.

Аңын сафландырыйм дисә кеше,
Булышырлар аңа шул мәлдә
Бихисап күп тормыш чишмәләре —
Игелек эзләп тормый гамәлдән.

*1988*

*Марс Шабаев тәрҗемәләре*

ПУБЛИЦИСТИКА

**Нариман Фәтхуллин,**
философия фәннәре докторы

# ХИКМӘТ НӘРСӘДӘ?

СОЦИОЛОГ УЙЛАНУЛАРЫ

Татарстандагы хәзерге криминоген хәл тискәре тенденцияләрнең өстенлек итүе белән характерлы. Ә моның нигезендә күп кенә сәбәпләр ята. Җинаятьләрнең гомуми фонында яшүсмерләр кыла торган төрле дәрәҗәдәге җинаятьләр кискен аерылып тора. Республика социология үзәге каршында оешкан бер коллектив ике ел буе, социологик бу күренешне алып, тикшерү үткәрде.

Җинаятьләрне китереп чыгара торган сәбәп-факторлардан фән 460 лапны күрсәтә. Әмма алар җинаятьне тудыруда төрле дәрәҗәдә катнашалар. Аларның һәркайсының «авырлыгын» билгеләү мөһим. Бу — җинаятькә каршы көрәш һәм аны булдырмый калу чараларын төгәл эшләргә мөмкинлек бирә. Ул гына да түгел, һәр аерым очракта бу факторларның ни дәрәҗәдә бер-беренә бәйләнгәнлеген һәм ни дәрәҗә бер-берен китереп чыгарганлыгын тәсдыйкълау (корреляция) зарур. Социаль чынбарлык өчен аларның үзара чарпылышуы, бер-берен көчәйтүе куркыныч. Шуңа күрә күренешне аңлау элемтә төенен ачыклаудан гыйбарәт. Без бу тикшеренүдә тулаем бөтен эшебездә дә, аерым шәһәрләрдәге ситуацияне анализлаганда да шундый методологияне алда тотып эш иттек.

## Казан

«Тяп-ляп» бандасының шаулы процессыннан соң ун елдан артык вакыт үтеп китте. Бу төркем кылган хәлләрне һәм алар белән бәйле бөтен нәрсәне Мәскәү журналистлары «Казан феномены» дип атадылар. Әмма бу атаманы шулай ук Казан яшьләре арасындагы тулаем җинаятьчелекне билгеләгәндә дә кулланалар. Л. В. Агеева үзенең «Казан феномены: әкият һәм чынбарлык» дигән китабында (рус телендә) бу банданың килеп чыгуының конкрет сәбәпләрен генә түгел, ә гомумән яшьләр арасында җинаятьчелекнең югары дәрәҗәдә торуын тәэмин итә торган социаль процессларны да яктырта.

«Казан феномены»ның әкиятме, чынбарлыкмы икәненә җавап эзләгәндә без әлеге, югарыда әйтелгән методологиядән чыгып эш иттек. Казан феномены аерым бер күренеш буларак бар нәрсә, әлбәттә. Әмма бүтән феноменнар барлыгын да истә тотарга кирәк: әйтик, Чабаксар, Чиләбе, Ростов, Воронеж, Дзержинск (Түбән Новгород өлкәсе) һ. б. феноменнары. Ягъни, бу шәһәрләрдә дә җинаятьчелек көчле, тик аларны тарих тудырган объектив сәбәпләр һәм замана китереп чыгарган «вакытлы» сәбәпләр җыелмасы бар.

Казан каласы башка калалар белән чагыштырганда гаять катлаулы шәһәр. «Феномен»нның килеп чыгуында хәтта тарихи урнашкан яшәү традицияләре, әдәп-низамнары, төрле социаль катлаулар аңындагы стереотиплар да чагылыш тапмый калмагандыр. Мәсәлән, караклык субкультурасы базар, вокзал тирәләрендәге күп халык шыплап тутырылган алачыклар илен әйләнеп кенә үтеп кит-

мәгән, әлбәттә. Шунын белән бергә, икенче сорау да килеп туа. Казан-борынгыдан килгән мәдәни һәм фәнни үзәк булып тора.

Нишләп соң бүгенге көнгә социаль элемтәләр һәм мөнәсәбәтләрнең иң яхшы үрнәкләре өстен чыгып хакимлек итә алмыйлар?

Ни өчен Республика башкаласында һәм башка шәһәрләрдә яшьләр арасында криминаль социализация хас күренешкә әйләнде?

«Тяп-ляп» бандасы «Теплоконтроль» заводы тирәсендәге «Калиновка» һәм аның янәшәсендәге бистәләрдә формалашып, шул якта «гөрләде». Очраклы хәлме бу? Башка өерләрнең дә үзәктә түгел, ә читтәге бистәләрдә калкып чыкканлыклары мәгълүм. Аларның үз җинаятьчел йогынтыларын үзәккә таба таратулары да билгеле. Ягъни, бу субкультураның конкрет туу учаклары булып, алар шулардан тарала башладылар. Нинди «учаклар» соң алар?

**Объектив сәбәпләр.** Алар турында сөйләгәндә, без барыннан да элек Казанның һәм башка шәһәрләрнең социаль структурасына анализ ясарга, көндәлек тормышның материаль шартларына, гаиләләрнең ни рәвешле барлыкка килеп яшәеп торуына, төрле социаль катлау вәкилләренең эш урынына һәм хезмәте эчтәлегенә игътибарны юнәлтергә һәм, шуның белән бәйле буларак, аларның ничек фикерләвен һәм яшәү рәвешен ачыкларга тиеш булабыз. Казан каласы төрлечә кайный, бөтенлек ягыннан аның халкы күп катлы, һәм бу аерымлыклар базар мөнәсәбәтләренә тирәнрәк кергән саен тагын да ныграк күренәчәк.

«Тяп-ляп» эшче бистәдә килеп туганлыктан, анализны бистә тормышыннан башлавыбыз очраклы хәл булып күренмәстер. Бистәләрдә күп халык килеп укмашкан, һәм алар карашлары, көн кичерүләре, әдәп-низамнары белән бербереннән бик нык аерылып тормыйлар. Шунысын да әйтеп үтик: әгәр дә 1939 елда Казан шәһәрендә 406 мең кеше исәпләнсә, соңгы 50 ел эчендә моңа тагын 700 мең кеше өстәлде. Бу процесс ничек барды соң?

Сугыш вакытында һәм аннан соң шәһәрдә бик күп промышленность предприятиеләре калкып чыкты. Авиация, нефтехимия, машина төзү комплекслары салу һәм аларда эшләү өчен өсте-өстенә эшче куллар кирәк булып торды. Төп ташкын авылдан килде. Шулай итеп, «Теплоконтроль», «Резинотехника», ясалма күн, синтетик каучук заводларын салып эшләтә башлау дәверендә алар тирәсендә олы-олы бистәләр дә пәйда булды. Монда, кагыйдә буларак, шәһәр хакимияте эшчеләр үз йортларын салып чыксын өчен предприятиеләргә җир бүлеп бирә иде. Шулай ук рөхсәтсез-нисез килеп урнашкан «нахаловка»лар да житәрлек булды. Яңа эшчеләрнең торак мәсьәләсе шулай хәл ителеп килende. Бу торак массивларга үтә хас сыйфатлар — аларда яшәү шартларының гаять дәрәҗәдә түбән булуы, урам-юлларның начарлыгы, мәдәният, сәламәтлек саклау, сәүдә нокталары, телефон элемтәсенең булмавы. Булса шул мәктәпләрнең генә булуыдыр. Дәүләт үз предприятиеләре өчен бушлай дип әйтерлек эшче көчләр җыйды: кешегә биргәне нибары шул бер үлчәм җир булды. Хәленнән килмәгәнгә бурычка бераз акча биреп торып, йорт салып чыгарга, яшелчә-мазар үстерергә булышты.

Хәзер инде шушы тору урыннарында аңның, яшәү һәм тору рәвешенең, әдәп-низамның ни рәвешле урынлашуына күз ташлау лязимдер.

Шәһәргә чыгып киткәндә авыл баласы монда үзен тудырып-үстергән, канына-аңына сеңгән, гасырлардан килгән тәртип кагыйдәләре белән бәхилләшергә мәҗбүр була. Авылның бер буыны икенчесеннән әллә ни аерылмый торган була. Мондагы объектив шартлар, социаль институтлар авыл кешесенең үз культурасы, милли үзенчәлеге, дине һ. б. булган үзенә генә хас төрен тәгәл «ясап» торган. Һәм менә «тормыш дулкыннары» дигән аяусыз тарихи процесс әвәрәләре аны шушы культурадан йолкып алып, көнкүрешнең яңа шартларына чумдыра, хезмәтнең яңа культурасын, яңача фикерләүне үзләштерүне, үз-үзеңне бүтәнчә тоту кирәклеген алдына шарт итеп китереп куя. Бу культураны тиз генә үзләштереп, җөлт кенә шәһәр кешесе булып киткәндә бер хәл иде дә бит... Хәлбуки, тормыш алай дими икән шул, чынбарлык алай килеп чыкмаганлыгын күрсәтә. Нәтиҗәдә, кеше бер культурадан аерылып, аның кадерен дә югалта, яңасына да буе җитми кала. «Җөлт кенә» бик зыялы «кала кешесе» булып китүе мөмкин түгел булып чыга. Ә моңа карамый, ул арада балалары да туып үсә тора, алары инде әнә шул урталыкта тәрбия ала башлыйлар. Ник алай килеп чыга соң? Монда бер-бер хикмәт бармы әллә?

Мондый процессларны тикшерергә **маргинальлек** дигән төшенчә ярдәм итәр. Маргиналь кеше ул — «юл чатындагы», «ике арадагы» кеше. Анарда берәр төрле тарихи рәвештә хасил булган зур социаль төркем, катлау хосусияте юк инде, ул бер-бер төпле генә культура иясе дә түгел. Без тикшергән процесслар безнең Республикага гына түгел, элеккеге СССРның күпчелек регионнарына хас вазгы-

ять. Воронеж галиме Е. Стариков, мәсәлән, «авылдан шәһәргә күпләп-күпләп күченгәндә социаль инфраструктураның тиешенчә үстерелмәвен, шуның аркасында авыл мөһаҗирләренең шәһәр субкультурасына керүенә киртә куелуын» билгеләп үтә. Шәһәрнең рурализациясе килеп туды — авылның матди һәм рухи культурасының бөтен-бөтен блоклары ят бер даирәгә күчереп утыртылды. Авыл субкультурасыннан аерылып, шәһәрнекенә кушылып китәргә мөмкинлеге булмаганлыктан, «нахаловка»ларда, «шанхай»ларда торучылар үзләренә генә хас маргиналь субкультура тудырдылар. Анда авыл гадәтләренең сынак-санагы аннан-моннан эләктергәләгән бишәһри «пиджик-цивилизация» кыйммәтләре белән буталып бетә. Бу очракта сүз һиҗрәтнең (миграциянең) конкрет бер төре турында бара. Чаллыда, мәсәлән, хәл тагын да кискенләшә, чөнки татар авылы мөһаҗирләре монда ят шәһәр субкультурасына гына түгел, ә инде башка телдә сөйләшүче даирәгә дә килеп эләгәләр.

Бүген артына борылып карагач, берничә буынның тернәкләнү юлын күрергә була (бүгенге яшьләр — асылда, 50 нче еллар мөһаҗирләренең өченче буыны). Бу үсмерләрнең аң дәрәҗәсенә, психологиясенә, тәртибенә һәм гамәлләренә анализ ясасаң, аларның башкача була да алмаслыгына инанасың. Аларның бер өлеше — аяусыз кыйнау, көчләү, талау кебек рәхимсезлекләр кылалар икән,— бу алла шулай язганга түгел бит. Бер яшь егет үзе кебек үк икенче берәүне салкын кан белән үтерә икән — бу нәрсәдән килеп чыга соң? Монда төпле анализ ясамыйча котылып булмый. Көн кадагындагы сорауларга дөрес җавап тапмыйча торып, бу куркыныч афәтне киметергә дә, бөтенләй бетерергә бигрәк тә инде мөмкинлек күренми.

Халык күпләп өелгән бу төбәктә маргиналь структураларның оешуы башка факторлардан да тора. Санагать хаҗәтләренә тартылган бу кешеләрнең күпчелеге әллә нинди белемнәр һәм шуңа бәйле рәвештә зыялылыкны күтәрүне дә таләп итеп тормый торган бер катлы гади эшкә урнаша. Андый эшләр хәзер дә буа буарлык: төзелештәме ул, транспорттамы, химия санагатендәме... Саулыкны бетерә торган, пычрак эш кешенең ачуын кабарта, ә хезмәткә түләүнең хәләл көчкә туры килмәве социаль нәфрәт уята.

Шулай да хикмәт башка нәрсәдә. Үзенең социаль хәле белән бу адәм — ярым шәһри, ярым авылый. Чөнки ул ярты көнен өй янындагы җир кисәгендә үткәрә, үзенә генә түгел, тегесен-монысын сатыштырырга да үстергән була. Мирный бистәсендә, мәсәлән, гөлләрне, асылда, сату өчен генә үстерәләр. Моны хурлап әйтү түгел, без бары тик хосусый милекче — хуҗа психологиясенең генә — ә үзенең бар көчен югары җитештерүчән хезмәткә бирүче эшченең түгел, ничек туа башлавын гына билгеләп куябыз. Эшче буларак, ул техника, технологияне һәм әһел буларак үзен камилләштерү шартларына куелмаган. Монда аның сүзе кыска — эшләгәнемне чыгарып сал һәм вәссәлам! Үз хуҗалыгында башкарак мәнфәгать — монда булганны ишәйтергә кирәк. Шушы урында минә бер мондый нәрсәгә аерым дикъкать юнәлтәсе иде. Аның шактый әһәмиятле икәнен үсмерләр проблемасын яхшы белүче галим Е. Н. Ганцук та билгеләп үтә.

Әйтик, киез итек-киез комбинатында эшләгәндә, кайтышлый берәр учма йон кыстырып чыгу бернәрсә дә тормый. Эшче моны караклык дип тә, җинаять дип тә баш ватып азапланмый. Көн дә, көн дә шулай берәр уч. Төзелештән берәр такта белән дүрт-биш кадак-фәлән. Тик — көн саен. Шулай, «оргсинтез»дан пластмасс чиләк, РТИдан дүрт-биш метр резин шланг, авиация заводыннан — болтлар белән гайкалар... Мех комбинатында да булдырган кешенең күзе төшәрлек нәрсәләр бар. Бу гаиләдәге бала хәлләрне күреп тора һәм аңлый: урлашуның әллә нәрсәсе юк икән ләбаса! Ә сыра, аракы заводлары, пром. һәм продбазаларда эшләүчеләрнең гаиләләрендә...

Әлбәттә инде, шәһәр бистәләре бары авыл мөһаҗирләре белән генә тулган икән, дип әйтеп булмый. Анда шулай ук Идел, Кама елгаларын буып, су басачак урыннардан күченеп килүчеләр дә байтак. Әмма алары да бит асылда авыл кебек җирләрдән килгән кешеләр. Җимерек алачыклардан чыгарып күчерелгән гаиләләр, вак шәһәрләрдән килгәннәр дә бар, ләкин нәтиҗәсе бер: монда мәгълүм бер аң дәрәҗәсенә ия булган шәхес тибы формалаша. Бу — өйрәнелергә, аннан сабак алынырга тиеш, чөнки үткәндәге шул унъеллыкларда барган процессларда бүгенге бәлаләребезнең су башы. Утызынчы, кырыгынчы, илленче еллардагы бараклар субкультурасына да анализ ясалмаган, аннан гыйбрәт чыгарылмаган. Казанның өчтән ике өлеш халкы шул кырыс шартларны кичкән кешеләр. Аларның гасаби ачуы, «дөнья тоткаларын» каһәрләве балаларның, оныкларының психологиясенә иңмәгән, акылына, әхлагына күчми калмаганмыни?!

Ниһаять, бу процессларга тагын бер фактор өстәлә: маргинализация социаль идарә сферасындагы житешсезлекләргә дә бәйле. Тормыш шартларының кискен алмашынуы белән мөһажирләрнең (мигрантларның) социаль-мәдәни тормышында күп нәрсә ватыла. Татар авылында бөтен бәйрәмнәр уен-җыр-бию, гармун моңнары белән уза торган булса, шәһәрләргә сибелгәч, болар сирәгәйгәннән-сирәгәя бара. Балалар өйдә ана телендә сөйләшсәләр дә, бакчада һәм мәктәптә инде рус теле хакимлек итә. Аң икегә чатный, кимсенү хисе («комплекс неполноценности») хасил була. Өйдән җыр китә, бераздан ана теле, яхшы гадәтләр, әдәп-итагать (олыны — олы, кечене — кече итү һ. б.) югала. Ә нәрсә кала соң? Алмашка ни килә? Рухың байлыгы урынына дөнья кызыгы булып — акча, мал туплау, тегене чәлдерү, моны эләктерү һ. б. уйлар гына кала. Шунысын да әйтергә кирәк: баштагы буын мөһажирләр (мигрантлар) үзләренең милли һәм гомуми культуралары ягыннан, яшьлекләре ач-ялангач үткән булса да, өстенрәк торалар. Аларның балалары әйбәтрәк киенә, ашый-эчә, магнитофоннары, видеолары, мотоцикллары бар. Ә менә җырны белмиләр. Казанның, Чаллының, Түбән Каманың әлеге икенче буын яшьләре, туйларда һәм бәйрәмнәрдә инде татар җырларын җырламасалар да, татар телен белә иде әле. Ә менә аларның балалары инде җырны да, телне дә белми. Аларга туган халкы тарихы да, үз тамырлары нәмәгълүм. Халык туфрагының уңдырышлы мәдәни катламын тарих өермәсе суырып алып киткән, халык рухсыз калган, ямьсез дәвер килгән...

Ә урысларда ничек соң? Аларга бу сөйләгән факторлар кагылмады шикелле: бакчасында булсын, мәктәбендә-өйдәме — олысы, кечесе бер телдә сөйләшә. Хәлбуки, үсмерләр арасында җинаятьчелек хәле монда да хәтәр: шундый ук рухсызлык, таш бәгырьлелек, шәфкатьсезлек. Аңламаслык әллә нәрсә дә юк монда. Урыс балалары да, чуваш һәм башка халык балалары кебек үк, рухи азыктан мәхрүм булдылар. Алар өннән дә җыр качты. Хәзерге урыс яшьләре борынгы җырларны гына түгел, бүгенге җырларны да җырламый. Мондый рух хәерчелеге бөтенсоюз күләмендә Хрущев вакытларыннан башланып китте. Совет идеологик доктринасы халыкның мул тормышын бары тик җан асрарлык иптозга гына әйләндереп калдырган иде (колбаса кисәге һәм аз-маз башкасы).

Ә шулай да, ни өчен соң Казанда үсмерләр җинаятьчелегә генә түгел, ә үсмерләрнең өер-өер җинаятьчелеге көчле? Монда тагын бер бик әһәмиятле сәбәпне күрмичә дә мөмкин түгел. Хак-хокукны бик чамалы аңлау, хокук кануннарын санга сукмау халык аңында киң таралуы күп очракта районнан алып үзәккә кадәр хакимиятнең бөтен буыннарында шул ук бозуларның ярылып ятуыннан да килә. Сүз 30-50 нче еллардагы өермә булып узган күмәк репрессияләр турында гына бармый. Аларны хәзер һәр үсмер белә. Ә сүз — өстәге эш урыннарында булулары белән үк, хак-хокук һәм югары әхлак сагында торырга тиешле кешеләрнең хәрам привилегияләре, аларның үзләренә таба кәкре бармаклары турында. Яшь кешенең аңына хак-хокукны аңлатуга караганда, олы кешенең гамәле ныграк тәэсир итә. Чыннан да, уналты яшьлек үсмер егет, мең тәңкә урлаган өчен сигез ел бирәчәкләрен белсә дә, бер «зур абый»ның төзелештән үзенә фәлән мең сумлык материал кайтартып ташлаганы өчен шелтә генә алганлыгын күреп-белеп торгач, ул бу дөньяны сөйми башлаячак һәм аны җимереп ташларга тотыначак.

Ә шулай да, ни өчен үсмер яшьләр үзләренең әшәке гамәлләрен кылу өчен өерләргә берләшәләр соң? Ни өчен Казанда һәм республиканың башка шәһәрләрендә бүтән регионнарга караганда «өерчеләр» («группировочниклар») күбрәк?

Беренчедән, яшүсмер психологиясе шундый: ул нәкъ менә өердә үзенең шәхесен урынлаштыра, шунда ул үзен «таныта» ала.

Өер реакциясенә карап син шундук үзеңнең кем һәм нинди кеше икәнлегеңне белеп аласың. Алай гына да түгел, өер кагыйдәләре, аның язылмаган кануннары синең статусыңны билгели, өердәге тиешле урыныңа куя. Ә ялгыз үсмернең берүзе ярамаган эш эшләп ташлавы — монысы бик сирәк нәрсә, гадәттә нормаль булмаган хәл була.

Икенчедән, яшүсмерләрнең тиктормаслыгы, нәрсә дә булса эшләргә атлыгып торулары мәгълүмдер. Бүгенге көнгә яшүсмернең рәсми-формаль структуралары күптән инде үзләренең ямаиатларын чыгарып өлгерделәр, болай да аларга яшьләр бик мөкиббән китмиләр иде. Үсмерләрнең үзеннән-үзе укмашкан оешмалары өскә калкып чыкты. Алар төрле мәзһәбләрдә торалар, төрлесе төрле низамнарга корылганнар. Криминаль төркемнәрдә ныклы иерархия куелган, вазифалар билгеләнгән, гамәлең тәвәккәллек белән бәйле, ролең — җаваплы роль. 14-18 яшьлек үсмер егет кебек берничә иптәшенең хәрәкәте хәтта гомерен дә үз кулында тотарга мөмкин. Монда эшләр бик җитди куелган, тормыш кабул

иткән нормативлар нигезендә син «хезмәт» буенча «үсә» дә аласың. Уйлап карасаң, чыннан да — «бик җитди» бу!

Өченчедән. Безнең җәмгыять буеннан-буена төркемчел, ягъни коллективчы булмаган характердагы корпоратив-паритетлы элементләр һәм мөнәсәбәтләр белән типчелеп беткән. Административ-команда тоталитар системасы үзенең барлык иерархия баскычларында алдан ук нәкъ әнә шундый мөнәсәбәтләргә исәп тота да. Үзләренә-үзләре аерым хокуклар һәм хәрам өстенлекләр биргән урыннарда болар инде, табигый ки, бик ныклап яшерелә һәм шул чакта бер-берене яклашу кирәклеге килеп туа. Шуннан инде группировкалар, кланнар, астыртын оешмалар һ. б. барлыкка килә. 30-80 нче елларда Татарстан республикасының идарәче номенклатурасында бу тенденцияләр аерым бер көч белән пәйда булдылар. Формальлек һәм бюрократизм, тәлинкә тоту һәм күз буяу, ике яклы мораль бөтен сфераларны биләп алып, хәтта мәктәпкә дә кереп утырды. Соңгысы аеруча куркыныч иде, чөнки мәктәп аша бөтен яшь буын уза. Шулай итеп, ике яклы мораль җәмгыятьне тулаем чорнап алды.

Күренә ки: «өерлек» моделе яшьләр уйлап чыгарган нәрсә түгел, әмма ул алар тарафыннан җиңел үзләштерелә, чөнки аларга ул безнең системаның социаль бер институты булып тоела башлый. Монысы — беренчедән. Икенчедән, тору урыннарында «астагылар» арасында да төрле-төрле төркемнәргә оешу табигый иде. Бараклар, алачыкларда шыпланып яшәгәндә, әлбәттә, ярдәмләшү, булышу, коткарышу һ. б. сыман әйбәт мөнәсәбәтләр дә булмады түгел. Тик, барыбер, уртак коридор-кухнялы «коммуналка»ларда бер-береңнән туяю, читләшү, гайбәт, җәнҗаллар күбрәк һәм ешрак кабатлана иде. Моңа тагын эчкечелек, угрылык, женси тотнаксызлык та өстәлә торды. Монда негатив төркемнәр хасил булып, үзләренең «паханнары» — башлыклары барлыкка килә. Хәзерге вакытта «Калуга», «Калиновка» һ. б. бистәләрнең үз паханнары, лидерлары бар. Монысы — олылар арасында әле. Ә яшьләр аларны үзләре арасына күчерә, лагерь-зона субкультурасы кануннары яшьләр арасында да формалаша.

Төрле яшьтәге төркемнәр үзара элемтәдә торалар, һәм үсмерләр төркемнәрендәге криминальлек олылар йогынтысының ни дәрәҗәдә булуына турыдан-туры бәйле. Үсмерләрнең бер өлеше өлкән җинаятьчеләрнең эшчәнлегенә турыдан-туры тартылган. Кайбер үсмер төркемнәре мөстәкыйль «эшли», ләкин «абыйлар» аларны күз угында тоталар. Сүз уңаеннан, район халкы эчендә «утырып кайткан» кешеләр белән балигъ булмаган яшьләр арасындагы җинаятьчелек нисбәте туры пропорциональ бәйләнештә тора. Монда да аңламаслык бер нәрсә дә юк: үсмерләр арасында лагерь субкультурасы формалашуга, анда караклык кагыйдәләрен, гадәтләрен, кануннарын урнаштыруга барыннан да элек шушы субкультураияләре — зона «мәктәбен» бетереп кайткан кешеләр үз өлешләрен кертәләр.

Шушы урында монысын да әйтеп үтәргә кирәктер: «утырып» кайткан, эшкә урнаша алмый аптырап йөрү бу кешеләрне тагын да усаллатып, аларны яңа җинаять бусагасы төбенә китереп бастыра. Тик без бу очракта башка якны алабыз әле: аларның менә шушы усаллануы, җәмгыятькә каршы корылуы үзеннән-үзе алар аралаша торган үсмерләр даирәсенә дә йога.

## Яшүсмерләр мәсьәләсен хәл иткәндә субъектив фактор эшчәнлегенең артта калуы

Халык аңының бүгенге структурасы һәм торышы, шәһәрдә яки районда гомуми тәртипнең торышы объектив яшәү һәм эшләү шартларына гына түгел, ә шушы процессларга иҗтимагый институтлар, оешмаларның ни дәрәҗәдә йогынты ясый алуларына да бәйле. Казанда соңгы ярты гасырда хезмәт ресурсларын шыплап тутыру һәм аерым-тору-яшәү структураларының хасил булуы куәтле мәдәни йогынты белән бергә барырга тиеш иде кебек. Без нәрсәне күз алдында тотабыз? Әлбәттә, барыннан да элек, яшәү урыннарында мәдәният сарайлары, кинотеатрлар кебек культура учаклары телләрендә эшләүче балалар оешмалары, шулай ук ике теллелекне истә тотып эшләүче урта мәктәпләр һәм ПТУлар. Хәлбуки, әле бүгенге көндә дә мәдәният оешмалары челтәре бик сыек, аеруча — югарыда телгә алып киткән бистәләрдә. Әйтик, шәһәр халкының яртысы яши торган Казанның аръягында өч районның һәркайсында татар һәм рус телләрендә театрлар булырга тиешлеге үзеннән-үзе күренеп тора кебек булса да, монын булганы юк. Кем әйтмешли, юктан күп нәрсә юк.

Кешеләрнең аңына, психологиясенә һәм, димәк ки, үз-үзен тотышына мәдәни йогынты ясауның икенче юлы массакүләм информация чаралары аша ята. Кызганычка каршы, субъектив фактор эшчәнлегендәге бу элемент асылда юкка чыгарылды: татар һәм рус телләрендә чыгып килгән дистәләрчә басма матбагалар, татар театрлары ябылды (республика башкаласында бер генә театр калды, икенчесе авыл халкына хезмәт күрсәтүче күчмә театр гына иде). Җирле радио һәм телевидение бүгенге көнгә кадәр бик кыска вакытка гына эфирга чыгалар. Күп кенә әйбәт гадәтләр, әдәп-итагать, социаль институтлар җимерелде, иман-шәригатькә бик нык зыян килде. Шуның нәтиҗәсе буларак, татар халкының зыялы катламы, сөртеп алгандай, бөтенләй диярлек юкка чыкты.

Күңеленнән иманы качкан кешене туры сукмактан алып баруы гаять тә авыр эштер. Әүвәледән килә торган структураларның җимерелүе гүяки атомнардан гына торган көпшәк җәмгыять хасил булуга китерде, әйтерсең лә кешеләр атомнарга әверелә дә, халык шуларның җыелмасы булган «массага» әйләнә. Бу масса үз кануннары белән кыскамы, озынракмы вакытлар яши торган төркемнәргә оеша башлый. Шушындый фонда җинаятьчелекнең канат җәюенә әллә ни гаҗәпләнергә дә туры килми. Бездә һәм чит илләрдә үткәрелгән тикшеренүләр люмпенлашкан халык катламнарының иң хас сыйфаты тәсендә аларның ачыктан-ачык һәм сугышчан әхлаксызлыгын күрсәтәләр. Бу төркемнәрдә кешелек дәрәҗәсе бик түбән бәяләнә, хезмәтне санга сугу юк, монда социаль һәм көнкүреш азгынлыгы хөкем сөрә.

«Тяп-ляп» кебек бандалар шытып чыгуын һәм үсмерләр арасындагы җинаятьчелекнең бүгенгедәй киң таралуын алдан кисәтергә һәм булдырмый калырга мөмкин идеме соң? Бу сорауга төрле җавaплы урыннарда утыручылар төрлечә җавап бирәчәк.

1987 елда Казанга СССР Эчке эшләр министрлыгының егерме кешелек комиссиясе килеп, җәмәгать тәртибенең, җинаятьчелекнең торышын тикшерде. Комиссия статистика мәгълүматлары һәм хисаплары белән килешмәде. Комиссия әгъзалары дәлилләрне һәм фактларны үзләренчә карарга теләп, кичләрен, сиздермичә генә кунакханәдән чыгып, шәһәр урамнарындагы «тәртип»не үз күзләре белән күреп, күбесе эшләми торган автомат телефоннардан үзләре шалтыратып-шалтыратып карадылар. Шул күзәтүләр һәм дәлилләр нигезендә СССР Эчке эшләр министрлыгы коллегиясендә тикшереп карау өчен белешмә әзерләнде. Анда эшнең торышына объектив бәя бирелеп, ТАССР Эчке эшләр министрлыгына сизелерлек ярдәм итәр өчен өстәмә техника, штатлар һ. б. бүлү турында рекомендацияләр күрсәтелгән иде. Ләкин боларның берсе дә тәтемәде, чөнки республиканың элеккеге башлыгы үз «мәхәлләсендә» хәлнең әйбәт булуын раслар өчен бөтен көчен куйды. Ул вакыттагы Союз министры Власов аның белән килеште һәм әлеге белешмә коллегиядә каралмады. Мәскәү комиссиясе җитәкчесе С. Суханов тикшерү йомгаклары буенча «Советская Татария» газетасына мәкалә язган иде, әмма ул басылмый калды.

Бу очракта нинди нәтиҗәгә киленә соң? Номенклатура үзенә аз гына тап төшерә торган информацияне дә читкә чыгармау өчен теше-тырнагы белән тырышты! Ул гражданнарның иминлеге хакында түгел, ә үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәде. Шуңа күрә дә элеккеге социаль-политик структураларның бөтен җитәкчеләре дә шәһәр проблемалары белән кызыксынып, аларны өйрәнәсе һәм бетерәсе урында «матур» отчетлар төзүче белгечләр булып утырдылар. Хокук саклау органнарында гына түгел, дәүләт идарәсенең башка буыннарында да, кагыйдә буларак, мәгълүматсыз кешеләр үтеп керде. Аларны сайлау бердәнбер критерий — шефка һәм административ-команда системасы кануннарына шәхси бирелгәнлек критерие буенча гына барды. Шушындый ук «кадрлар»ны мәктәптә һәм педагогия идарәсенең башка буыннарында да күпләп очратырга була. Иң яманы шунда: алар, бу урыннарда эшләү өчен мәгълүматсыз булулары өстенә, кеше баласы язмышы белән бөтенләй кызыксынмыйлар. Хәер, күп кенә очракта андыйларның үз балалары да күп кенә очракларда нормаль тәртип ияләре булып чыкмыйлар.

Чыннан да, әгәр дә яшьләребез «бозык» икән, моның сәбәпләрен җәмгыятьнең бозыклыгыннан эзләргә кирәк. Үсмер егетләр арасындагы җинаятьчелек җәмгыятьтә бара торган барлык негатив күренешләр белән турыдан-туры бәйләнгән. Тулаем республикада да, башкалабыздагы хәл дә шуны күрсәтә. Хакимиятнең өстәге эшелоннарының һәм шул исәптән хокук саклау органнарындагы күп кенә кешеләрнең дә «астыртын» экономика (теневая экономика), криминоген

катлаулар белән үрелеп үсә башлавы да оешкан җинаятьчелеккә каршы нәтиҗәле көрәшкә, җәмгыятьне сәламәтләндерергә бик нык комачаулык итә.

Катлаулы да, җитди дә сорау туа: ничек соң бу җинаятьчел дөнья үз ягында кануны да, башка төрле дәүләт институтлары да, житештерү чаралары да, армия дә, институциональ идеология һәм политика да булмавына карамастан, яшьләрне көннән-көн үзенә ныграк җәлеп итеп, алар арасында үз йогынтысын киңрәк тарата бара? Бер сүз белән генә җавап биреп булмый бу сорауга. Беренчедән, җинаятьләр тизлек белән һәм даими үсә барганлыктан, аларга каршы көрәш аппараты фактларны ачып, ә судлар ул «эш»ләрне карап бетереп бара алмый. Җинаятьчелекнең үсеше тәэмин ителә, ә бу инде шәһәрдә һәм республикада криминоген хәлне катлауландыра, социаль-криминоген мәйдан киңәйгәннән киңәя һәм тупланә бара.

Икенчедән, хокук саклау органнары һаман да әле өстәге структураларның телефон басымыннан арына алганнары юк. Бу басым еш кына куллары да, намуслары да чиста булган яхшы белгечләрнең вөҗданнарын буярга теләмәүләре аркасында эштән китүләренә сәбәп була. Ә бу үз чиратында милициянең сугышчан сафларын йомшартуга китерә. Милициядән башка сәбәпләр белән дә китәләр — бу асылда эш хакының түбән булуы, торак белән начар тәэмин ителү һ. б. Алар тотылган энергиягә, тәвәккәллеккә һич тәңгәл түгелләр. Кадрларның органнарга караган берничә тапкыр күбрәк түләүче кооперативларга савылуы тенденциягә әйләнеп бара. Һәм, ниһаять, хокук саклау органнарына, мондый дәүләт оешмасына ят элементлар үтеп керүен дә күрсәтми булмый. Бу хәл көрәш һәм профилактика органнарындагы әхлакый-сәяси һәм хокукый тотрыклылыкны бетерә, профессиональ механизмны эчтән боза: эшнең ритмына, һөҗүмчәнлеге, нәтиҗәлелегенә зыян килә.

Шулай итеп, ничек соң бу җинаять дөньясы үз карамагында бернәрсәсе булмаса да, җәмгыятькә, дәүләткә, меңнәрчә кешеләргә һөҗүмчән төстә каршы тора ала, дигән сорауга гомумиләштерелгән җавап мондый гына була ала: димәк, бу дөнья кулында кануны да, анда кертелгән үз кешеләре йөзендә хокук саклау органнары да бар, дәүләт чиновникларын сатып алып, ул хөкүмәтнең үзенә йомшак каравына ирешә, шул ук түрәләр аркылы дефицит булган фонд материаллары һәм житештерү чараларына элгәшә. Җинаять дөньясы үз кооперацияләреннән тыш та бүгенге көндә үзенең идеологиясен һәм нормативларын урынлаштыра, ягъни теләсә кайда, нормаль хәл буларак, кешеләрне сатып алу һәм ялган, ришвәт һәм дәүләтне алдау, караклык һәм фәхишәлек таратыла. Мафия төркемнәренең тырышлыгы белән тора-бара җәмгыять үзе дә җинаятьчел була бара.

Җәмгыятьнең, дәүләт житәкчелеген социаль яңарту, хокукый дәүләт формалаштыруда нинди социаль көчләргә таянырга соң, дигән сорау алга юкка гына килеп басмый. Шушы глобаль мәсьәләләрне хәл иткәндә генә яшь буынны коткарып калу, аңардан ил-йорт иминлегенең иртәгәге гаранты булырлык социаль таза шәхес формалаштыруга ирешергә мөмкин булачак.

Субъектив факторның эшчәнлегендәге тагын бер житешсез як — ул кануннар һәм нормативларның тиз үзгәрүчән чынбарлыктан, социаль идарә таләпләреннән артта сөйрәлүе. Күп кенә очракларда бу хәл хокук органнарының аяк-кулын бәйләп тора. Хәтта Казанда әлеге «өерләр» (группировкалар) белән көрәшне яхшырту өчен дә Мәскәү рөхсәте кирәк булды. Республика прокуратурасы житәкчесенең фикеренә таяныйк. Үсмер яшьләр мәсьәләсе буенча Л. В. Агеевага җавабында ул, әлешчә, менә нәрсә ди: «Җинаять кануниятендә группировкаларга бәйле җәмгыять өчен хәтәр булган гамәлләр өчен җаваплылыкны күз алдында тота торган махсус нормалар булдыру кирәк. Алар хокук институтларының һәммәсен дә колачлый алырлык булырга тиеш. Җәмгыятькә каршы группировка дигән төшенчәне: лидерлыкны, әгъза булуны, катнашу, сатып алу, янау һ. б. ны кануниятка кертү зарур. Әлеге оешмадан ирекле чыгуны тоткарлауның бөтен төрләре өчен хокукый җаваплылык булдырырга һәм андый ирекле чыгучы өстеннән җаваплылыкны алуның хокукый механизмын эшләү кирәк».

Бик ачык та һәм бик кирәкле, хаклы да позиция. Группировкалар бит күп яктан Казан яшьләре күренеше. Андый бүтән шәһәрләр күп түгел. Инде прокуратура булып прокуратура хәлне аңлап тиешле хокукый нормалар әзерләгән икән, аларны нәтиҗәле куллануда берниди дә киртәләр булмаска тиеш иде кебек. Хәлбуки, андый карар кабул итү өчен тагын Мәскәү кулы кирәк. Үз вакытында ТССР Прокуратурасы андый норманың кирәклеген СССР һәм РСФСР прокуратуралары алдына куйган булган иде. Хәлбуки, Татарстан прокуроры күрсәтеп үткәнчә, Мәскәүдә яшьләр компанияләренең үзара сугышы — Казан күренеше генә, дип карап, андый норманы канунга кертергә кирәк дип тапмадылар.

Шушыннан инде бер нәтиҗә килеп чыга: нормативлар, һәр регион үзенчәлекләренә карап, урыннарда хәл ителергә тиеш. Шулай булганда Татарстан җитәкчелегенең һәм аның хокук саклау органнарының активлыгы һәм җаваплылыгы — югарырак, идарә итү нәтиҗәлерәк, сыгылмалырак булыр иде. Шушыны да истә тотканда, гаять мөһим икътисади, сәяси, милли һәм башка мәсьәләләрне хәл итү зарурлыгы белән бергә, Татарстан Республикасы Суверенитеты турындагы мәсьәләнең тарихи хаклы куелганлыгы ачык күренеп тора. Тулы бәйсезлек Республикага средстволар һәм кеше ресурсларын җинаятьчелек белән көрәшү, аны булдырмауның озак вакытлы һәм оператив эшкә каралган ысулларын тормышка ашыруга мөмкинлек ачачак.

## Базар мөнәсәбәтләре шартларында хәлнең катлаулануы

Базар экономикасының үсеше, предприятие һәм социаль-көнкүреш сфераларында (сәүдә, коммуналь, көнкүреш хезмәте оешмалары һ. б.) хосусыйлаштыру котылгысыз рәвештә эшче көчләрнең мәгълүм бер өлешен эштән чыгарып ташлаячак. Бу процесс бүлемле-бүлемле булыр. Искерәк профессия иясе булган олырак яшьтәге кешеләр әйбәтрәк һәм, әлбәттә, яшьләр белән үсмерләр профессиональ яктан әле формалашып җитмәгәнлектән, артык кешеләр булып чыгачаклар. Базар шартларында социализмның гуманлык һәм башка кыйммәтләре санга сугылмаячак.

Эшсез калган яшьләр нишләр соң? Аларның бер өлешен мафия — оешкан җинаятьчелек суырып алачак. Бу өлеш энәсеннән җебенә кадәр криминаллы булачак. Бу бик аңлашыла, чөнки сайланыш әүвәлгечә криминаль ориентация билгеләре буенча бик каты булачак. Аерма хәзер бу хәлнең күмәк төс алып, системага салынуында гына булачак.

Яшьләрнең калган өлеше урам стихиясенә биреләчәк. Шуның белән асылда урлашу һәм талау кебек төрлечә криминаль специальләшкән төркемнәр артачак. Шуның фонында тәртипсезлекләр, хулиганлык, җәмәгать урыннарында әхлаксызлыклар эшләү күбәеп, җәмәгать тәртибенең торышы тагын да катлауланачак. Моның бөтенесе бергә шәһәрләребездә әхлаксыз-җинаятьчел тәртипнең өстенлек алуына китерергә мөмкин. Ачылмаган җинаятьләрнең һәм астыртын җинаятьләрнең күп мәртәбәләр артып, әхвальнең бөтенләй үк кулдан ычкынуы да ихтимал.

Каттый кистереп әйтергә мөмкин: җинаятьчелекнең тоталь үсеше, аның базар мөнәсәбәтләре чорында чиру рәвешен алуы, Республиканы кризиска китереп терәп, Республиканың суверенитеты, экономиканы торгызу кебек гаять мөһим стратегик планнар һәм программаларны башкару юлында зур чоңгыл хасил итәргә бик мөмкин. Үсеп килүче яшь буынның күпләп-күпләп җәмгыятькә каршы рәвештәге эшчәнлеккә тартылуы, аларда кулланучы гына психологиясе һәм аңның акчага гына корылган структурасы формалашу, бер яктан, зур күләмдә социаль брак китереп чыгарса, икенче яктан, күп тә үтмәстән актуаль техник-технологик, иҗтимагый-сәяси, икътисади, фәнни мәсьәләләрне тормышка ашыруда дефицит та китереп тудырачак. Республиканың гомумкешелек культурасы куркыныч астында калуы ихтимал.

Бу хәтәрлекләр каршыга килеп басмас борын алданрак кыймылдарга, андый ихтималлыкны булдырмау чараларын күрергә кирәк. Бу яктан, кардиналь чараларның берсе булып, яшь буынны коткарып калу тора. Монда иң нәтиҗәле юл — ул да булса социаль уңай эшчәнлеккә — укуга, эшкә тарту. Аның өчен дәүләт предприятиеләре һәм оешмалары аларны эштә файдалануда кызыксынганрак булырга тиешле. Дәүләтнең налог сәясәте яшьләрне эшкә алуда предприятиеләр, оешмалар өчен файдалырак итеп корылган булырга тиеш. Һәм, киресенчә, яшьләрдән баш тарту зыянга булсын. Кооперативларга, төрле акционерлык ширкәтләренә килгәндә исә, монда да шундый ук сыгылмалы, алар өчен файдалы стимуляторлар эшләнүе кирәк. Яшьләр проблемасы гомумдәүләт проблемасы булып, бүгенге көндә гаять актуальгә дә әйләнгәч, безнеңчә, бу үткен мәсьәләне хәл итү өчен махсус максатка юнәтелгән акча чигерүләрне истә тотарга кирәктер. Үсмер яшьләрне базар мөнәсәбәте шартларында уңай социаль эшчәнлеккә тартуның икенче юлы яшьләрнең үз-үзләреннән хезмәт ширкәтләре оештыру өчен шартлар булдырудан гыйбарәт. Дәүләт оешмалары үсмерләр өчен хезмәт сфера-

лары, яшенә һәм үзенчәлекләренә ярашлы эш төрләре булдыралар. Бу хәрәкәт үзәкләштерелгән булырга тиеш. Республиканың махсус яшьләр берләшмәсе тарафыннан. Хәзер яшәп килә торган «Яшүсмер» («Подросток») берләшмәсе бүгенге көн таләпләргә җавап бирә алмый инде.

Тормыш яшьләрнең хәтта бәләкәй вакыттан ук уртак эшчәнлек белән оешу кабилиятен күрсәтә. Бары максатлары гына төрле булуы мөмкин. Алларына ачык максат куеп, конкрет эш тәкъдим иткәндә, алар үзләре файдасына һәм, димәк ки, җәмгыять хакына да рәхәтләнеп эшләячәкләр.

Монда берничә мәсьәлә хәл ителә: беренчедән, шәхеснең социальләшүе конкрет эшкә тартылу аркылы бара. Күңеле теләгән эшне сайлап алырлык кына булсын. Икенчедән, үзеннән-үзе оеша торган социаль системаларда уртак эшчәнлекне оештыруда активлык күрсәтү мөмкинлеге ачыла. Күпләр өчен бу оештыру сәләтен үстерү, киләчәктә җитди идарә итү эшчәнлегенә әзерлек мәктәбе булачак. Икенчедән, бу криминаль гамәлләрдән, җинаятьчел социальләнүдән арындыруның бер дигән юлы. Сүз бит аерым бер кешеләрнең язмышы, аларны коткару һәм аларга алгы көннәрдә нормаль тормыш тәэмин итү турында гына түгел, ә иҗтимагыймөнәсәбәтләрне савыктыру, Республикада социаль прогресс турында бара.

Хәтта ирекле базар шартларында да күп кенә функцияләр дәүләт кулында калырга тиеш. Алар арасында иң әһәмиятлесе булып, буыннан-буынга күчүчәнлекне тәэмин итү, кешелек факторын саклау торырга тиеш. Гадирәк итеп әйткәндә, яшь буынны стихия кочагында калдырырга һич ярамый. Юкса, җәмгыять үзен-үзе харап итәчәк.

# МӘҢГЕЛЕК МӘШӘКАТЬЛӘР



Табигый ки, кешенең бөтен яшәеше Бөек Җиргә бәйле. Ул безне туендыра, аның өстенә олуг карханәләр салынып, алар безгә кирәкле әйберләрне булдыралар. Җир хәтта машина-фәлән ясардай матдәләрне дә үз карынында житештерә: тимер, жиз, алмаз, алтын, көмеш һәм башкалар. Ниһаять, Җир безне мәңгелеккә үзенә сыендыра.

Борынгылар әйткәннәр бит:

*... Кыз баланың гөнаһысын ир яшерер,*
*Ир-егетнең гөнаһысын ил яшерер,*
*Адәмнәрне, берәм-берәм, Җир яшерер...*

Җир, Җир, Җир!!! Без, адәм балалары, шул иң гади хакыйкатьне тирәннән, ихлас күңелдән аңлап житкерәбезме соң?!

Мин бу хакта жөмһүриятебез авыл хужалыгының төп житәкчесе булган шәхес — Татарстанның авыл хужалыгы министры Фатыйх әфәнде Сибәгатуллин белән сөйләшеп, хәлне укучыларыбызга житкерергә ниятләгән идем. Очрашуыбыз, ай-һай, озакка сузылды. Ул — әле юлда, кайсыдыр авылыбызга чыгып киткән, әле — Президент утырышында, әле — үзендә киңәшмә, әле — күрше Башкортстан жөмһүриятенә чакырылган.

Ул арада Татарстан Югары Советы сессиясе башланып китә. Министрлар анда да булырга мәжбүр, чөнки һәр депутат, аларга сорау биреп, аңлатма таләп итәргә хокуклы.

Кыскасы, шул рәвешле, безнең очрашу һаман сузыла килде. Инде, бөтен сабырлыгымны җуеп, телефонга кабат ябышкан идем:

— Ул авырый,— диделәр.

Аны шифаханәдән эзли киттем. Янына керергә өметем юк дәрәжәсендә иде. Ходаның рәхмәте — рөхсәт итте. «Килегез. Көтәм!» — диде.

Мәсьәләнең болай хәл кылынуы хәерлегә булды әле, ник дигәндә, без министр кабинетында гына күпме сөйләшә алыр идек: иң артыгы — унбиш минут. Шифаханә бүлмәсендәге әңгәмәбез исә өч сәгатьтән артып китте. Белми әйтмәгәннәр икән: бер хәсрәтнең юньле ягы булмый калмый.

— Хәлегез ничек? — дим. Үзем, аңа карап, сокланам: баһадирдай гәүдә, көпкөләч йөз, ап-ак спорт киемнәре... Болар барысы да аны фәрештә кыяфәтенә керткән. Министрлар кабинетында ул, мөгаен, мондый ук ягымлы түгелдер.— Ни булды, ходаем, нинди авыру борчый? — дим.

— Температура. Кан басымы. Әллә ни булды шунда. Күргән хәлем түгел иде. Әле дә менә кан басымын үлчәтергә җыенган идем. Хәерле булсын...

— Барыгыз инде. Тоткарлык чыкмасын,— дим.

— Ә-ә-әй! Өлгерер әле! Әйдәгез, мин бит сезне үзем чакырдым! Сөйләшик соң бер!

Алар бер палатада икәү икән. Миңа икенче сырхау да яхшы таныш булып чыкты. Аның да хәлен белешәм: «Ни булды?» — дим.

— Аягымны пешердем менә, төзәлә инде,— ди.

— Күчтәнәчем берегезгә генә,— дим.— Мин, министрыбыз янына гына дип кергән идем. Икегезнең бер бүлмәдә ятуын башыма да китермәдем...

Министр елмаеп жибәрде.

— Авыру килеш ялгыз яту күңелсез бит ул,— ди.— Күчтәнәчегез өчен борчылмагыз, без аны барыбер бүлешәбез...

Инде төп сүзгә, журналда чыгарга тиешле әңгәмәгә, Татарстан авыл хужалыгы алдында торган мәсьәләләргә күчәргә кирәк иде.

— Фатыйх әфәнде! — дим.— Минем берничә соравыма гына җавап бирсәгез иде! Хәлегезне бик аңлыйм! Авырсынмагыз, зинһар!...

Ул бүлмәдәшенә карап куйды һәм:

— Карале, синең шәфкать туташы янына барасың бар иде түгелме соң? — ди.

Тегесе бөтенләй аптырады. Министр аңлатырга мәҗбүр булды.

— Карале, мин бит синең алдында сөйләргә уңайсызланам...

Тегесе:

— Минем тыңларга ниятем юк,— диде.

Мин дә, кулымнан килгәнчә, Фатыйх әфәндене тынычландырырга тырыштым. Килештек. Мин аңа үземне кызыксындырган сорауларны яудыра башладым.

— Фатыйх әфәнде! — дидем.— Безнең Татарстанда министрлар — аллага шөкер! Тик халык аларның күбесен бөтенләй белми: кайдан килеп шулкадәр олуг дәрәҗәгә ирешкәннәр? Ачыклап үтәсем килә: Сез бу югары урынга ничек күтәрелдегез? Кем Сезгә ярдәм итте? «Үзем турында — үзем» дигән уй туса, Сез ничек җавап бирер идегез?

— Кызык,— диде ул, аннары, бераз уйланып торгач:— Хәер, әллә нәрсәсе юк,— дип өстәде. Мин бит — татар малае, туганнан бирле эштә мин...

Аны инде мин дә, бүлмәдәше дә, ара-тирә кереп йөргән шәфкать туташлары да борчымый иде. Сөйләде дә сөйләде.

— Мин — Арча егете. 1950 елда туганмын. Апаста.

Аны бүлдерергә җөрьәт иттем:

— «Апас» Арчада да бармыни соң?

— Бүтән ул, «Ап-аз» сүзеннән... Мин менә шул авылның биш балалы гаиләсендә туып үстем. Әнием — гади колхозчы, әтием — гомерлек механизатор. Урта мәктәпне Шушмабашта бетердем. Мәктәптә үк комсомол секретаре идем инде. Аннары Казанның ветеринария институтына киттем. Конкурстан үтмәдем, мине, үз теләгемә каршы, зоотехника бүлегенә, читтән торып уку шартында гына кабул иттеләр. Шул арада ук авылыбызда зоотехник булып эшли башладым. Әмма теләгем ветврач булу иде. Шунлыктан, икенче елны, шул ук институтка, кабат киттем, имтихан тоттым, барыбер эләктем бит үзем теләгән бүлеккә!

Бик тырышып укырга тотындым. Спорт белән шөгыльләнә башладым. Кечкенәдән үк көрәшергә ярата идем. Тренерым Мәгаз агай Сәхәбетдиновка әле дә рәхмәтлемен. Зур-зур ярышларга катнаштым. Җиңгән чаклар да аз булмады.

Укыганда акча җитми иде. Мин моны бик тиз аңладым да — эш эзләдем. Эш җитәрлек: заводында да, станцияләрендә дә — иренмә генә дә, ялкауланма гына!

— Спорт — кешенең гомере буена барырга тиешле гадәте. Сез моңа хәзер ничек карыйсыз? Спортның кайсы төрләре сезне аеруча мавыктыра?

— И-и-и! Кая инде ул спорт?! Мин хәзер һәр көнне иртәнге җиденче яртыдан башлап — эштә. Кичләрен ничәдә бушаганыңны үзең дә белмисең...— Ул, бераз уйланып алды да, беренче соравыма җавабын дәвам итте.— Укуны уңышлы гына тәмамладым. Без укуны бетергән елны институтның 100 еллык юбилее булды. Имтиханнар кичерелде. Без июльдә генә диплом алдык.

Мин шул чакта ук, сабырсызланып, өйләнеп тә куйган идем инде. Күрше авылыбыз кызы Тәслимәгә. Ул химия-технология институтын тәмамлады, гел мәктәпләрдә эшләде. Әле дә укыта.

Үзебезнең гаиләдә мин — бер генә егет. Кияү булып төшсәм, өч — кайнеш! Әйбәтләр барысы да! Берсе хәтта, минем һөнәргә кызыгып, ветеринар булды.

Институтны тәмамлагач, Зеленодол районының Бишнә авылында тыныч кына эшли башлаган идек... гаилә мәшәкатьләре әти-әни янына китәргә мәҗбүр итте. Ике балабыз бар иде инде: Фәрит белән Фәридә. Алар хәзер зурлар: берсе мединститутта укый, икенчесе — университетның юрфагында...

Безнең авыл, Арча районына керсә дә, Балтачка бик якын. Шунлыктан мин Балтачта эшли башладым. Ветврач булып. Бераздан Соснага — «Правда» колхозына рәис итеп күчерделәр. Күпләр хәтерлидер әле: ул колхозда дөньяның бердәнбер тимерче кызы Сәрвәр эшли иде бит!

Бу колхозда, зур уңыш алган өчен, миңа ВДНХның «Алтын медален» бирделәр. Бу авыл моңарчы мондый уңыш күрмәгән булган икән. Минем шәхси «күтәрелеш» шуннан китте, дисәм дә, ялгышмам.

Соңгыларын санап кына китсәм дә ярар кебек: КПССның Балтач райкомында икенче секретарь, Арчаның Башкарма комитеты секретаре, аннары инде — КПССның Мамадыш райкомы беренче секретаре. Бу соңгы урында алты елдан артыграк эшләдем. Аннары — менә инде, министр иттеләр.

— Минем аңлавымча, хәзер Сезнең җилкәдә — Татарстанның иң авыр бер тармагы. Заманның болгавырлыгын да исәпкә алсак, мәсьәлә тагын да катлаулана кебек. Җөмһүриятебезнең суверенлыкка ирешү өчен көрәшкә чыгуы, үз Конституциябезне булдыру өчен тырышулар һәммәсе Сезнең эшне дә мәгълүм бер кысаларга кертә. Гел Мәскәүдән күрсәтмә көтеп утыру гадәтләре артта

калып бара. Мондый шартларда Сезгә, мөстәкыйль рәвештә, өр-яңа ысуллар, моңарчы кузгатылмаган мәсьәләләргә җавап эзләп баш ватарга туры киләдер?

— Татарстан халкы суверенлыкка омтылып, Референдумда уңай тавыш биреп, гаять мөһим адым ясады. Бәхеткә, бу юлда Югары Советыбыз да, Президентыбыз да, галимнәребез дә, һичнинди закон бозуларга урын калдырмыйча, сабырлык күрсәтеп һәм таләпләрендә нык торып, бәхәсләрдә һәрчак дөньякүләм кабул ителгән шәхес иреге кануннарына таянып эш итәләр.

Тик, мин кешеләребезне бер хакыйкатькә ышандырырга кирәк саныйм: коры мөстәкыйльлек кенә безнең тамакны туйдырмаячак. Киресенчә, киләчәктә безнең тормышның ниндилеге бары үз тырышлыгыбызга гына бәйле булачак. Шул ук вакытта мин нык ышанам: халкыбыз сынатмас. Без бит күпне кичергән инде, сынмаганбыз-сыгылмаганбыз. Беренче чиратта мин җиребезгә кадер-хөрмәтне арттырырга кирәк саныйм. Без бит аны гасырлар буе таладык та таладык. Әле шунда да алынган уңышка үзебез хуҗа була алмый идек. Авыл хуҗалыгы белән нинди генә наданнар җитәкчелек итмәде?! Әле бүген дә җиргә һичнинди хезмәт күрсәтмәгән, хәтта гомере эчендә аңа яланаяк бер мәртәбә басып та карамаган кайбер депутатлар крестьянны өйрәтеп маташа. Кызганычка каршы, кайбер журналистлар да тузга язмаган шул фикерләрне күтәреп ала.

Бер генә мисал китерим әле. Менә безгә чит ил фермерлары өчен бик кулай булган кечкенә тракторлар сатып алырга киңәш бирделәр. Алдык. Алар исә көненә нибары гектар ярым җир сөрә ала. Безнең офыктан-офыкка сузылган басуларны бу акрынлыкта сөрергә тотынсаң, урак өсте килеп җитә бит, валлаһи!

Һәр эшнең үз белгече, үз остасы булу хәерлерәк. Күрегез инде: РСФСРның авыл хуҗалыгын хәрби белгеч җитәкли! Шул да булдымы эш?! Аңа нинди киңәш сорап барырга мөмкин?

— Фатыйх әфәнде! Хәзер бик сәер хәлләр күзәтелә: дөньяның асты-өскә килде кебек. Ни генә сатылмый! Ул бәяләр! Ул тәртипсезлекләр! Авылда да үзгәрешләр шактый. Элек-электән тыныч кына көн иткән, Җиргә хезмәт күрсәтеп, илне туйдырган уңганнар күңеленә дә төрледән-төрле шомлы уйлар килә: колхоз-совхозлар нишләр, җирне кемнәр яулап алыр? Шуңа охшаш сораулар шактый. Авылларыбызның киләчәген ни көтә?

— Авыл халкы элек-электән иң акыллы затлардан саналып килде. Хәзер дә аны тиз генә кысадан чыгарып булмас әле. Мин үзем бүгенге үзгәрешләрдә берничә юл сиземлим. Әйтик, моңарчы халык җилкәсендә ятып, һичнинди файда да китерә алмаган кайбер басуларны арендага бирергә мөмкин. Ә нык күмәк хуҗалыкларны (әйтик, Фәйзи Галиев җитәкләгән «Искра» кебек колхозларны) үз карамакларында калдыру яхшырак, минемчә. Инде җирне сатуга килсәк... Дөньяда аннан да кыйммәтлерәк мал юк. Кем генә сатып ала алыр аны?

Табылыр, әлбәттә, калын кесәле акыллыбашлар. Алар безнең төп халыкны юк кына бәягә эшләтеп, җиребездән тәмам череп баер өчен файдаланачак.

Кыскасы, моңарчы оешкан хуҗалыкларны, алдын-артын уйламый гына, туздырырга ашыкмаска иде. Әле быел гына шул басуларыбыз, күмәк эшкә күнгән кешеләребез моңарчы күрелмәгән байлык җыеп тапшырды.

Әмма авыллар бу хәлендә калмаска тиеш. Дәүләт аңа акчасын кызганмасын иде! Юллар, торак йортлар, мәктәпләр, балалар бакчалары, мәдәният сарайлары — барысы да салынырга тиеш. Бары шул чагында гына кешеләр — әйтергә кирәк, моннан дистә еллар элек, авырлыкка чыдый алмыйча, авылдан китәргә мәҗбүр ителгән кешеләр — безнең бай, төзек, күркәм авылларыбызга кызыгып караячак. Шуңа күрә дә әйтәм мин: авылга бирелгән акчаларны кызганмаска, чөнки бу чыгым тиз арада меңе белән кире кайтачак.

Җир бит ул, сабый бала кебек, назлау-кайгыртучанлык та көтә, кырыс ата кебек, бик җитди итеп «ачуланып» куярга да күп сорамый. Билгеле бит: Идел буе басулары элек-электән йә корылыктан интеккән: йә кешеләр ел буе бил бөгеп үстергән мул уңышны җыя алмыйча, көзге яңгырлардан җәфаланган. Дөрес, бүгенгедәй фәнни ачышлар заманы өчен адәм баласы хәл итә алмастай проблема булмаска тиеш иде инде. Әйтик, корылыкка каршы су сиптергеч җайланма коеп куй, яңгырда да урырдай машиналар, киптергеч корылмалар сал! Алга киткән илләр әнә шулайрак хәл итә мондый мәсьәләләрне. Без, кызганычка каршы, шактый артта сөйрәләбез шул. Мөстәкыйльлегебез бу өлкәдә дә этәргеч булыр кебек, хәзер без үзебезгә кирәкле чит ил белгечләре белән турыдан-туры элемтәгә керә алабыз. Ярдәм итәргә теләүчеләр дә табылыр кебек.

Җир исә уңай җавапны озак көттермәячәк. Әле әнә узган ел гына игътибарны бераз арттырган идек, моңарчы күрелмәгән уңыш җыйдык. Кеше һәм Җир,

Җир һәм Кеше — бербөтен ул. Барысы да аларның бер-берсенә булган мөнәсәбәтенә барып тоташа.

— Бу хакта шагыйрь Равил Фәйзуллинның «Безнең җир» дигән шигыре бар. Болай яза шагыйрь:

*Җырлады читләргә китүче*
*яшь, таза, сөлектәй бер егет:*
*«Безнең җир — сыктар-елар җир!*
*Безнең җир — шурәле каргар җир!..»*

*Җырлады читләрдән кайтучы*
*ак йөзле, чал чәчле бер бабай:*
*«Безнең җир — уйнар-көләр җир!*
*Безнең җир — сандугач сайрар җир!»*

— Шагыйрь дөрес чамалаган,— дип алып китте министр.— Җирнең «шүрәле каргар җир» булуы да, «сандугач сайрар җир» булуы да кешенең аңа мөнәсәбәтенә бәйле.

— Фатыйх Сәүбәнович! Без узган елгы мул уңыш өчен ифрат шатландык. Шулай да ник соң икмәкне һаман читтән сатып алабыз? Җиребезнең киләчәге нинди-рәк? Башка күршеләребезнең басулары белән чагыштырганда, нинди-рәк урында торабыз? Беренче чиратта җиребезгә ни җитми? Артык агуланып, тәмам чыгырыннан чыгып бетмәгәнме ул?

— Үз икмәгебез үзебезне генә туйдырырга җитәрлек булырга тиеш безнең. Читтән икмәк кертүнең башка сәбәпләре дә бар бит әле. Әйтик, бездә ак күмәч, токмач пешерергә яраклы ак он тарттырырдай каты сортлы бодай үсми. Аны җылы яктагы республикалардан алырга туры килә. Әмма якын киләчәктә, уңган селекционерларыбыз тырышлыгы нәтиҗәсендә, бу хәлдән дә котылырбыз кебек. «Мишә» кебек яңа төрле бодайлар игәчәкбез. Кайбер тәҗрибәләр бар инде.

Әлеге дә баягы, шушы мөстәкыйльлегебезгә таянып, башка юнәлешләрдә дә эшләр җәелдерелә. Шулай да Татарстандагы җирнең язмышын да, уңышларыбызны да күршеләрдәге хәлләр белән чагыштырырга туры килми. Ник дигәндә, безнекедәй промышленность предприятиеләре белән тыгызланган бер генә регион да юк. Соңгы егерме ел эчендә аеруча күп җиребез, иң уңдырышлы басулар КамАЗ, ГРЭС, АЭС кебек коточкыч киң колачлы төзелешләргә бүлеп бирелгән. Күпме җир су астында калды. Соңгы елларда шул ук предприятиеләр: «Өстәмә хуҗалык оештырабыз!» — дип, тагын 200 000 гектар җирне алдылар. Бу җирдән кемнең күпме уңыш җыюын исәпләүче дә юк. Эшчеләренә берничәшәр килограмм ит саталар да — герой кебек йөриләр.

Менә шул рәвешле авылларыбыз, әле булса, гаделсезлектән интегә. Җир биргән уңыш та, терлекчелек ризыклары да, промышленность әйберләренә, ягулыкка, ашламаларга үзгәргән бәяләр аркасында, үзкыйммәтләрен бик нык арттырдылар. Соңгы шартларда, мәсәлән, бер кило итнең үзкыйммәте 500 сумнан артып китте. Без исә аны әле һаман бик түбән бәягә алабыз. Кыскасы, көнне төнгә ялгап эшләгән авыл кешесенең хезмәте әлегәчә дөрес бәяләнми, хуҗалык чыгымнары үз-үзен аклый алмый. Узган көздә бик зур уңыш җыйган хуҗалыклар да машиналарның һәм башка кирәк-яракларның коточкыч бәясе аркасында, тагын бер тиенсез торып калдылар. Авылларыбызга миллионнарча сум акча кирәк һәм, мин кабатлап әйтәм, без бу чыгымнардан курыкмаска тиешбез.

— Сезнең әдәбият-сәнгать әһелләренә хәерхаһ икәнлегегез мәгълүм инде. Ярдәмнәрегез тиеп тора. Әле менә газета-журналларга язылу барганда да ярдәмегездән ташламадыгыз: күп кенә авыл җитәкчеләре уңган кешеләрен безнең журналга язылу кәгазе белән бүләкләде. Бу бит — ай саен гаиләгә бер китап килеп тора, дигән сүз. Бик мактаулы һәм үрнәккә лаек алым бу! Рәхмәт яусын!

Шулай да үзегезгә аерым китапларны укырга, театрларга, концертларга йөрергә вакыт күп тимидер, мөгаен?

— Мин үземдәге иң күркәм сыйфатлар өчен үзебезнең язучыларга, артистларыбызга бурычлымындыр, дип саныйм. Язучыларыбызның үзебезнең Арча ягыннан чыгучылары күңелемә аеруча якын. Театрлардагы яңа спектакльләрне карамый калмыйм. Кайчак «йомшак» әсәр укысам, рәнҗеп тә куйгалыйм. Газеталарда да уйлап бетермичәрәк «кыюланып» ташлаштыргалыйлар. Идеологиядә ашыгырга ярамый. Күпне күрдек бит инде — уйлап эш итүнең зарары булмас иде! Укучыда ашыгыч фикер тудыру кайчак зур эшләргә комачаулап куя...

— Тел очымда торган тагын бер соравым бар: шушындый япь-яшь башыгыздан бик күп дәрәҗәле урыннарда эшләп өлгергәнсез. Инде — министр ук булдыгыз. Шөкер, бу юлны да уңышлы гына башлап алып киттегез. Шулай да... берәүне дә урамнан тотып кереп кенә колхоз рәисе дә, партия житәкчесе дә итмиләр. Безнең монарчы елларда «этәргеч»ләр бигрәк тә модага кергән иде. Әйтегез әле, зинһар, Сезне кем шулай дәрәҗәдән-дәрәҗәгә күтәреп йөртте?

— Бу сорау, минем өчен, яңалык түгел инде. Ник дигәндә, гомерем буе япь-яшь житәкче булып йөрдем. Мәсәлән, Табиев мине, һәр киңәшмә саен берничә тапкыр, урынымнан сикертеп торгызып: «Әнә, күрәсезме Сибагатуллинны?! — ди торган иде.— Үзе барыгыздан да яшь, үзе ин зур уңышка ирешә!» Тагын берничә минут уза, тагын бастыра: «Кем алды «Правда» кебек авыр колхозда ВДНХның Алтын медален?! Шул ук — Сибагатуллин Фатыйх!..»

Минем хәлләр әнә шулайрак башланып китте. Үзем исә ата-баба гадәтенә буйсынырга өйрәнгәнмен. Бездә бит олылар сүзен үргә алу кебек бик күркәм гадәт бар. Халыкта да: «Олы сүзен тыңламаган — олыгаймаган»,— диләр. Мин һәр житәкчемне сабыр гына тыңлап торам. Ә эшкә килгәндә, үз җаеңны үзең карыйсың инде. Һәр олы житәкченең урындагы хәлне аеруча анык белеп житкермәве дә бик ихтимал лабаса! Ул кушты, дип кенә, өлгермәгән басуга ашлык сиптереп чыкмассың бит инде?! Андый хәлләр адым саен очрап кына тора. Әмма, мөгезсез сыер кебек, житәкченнең һәр киңәшенә «сәнәк күтәреп» тору да, минемчә — егетлек түгел. Тыңлый бел дә, эшеңнең нәтиҗәсен күрсәтеп бир — менә булырсың егет!

— Тагын бер, моңарчы берәү дә ачыклый алмаган сорау биреп карыйм әле, Фатыйх әфәнде! Татарстан Җире, халкыбыз бик күп иза чикте. Борын-борыннан килгән данлы халык, соңгы дәвердә, нинди генә кимсетелүләр кичермәде дә күпме «тал чыбыгы ашамады»? Дөрес, тирә-күрше җөмһүриятләргә караганда, яхшырак та яшибез, диләр. Тик көн күрүләре җиңел түгел бит. Аның иң аянычы — иртәгәге көнгә ышанычның булмавында. Бу өметсезлекләргә бер чик табылырмы?

— Миңа калса, барысы да — үзебезгә бәйле. Без бит бик озак еллар: «Безне ач итмәсләр! СССР безне бәхетле итәр! Бездән дә бәхетле халык юк!» — дип яшәдек. Бөтен милек — халыкныкы!» — дидек. Ул милек исә бөтенләй хуҗасыз яки бер төркем намуссыз кешеләр карамагында булып чыкты. «Колхоз басуы — минеке!» — дип, түш киереп йөргән крестьян, шул басудан бер уч борчак уып ашаса, аны хөкем иттеләр.

Минемчә, ялгышлыклар әнә шул ялганнан башланды. Кеше урларга, эшләмичә генә дә яшәргә ияләнде. Эшләмәсәк тә «фәлән тәңкә» килеп торды. Шушы бинһая зарарлы фәлсәфә хәзер безнең канга сеңгән. Безгә әнә шул ямьсез гадәттән котылырга кирәк! Адәм баласының тормышы бервакытта да мәшәкатьсез генә дәвам итә алмый. Тормыш мәшәкате мәңгелек...

*Әңгәмәне Кояш ТИМБИКОВА алып барды.*

## Сөйләшү башлыйбыз:

## *БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ. БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ.*

**Хөрмәтле укучылар!**

*Белгәнегезчә, журналыбыз битләрендә кызыклы роман һәм повестьлар даими басыла килә. Алар арасында татар халкының соңгы еллардагы тормышын чагылдырган әсәрләр төп урынны алып тора. Мисал өчен, соңгы өч елны гына алсак та, журналыбыз битләрендә татар халкының хәзерге чор тормышын күрсәтүгә багышланган әсәрләрдән түбәндәгеләр басылган: «А. Гыйләҗев «Балта кем кулында?» (7—8 сан, 1990 ел); М. Маликова «Фидая» (10—11 сан, 1990 ел); З. Хөснияр «Каешлану» (6 сан, 1990 ел); Г. Ахунов «Гомер юлы» (1—2 сан, 1991 ел); Ф. Гыйльми «Зәйтүнәкәй — акчарлагым» (9 сан, 1991 ел); Ә. Баянов «Җәй белән җәй арасы» (6 сан, 1991 ел); Н. Фәттах «Кичү» (7—8 сан, 1991 ел); Ә. Галиев «Авылдашлар» (9—10 саннар, 1992 ел); А. Хәлим «Өч аяклы ат» (6—7 сан, 1992 ел) һ. б.*

*Үткән елның 10—11 нче саннарында без сезнең игътибарга язучы Фоат Садриңең бүгенге көн тормышына багышланган «Таң җиле» исемле яңа романын тәкъдим иттек. Шул уңайдан, сезне журнал битләрендә башланачак сөйләшүгә чакырдык. Сөйләшүнең темасы — «Безнең тормыш. Безнең әдәбият» иде.*

*Бу санда әнә шул сөйләшүне башлап җибәрәбез. Анда язучыларның, тәнкыйтьчеләрнең һәм шулай ук укучыларның актив катнашуларын көтеп калабыз.*

### Фоат Галимуллин

# ГЫЙБРӘТЛӘР АЛСАК ИДЕ...

Аерым кешеләр кебек, тулаем җәмгыять тә даими рәвештә үсеш-үзгәреш кичереп тора. Һәм теләсә кайсы җәмгыятьтә дә яхшы, алдынгы карашлы кешеләр була. Алар, җәмгыятьнең тискәре көчләре белән каршылыкка керәләр, шул юлда шактый газапларга да дучар булалар.

Әдәбиятыбыз соңгы унъеллыкларда бездәге шушы хәл-әхвәлне ничек сурәтләде соң? Бу өлкәдә бездә җитди сүз әйтү булдымы? Ягъни, төгәлрәк әйткәндә, язучыларыбызның бүгенгене бәяләүдә һәм киләчәккә күз ташлауда зирәклекләре кай тирәдә булды? Тормышыбызның әдәбияттагы сурәтләнешенә бәйләнешле рәвештә шул турыда бергәләп уйланыйк әле.

---

Фоат ГАЛИМУЛЛИН (1941) — *әдәби тәнкыйтьче, филология фәннәре кандидаты. Бүгенге татар әдәбиятын яктырткан китаплар авторы. Казанда яши.*

Әйе, бу дөньяда намуслы кешегә яшәве авыр. Бигрәк тә безнең җәмгыятьтә. Ник дигәндә, җылы, төшемле урыннарның күбесенә сәләтләре буенча түгел, бәлки әшнәлек юлы белән килгән түрәләр үз әйләнә-тирәләрен ялагайлар белән чолгап алырга тырышалар. Чөнки беләләр: болай иткәндә җаның тыныч. Кул сынса — җиң эчендә, баш тишелсә — бүрек эчендә. Курыкмыйча дөньясының артына тибеп яшәргә мөмкин. Әнә шундыйларның без А. Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?», Р. Мөхәммәдиевнең «Кенәри — читлек кошы» әсәрләрендә аеруча гыйбрәтле итеп сурәтләнүен күрдек. Мондый капкорсаклар бер нәрсәне оныталар — шеш, тула торгач, барыбер тишелгән шикелле, көннәрдән бер көнне хәрам ризык өчен җавап бирергә туры киләчәк. Ихтимал, аларның кайберләре хөкем алдына да басмаслар, ләкин намус, вөҗдан хөкеме бар бит әле. Андыйларга, гадәттә үлем газабы да катырак була. Моны меңәр еллык тәҗрибә раслаган бит инде. Ә менә күңеле тулы изгелек, яктылык булган, бары тик игелекле гамәлләр белән мәшгуль кешенең тышкы кыяфәте белән дә бүтәннәрне җәлеп итүчән булуы, дөнья белән алыш-бирешен дә шактый җиңел өзүе — хакыйкать. Фоат Садриевнең «Таң җиле» романындагы Нуриасма апа — әнә шундый бәхеткә ия сирәк кешеләрнең берсе.

Нуриасма. Исемнәр буенча белгеч Г. Саттаров китабында Әсма исеменең бик өстен, югары дәрәҗәле, бөек дигән мәгънәләргә ия булуы турында әйтелә. Шуның өстенә «Нур» дигән матур сүз дә өстәлгәч, Нуриасма исеме тагын да яктырып китә, аның затлылыгы арта. Җиһанга якты нурлар сибүче Кояшыбызны таңда сөенеп көтеп алып, кичен хәер-дога белән озатып калып гомер иткән Нуриасма үзе дә җылылык, ягымлылык, игелеклелек чыганагы булып тоела. Гомерен кирсез-тапсыз үткәргән Нуриасма әсәр ахырында гөнаһлы бәндәләр өчен әхлакый хөкемдар югарылыгына күтәрелә. Аның бәхиллеген алу — кешеләр өчен иң олы бәхет булып кабул ителә, кире җавап ишетү исә теләсә нинди хөкемнән дә катырак булып чыга.

Әнә Бәрия дигән бозык хатын җиңгәсе Нуриасмадан «бәхил» сүзен кабул итеп алырга бик тә теләр иде. Ләкин мондый үтә газиз сүзне ишетмәү аның мәгънәсез яшәгән гомеренә бирелгән гадел бәя. Бәрия — өе алтын-көмешкә күмелгән, сандык тулы акчалы хатын — ахыр чиктә үзенең иң фәкыйрь һәм рухи ярлы икәнен сизә башлый.

Нуриасманы исә фәрештәгә тиңләргә мөмкин. Татар хатыннарына хас затлылык, сабырлык, эшчәнлек, вөҗдан чисталыгы — боларның һәммәсе әлеге образда шактый тулы тупланган.

Йә, әйтегез, кияүгә дә чыкмаган башы белән, кыз килеш башка берәү тарафыннан урамга ташлап калдырылган баланы алып кайтып, булачак иренә аны үзенеке дип әйтергә кемнең кыюлыгы җитәр икән?! Бу бөек серне бөтен дөньядан гомер буе яшереп сакларга, малайның ятим икәнлеген сиздермәс өчен аны икеләтә яратырга Нуриасмага аз көч кирәк булмагандыр... Әтиләре үлгәч, шушы Фәрит ике энесе, бер сеңлесе өчен ата урынына калган икән, бу инде әлеге гаиләнең таза әхлак нигезенә корылганлыгын раслый.

Йә, әйтегез, иренең күрше хатыны белән йөрүен күреп тә, шау-шу куптармыйча, кешелек дәрәҗәсен саклап калырга кемнең көче җитәр иде икән?! Бу хыянәтнең сәбәбе үзенең тиешенчә хатын-кыз була алмавыннан икәнен төшенеп, ирен яңадан яулап алу өчен иң дөрес юлны табарга күңел сизгерлеге, зирәклеге һәм ихтыяр көче җиткән хатын бездә ихтирам уятмыймыни?

Йә, әйтегез, тудырып үстергән кызы тарафыннан куып чыгарылган кайнанасын үзенә алып, аны ун ел тәрбияләү, актык сулышынача хөрмәтләү һәм тагын ирсез көенчә дүрт баланы аякка бастыру, һәрберсен Кеше итеп үстерү өчен күпме түземлелек таләп ителгәндер! Шуның өстенә, авыл яме, аның иминлеге, бөтенлеге, төзеклеге өчен борчылып, балалары белән тау битләренә агачларга хәтле утыртырга аңа нинди илаһи көч ярдәм итте икән?

Мондый кешенең үзен иң бәхетле җан иясе итеп санарга хакы бар. Моны тою — зур әйбер. Ләкин, шул ук вакытта, үзе дә сизмәстән, Нуриасма ялган идеаллар колына да әверелә. Аның бик күп матур сыйфатлары (һәм Нуриасма кебек бик күпләрнеке) алдауга корылган җәмгыятебездә рәхимсез файдаланылды, аларның хезмәт нәтиҗәләре социализм строеның өстен катлаулары тарафыннан оятсызларча үзләштерелде. Нуриасма изге дип исәпләгән нәрсәләр бары тик нормаль җәмгыятьтә генә кыйммәткә ия булырга мөмкин иде. Ә болай ул кешегә каршы корылган мәкер җәтмәләре белән уратып алынган иде.

Чыннан да, күмәк эшкә әллә ни исе китмичә, үз җаен гына кайгыртып яшәгән Хәдичәләр — «егерме елдан коммунизм булачак» дип аңлаткан райком инструкторына «әкият сөйләмәгез» дип әйткән Хәдичәләр, җае туры килгәндә кешенең

тиресен тунап байлык җыйган Бәрияләр ул елларда дөресрәк яшәгән түгелме соң? Алар акыллырак булып чыга ич! Чөнки боларның күзеннән социализмның гаделлегенә ышану пәрдәсе күптән төшкән.

Мәҗит Хөснуллин кебек читтән килгән колхоз рәисләренең күп очракта гастролер икәнлекләрен аңлау өчен дә әлләни акыл кирәкми. Әнә бу капкорсак колхоз исәбенә нинди йорт җиткергән! Аннары аны сатып җибәргән. Хәзер исә әллә кайдагы туган авылында йорт салу өчен күмәк хуҗалыкның бөтен мөмкинлеген эшкә җиккән. Шофер Гарифҗанның исерек икәнлеген күрә торып, Хөснуллин аны әнә шул урлап оешачак өенә бүрәнә алып кайтырга урманга җибәрә. Нуриасма кебек үк изге җанлы Рәмзинең үлеменә дә колхоз рәисе иң әүвәл үзе гаепле. Аның шул гөнаһсын каплау өчен, күрәләтә торып, врачлар «Гарифҗан рульгә аек хәлдә утырган» дигән белешмә бирәләр. Үлгән Рәмзинең хатынын ферма мөдире итеп билгеләп, бүтәннәрне башкача җайлап, Хөснуллин эшне үз файдасына үзгәртүгә ирешә. Нуриасма белүенә караганда, «һәммәсе дә Хөснуллинга килеп тоташа иде. Врачлар аның кулында. Ул аларга колхозның түшкәтүшкә итен, чиләк-чиләк балын, капчык-капчык икмәген озата. Аптека мөдирләрен әйткән дә юк. Халыкка дип кайткан барлык кыйммәтле дарулар райкомның беренче секретаре белән Хөснуллинга китеп бара, дип сөйлиләр... Халык җилкәсендә кәеф-сафа корып, җинаять өстенә җинаять кылып, үз башларын гына саклап яшәүчеләр менә шушы идарә йортыннан алып Мәскәүгә кадәр берберсе белән бәйләнгәннәр».

Колхоз рәисенең кодрәте аның прокуратура тикшерүчесен уч төбендә биетүендә бигрәк тә ачык, җирәнгеч булып күренә. Бөтен тикшерү-хөкем әһелләре райкомга һәм хуҗалык җитәкчеләренә сатылып беткән җәмгыятьне хокукый дип әйтергә мөмкин түгел иде шул. Шушы шартларда дөреслекне яклаучы Нуриасма, әлбәттә, кара каргалар арасындагы бердәнбер ала канат булып кала. Улы Мизхәт тә, дуслыкка тугры калам дигән булып, караны ак диючеләр ягына баса. Мондый шартларда, өстеңә ябырылган пычрак ташкынга каршы тору өчен, әйтеп бетергесез ныклык, үҗәтлек кирәк. Ләкин кешенең намус көченә чама булмаса да, йөрәкнең мөмкинлекләре чикле икән шул. Гомер буе дөреслек юлында җәфа күреп яшәгән Нуриасманың йөрәге дә хуҗасына хезмәт итүдән баш тарта. Әмма шунысы кыйммәт: Нуриасма апа үзенең дөньяда яхшы исем, менә дигән уллар-кызлар, оныклар, игелекле эшләр калдыруына сөенеп үлә. Ә менә аракы сатып кеше бозып ятучы Бәрияләргә үлгән чакта беркем дә бәхиллек сорап килмәс. Нуриасма бәхиллеге — гаделлек, изгелек юлына фатиха дигән сүз. Бу ананың бөеклеге әнә шунда. Дөреслек хакына бернинди чигенүләргә бара белмәгән, хәтта кече улы белән ара бозылуыннан да курыкмаган ана образы — укучыда чиксез хөрмәт уята. Язучы Ф. Садриев үзенең уйлануларын шушы бер ноктага — намуслы яшәү тирәсенә туплап бик дөрес иткән.

Соңгы елларда язучыларыбыз намус, гаделлек мәсьәләсен әсәрләрдә еш күтәрәләр. Дөрес, Р. Төхфәтуллин, Ә. Еники, А. Гыйләҗев кебек әдипләребез укучының игътибарын ул якка элеккеге елларда ук юнәлтәләр иде. Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым» повестен гына искә төшерик. Әле 1960 елда, ягъни коммунистлар фиркасенең хакимияте аеруча көчле бер чорда, ул әлеге иҗтимагый оешманың, дәрессендә дәүләтне муенчаклап алган бер катлам җитәкчеләренең, кыек куллы бәндәләр белән бер кашыктан ашаулары, моңа комачаулаган намуслы кешеләрне үз ихтыярларына ни рәвешле буйсындыру алымнарын күрсәтеп бирде. Хәтерегездәдер, анда Хәмдиев фамилияле райком хезмәткәре образы бар. Гөлзифалар колхозының рәисе һәм склад мөдире күмәк малны ничек теләсәләр шулай тоталар. Әлбәттә, Хәмдиев кебекләргә дә өлеш чыгаралар. Моны үткен күзле Гөлзифа сизә һәм башта, Хәмдиевне намуслы җитәкчегә санап, аңа бу турыда сөйләп бирә. Тегесе чара күрергә вәгъдә бирә. Бу очракта шушы Хәмдиевнең, шактый көннәр узгач, Гөлзифага әйткән сүзләре гыйбрәтле:

— Каракны бит аны өстендә тоткан яхшы. Хәзер бик авыр мәсьәлә шул инде ул... Аннары, сеңлем, син бу арада эшкә салкын карый башлагансың. Ярамый алай. Үзең комсомолка. Анда безнең туганнар кан коя, илнең язмышы хәл ителә, ә син тылда ятып җиңү эшенә аяк чаласың. Кара аны!

Күрәбез, колхоз исәбенә ашаучылар мафия булып оешканнар. Алар райкомда эшләүчеләр белән бер булып эш итәләр. Шуңа күрә андыйлар белән көрәшү күп очракта мөмкин түгел. Ярый, Гөлзифага әлеге хәлдән чыгарга Мөнир дигән егет ярдәм итә. Югыйсә, Хәмдиев дигән бәндә, Гөлзифа турында чүп-чар гайбәт җыеп, шактый җитди «эш» ачу нияте белән йөри башлаган була инде.

Җитәкче оешманың кешеләр язмышын әнә шундый интригалар оештырып «хәл итүен» моннан да оста күрсәтеп булмыйдыр. Заманында А. Расих, М. Хә-

бибуллин, Х. Хәйруллин, Г. Ахунов, В. Нуруллиннар кебек авыл мәүзугына уңышлы әсәрләр иҗат иткән язучыларыбыз да шушына охшаш күренешләрне сак кына булса да бирә бардылар. Җәмгыятьнең болай барса алга таба да мантымасын унай геройлар авызыннан булмаса, тискәреләренең сүзләре аркылы булса да искәртергә тырыштылар. Һәр җөмлә партия цензурасы иләге аркылы үткәрелгән ул заманнарда шуннан да артыгына өмет тоту мөмкин түгел иде.

Бүген исә бу мәсьәләләр хакында кыю язылган әсәрләр укыйбыз. Фәрит Гыйльминең «Зәйтүнәкәй — акчарлагым» дигән хикәясе шуларның берсе.

Элеккеге татар тормышының каһәрле яклары турында сүз чыкса, еш кына М. Гафуриның «Шагыйрьнең алтын приискасында» повестендагы бер күренешкә игътибарны юнәлтүләр була иде. Имеш, алтын юып интегүчеләр янына приска хуҗалары бертуган Рәмиевләр әнә ничек итеп пөхтә, матур киенеп килгәннәр. (Кешеләр тиргә батып эшләгәндә, болар шәмдәй төз гәүдәләрен күрсәтеп йөргән тәм табалар, янәсе.) Ләкин шушы хуҗалар йөзләгән кешеләрне эш, яшәү чыганагы белән тәэмин иткәннәр, тамакларын туйдырганнар. Белүебезчә, аларның миллионнар туплаганчы, йә баш, йә мал дип, нинди тәвәккәллекләргә барганлыкларын да истән чыгарырга ярамый. Җәй көне үз приискаларын бер карап китәләр икән, монда мин үзем бернинди дә гаеп-кыек күрмим. Аның каравы, алар бирегә гаиләләре, бала-чагалары белән килгәннәр. Мөселманча яшәү рәвешенең бөтен шартын китереп, кирәгендә эш белән мәшгуль булып, вакытында намаз укып, гадәтчә генә күңел ачып, бераз шушында торып китүләрендә бернинди дә хилафлык юк. Әлбәттә, совет хакимияте урнашып ун ел тулып узгач, «буржуйлар»ның тетмәсен тетү иң модада чагында М. Гафури да, заман шаукымына ияреп, миллионер шагыйрьгә сонлап булса да рәсми идеология күңеленә сары май булып ятардай сүз әйтүдән тыелып кала алмаган. Ләкин «а»ны әйткәч, «б»сын да әйтү тиеш иде. Шул ук Рәмиевләрнең Орск ягындагы Юлык авылында 1898 елда мәһабәт итеп таш мәчет салдырулары, зур мәдрәсә ачулары, русча укыта торган мәктәп булдырулары, хәлфә-укытучыларны үз исәпләренә тотулары, хәтта китапханә оештырулары турында да ник әйтмәскә? Билгеле булганча, 1919 елда шушы китапханәдә күренекле драматургыбыз М. Фәйзи эшли. Алай гына да түгел, егермеләп приискаларының һәрберсендә мәдрәсә ачып бирүләре дә мәгълүм. Шушы бертуганнарның «Вакыт» газетасын, «Шура» журналын чыгаруларын да өстәсәң, аларның татар халкы өчен кылган гамәлләренең зурлыгы тагын да ерактанрак күренә. Болар М. Гафурига мәгълүм идеме? Шикләнми әйтергә мөмкин, белгән ул аларны. Ләкин большевиклар каләменнне мең күз белән күзәтеп торганда, бар, «буржуй»ларның унай ягын әйтеп кара! Башың ике булса!

Ярый, хуш, инде совет чоры түрәләренең «приискаларга» ничек килеп йөрүләрен күздән кичерик. Бу эштә безгә Ф. Гыйльми әсәре ярдәм итәр. Әйе, бу катлам, әхлакның бөтен кануннарын атлап чыгып, үзләре белән бергә башкаларны да, аеруча яшь буынны аларча тәрбияләүдә аз эшләмәде. Чөнки аларга биләгән урыннарында нык басып тору, һаман саен көчәя барган азгынлык омтылышларын канәгатьләндерү өчен янадан-яна куштаннар, «айт» дигәнгә «тайт» дип торучылар, һәм, әйтергә кирәк, йә ирекле рәвештә, йә шуна мәҗбүр ителгән корбаннар кирәк иде. Ф. Гыйльми шулар җәннәтенең бер кечкенә генә читен ачып күрсәтә.

Татарстан элеккеге бөек илдә иң кыерсытылган өлкәләрнең (әйе, Мәскәү өчен ул җөмһүрият түгел иде) берсе булып, халкы да түбән сорт дип бәяләнде. Тантаналы утырышлардан соң уздырыла торган хөкүмәт дәрәҗәсендәге концертларда татар артистларының чыгышын тыңладыкмы без? Юк! Ил үсешенә өлеш керткән халыкларны санаганда союздаш җөмһүриятләрнең милләтләре генә искә алынды һ. б. Татарстанга башлык итеп читтән китерелгән, исемнәре генә татарча яңгыраган түрәләр яшәп күрсәттеләр дә соң! Төрле төбәкләрдә алар өчен салынган күңел ачу ханәләрен генә ал син. Ф. Гыйльми дә шундый «теге йорт»ларның берсе ерак бер авылның иң матур, җәннәт урынына салынуын әйтә. Шул районның түрәләре аны «Минзәләләрнекеннән әйбәт булырга тиеш!» дип салдырганнар. Шулай булмаса, аларның эшчәнлекләре, башларын ташка орсалар да, тиешенчә бәяләнмәячәк, янәсе.

Көннәрдән бер көнне «теге йортка» Хуҗа килеп төшә. Моны белгәч, район дәррәү аякка баса! Көтүчедән алып райкомның беренчесенә кадәр һәммәсе Хуҗаның күңелен күрү өчен тырышалар. Сый-хөрмәтнең чиге юк. Ләкин Хуҗага бу гына җитми. Аңа кичке чәйне чибәр, саф, яшь кыз ясап бирергә тиеш икән. Алай гына да түгел, бу кыз төнен аның ятагында уздырырга да бурычлы. Шулай булмаса, Хуҗаның күңелен күрдем дип уйлыйсы да юк. Димәк, ул синең эшеңнән

канәгать булмаска, шунардан теләсә нинди нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Классик язучыбыз М. Гафури боларны күрсә, нәрсә дияр, аларны үз әсәрләрендә ничегрәк итеп яктыртыр иде икән? Иманым камил, бередә сурәтләнгән мир үгезләрен берәр әсәренен үзәгенә куеп сурәтләүнең бер-бер җаен тапмый калмас иде ул!

Мине иң хәвефләндергәне шулай да әле бу түгел. Боларны инде төзәтеп булмый, бары тик шулай гыйбрәт итеп сөйләргә генә кала. Мине иң борчыганы — шушы хуҗаларга алмашка әкренләп яңаларның әзерләнүе һәм килүе. Моны Ф. Гыйльми дә ассызыклап күрсәтә. Егерме дүрт яшьлек Равил мәктәп директоры булып эшли. Ул үз коллективында пионер вожатые булып эшләүче унсигез яшьлек Зәйтүнәне ярата. Аларның икесе арасындагы мәхәббәткә укучы соклана башлый. Ләкин... көннәрдән бер көнне колхоз рәисе Равилгә үзенең сөйгәнен теге Хуҗага «кичке чәй эчерергә» җибәрергә куша. Равил бала-чага түгел, урман эчендәге аулак өйдә Хуҗаның кызлар белән нинди «чәй» эчүен яхшы белә. Шуңа күрә, аның мондый тәкъдимне ишеткәч: «Бу мөмкин түгел, мин рөхсәт итә алмыйм...» — дип белештермичә әйтеп куюы да бик табигый. Ләкин колхоз рәисенең: «Ул синең хатыныңмы әллә? Түгел! Уйла!.. Син ахмак малай түгел!» — дип әйтүе була, егетнең ихтыяры сына, сөйгән кызын үз карьерасы өчен корбан итә. Нәтиҗәдә, төн буена мәсхәрәләнгән кыз иртәгесен үз-үзенә кул салырга мәҗбүр була.

Равил, өлкән кешеләрдән күреп, әгәр өстен катлау арасында калырга теләсәң, бүген һәм алга таба ничегрәк эш итәргә кирәклеген шактый яхшы төшенгән. Ул инде кешеләрне үзе өчен ике сортка бүлгән. Берәүләр аңа аралашырга яраклы кешеләр: райкомда эшләүчеләр, халык мәгариф бүлеге мөдире, колхоз рәисе. Икенчеләре — гади халык, «кара сарык». Әнә Зәйтүнә аңа авыл егетләре-кызлары янына уен кичәсенә барырга тәкъдим итә. Бу сүздән Равилнең коты оча. Чөнки кичә генә партиягә кандидат итеп алынган кешегә андый җирләргә барып йөрү килешә торган эшмени? Ул, киресенчә, авыл халкыннан читләшергә, биек коймалар артына яшеренергә, серле булып калырга тиеш. Кешеләр аңардан куркырга тиешләр. «Куркалар — димәк, мине хөрмәт итәләр!» — ди ул. Әйе, түрәләрнең эреләре дә, ваклары да шушындый җирәнгеч фәлсәфә белән коралланган иде. Мондыйлар утырган урыннарында калу өчен, сөйгән кызларын гына түгел, туган ата-аналарын да, һич авырсынмыйча, сатып җибәрә ала!

Ә. Баянов — тормышта бара торган тенденцияләргә иң сизгер әдип — «Таш китап» әсәрендә байтак еллар элек инде бу теманы күтәргән һәм аның авыр нәтиҗәләргә китерәчәген кисәткән иде. Кызганыч, партия әдипләрнең акыллы сүзенә үз вакытында колак сала белмәде. Бу исә аның үзен үк тирән упкынга китереп чыгарды. Әйе, күз яшьләре бервакыт якадан китереп тота шул. Ә намуслы яшәү — гомерне озайта, аны мәгънәле итә. Ни үкенеч, бик күпләр бу хакыйкатькә эш узгач кына төшенә.

Гомер, вакыт — аккан судай хәрәкәттә. Бер үк суга ике тапкыр кереп булмый, диләр. Язучыларның исә бер үк темага кат-кат алынуларын очратырга була. Г. Ахуновның «Гомер юлы» романын укыгач, шундый фикергә килдем. Бу әсәр 1985—89 елларда язылган. Билгеле булганча, бу язучыбыз моннан егерме еллар элек, ягъни 1970—71 елларда «Чикләвек төше» повестен биргән иде. Әлеге әсәрләрнең икесе дә (гәрчә тормышыбызның төрле чорларын яктыртсалар да) бер үк темага: җәмгыятебез белән кеше, тарайтыбрак әйтсәк, ул вакытларда үзен ходай тәгаләдән дә өстен куйган коммунистлар партиясе белән аның әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрне күрсәтүгә багышланган.

Г. Ахунов — олы биографияле, гомерендә күпне күргән, күпне кичергән, ходайның һәр бирмеш көнне әдәбият мәйданында иҗат иткән кеше. Шул ук вакытта, Язучылар берлеге җитәкчесе буларак, партия өлкә комитеты тирәсендә, илнең Югары Советы депутаты буларак, Мәскәү җитәкчелеге мохитендә дә күп йөргән шәхес. Гади халык тормышыннан да аерылып торган чагы булмады аның. Шулай булгач, аның үз заманы тормышын яхшы белүенә кем шикләнер икән? Сүз илленче еллардан алып бүгенге көнгә кадәр булган вакыт аралыгы турында бара. Үзе яшәгән елларның бөтен катлаулылыгын әдәби әсәрләрдә сурәтләп биргән язучы тарих өчен бик игелекле эш калдыра.

Г. Ахуновның «Чикләвек төше» белән «Гомер юлы» әсәрләрен янәшә телгә алуым очраклы түгел. Бу соңгысын укыганда, телисеңме-теләмисеңме, Халикъ Саматов белән булган хәл-әхвәллар параллель рәвештә искә төшәләр һәм табигый генә уйлап та куясың: бу икенче әсәрен язып, инде үз вакытында шактый уңышлы дип табылган повестында гәүдәләндерелгәннәргә язучы нәрсә өстәгән? Алдан ук әйтеп куям, романның соңгы битен (журнал варианты турында сүз бара) ябып куйгач, күңелдә канәгатьлек туа. Г. Ахунов элеккеге әсәрендәге

уйларын бу юлы яңа югарылыкта дәвам иттерә, житмешенче еллар башында әйтеп бетермичә, күп ноктлалар белән калырга мәжбүр булганнарны каләменнән түгә. Иң мөһиме, коммунистлар партиясенең җәмгыятьтәге урыны турындагы уйлануларына күпмедер дәрәҗәдә йомгак ясый.

Әйе, партия, ничек кенә гаҗәп тоелмасын, илебез җәмгыятенең нигезен какшатучы көч булды. Аның эшчәнлегендәге бер якны гына карыйк. Ул да булса кешенең түбәнгерәк урыннан югарырак баскычка күтәрелүенә куелган шартны. Мин, комсомол һәм партия райкомнарында эшләп алган кеше, бик яхшы беләм: бары тик эш өчен янып, булсын дип йөреп кенә өскәрәк күтәрелеп булмый иде. Алай була торган булса, Кукмара райкомының «мәңгелек» инструкторы Фәрхинур Вәлиуллина әллә кем булган булыр иде. Юк, аңа шул сызыкны атлап чыгу мөмкин булмады. Чөнки түрәләр алдында тәлинкә тоту гадәте юк иде. Мин үзем дә моны бик тиз сизеп алдым. Яшь чак, көч-куәт бер кочак. Партиянең бик акыллы, әмма тормышта кулланырга ярамый торган матур сүзләренә ышанып, мин бик «хәтәр» башбаштаклык эшләп ташлаганмын. Көннәрдән бер көнне «Дружба» колхозы парткомы секретарьсез калды. Читтән килгән бу кешене каядыр икенче урынга күчерделәр. Колхозның үзәге Иске Кенә (Мултан дип тә йөртәләр) исемле мари авылында. Карыйм, колхозның рәисе дә җирле кеше түгел, каяндыр килгән татар кешесе. Партком секретаре шушы авыл кешесе булса, моңардан эш отар гына иде. Лаеклы кешесе дә бар. Тоттым да партбюрода А. Григорьев дигән укымышлы гына, оештыру сәләтенә дә ия, абруйлы мари егетен тәкъдим иттем. Шунда мариларның куанулары! Әле дә күз алдымнан китми. Ләкин бу минем үземә шактый кыйммәткә төште. Күз ачып йомганчы район мәдәният йорты директоры итеп күчереп тә куйдылар! Кычытмаганны кашып, мариларны номенклатурага кертеп йөрмәсен, янәсе.

Партиянең кадрлар мәсьәләсендәге төп хаталарыннан берсе, Г. Ахунов әйтмешли, аңа «тырышып ярамый кеше, койрык болгап ярый». Әгәр дә партиягә күпчелекнең карьера, түрә булып үрмәләү өчен кергәнлеген искә алсаң, бик куркыныч әйбер бит бу. Алар эшнең рәтенә төшенү, хезмәт ияләренә игелекле булу, үзләре житәкләгән коллективларны үрчемле эшкә оештыру урынына «болай итсәм, райком, обком секретаре нәрсә әйтер икән?» дигән үлчәм белән эш иттеләр. Төп тырышлык партия түрәләре алдында яхшы атлы булып күренергә юнәлде. Моның бәрабәренә гомуми эшкә зыян китерү алар өчен берни дә тормады.

Г. Ахунов сүз бара торган ике әсәрендә дә шушы мәүзугны тирәнәйтеп, әлеге хәлнең афәтле якларын ачуга язучылык сәләтен туплый. Укучы белә, «Чикләвек төше»ндә, дүрт мең центнер ашлыкны күгәрткән дигән сылтау белән, райком секретаре Байназаров колхоз рәисе Саматовны эшеннән алу мәсьәләсен куя һәм моңа ирешә дә. «Гомер юлы»нда да шул ук хәл. Утыз җиде яшьлек колхоз рәисе Галинур Айтуганов ашлыкны райком таләп иткән вакытта чәчмәве (җир өлгерүгә карап эш итүе), икмәкне хөкүмәткә киптереп тапшыруы (чи тапшырсаң, план үтәү өчен бермә-бер артык бирергә кирәк) сәбәпле районның бу мәсьәләләрдә планны үз вакытында үтәвен өзгән булып чыга. Гомумән, аның үз акылы үзендә, шуңа күрә колхоз елдан-ел ныгый гына бара. Болар, әлбәттә, «райкомга бар җирдә дә буйсыналар, бар җирдә дә партия җитәкчелек итә» дип катып калган райком секретарьлары Байназаров, Тимергалиев ишеләр өчен гадәттән тыш хәлләр. Халикъ, Галинурлар исә мондыйларга тамак төбенә утырган балык кылчыгы иде.

Шунысы кызык, Халикъны урыныннан алырга килгәч, Байназаров партбюро җыя. Аның әгъзаларын колхозның гомуми җыелышында райком ихтыярын якларга күндерү берни дә тормый. Ләкин җыелышта Халикъны урыныннан алу мәсьәләсе тавышка куелгач, шушы алты коммунисттан гайре беркем дә кул күтәрми. Биш йөз колхозчы намуслы булып, ә алты коммунист исә үз фикерсез, өстән кушканга мөһер сугып утыручы гына булып кала. Мондый эш стиле партиянең җәмгыять өчен куркыныч көч булып әверелә баруы турында сөйли иде.

«Гомер юлы»нда исә Тимергалиев, үзе килгәч, шулай ук иң әүвәл партия активын җыеп ала. Әмма, бәхеткә каршы, эш шуннан артыкка китми. Бирелдәге коммунистлар Галинурны эштән алу мәсьәләсен җыелышка куюдан баш тарталар. Сорауның: «Райкомның авторитеты бер тиенгә дә тормыймыни? — дип куелуына да аларның җавабы әзер. «Партия исеменнән сөйләүчеләрне күргән бар безнең. Үзенең шәхси мөнәсәбәтен партия бәясе дип житкерергә килгәннәрне дә, шөкер, күрмәдек түгел, күрдек». Шулай итеп, Тимергалиев җиңелә. Әлбәттә, 1985 елдан соңгы шартларда вакыйганың мондый борылыш алуы табигый иде. Ләкин ахыр чиктә, Халикъ кебек үк, Галинур да рәислеген ташлап китәргә мәжбүр була.

Димәк, нәтиҗә бер — райкомнарның җыелышлардан башка да җирле кадрларга тәэсир итәрдәй көчләре зур иде шул. Күргәнебезчә, җәмгыятебез үсешенә комачау булучы көчкә әверелгән мондый партиянең алга таба да яшәргә хокукы булмагандыр. Шулай булмаса, ул юк кына сәбәпләр аркасында тиз генә җимерелеп төшмәгән дә булыр иде.

Г. Ахунов соңгы әсәрендә бик кызыклы бер күзәтү ясый. Ул да булса эш рәтен белүче, «киребеткән» кешеләргә карата райком җитәкчеләренең тискәре мөнәсәбәтләренең күчемлелеген ачып сала. Тимергалиевка эшне тапшырганда райкомның элеккеге Беренчесе Ханзафаров аңа баштан ук Айтугановлар турында (районлагы иң акыллы һәм булдыклы колхоз җитәкчеләре хакында!) күңел кайтарырлык бәяләмә бирә. «Айтугановлар,— ди ул,— коммунист булсалар да, партия солдатлары димәс идем мин аларны. Барлык урында ил кушканны, партия кушканны үтәп тору нык җәелгән бер заманда, болар, үзләренчә кыланган булып, райком эшенә аяк чалалар... Килгән-киткән түрәләргә күрсәтер өчен файдалан син аларны, вәләкин азындырма... Айтугановларның икесенең берсеннән котылырга кирәк сиңа». Аз да түгел, күп тә түгел, нәкъ менә шулай ди.

Шунысын да әйтергә кирәк, эшнең мондый стиле райкомнарга гына хас түгел иде, өлкә комитеты, Үзәк Комитет та шул ук сәясәт белән эш итте, шуңа охшаш алымнар кулланды. Әмма Г. Ахунов — әсәрләрендә райкомнарны тәнкыйть иткән язучы — өлкә комитетын гаделлек урнаштыруда арбитр итеп сурәтләргә омтыла. Тимергалиев эшне кирәгенчә оештырмаган өчен эштән алына, Фәһим, Галинур Айтугановлар да гаделлек эзләп шулай ук обкомга баралар һәм, гаҗәпкә каршы, табалар да. Ә обком дөреслекне табу урыны идеме соң?

Юк шул! Обком, гаделлек органы булса, татар телен урысныкына алыштыру кампаниясенә каршы тора алган булыр иде. Обком, кеше мәнфәгатьләрен кайгыртучы булса, кемнәрдер подвалларда интеккән чакта аның түрәләре үзләренә фатир-сарайлар ясатмаслар, халыктан оялу хисенә ия булырлар иде. Обкомда аз гына булса да халык мәнфәгатьләре турында уйлау булса, тарихыбызны шулкадәр бозуга юл куелмас иде. Обком, ак гамәлләр кылучы булса, Гаяз Исхакый, Гайнан Вәисов кебек тарихи шәхесләр эшчәнлегенә үз вакытында тиешле бәя бирелер иде. Мондый дәлилләрне тагы да куярга мөмкин. Шуңа күрә, райкомнарны тәнкыйтьләп тә, өлкә комитетын сөттән ак итеп тасвирлау дөреслеккә хилафлык итү.

Шунысы ачык, бу хәлгә өлкә комитеты гына да гаепле түгел иде. Ул бичара, үз чиратында, Үзәк Комитетның колы булды. Шул рәвешле, партия мафиясенең югарыдан түбәнгә кадәр төшә торган төзек структурасы, гаять оста җитәкчелек итә торган коралы бар иде. Инде 1985 елдан соң болар хакында шомартмыйча язарга ярыйдыр лабаса? Г. Ахунов кебек әдипнең моны аңламавы мөмкин түгел. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, аларның күңел дөньясын гомере буе кызыксынып өйрәнгән Г. Ахунов аның каравы шул ук номенклатурага керүчеләрнең икейөзлелеген оста ача. Бу бигрәк тә агропром җитәкчесе Сәүбановның эшхәрәкәтләрендә ачык күренә. Бу кеше, яңа хуҗа Тимергалиевкә ярар өчен, аңа атап патша сарае кебек итеп йорт салдыра, беренче секретарьның күрсәтмәләрен кушканнан да арттырып үтәп йөри. Ә инде шул ук Тимергалиевнең астына су кергәч, әлеге Сәүбанов, маскасын алып ташлап, әүвәлге җитәкчесенә бәйдән ычкындырылган эт кебек ташлана. Кайда монда әхлак? Юк ул. Була да алмый. Мондыйлар өчен бары бер кагыйдә бар — җае туры килгәндә, башкаларны этеп-төртеп, башларына басып алга үрмәләү, үз җирлегенне ныгытып калу. Юкса, беләләр, номенклатурадан бер чыктыңмы, син инде кеше түгел, бетәсең. Ә кемнең тере килеш бетәсе килсен? Шуңа күрә алар, көйле эшләгән чакта бербересен куәтләп җан атарга әзерләр, ә берәрсе өстәге түрәләр алдында «иләмсез үрдәккә» әйләндеме, аны рәхимсез рәвештә үз араларыннан кысып чыгарырга тырышалар.

Г. Ахунов моны семьячылык белән чагыштыра. Бездә, билгеле булганча, шушы сүзне бүки урынына кулландылар, берүк семьячылыкта гаепләмәсеннәр — беттең! Тимергалиевнең: «Тәмам тулган икән безнең район Айтугановлар белән. Башка чакта семьячылык дип кычкырабыз. Айтугановларныкы ничек соң ул семьячылык булмый?» — дигән соравына Гайниев бик тә акыллы җавап бирә: «Семьячылык бит ул бер гаилә кешеләре җыелуда гына түгел. Үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан кешеләрнең бер өергә җыелуларында ул». Бу сүзләрне укыгач, «Афәрин, Гариф абый» — дип куйганынны сизми дә каласың.

«Өер!» Р. Мөхәммәдиев үзенең «Кенәри — читлек кошы» әсәрендә моны бик гыйбрәтле итеп сурәтләп бирде. Автор аларны арысланнар өеренә охшата. Ерткычлар төркемендәге кебек үк, бирелә дә ныклы иерархия кабул ителгән.

Аның иң югары баскычында ниндидер билгесез (мафиядә житәкченең билгесез булуы табигый нәрсә) Лев Белялович. Аннан бер баскыч кала — сәүдә базасы директоры Арслан Сәхипович (игътибар итегез: икесенең дә исеме — Арслан). Халык контроле башлыгы боларга шашлык кыздырырга гына ярый. Тәмле ризыклар белән тәэмин итүче кибет директоры Капкаев белән алар икесе өстен катлауларга хезмәт күрсәтә. Ләкин бу соңгылары да үзләрен арсланнар рәтендә исәпли. Әшнәләрнең арасына кыл да сыярлык түгел. Хезмәтләрендә дә кул — кулны, ә ике кул битне юа. Кырык-илледән узган бу азгын ирләр, хатыннары-балаларыннан качып, бирегә төрле тәтәйләр белән типтерәләр. Төнге уникегә кадәр кәеф-сафа кылып «хәлдән тайгач», кинәшмәләрнең шулай озак баруын сүгә-сүгә, өйдәге хатыннары янына кайтып авалар. Көндез, кеше кыяфәтенә кереп, житәкчелек дилбегәсен үз кулларына алалар. Кул астындагыларга икенче, өченче сорт кеше дип карап, аларның хезмәт нәтижәләрен шәхси мәнфәгатьләре өчен файдаланалар. Йә, әйтегез, болар кемнәр? Җавап бер — жәмгыятебезнең соры кортлары. Мондыйлар үз теләге белән шушы рәхәт тормышларыннан аерылырга теләмәс шул.

Әлбәттә, барлык эш урыннарында житәкчеләрне сайлап кую гамәлгә ашырыла башласа, хезмәт иясе дилбегәне кемнәр кулына тоттыру-тоттырмау мәсьәләсен мөмкин кадәр дөрес хәл итәр иде. Тик бирегә дә, әзергә бәзер булып, кул кушырып утырырга ярамый. Ник дигәндә, әлеге «арысланнар» да тик кенә көтеп тормый. Лев Белялович сүзләренә колак салыгыз әле: «Бер йодрык булырга кирәк хәзер. Салпы якларына салам кыстырып, кешеләрнең күңелен күрә белергә. Таныш-белешең ишлерәк булу зыян итми. Җанны ачмыйсың, авызны ачыбрак исәнләшсәң, шул житә андыйларга. Обстановка шуны таләп итә хәзер, сайлый калсалар — шулар хәл итәчәк. Димәк, кешеләргә яхшы атлы булган булып жылы урыннарын саклап калу мондыйларның төп максатына әверелә. Ә үз араларында исә бөтенләй туарылып бетәләр, хайвани тормыш белән яши башлыйлар. Шулай да эч серләрен «кенәри» дип аталган сөяркәләре алдында да ачып селкемиләр. Бу соңгылары аларга бары тик ятакларын ямьләндерү өчен генә кирәк.

Дөресен әйткәндә, «кенәри»ләргә карата боларның тулы бер фәлсәфәсе бар. Ул бигрәк тә Арслан Сәхипыч сүзләреннән аңлашыла: «Кенәри озак яшәми, — ди ул, — алышынып торулары хәерле». Түгәрәк корсаклы арыслан дигәннәребез генә озын гомерле булырга тиеш икән, ә аларга наз бүләк итүче фәхишәләрнең, кульяулыгы кебек, атна саен чистага алыштырылуы мөһим булып чыга. «Кенәри — бәхет кошы», — димәкчеләр әлеге арысланнар. Әмма тирән ялгышалар. Харам ризык белән эч күперткән бу түрәләр белән булырга мәжбүрләнү кенәри исеме тагылган хатыннарга мең газап алып килә. Газапланмаслар иде, яшиселәре килә, форсаттан файдаланып күбрәк акча умырып калырга исәпләре.

Дөнья булгач, әлеге «кенәри» дигәннәре дә берторле генә түгел. Бар шушы кәсепне ихтыяри алганнары, бар, Асия кебек, моны мәхәббәт дип алданганнары. Автор роман үзәгенә хәзерге чынбарлыкта буталып, адашып калган шушы Асия образын куя. Аның фәхишәлек юлына төшүенең тарихын эзлеклелек белән ачып сала.

Безнең жәмгыятебездә ни өчен Асия кебекләр тәрбияләнә? Романның катлаулы тукымасы шушы сорауга жавап бирә. Иң аянычы шунда: кешеләрне проблемага бүлү бездә балалар арасында ук башланган булган бит. Карагыз сез ит чабучы кызы Рамилә белән партия хезмәткәре кызы Юлияне. Югыйсә, бер караганда, аларны нәрсә берләштерә дип уйлыйсың? Гажәпкә каршы, боларны якынайтучы нәрсә әшнәлек, байлык икән бит. Икесе дә, базаның үзенә барып, иң дефицит товарларны беренче чиратта алу хокукына ия булганнар. Кая ул укытучы кызы Асиягә алар артыннан житү? Бу нәрсәләр кыз күңеленә жәрәхәт ясый. Юк, укытучы кызы үзен болардан өстен куярга теләми, әмма шулар арасында аңа да урын табылмавын аңларга әле Асиянең тормыш тәжрибәсе дә, уйлау сәләте дә житми. Шулай да яшь кызны матур кием, ресторан утлары, бәллүр чыңнары кызыктыра. Чөнки кемнәрдер өчен боларның гадәти әйбер икәнен күрә, житмәсә ходай тәгалә буй-сынны, матурлыкны да аннан кызганмаган. Ата-ананың «эш өчен үстерелмәгән кызы», шул рәвешле, үзенә шогыльне төнге күңел ачу кичәләрендә таба башлый. Кеше чыгарган тәтеине мин дә чыгарыйм, дип кенә Фидаил исемле бер авыл егетенә кияүгә чыга. Әмма табигатенә азгынлык сеңгән бу хатын инде бер иргә генә карап тора аламы соң? Ул Арслан Сәхипыч белән әлеге «мәхәббәт утравында» типтерә башлый. Асиянең иң зур ялгышы шунда: ул моны чын мәхәббәт дип кабул итә. Килер бер көн, Сәхипыч дигәнебез, хатыны белән кызыннан аерылып, үзе белән яши башлар дип өметләнә ул.

Җәмгыятебездәге мондый тискәре нәтиҗәләр соңгы берничә ел җимеше генә түгел. Р. Мөхәммәдиев романда моннан элеккеге берничә дистә елга да күз ташлый. Кешедә бер-берене ышаныч бетә баруның, алай гына да түгел, әйләнә-тирәдәгеләргә ачу туплану процессын әкренләп ачып бара. Моны ул Фидаил һәм Гыйлем образлары мисалында күрсәтеп бирә. Гыйлем бәхетсезлегенең сәбәбе утыз җиденче еллар тирәсендәге террор булса, Фидаил — җитәкчелектәге әмер-администраторлык методы корбаны. Чөнки аның шаукымы ерак авылларда да тамыр җәйде. Һәр авылда кешене төрмә, штраф белән куркытучы бәндәләр бар иде. Куштаннар номенклатурасына кереп алган мондый куркыныч затлар авылдашлары өстенә кояш чыгармадылар. Әйтерсең лә, мең күзләре бар: һәммәсен белеп, күреп, чагып торалар. Куркуга, таякка нигезләнгән, шундый тәрбия күргән буыннар психологиясенә әле һаман да өстән нәрсәдер басып тора кебек. Ә арысланнар төркеменә исә манкортлар, наркоман Җантимерләр кирәк. Чөнки мондыйларны, кирәге чыкса, Лев Белялович ымлаганча, юк итеп тә була.

Менә нинди кагыйдәләр белән яши әлеге ерткычлар өере.

Күрәбез, соңгы еллар татар прозасында җәмгыятебезнең хәл-әхвәле төрле яклап һәм шактый үтемле яктыртыла. Иң мөһиме — шул мохитнең кешегә тәэсире сәнгать чаралары ярдәмендә өйрәнелә. Ләкин, кем генә, ни генә язмасын, нәтиҗә бер: алга таба да болай яшәү мөмкин түгел иде. Кешене милли рухыннан, гореф-гадәтләреннән, диненнән аерып, боларның һәммәсен партиянең ясалма, уйлап чыгарылган идеологиясе белән алыштырырга омтылу тискәре нәтиҗәләр генә бирде. Меңнәрчә еллар бөртекләп тупланган, камилләшкән рухи кыйммәтләрне бер селтәнү белән юкка чыгару башыннан ук дөрес түгел иде. Ә хәзер кешелек җәмгыяте тудырган барлык игелекле нәрсәләрне заманча үстерү, аларны адәм балаларына тагын да якынайта төшү генә изгелек юлына алып чыгачагын онытмаска тиешбез.

Хәзергә әле без каләмдәшләребезнең тәнкыйть белән мавыгып китүләрен дә күреп торабыз. Шулай да әдәбиятта тәнкыйть рухы үзмаксат булып әверелмәсен иде. Безгә бүгенгебезне, киләчәгебезне яхшырак, кешелеклерәк итәргә булышса гына, аның мәгънәсе булыр. Язучының каләме барыннан да элек шуңа хезмәт итәргә тиеш.

Ә сез ничек уйлыйсыз?

**Яхъя Абдуллин**
философия фәннәре докторы, профессор

# ФИКРИ ЭЗЛӘНҮЛӘР ЮЛЫНДА

Гаяз Исхакый халкыбызның рухи тормышы һәм мәдәнияте тарихында тирән эз калдырган олы шәхес. Ул — җәмәгать эшлеклесе дә, халкыбызның киләчәген кайгыртып иҗат иткән әдип тә, милли азатлык хәрәкәтенә зур өлеш керткән көрәшче дә. Аның иҗаты киң планлы эшчәнлеге иҗтимагый фикеребез тарихында мөһим роль уйнады. Халкыбызның мәнфәгатьләрен күз алдында тоткан хәлдә, ул туктаусыз эзләнде һәм бу эзләнүләр аның фәлсәфи карашлары үсешендә киң чагылыш тапты.

Әйтелгән үсешне өч этапка бүлеп карарга мөмкин: беренчесе — мәгърифәтчелек идеалларына йөз тотып иҗат итү, икенчесе — революцион һәм сыйнфый позицияләрдә торып фикер йөртү һәм, ниһаять, өченчесе — иҗатын һәм бөтен эшчәнлеген милли идеаллар белән бәйләү. Бу этаплар, әлбәттә, берсеннән-берсе кискен рәвештә аерылып тормый. Исхакый иҗатындагы бу катламнарның берсе алдан, икенчесе соңрак барлыкка килә, әмма алар үзара үрелеп, берсен-берсе тулыландырып үсә. Мәгърифәтчелеккә хас тенденцияләр иҗатының беренче этабында барлыкка килә, ләкин алар соңгы ике этапта да күзәтелә. Революцион көрәшкә йөз тоту исә 1905—07 еллар революциясе чорында формалаша. Милли позициядә торып фикер йөртү Исхакый эволюциясенең соңгы этабына хас күренеш. Әмма аның чаткылары инде иҗатының беренче баскычларында ук күзгә ташлана.

Г. Исхакый иҗат мәйданына XIX гасырның азагында килеп керә. Бу елларда татар иҗтимагый фикеренең прогрессив тенденцияләре мәгърифәтчелек фәлсәфәсе белән бәйләнгән була һәм шушы фәлсәфә яшь әдипнең иҗади эшчәнлегенең эчтәлеген били дә. Рационализм һәм мәгърифәт идеясе бу фәлсәфәнең төп принципларыннан санала. Без моны Г. Исхакый иҗатында да ачык күрәбез. Нәрсә турында гына сүз алып бармасын, нинди генә проблема күтәрмәсен, ул аларны рационализм һәм мәгърифәтчелек калыбына салып анализлый, аларга шушы позициядән чыгып бәя бирә.

Г. Исхакый бөтен уй-фикерләре белән туган халкына аерылгысыз бәйләнгән әдип. Әдипне кайчандыр тарихи казанышларга ирешкән татар халкының торгынлыкка төшүе, киләчәге билгесез булу һәм тәрәккыят юлына аяк баса алмавы борчый. Ул, мәгърифәтчеләргә хас рационализм принципына таянып, артталыкның сәбәпләрен ачарга тырыша. Бу эзләнүләр Г. Исхакыйның 1905 елгы революциягә кадәр иҗат иткән күп кенә әсәрләрендә чагылыш тапты. «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле фәлсәфи-публицистик хезмәтендә исә ул тәнәззелгә дучар ителүнең, түбәнгә төшүнең сәбәпләренә тәнкыйди анализ ясый.

Безнең арада мәгърифәтчелекне гадәти уку-укыту, әхлак төзәтү һәм дидактизм дип күзаллау яшәп килә. Хакыйкый мәгърифәтчелек исә — тәнкыйди адым. Аның тарафдарлары урта гасырчылык күренешләрен һәрьяклап тәнкыйтьләп чыктылар. Бу — Г. Исхакый иҗатына да хас. Ул, халыкның аяныч хәлен һәм тәрәккыят юлындагы киртәләрне ачыклау максатында, иҗтимагый тормышны һәрьяклап тәнкыйть күзлеге аша үткәрә. Бу анализ аны, тәрәккыят юлында биш киртә бар, дигән фикергә китерә.

Бу киртәләрнең беренчесе (манигы тәрәкъкый) — халык тормышына тәгассыблык сазлыгына баткан, искелеккә ябышып ятучы руханилар төркеменең

тәэсире. «...Милләтнең тәрәкъкыйга манигъларын эзләгәндә,— дип яза ул,— кай-сы яктан караганда да шул «голяма» сыйнфының иң алда кылычын тотып «җәһаләтне саклавын» күрәсең. («Казан утлары», 1990, № 1, 110 б.) Дөрес, ул руханилар арасында тәрәккыят тарафдарлары барлыгына искәртә. Ләкин, шул ук вакыт, караңгылык сагында торучы тискәре руханиларның өстенлек итүенә басым ясый.

Халыкны тәрәккыят юлыннан читләштерүче сәбәпләрнең икенчесе — заман таләпләренә җавап бирердәй, җәмгыять тормышына, аның алга баруына файда китерерлек гыйлем эстәргә мөмкин булган мәктәп-мәдрәсәләрнең булмавы, ә булганнарында урта гасырдан калган тәртипләр һәм схоластиканың саклануы.

Тәрәккыят юлындагы киртәләрнең өченчесе — милләт хадимнәренең дәрәҗә һәм мәгыйшәте түбән булу. Бу сәбәпкә үз вакытында Ш. Мәрҗани дә игътибар иткән иде. Аның юлыннан барып, Г. Исхакый милли мәсьәләләрне аңлаган, милләткә хезмәт итәрдәй кешеләрнең ярлы булып, милләт файдасына эш-гамәл кылу урынына, көнлекче хәленә калып тамак туйдырырга мәҗбүр булулары тәрәккыят юлында зур киртәдер, дип күрсәтә. «Хәзерге күзгә күренгән эрбабе каләмнең,— дип яза ул,— һичберсе юк ки мөстәкыйльләм хәрәкәт итә алсын, һәммәсе үз тамагын туйдырыр өчен, үзләренең башмакчысы булырга ярамаган кешеләрнең кулларында уенчык булып йөриләр». Нәтиҗәдә, «милләтнең алдан бара торган кешеләре һәм халыкка караңгы юлда ут күрсәтә торган затлары, үзләренең утларын сукырларның күзләренә зарар итмәс өчен, йә бөтенләй күр-сәтмәенчә халыкны караңгылыкта калдыралар, яисә тычкан уты төсле генә якты биреп, халыкны караңгы төндә адаштыралардыр» (шунда ук).

Милли тәрәкъкыйның дүртенчесе, Г. Исхакый фикеренчә, рус мәктәпләрен-нән йөз чөерү, аларга шикләнеп карау, балаларны аларда укытырга теләмәү. Руслар соңгы вакытларда мәктәпләр эшчәнлегенә зур үзгәрешләр кертteләр, уку-укытуны заман таләпләренә муафик рәвештә кордылар, җәмгыятьнең нор-маль яшәеше өчен файдалы гыйлемнәр өйрәнә башладылар. Ә без боларны күрмәмешкә салыштык, уку-укытуда русларда барган бу файдалы үзгәрешләрне кабул итәргә теләмәдек.

Манигы тәрәкъкыйның бишенчесе — алга карап, ахырын уйлап эш итә бел-мәү, эшләгән эшләребезнең төпсез, әссассыз (нигезсез) булуы, эш-гамәлдә эзлек-лелек булмау, башланган эшне ахрына кадәр җиткермичә ярты юлда калдыру, җәмгыятькә, халкыбызга файда китерердәй эш белән шөгыльләнү урынына, вакытны буш гамәлгә сарыф итү.

Менә шушы сәбәпләр, Г. Исхакый фикеренчә, милләтнең чабуыннан тартып тора, артка өстери, туңлыкка, катып калганлыкка китерә һәм ахырда моның бөтенләй юкка чыгуга, инкыйразга илтүе мөмкин.

Халкыбызны бу һәлакәттән коткару өчен ни эшләргә кирәк соң? Г. Исхакый бу сорауга мәгърифәтчелек позицияләрендә торып җавап бирә. Аның фикеренчә, тәрәккыят аерылгысыз рәвештә мәгърифәткә бәйләнгән. Шулай булгач, арт-талыктан, туңлык богауларыннан котылу, караңгылыктан арыну өчен халыкны агартырга, мәгърифәт нурлары белән нурландырырга кирәк. Беренче язма әсәре «Тәгаллемдә сәгадәт» (1897) тә үк инде, Г. Исхакый гыйлем — ул бәхет чыганагы, бары гыйлемнәрне үзләштергәндә генә тормышны бизәргә мөмкин, дигән идея уздыра.

Халыкны мәгърифәт белән нурландыруда иң нәтиҗәле юл — уку-укыту. Ә моңа заман таләпләренә җавап бирердәй уку йортлары аша гына ирешергә мөмкин. Бездә исә хәзергә мондый уку йортлары юк. Булганнарында да шәкерт-ләр вакытларын заяга уздыралар һәм тормышка файда китерердәй гыйлем ала алмыйлар. Милләтнең тәрәккыяте өчен безгә, Европа илләрендәге һәм руслар-дагы кебек, эштә-тормышта файда китерердәй фәнни һәм гамәли гыйлем бирә алырдай уку йортлары кирәк. Моның өчен булган мәктәп-мәдрәсәләребезне ислах кылырга, аларны тәртипкә салырга, фәнни һәм гамәли гыйлемнәр укыта башларга кирәк. Г. Исхакый җәдит мәктәпләре ишәюгә уңай карый һәм аларда шул яна тип, фәнни һәм гамәли белемнәр бирердәй уку йортларының башлан-гычын күрә.

Фән һәм гыйлем өлкәсендә заман белән бергә атларга кирәклегенә Г. Ис-хакый аеруча басым ясап күрсәтә. «Бу гасырда халыклар гакыллар ышанмаслык машиналар иҗат кылганда, безнең димагыбыз (миебез) уйлый алмас дәрәҗәдә фәннәрне тәрәккый иткәндә, безгә дә,— дип яза ул,— башкалар белән бер булыр-га, башкалар кебек эшләргә кирәктер» (шунда ук). Моның өчен безгә һөнәр һәм сәүдә мәктәпләренә керергә, башкалар кебек ук эш-гамәл кылырга өйрәнергә кирәк. Шул ук вакыт, безгә хөкүмәт мәктәпләреннән дә, рус уку йортларыннан

да, университетлардан да читләшмәскә, аларга кереп укып үзебезгә файдалы гыйлемнәр алырга кирәк.

Мәгърифәт казанышларын үзләштерү өчен шулай ук халыкны уятырдай фәнни һәм әдәби әсәрләр тарату да зур әһәмияткә ия. Шуна күрә безгә яна әдәбият тудырырга, милләтебез тормышын яктырткан рисаләләр язарга, эшебез-гамәлебезгә файда китерердәй китаплар иҗат итәргә, ә укымышлыларыбызның авылларга китеп агарту эшләре җәелдерүе кирәк. Бу унайдан әдип «Тәрҗеман» газетасы алып барган эшне югары бәяләп үтә.

Торгынлыктан, инкыйразга тәгәрәүдән котылу өчен мөһим шартларның берсе — бердәм һәм актив эш-гамәл юлына басу. Әгәр милләтнең киләчәге имин булуын телибез икән, курчак уены белән мавыгуны туктатырга, бөтен көчне һәм сәләтне җәмгыять өчен файдалы шөгыльгә җигәргә, максатка яраклы эш алып барырга кирәк. И. Гаспралы эшчәнлеген милләт өчен, аның киләчәге өчен сарыф ителгән изге хезмәт дип бәяли әдип һәм аның үрнәгендә эш итәргә чакыра.

Иҗтимагый тормышның нигезе — кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең югары әхлак нормаларына нигезләнгән булуы. Әхлакый бозыклыклар таралу җәмгыятьне һәлакәткә илтә. Бу унайдан Г. Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз» да Казан халкы арасында күренә башлаган әхлакый бозыклыкларны тәнкыйть утына ала. «Аерым бәндәләр,— дип яза ул,— бөтенләй этлеккә салынган... Көндезләрен вак-төяк сату иткән булып маташалар да, кичләрен гостиницалар, пивной вә фәхеш урыннарында үткәрәләр...»

Иҗтимагый тормышны мондый әхлакый бозыклыклардан арындыру, әхлакый сафлык — җәмгыятьнең нормаль яшәешенең мөһим шарты, халкыбызны торгынлык баткаклыгыннан һәм инкыйраз куркынычыннан коткару юлында хәлиткеч чара. Шушы фәлсәфәгә бәйле рәвештә Г. Исхакый үз иҗатының беренче елларында язылган әсәрләрендә кешеләр арасындагы татулыкка, дуслыкка, ярдәмчелеккә дан җырлый, мәрхәмәтлек, шәфкатьлелек һәм фидакарьлек идеалларын күтәрә. Бу җәһәттән аның «Остазбикә» повесте бигрәк тә аерылып тора. Шул ук вакыт «Кияү» дигән повестында әдәп әхлакый сукырлыкны гаепләп чыга, шөһрәт артыннан куунын нинди түбәнлеккә китерүе мөмкинлеге турында кисәтә.

Мәгърифәтчеләргә хас рәвештә Г. Исхакый иҗатының бу чорында тәрбия мәсьәләсе мөһим урын алып тора. Кешенең әхлакый йөзе, аның фикеренчә, тәрбиядән бәйле. Бала күнеле — язылмаган такта. Бу тактага нәрсә язылу — анысы тирәлектән, бала кемнәр белән аралашып, кем тәрбиясендә үсүенә бәйле. Менә әдипнең «Бай улы» дигән әсәре. Бай кешеләрнең бердәнбер баласы Кәрим туган көненнән ук бозык атмосферага эләгә. Аның әнисе, баласы дигәндә, бер нинди әхлак нормалары белән дә исәпләшми. Кәримне тәрбияләргә дип әтисе әхлакый яктан бик түбән, диннең нәрсә икәнен дә белмәгән надан Фәхрине хезмәткә ала. Балага үрнәк булырлык зат түгел, киресенчә, ул аны акрынлап алдашырга, угрылыкка, тәмәке тартырга, эчәргә өйрәтә, мәйханәләргә, фәхешханәләргә тарта. Нәтиҗәдә, Кәрим бер эшкә яраксыз һәм бозык шәхес булып формалаша. Ахырда әтисен бөлгенлеккә китерә һәм үзе дә һәлак була.

Таза мохит белән бергә, тәрбиядә уку-укыту, гыйлем үзләштерү дә мөһим роль уйный. Кәрим болардан да мәхрүм булып үсә. Аның әтисе-әнисе иске фикерле кешеләр, алар баштанаяк кадими карашларга буйсынганнар һәм балаларын заманча итеп укытырга теләмиләр. Нәтиҗәдә, бала мәгърифәттән читтә кала бернинди белем алмый, китап белми. Бу да аны әхлакый баткаклык һәм бозыклык сазлыгына батыруда үз ролен уйный.

Үзенең әсәрләрендә Г. Исхакый хатын-кыз шәхесе, аның азатлыгы һәм тәрбиясе мәсьәләләренә бик зур урын бирә, моны милләт тәрәккыятенең мөһим шарты итеп карый. «Һәр милләтнең,— дип яза ул,— яртысы хатын-кызлар, һәр милләтнең рухын саклаучылар — хатыннар, һәр милләтнең теленең хосусый тәләффызларын, шивәсен саклаучылар хатыннар, киләчәктә ата булачак ирләрне, ана булачак кызларны тәрбия кылучылар — хатыннар идеке һәркемгә мәгълүм бер нәрсә». Бәс, шулай икән, ана тәрбияләү — әхлакый яктан саф, намуслы, укыган, дөньяны белә торган ана тәрбияләү җәмгыятьнең нормаль яшәеше өчен зарури шарт. Ана — баланың иң якын кешесе. Югары әхлаклы, киң күнелле, белемле ана янында бала да әхлак ягыннан саф булып тәрбияләнә. Ә бозык ана янында бала бозык булып үсә. Әгәр ана тәрбияле булса, ул баласын ашату-эчертү белән генә канәгатьләнеп калмас, аның холкы яхшы булуы, сәламәтлеге, мәгълүматының артуы, күзенең ачылуы турында да кайгыртыр. Мондый «аналар милләт вә дин ноктаи назарыннан һәм җәмгыяте бәшәрия ноктаи назарыннан бик мокаддәс затлар булачаклардыр».

«Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрендә Г. Исхакый татар тормышының ачы якларын ачып салды, аны артка этәрүче сәбәпләргә һәрьяклап анализ бирде. Шулай да әдип киләчәккә өмет белән карый: аның ул еллардагы әсәрләреннән омтимизм рухы балкып тора. Ул үз халкы торгынлыктан котылып, тәрәккыят юлына басар, дип ышана. Моның өчен халыкка үзенең ачы язмышын күреп, инкыйразга илтүче сәбәпләрне ачык күзаллап, киләчәккә өмет белән мәгърифәткә таянып, актив эшчәнлек юлына басарга кирәк. Шулай иткәндә киләчәгебез якты булыр. Шушы фәлсәфә аның бу чордагы иҗатының нигезен тәшкил итә.

1905—07 еллардагы революция Г. Исхакый иҗатына зур үзгәрешләр китерде. Революциянең беренче көннәреннән ук ул актив көрәш юлына баса. Ә монда аның элеккеге әзерлеге, татар укытучылар мәктәбендә укуы, революцион партияләрнең программалары белән танышу, революцион карашлы шәхесләр белән аралашу, хезмәт кешесенең аяныч хәленә ачык күз һәм аек акыл белән карый алуы үзенең ролен уйнады. Болар барысы да Г. Исхакыйның иҗатында үзенең чагылышын тапты. Аның революцион күтәрелеш башланганнан соң язган әсәрләрендә инде ачыктан-ачык революцион демократиягә хас идеяләр үзләрен сиздереп тора. 1906 елда Казанда Г. Исхакыйның идея җитәкчелегендә «Таң йолдызы» газетасы, ә инде ул ябылгач, «Таң мәҗмугасы» чыгарыла. Боларның һәр икесендә дә илдә бара торган вакыйгалар һәм алда торган бурычлар эсерлар позициясендә торып яктыртыла.

Г. Исхакыйның фикри үсешендәге бу икенче этапның кайбер үзенчәлекләренә күз салып үтик. Бу үзенчәлекләрнең иң мөһимнәреннән берсе — иҗтимагый тормыш күренешләрен, анда бара торган процессларны сыйнфый позициядән чыгып карау. «Җәмгыять,— дип хисаплый әдип,— ике капма-каршы сыйныфка бүленгән. Бер якта халыкның 96 процентын тәшкил итүче авыл хезмәтчәннәре белән 3 процентын тәшкил итүче эшчеләр һәм приказчиклар, ә икенче якта калган бер процентын тәшкил итүче зур корсаклы байлар һәм алпавытлар».

Бу сыйныфларның һәркайсының үзенә хас мәнфәгатьләре бар. Әйтик, байлар үзләренең хезмәтчеләренең озаграк та, күбрәк тә эшләүләрен, эш көненең озынрак, эш хакының исә кимерәк булуын телиләр. Ә эшче халык исә үз өстенә төшкән авырлыклардан котылырга, хезмәтен җиңеләйтергә, тормышын яхшыртырга, күбрәк эш хакы алырга тырыша. Шушы нигездә сыйныфлар арасында каршылыклар туа. Бу каршылыкларны тасвирлаганда һәм эшчеләр белән авыл халкының авыр тормышы турында сүз алып барганда, Г. Исхакый хезмәт кешесенең кайгысы ягыннан торып фикер йөртә.

Шушы сыйнфый позициядә торып, Г. Исхакый дәүләт органнарының, шул хисаптан дәүләт думасының эшчәнлеген һәм үзе бюрократия дип атаган катламны тәнкыйтьли, аларны байлар мәнфәгатен яклауда, халыкка карата башбаштаклыкта гаепли. «Боларның,— дип яза ул Чистай төрмәсендәге тәртипләр һәм андагы чиновникларның башбаштаклыклары турында сөйләгәндә,— кыланышлары, боларның йөрешләре миңа Испаниядәге инквизиция мәхкәмәләрен хәтеремә төшерде. Мондагы һәрнәрсәдән әллә нинди золым исе тоелган кебек, яшь тавышы ишетелгән кебек иде. Мондагы һәрнәрсә бюрократия золымының әллә ничә елгы шаһиты булганга, бюрократия золымының, вөҗдансызлыгының кораллары булганга, болар һәммәсе миңа җирәнгеч, сасы, кабәхәт күренәләр иде. Мондагы кешеләрдә хайвания хисеннән башка бер нәрсә булмаган кебек, мондагы әйберләрдә дә матурлык-фәлән кебек нәрсә юк иде» («Зиндан», Казан, 1991, 26 б.). һәм мондагы тәртипләр, мондагы тупаслык, мондагы җәберләүләр барысы да хезмәт кешесен буйсындырып тору максатында эшләнә.

Милли мөнәсәбәтләрне дә Г. Исхакый сыйнфый күзлектән чыгып бәяли. Менә «Таң йолдызы»ның 1906 ел, 29 май санында басылган «Безнең мәсләгебез һәм милләт» дигән мәкаләсе. «Без, татарлар,— дип яза ул анда,— бюрократия җәберләрен Россиянең башка халыклары кебек гражданское право ягыннан гына түгел, ә бәлки татар булганы өчен дә, мөселман булган өчен дә татыйбыз. Безнең телебез кысылган, динебез кысылган. Без социалистлар һәр шәхескә хөрлек теләгән кебек, милләтчеләргә дә хөрлек телибез. Шул ук вакыт без һичбер вакыт та милләт буявына буяп эшче һәм авыл халкын үзенең милләттәш байлары, алпавытлары файдасы өчен генә корбан булып, үзләренең икенче кавемнән булган сыйныфташлары белән дошманлыгына риза булмыйбыз. Шуның өчен милли автономия идеясе «эшче һәм авыл халкының күзен дин, милләт буявына буяп икенче милләтләрнең эшчеләре һәм авыл халкыннан... аерыр өчен генә булса, безгә, туксан тугыз проценты эшче һәм авыл халкы булган татарларга, андый автономия кирәкми». Күренүенчә, Г. Исхакый бу очракта милли мән-

фәгатьләрне сыйнфый мәнфәгатьләргә буйсындырып карый, сыйнфый мәнфәгатьләрнең өстенлеген алга сөрә.

Сыйнфый каршылыкларны ничек хәл итәргә, хезмәт халкын сыйнфый изүдән ничек коткарырга соң? Моның юлы бер генә — көрәш, эшчеләрнең, авыл халкының үз азатлыклары өчен тартыш юлына басуы, дип җавап бирә Г. Исхакый. «Тартышуда гына табарсыз сез үз хакыгызны»,— дип күрсәтелә «Таң йолдызы»ның 18 маенда басылган кереш мәкаләдә. Г. Исхакый әсәрләрендә сыйнфый көрәшнең, тартышуның максатлары ачык итеп күрсәтелә. Бу максатны характерлап «Таң йолдызы» 1906 елның 18 маенда басылган редакцион мәкаләдә «Таң»ның лозунгасы: авыл халкы өчен җир һәм ирек, эшчеләр өчен аларның хакын хаклый торган законнар, эш сәгатен 8 сәгатькә калдыру, эш бәһасен арттыру»,— дип язды. Г. Исхакыйның «Таң йолдызы»нда басылган башка мәкаләләрендә бу таләпләр тагы да киңәйтелә һәм үстерелә. Алар арасында, мәсәлән, завод-фабрикаларны эшчеләр кулына тапшыру, җирне алпавытлар кулыннан алып крестьяннарга бирү, забастовкалар ясарга һәм профессиональ берлекләргә оешу мөмкинлеге кебекләр дә бар. Максатның иң зурысы — хезмәт халкына ирек һәм социализм яулау.

Г. Исхакый үзенең әсәрләрендә байлар һәм бюрократия золымыннан котылу, ирекле тормыш яулау өчен көрәшнең юнәлешләрен дә билгели. Алар арасында беренче чиратта яңалык тарафдарлары булган яшьләрнең искелек ягында торган картларга каршы көрәше күзгә ташлана. Бу көрәш XX гасыр башында иҗат иткән күп кенә әдипләребезнең игътибары үзәгендә торды. Шул характердагы әсәрләр арасында безгә Ф. Әмирханның «Яшьләр»е яхшы билгеле. Бу проблема Г. Исхакыйны да читләтеп үтмәде. Без моны аның иҗатының башлангыч адымнарында ук күрәбез. Ә 1907 елда язылган «Алдым-бирдем» драмасы исә, гомумән, шушы проблеманы ачуга буйсындырылган. Дөрес, бу әсәрдә яңалык белән искелекнең көрәше әле яшьләрнең шәхси бәхетләре өчен көрәше рәвешендә генә гәүдәләндерелә, ул искелекнең гәүдәләнеше булган «аксак хатыннар» дөньясының җиңелүе һәм мәхәббәтнең тантанасы белән тәмамлана. Ә «Тартышу» дигән драма әсәрендә искелек белән яңалыкның көрәше киңрәк планда алына, татар тормышын һәрьяклап колачлый, халыкның ихтыярын басып торган караңгылык, тәгассыблык күренешләренә каршы юнәлдерелә.

«Тартышу» драмасында да, татар җәмгыятен тамырдан үзгәртеп кору бөтен Россия күләмендәге революция аша гына, илдә гадел, демократик тәртипләр урнаштыру нәтиҗәсендә генә мөмкин булыр, дигән фикер үткәрелә. «Вакыт, иптәшләр, вакыт,— ди әсәрнең герое Закир,— бу сасы куй маеннан аерылырга, күзебезне зуррак ачарга, киләчәкне ачыграк күрергә вакыт! Без моңарчы анда бер җәмгыяте хәйрия ачылуына, монда бер мәктәп салынуына әллә нинди бер зур эш дип карый идек. Ул хата. Нигез черек булганда ул мәктәптән генә, ул җәмгыяте хәйриядән генә бер ни чыкмый... Безгә нигезне тазартырга кирәк». «Таң йолдызы»ның 1906 ел, 31 август санында басылган «Мөселман иттифакы»на безнең карашыбыз» дигән мәкаләсендә Г. Исхакый җәмгыятьтә экономик интереслары капма-каршы булган сыйныфлар яшәгәндә революцион көрәшнең тукталмаячагын басым ясап күрсәтә.

Революцион көрәшнең өченче юнәлеше — массалар арасында революцион агарту эше алып бару, аларны тартышка әзерләү. «Таң йолдызы» газетасын Г. Исхакый шушы максатны үтәүдә мөһим чара итеп карый, аның битләрендә патша хөкүмәте үткәргән реформалар сәясәтенең ялган асылын ачып сала, дәүләт думасының халык мәнфәгатен яклап бер ни эшли алмаячагын күрсәтә, хакимият даирәләренең погромнар оештырып халык массаларының революцион энергиясен милләтара ызгышларга юнәлтергә тырышканлыгын фаш итә. Халык арасында, бигрәк авыл хезмәтчәннәре арасында революцион агитация алып баруда әдип турыдан-туры үзе дә катнаша.

1908 елда язылган «Тартышу» драмасының соңгы пәрдәсендә Г. Исхакый 1905—07 еллардагы революцион эшчәнлеккә йомгак ясый һәм революцион җиңелгән илдә урнашкан тәртипләргә, реакция золымына бәя бирә. «Һәммәсе бетте, һәммәсе,— ди әсәрнең геройларыннан берсе ачынып.— Бер ел эчендә никадәр үзгәрү, бер ел эчендә никадәр артка китү! Кайда карама анда катылык. Газеталар тагы баллар хакында, генералларның чин алулары хакында яза башлады... Әдәбият тагы кысылды, тагы изелде... Җәмгыятьләр тагын юк хөкеменә китерелде. Кайда карама — анда тентү, кайда карама — анда арестлар, кайда карама — анда суд, төрмә, ссылка, каторга, үлем!.. Бөтен Русия әсәнҗәгә кысылды!» Ләкин, революция җиңелсә дә, нәтиҗәсез булмады. Ул татар халкының уянуында үзенең ролен уйнады, хәр, якты дөньяга юл күрсәтте. Революция яңадан күтәре-

лер, чәчкән орлык чыкмый калмас, тагы җылы көннәр килер, тагы яңгыр явар, революция чәчкән орлыклардан чыккан үсентеләр ямь-яшел булып җирне каплар. Алда яңа көрәш, яңа тартышлар тора. Шулай итеп, автор Россиядә урнашкан реакциягә үзенең бәһасен бирә, ул китергән авырлыкларны ачып сала. Һәм, шул ук вакыт, киләчәккә өмет белән карый, яңа революцион көрәшкә өнди.

1905—07 еллардагы революция җиңелгәннән соң Г. Исхакый иҗатының яңа этабы — милли позициягә күчү чоры башлана. Дөрес, бу күчеш кинәт кенә булмый. Әдипнең 1908—11 елларда иҗат ителгән «Мулла бабай» романында, «Тормышмы бу?» дигән әсәрдә, «Сөннәтче бабай» һәм «Кияү» повестьларында, «Шәкерт абый» дигән хикәядә, «Җәмгыять» һәм «Кыямәт» дигән комедияләрдә социал-политик мотивлар инде артык күзгә ташланмыйлар. Аларда, И. Нуруллин әйтеп үткәнчә, гадәти татар тормышы, төрле катлау кешеләренең хәләхвәлләре, теләк-омтылышлары, шатлык-куанычлары, кайгы-хәсрәтләре, татарларга хас гореф-гадәтләр тасвирлана.

1911 елда тәмамланган «Зөләйха» драмасында исә әдипнең милли идеягә йөз белән борылып иҗат иткәнлеге инде ачыктан-ачык күренеп тора. Л. Гайнанова һәм Һ. Мәхмүтов әйтеп киткәнчә, Г. Исхакый бу әсәрендә «Ничә йөз еллар изелеп яшәп тә, телен, динен, гореф-гадәтләрен, милли йөзен саклап кала алган татар халкының аяныч хәлен һәм бер үк вакытта рухи батырлыгын күз алдына китереп бастыра». Шушы миллилек позициясенә басуы Г. Исхакыйның 1912 елның 13 июнендә Ф. Әмирханга язган хатында да ачык күренә. Бу хатта сүз татар шагыйрьләренең мәҗмугасын әзерләү һәм аңа Тукай шигырьләрен дә кертү турында бара. Г. Исхакый фикеренчә, бу шигырьләрдә «татар тормышы аңкып торырга тиеш». («Казан утлары», 1991, № 2, 183—184 б. б.)

Г. Исхакыйның иҗади кыйбласының болай үзгәрүен ни белән аңлатырга соң? Монда, мөгаен, 1905—07 еллардагы революция җиңелгәннән соң илдә тантана иткән реакция, патша хөкүмәтенең рус булмаган милләтләргә карата үткәргән ачыктан-ачык шовинистик сәясәте, аларның теленә, диненә, мәдәниятенә каршы һөҗүмнәр үзенең ролен уйнаган булыр. Патша хөкүмәтенең Балкан сугышы вакытында үткәргән сәясәте дә бу җәһәттән эзсез калмады. Хөкүмәт тарафыннан татар мәктәпләренә карата алып барылган сәясәт, Буби мәдрәсәсенең таркатылуы да татар зыялыларының игътибарын социал-политик мәсьәләләрдән милли мәсьәләләргә этәрде. Сөргендә вакытта милли-азатлык хәрәкәтендә актив эш алып барган затлар белән аралашу да Г. Исхакыйның милли проблемаларга йөзе белән борылуында үзенең ролен уйнагандыр.

Милли позициягә күчү өчен Г. Исхакый иҗатының элгәреге этапларында да билгеле бер җирлек әзерләнгән иде. Менә аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» дигән әсәре. Бу әсәр, инде әйтелгәнчә, 1902—1903 елларда мәгърифәтчелек позициясендә торып иҗат ителгән. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр авторның милләт кайгысын кайгыртып фикер йөрткәнлеге күзгә бәрелеп тора. Әдип үзенең сыйнфыйлык рухы белән сугарылган «Безнең мәсләгебез һәм милләт» исемле мәкаләсендә милли таләпләрнең эчтәлеген ачып: «Безнең татарлар үзләренең телләрен рус теле белән бер дәрәҗәгә килүен, безнең дә үзебез кирәкле нәрсәләргә правобыз булуын, мәктәпләрдә үзебезнең телдә укытуны, кирәкле законнарның татарга татарча язылуын телибез»,— дип яза. Ә «Таң йолдызы» үзенең беренче санында (1906, 18 май) басылган баш мәкаләдә газета: «Татарларның милли вә дини эшләренең тәмам үз кулларына керүенә тырышачак, шуларны мәйданга чыгару өчен тартышачак»,— дип белдерә. Кабатлап әйтәм, «Таң йолдызы»н да бу таләпләр әле сыйныфлар күзлегеннән чыгып яктыртыла. Революцион демократик позициядә торып язылган «Тартышу» драмасында да (1908 ел) шулай ук милләт идеясе, аның уянуы өчен көрәш идеясе күтәрелә. 1911 елдан соң иҗат иткән әсәрләрендә инде бу идея әдипнең иҗади кыйбласына әйләнә.

1913 елда Петербургта Г. Исхакый нәшерлегендә һәм мөхәррирлегендә «Ил» исемендә татарча иҗтимагый-сәяси газета чыга башлый. Газетаның идея юнәлеше һәм эчтәлеге Г. Исхакый тарафыннан билгеләнә һәм миллилек рухы белән аерылып тора. «Милли тойгы мәсъулиятен хис итү,— дип күрсәтелә «Ил»нең 1913 ел, 28 ноябрь санында,— безгә эшләргә, хәл итәргә куша, көчләп-көчләп куша, безне генә түгел, бөтен зыялыларыбызны куша». Газета битләрендә татар тормышының төрле яклары киң яктыртыла.

«Таң йолдызы» битләрендә Г. Исхакый милли идеал мәсьәләсен дә күтәрә. Бу турыда сүз йөртеп ул, мәсәлән, «Әдәбиятыбыз мәйданга чыгар-чыкмас аның беренче эше һәм дә уйлап, план белән түгел, үзеннән-үзе килеп чыгып эшләнгән эше, табигый бер хәрәкәтне әдәбиятыбызга максатка әйдәүче идеал тәгаен итү булды. Ул аны газеталар, журналларда үзен мөзәкарә, мөнәзарәләр соңында

гакыл белән уйланып, мантыйкъ белән үлчәп бу кирәк, бу кирәкми юллары белән түгел, тагы ук табигый юл белән, иң дөресе милли йөрәк белән генә хәл итте дә куйды. Ул идеальда без бер халык, бер милләт» («Ил», 1913, 14 ноябрь).

Бу миллилек позициясе, уй фикерләрне милли идеалдан чыгып йөртү Г. Исхакыйның «Ил»дә басылган башка мәкаләләрендә, ул ябылгач «Сүз» газетасында дөнья күргән язмаларында, әдәби һәм публицистик әсәрләрендә тагы да үстерелә һәм нигезләнә. Аның 1917 елда Ф. Әмирхан рәислегендә үткәрелгән банкетта ясаган чыгышы бу үсешне йомгаклау рәвешендә әйтелгән сүзләр булып яңгырый. 1905 елгы революциядә, дип белдерә Г. Исхакый бу чыгышында, без сыйнфыйлык байрагы астында бардык, хәзер исә милли байрак астына басарга тиешбез. Ләкин бу — безнең демократиягә хыянәт итеп, буржуазиягә сатылуыбыз, дип каралырга тиеш түгел. Чөнки хәл үзгәрде. Безне буып торган самодержавие җимерелде һәм безнең бурыч хәзер «шул хәрабәнең урынын чүпләрдән арчып, аның урнына милли мәдәният иҗат итү, милли рәфаһидәт (ирек) торгызудыр».

1905—07 елгы революция җиңелгәннән соң акрынлап сыйнфый позициядән милли позициягә күчү, әйтергә кирәк, бер Г. Исхакыйга гына хас нәрсә булмады. Бу татар демократик интеллигенциясе вәкилләренә хас гомуми күренеш иде. Бер генә мисал. 1914 елда «Аң» журналында Ф. Әмирхан «Олуг милләтче тугрысында кечкенә бер хатирә» дигән мәкалә бастырды. Анда сүз күренекле җәмәгать эшлеклесе И. Гаспралының 1906 елда Петербургта мөселман съездында ясаган бер чыгышы турында сүз бара. Безнең арадан бер иптәшебез (сүз сыйнфый позициядән торган революцион рухлы татар яшьләре турында бара), дип яза Ф. Әмирхан үзенең мәкаләсендә, съездны әйдәп баручы милләт эшлеклеләрен гаепләп бик ачы сүзләр әйтте. Моңа каршы И. Гаспралы: «Углым,— дип белдерде,— сез яшьсез, тәҗрибәсез сез. Шунлыктан кирәгеннән артык каты гыйбарәләр истигъмал итәсез... Сезнең кеби кызу рухлы яшьләребез милләткә хезмәт итеп, аның мәдәни дәрәҗәсен үстерсәләр, ул вакытта без сыйнфый ихтиляфлар (каршылыклар) тугрысында сөйләшербез, фикер йөртешербез. Мәдәнияте юк бер милләтнең промышленносте була алмый, шулай булгач әле сыйнфый низагларга да иртә. Безнең бу көнге вазыйфабыз әле мәдәни үсүдән вә шуңар юллар әзерләүдән гыйбарәт... Аннан соңгысы бездән соңгылар карарлар» (Әдәби мирас, 1 китап. Казан, 1991, 23 б). Бу — карт татар милләтчесенең позициясе. Ф. Әмирхан исә ул вакытта әле сыйнфыйлык һәм революцион көрәш позициясендә тора. Ә 1914 елда, бу мәкаләсен язганда, ул инде И. Гаспралының үзенә дә, аның бу карашларына да ихтирамын, аңа теләктәшлеген белдерә һәм үзенең дә шушы позициягә күчеп фикер йөртә башлавын күрсәтә.

Инде күргәнебезчә, Г. Исхакый да бу елларда шушындый ук фикри эволюция кичерә һәм милләт кайгысын кайгыртып яза башлый, милләтне, аның телен, мәдәниятен саклау идеясен күтәрә. Ул милли һәм дини изүне гаепләп чыга, патша чиновникларының, миссионерларның татар халкына карата үткәрелгән ерткычлыкларын фаш итә, милли-колониаль изүнең, шуның бер күренеш булган көчләп чукындыруның фаҗигале нәтиҗәләрен ачып сала. Бу яктан аның «Зөләйха» исемле драмасы аерым урын алып тора. Төрле кыерсытуларның, иң авыры — физик җәбер түгел, ә рухи җәбер, рухи богаулар. Зөләйха 25 ел төрмәләрдә утыра, каторгада була, Себерен дә күрә, андагы җәбер-золым турында ачынып сөйли. «Бик күп нәрсә күрдем,— ди ул.— Ләкин иректә күргән начарлыкны төрмәдә күрмәдем. Ниләр булмады, ниләр баштан кичмәде. Кыйналдым, мыскыл ителдем, суктырылдым. Бөтен тән җәзаларын күрдем. Ләкин мондагы кебек, иректәге кебек, күңелемә каравыл куймадылар. Теләгәнчә намазны укыдым. Теләгәнчә рузамны тоттым».

Г. Исхакыйның «Зөләйха» дан соң иҗат ителгән әсәрләрендә һәм публицистик язмаларында инде беренче планга турыдан-туры милләт язмышы, аның бүгенге хәле һәм киләчәге калкып чыга. «Халкыбызның өсте-башы бөтен, ашысуы иркен, йөзе-күзе күркәм, көс-җыры көчле, йөреше-барышы тугры иттереп күрәсебез килү,— дип белдерелә «Ил»нең беренче санында,— безне зур мәсьулиятле «Ил» эшенә җилкәбезгә алырга мәҗбүр итте... Милли тойгыбыз шул хәрәкәттә бергә булырга, тарих көпчәге әйләнгәндә аның (милләтнең — Я. А.) алга таба атлавы өчен тырышырга, үтешергә, тартышырга безне дә кушты». («Ил», 1913, 22 октябрь). Газетаның шушы ук санында басылган «Матбугат» исемле мәкаләдә Г. Исхакый татар матбугаты алдында торган бурычлар турында сүз алып бара. «Матбугат вазыйфасының иң авыры, иң изгесе,— дип яза ул анда,— милләт эшләре». Милләткә хезмәт итү аның фикеренчә, матбугат эшчәнлеген бәяләүдә иң төп үлчәм булып тора.

Милләтне саклауның мөһим шарты, Г. Исхакый фикеренчә, милли үзенчәлекләрне, милли мәдәниятебезне саклау. «Безнең халкыбыз, мәдәниятебез,— дип яза ул «Ил» дә урнаштырылган «Элек һәм хәзер» дигән мәкаләсендә (1913 ел, 14 ноябрь),— элек-электән фарсылык һәм гарәбилек басымын тоеп яшәде. Ул йөрәге белән черегән фарсы, мөнкарыйз булган гарәп белән таза төрек, нык татар арасында уйда, фикердә, планда һичнинди бертөрлелек булмавын аңлап, үз юлына, үз төркилеге юлына басты һәм милләт буларак үзен саклап кала алды. Милли үзенчәлекләрне саклауда аңа милли тойгылар, милләт идеалы таяныч булды.

Хәзер безнең милли бөтенлегебезгә, милләтебезнең асылына Аурупадан килә торган яңа куркыныч яный. Бу Ауропаның әдәбияты, театры, фәлсәфәсе, музыйкасы, фәне, сәнәигъ нәфисәсенә, техникасына, экономиясенә ияреп килә торган агу — фәхешлек, рухи пычраклык, әхлаксызлык һәм һәрнәрсәне, шул хисаптан кеше намусын да, сату-алу объектына әйләндерү. Болар безнең борынгыдан килә торган әхлакый ныклыгыбызны кырыеннан кимерәләр. Без моңа юл куймаска, әхлакый сафлыгыбызны, рухи бердәмлегебезне җимерергә ирек бирмәскә, милли үзенчәлекләребезне саклап калырга тиешбез». Әдип фикеренчә, татар халкы мондый көчкә ия һәм ул үзенең мәкаләсен: «Идел буенда гарбтән алып килә торган икенче туфанда батмаслык көч бар»,— дип тәмамлый.

Милләтнең бөтенлеге, башка милләтләр арасында хөрмәткә лаеклы булып яшәве мәсьәләсенә Г. Исхакый үзенең публицистикасында кат-кат әйләнеп кайта. «Без,— дип яза ул «Ил»нең 1914 ел, 5 февраль санында,— хәзер үзебезнең киләчәк өчен тырышырга, пакь мәдәни бер милләт булып яшәргә хакыбыз бармыюкмылыгын тикшерә торган бер имтихан алдында торабыз. Без үзебезнең татар дөньясы алдында гына, мөселман голәмасының матбугаты алдында гына түгел, Россиянең эфкяр гомумиясе, Россиянең матур пакь интеллигенциясе алдында имтихан тотабыз». Әдип татар халкының бу имтиханны тота алуына, пакьны пычрактан аера алуына, сәяси тәрбиясенең югарылыгына, милли рухны саклый алуына ышанып фикер йөртә.

Шул ук вакыт ул халкыбыз арасында милли горурлык тәрбияләүнең мөһим икәненә дә басым ясап үтә һәм милли талымсызлыкны гаепләп чыга.

Күргәнебезчә, Г. Исхакый милләт кайгысын кайгыртып, аның башка халыклар арасында дәрәҗәсе турында кайгыртып, татар халкының киләчәктә дә милләт буларак яши алуы, аның мәдәнияты үсеше турында кайгыртып фикер йөртә. Революцион 1917 елга ул шушы позициядә торып аяк басты һәм татар халкының милли-азатлыгы өчен көрәшүчеләрнең алгы сафында торып эш итте. Ул мөселман корылтайларының эшендә актив катнашты һәм аларның эшчәнлегенә идея юнәлеше бирүчеләрдән булды. Бу корылтайларда кабул ителгән карарларның күбесе аның кулы белән языла. Милли азатлык өчен көрәшкә басарга чакырып Г. Исхакый ялкынлы чыгышлар ясый, вакытлы матбугатта мәкаләләр бастыра. Ул башта татарлар арасында зур яңгыраш тапкан, «милли-мәдәни автономия» идеясенең тарафдары була һәм аның концепциясен әзерләүдә актив катнаша. 1917 елның азагында «Милли мәҗлес» оеша. Г. Исхакый аның эшендә шулай ук актив катнаша. «Милли мәҗлес» рамкаларында милли-территориаль автономия һәм «Идел-Урал штаты» идеясе калкып чыга. Г. Исхакый бераз икеләнүләрдән соң бу идеяне дә кабул итә һәм «Идел-Урал штаты» лозунгысы астында татар халкының милли үзбилгеләнүе өчен җәелдерелгән көрәшендә актив роль уйный.

Г. Исхакыйның бу эшчәнлеге милләтчелек дип бәяләнде һәм бу бәяләмә бер өрәк рәвешендә аның иҗатын һәм эшчәнлеген каһәрләү максатында кулланылды. Дөресен әйтергә кирәк, бу эшчәнлек, бу иҗат, чыннан да, милләтчелек рухында иде. Ләкин аны каһәрләргә урын юк. Милләтчелек — ул үз милләтенең, аның киләчәге, теле һәм мәдәнияты турында кайгыртып эш итү. Бу Г. Исхакый эшчәнлегенә дә хас нәрсә булды. Бездә милләтчелекне еш кына шовинизм белән тәңгәлләштерәләр. Әмма милләтчелек ул шовинизм түгел. Анда башка милләтләргә карата өстен карауның, башка милләтләр өстеннән хакимлек итәргә тырышуның мыскалы да юк. Г. Исхакый иҗатында да шовинизмга хас мондый сыйфатларның эзе дә күренми. Бөек әдипнең әсәрләрендә һичнинди милли чикләнгәнлек юк. Ул рус халкына да, аның мәдәниятына да ихтирам белән карый, руслар белән татарлар арасында мөнәсәбәтләрнең нормаль булуын канәгатьләнү хисе белән күрсәтеп үтә.

Г. Исхакыйны милләтләр арасына чөй кагуда, татар халкына башка милләтләр арасында өстенлек даулауда гаепләү — бары уйдырма гына. Гали Акыш үзенең истәлекләрендә күрсәткәнчә, ул коммунизмны җимерүне дә максат итеп

куймады. Анын төп максаты «Идел-Урал халыкларынын һәм, гомумән, рус булмаган халыкларнын үзбилгеләнү хокукын яулап алудан гыйбарәт иде» (Нуруллин И. Әдипнең соңгы көннәре. «Шәһри Казан», 1992, 12 февраль).

Г. Исхакый милләтчелегенең асылында татар халкының милләт буларак яшәеше мәсьәләсе ятты. Ул үз халкының бөтенлеге, иминлеге, тормышын үзе теләгәнчә кору мөмкинлеге турында уйлап иҗат итте, шуның өчен көрәште. Ул милли телнең, милли мәдәниятнең яшәеше турында кайгыртты, моның юлларын эзләде. «Мин,— дип язды ул соңыннан,— бөтен гомерем буена төрек-татар халкының бәхете, иркенлеге өчен көрәштем... Тәңре сезләргә ватаныбыз Идел-Урал азатлыгын күрергә насыйп итсен». («Казан утлары», 1991, №5, 161 б). Ул бу көннең килүенә ышанып яшәде.

Үз халкының бу азат киләчәгенә ышанычын Г. Исхакый 1933 елда эмиграциядә язылган «Идел-Урал» дигән хезмәтендә кабатлый. «Русские,— дип яза ул анда,— привыкшие в течение столетий властвовать над всем и национальностями бывшей России, до сих пор еще, несмотря на тяжелые уроки истории, не могут отказаться от мысли быть господином над «инородцем». Но они жестоко ошибаются. Российская революция еще не закончена. Большевики в этой революции являются только одним из переходных этапов ее. Эта революция, имеющая в настоящее время своим основным содержанием именно национальный вопрос, может быть закончено только радикальным разрешением национального вопроса в бывшей России и окончательным освобождением народов, борящихся за свою независимость. Если великая французская революция принесла национальное освобождение народам запада Европы, то российская революция принесет освобождение народам востока Европы» (Исхаки А. «Идель-Урал. Париж, 1933, с. 62).

Әдип бик ерактан күрә белгән. Рус империясенең совет чорындагы гәүдәләнеше булган СССР инде таркалды һәм күп кенә халыклар үзләренең милли бәйсезлегенә ирештеләр. Әмма көрәш дәвам итә. Россия федерациясенең идарәче даирәләре кысылганрак рамкада булса да империяне саклап калырга тырышалар. Әмма көрәш, Г. Исхакый билгеләп үткәнчә, Европаның көнчыгышындагы барлык халыкларның милли бәйсезлеге яулап алынганчы дәвам итәчәк!

# ФАТИХ КӘРИМИ ТУРЫНДА

«ВАКЫТ» ГАЗЕТАСЫ БИТЛӘРЕННӘН

Татар матбугаты тарихы әлегә тулысынча ачыкланып бетмәгән, кайбер басмаларны санамаганда, революциягә кадәр чыккан газета һәм журналларга тәфсилле тикшерү уздырылмаган. Ә бу тема гаять мөһим. Ул беренче чиратта, Россиядә яшәүче халыкларның иҗтимагый фикер үсешенә, алдынгы карашларның формалашуын күзаллауга, халыкларның тарихын торгызу максатларына хезмәт итәргә тиеш.

«Фикер», «Әлгасрелҗәдид», «Урал»ның барлык саннарының, алар тарафыннан чыгарылган махсус әдәби җыентыкларның, ул редакцияләр архивларының әлегә кадәр табылганы юк. Революциягә кадәр чыгып килгән газета һәм журналлар нәшриятләренең һәм мөхәррирләренең исемнәрен ачыклар вакыт та җитте. Бүген исә «Вакыт» газетасына гына тукталыйк һәм аның редакторын искә алып китик.

Фатих Кәрими җитәкләгән «Вакыт» редакциясе дөнья күләм проблемаларга да кагылып, бөтен Рәсәй тормышын яктыртып, киң колач белән эш йөрткән. Газетага Вамбери, Бартольд кебек күренекле галимнәрне тарту, чит илләр белән даими элемтәләр урнаштыру редакция коллективының мәсләгенә җавап биргән һәм бу матбаганың дәрәҗәсен күтәргән. Монда фикер төрлелегеннән курыкмаганнар, вак-төяк сәяси ыгы-зыгылар белән маташмаганнар.

Газетада М. Ломоносовның тәрҗемәи хәлен һәм М. Лермонтовның шигъри дөньясын, Мирза Фатали Ахундов эшчәнлегенең әһәмиятен ачып бирүче мәкаләләр дөнья күрә. Һәр укучы күңеленә барып җитәрлек итеп Л. Толстой иҗаты хакында язалар.

«Вакыт»та Иран социал-демократлары һәм Кавказ фидаиларының аларга ярдәме, гомумән, Россия мөселманнары турында шактый төпле мәгълүматлар бастырыла. Кытайдагы хәлләрдән хәбәрдар булалар. Сун Ятсенның шәхесенә бәя бирәләр.

Либераль-прогрессив милли газета, табигый ки, милли мәсьәләгә, дөресрәге урыс булмаган халыкларның — казакъ, башкорт, яһүд һәм башкаларның хәленә киң урын бирә. Башка милләтләргә хөрмәт белән карау татар матбугатына гомумән, хас нәрсә, бу җәһәттән «Вакыт» алар арасында аерылып тора.

Редакцияне башкортларның тормышы, киләчәге дә дулкынландырган. Бу хакта газета берничә тапкыр чаң сугып чыгыш ясый һәм аларга ярдәм күрсәтергә чакыра. Шундый бер язмада «Вакыт», башкортларның яртысыннан артыгы ачлыктан интегә, дип белдерә. Шуның белән бергә, ул аларда милли үзаңның уянуын да күрсәтеп үтә. 1911 елның 30 ноябрендә Куһайский (Килдебәкев) дигән журналистның язмасында Уфада узган әдәби кичә тасвирланган. Анда татар, башкорт, казакъ җырлары башкарылуы, милли шагыйрьләрнең әсәрләре укылуы, рояльдә С. Габәшинең үзенчәлекле көйләре уйналуы бәян ителә.

Казакълар татар газетасы битләренә үз җирләренең патша колонизаторлары тарафыннан талануын туктатуны сораган таләпләре, җир мәсьәләсен гадел хәл итү турында урыс халкына мөрәҗәгатьләре белән килеп керәләр. Язмаларда туып килә торган зыялыларның иҗади эшчәнлеген күрсәтүгә омтылыш зур. 1907 елның 10 февралендә Оренбурда И. Ашказарский тарафыннан Гогольнең «Өйләнү»е куелганнан соң, кичәдә шигырьләр укыла. М. Сәетгалин казакъча җырлый, аны бик җылы каршылыйлар һәм сәхнәгә кабат-кабат чакыралар. Скрипка һәм пианинода татар көйләре башкарыла, биюләр була. Концерт хәтта урыс тамашачысына да ошый. «Вакыт» редакторы бөлгән татар бае ролен «Ай дөнья» көенә башкара һәм актер сыйфатында халыкны көлдерә.

Газетада Р. Илкебаев кебек күп кенә казакъ авторларының язмалары да очрый. Тургай өлкәсеннән Хаҗи Дусмаил Качкынбаев шагыйрь Акмулла хакында мәгълүматлар һәм аның шигырьләрен сорап укучыларга мөрәҗәгать итә. Казакъ студентлары, «Айкап» журналы һәм «Казагыстан» газетасы турында да язалар.

Газетада яһүдләрне эзәрлекләүләргә, карагруһчыларның погромнарына, антисемитизмга кискен каршы чыга. Шул ук вакытта редакциядә сионизмның нәрсә икәнен бик яхшы белүчеләр дә була. Ул елларда бу темага ачыктан-ачык язылган мәкаләләр гаять сирәк очрый. «Америка хөкүмәте һәм татарлар» дигән язмада

билгесез автор. АКШ хөкүмәте фәкать яһүдләрне генә кайгыртып, Россиядә яһүдләрнең хокуклары хакында лаф орып, татарларны кешегә дә санамый, ди. Һәм әле бүгенгә кадәр матбугат яһүдләрнең каһәрле язмышын кайгырта, аларны югары уку йортларына кабул иткәндә 5 процентлы чик яшәвенә хәсрәтләнә. Ә менә бу чикнең татарлар өчен фәкать 3 процентны гына тәшкил итүе хакында ләм-мим сүз юк.

Татар милләтенең идеологлары бәлки күпмедер күләмдә мәсьәләне берьяклы гына аңлаганнардыр. Ләкин алар Себердә яһүд сәүдәгәрләренең мөселман коммерсантларын кысуларын бик яхшы күреп торганнар.

Бу темага «Йолдыз» дигән икенче татар газетасы да яза. «Яһүдләрне кысу» рубрикасы астында чыккан язмада урыс матбугатыннан алынган өземтәләр урнаштырылган. Анда моңа бәйле рәвештә татарның һәм хәтта гади гавәм кешесенең сүзләре генә түгел, ә Россия премьер-министры П. А. Столыпинның фикере китерелә: «Илдә икмәк сәүдәсе яһүдләр кулына эләкте. Алар Иделдән Себергә кадәр зур төбәкне контрольдә тоталар, күпләп икмәк сатып алалар һәм биржада бәяләрнең котырынып үсүенә китерәләр, ә банклар исә яһүдләргә акчаны кызганмый»,— диелгән. Газета, министрлар кабинеты утырышында Столыпин яһүд маклерларының гамәлләрен кысачагы хакында белдерде, ләкин аны министрларның барысы да якламады, хөкүмәтнең банклар эшенә тыкшынырга хакы юк, дип яза.

Тиздән шул ук «Йолдыз» Столыпинны үтерүче Мотель Багровның яһүд булырга тиешлеге хакында фараз итә. Соңгысы, кулга алынгач, яһүд погромнарыннан курыкмаса, тагын да югарырак дәрәҗәдәге әфәнделәргә дә аткан булыр идем, дип белдергән. Соңрак газета эсерлар партиясе кушуы буенча премьер-министрны үтергән яһүд Д. Багровның үзен яһүд түгел дип әйтүе хакында яза. Татар матбугатында күренеп киткән бу тыелган тема күп нәрсәләр турында сөйли.

«Вакыт»та чит илләрдәге татарлар турында хәбәрләр дә еш күренә. Илдә яхшы мәгълүм мәдрәсә тоткан Габдулла Буби «Мәдинәдә Казанлы мәдрәсәсе» дигән язма бастырган. «Будапешттан Вамбериның хаты дөнья күргән. Эшләре гөрләп барган Казан сәүдәгәре Г. Казаковның Берлиндә конторасы, Лейпцигтәге Семипалат бае Ф. Мусин турында хәбәрләр бар. Парижда, Токиода уңышка ирешүчеләрнең (И. Аптюшев) исемнәре санала, Америкада эшмәкәрлек белән шөгыльләнгән Урал сәүдәгәрләре С. Гобәйдуллин һәм Латыйповлар атала. Татар шәкертләре хакында да (алар ике дистә кеше, араларында хатын-кызлар да бар) мәгълүмат бар. Әле 1911 елда ук, «Мөселманнар дөньясында» газетасына таянып, «Йолдыз» кемнеңдер (исеме аталмаган) Нью-Йоркта мәчет салдыру өчен 600 мең акча бирүен хәбәр итә. Татарларның дөньяга танылуы кайберәүләрне сөендергән, күрәсең.

Цензура һәм Ф. Кәрими артыннан күзәтеп торучы агентлар газета редакциясенә бөтен куәтенә җәелергә мөмкинлек бирмиләр, талантлы авторларга сәләтләрен ачарга комачаулыйлар. Газета битләре татар журналистлары һәм публицистлары уйлаганнарның барысын да чагылдырып бетерә алмый, әлбәттә.

Оренбур жандарм идарәсе башлыгы 1911 елның 21 сентябрендә «Вакыт» газетасы турында Казан губернасының жандарм идарәсенә түбәндәгеләрне хәбәр итә: «...халыкның түбән катламнары өчен аңлашылмый торган төрки-татар телендә нәшер ителә, тиражы — 5 мең, ләкин чынлыкта 10 меңнән артык данә таратыла. Узган ел газетада панисламизм рухында язылган мәкаләләр күренгәләде, ләкин анда ачыктан-ачык хөкүмәткә каршы язмалар басылды дип әйтмәс идем. Чөнки губернатор тарафыннан газетаны күзәтүе өчен цензура билгеләнде, ә агымдагы елның башыннан аны жандарм идарәсе дә күзәтеп бара. Аны штрафлар белән тинтерәтәләр»,— дип тәмамлый Оренбур жандармы.

Кайбер темалар бөтенләй тыелган. Ә шулай да газета, читләтеп кенә булса да, аларны да бирергә тырыша.

Архангельск суыгына сөрелгән, ачлыкка дучар ителгән Г. Исхакый «Вакыт», «Йолдыз», «Ялт-Йолт» битләрендә күренеп китә. Артистлар аның пьесаларын сәхнәгә куялар. Мәсәлән, «Вакыт»та 1913 елның 3 апрелендә Җәләйнең «Гаяз әфәнде» дигән мәкаләсе басыла. Шакир Мөхәммәдьяров теманы 2 майда дәвам итә. Ул Исхакыйның сөргендәге хәле, аның «Мөгаллим», «Солдат», «Мулла бабай», «Теләнче кызы» дигән әсәрләре турында яза. Язучы яшьләр тормышыннан алынган «Тартышу» китабы өстендә эшли. Әсәрендә ул аларның ничек итеп революциягә килүләрен сурәтли. Гаяз Исхакый монда «Кыямәт» һәм «Җәмгыять» комедияләрен дә иҗат итә. 1910 елда Финляндиядә аны бик яхшы каршы алалар. Хәбәрче «Сөннәтче бабай»ны, «Кияү»не, «Шәкерт абый»ны, «Зөләйха»

фажигасен Г. Исхакый Истанбулда язган дип раслый. Ул Г. Исхакый сөргендә михнәт чигеп яши, аңа көнгә 10 тиен генә бирәләр, ярымлангач, дип яза һәм аны 1913 елның 4 апрелендә азат итүләрен әйтә.

Г. Ибраһимов, милли әдәбият буенча Тукай эшләгән дәреслеккә бәя биреп, шагыйрьнең Г. Исхакый әсәреннән өзек урнаштыруын хуплый һәм шул ук вакытта бу авторның «Бай» дигән әсәрен кертү яхшырак булыр иде, дип искәртә.

Г. Исхакыйның Архангельскидан җибәргән мәкаләсе дә дөнья күргән булырга тиеш. Ул Г. М. Калмык кушаматы белән чыга. Ниндидер Габди (бу Г. Ибраһимов түгел) татар буржуаларын Г. Исхакыйның «Тормышмы бу?», «Җәмгыять» әсәрләрен басмауда гаепли. Г. Тукайның вафаты уңае белән Г. Исхакый Череповецтан редакциягә телеграмма җибәрә: «Үземнең күпне күргән халкым белән кайгырам. Гаяз». Шул ук көнне, 1913 елның 9 апрелендә, «Вакыт»та Г. Исхакыйның сурәте бирелә. Исхакый һәм аның төрек журналында чыккан мәкаләсе турында С. Рахманкулов уңай яктан яза. Ул анда авторның төрек әдәбиятының киләчәгенә ышанмыйча каравын билгеләп үтә. Тукайның дусты, киләчәкне һәм төрекләрне революцион яңарыш белән бәйләп, үзен оптимист буларак таныта.

Милләт Тукай, Әмирхан, Г. Камал, Г. Исхакый, Р. Фәхретдинев, Ф. Кәрими кебек шәхесләрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә йокысыннан уяна. Моңа социал-демократлар да үз өлешләрен керттеләр.

1907 елның 9 октябрендә Петербургта башкалада укучы мөселман кызларының җыелышы була. Алар, озак еллар әдәби эшчәнлек белән шөгыльләнгән, хатын-кызларның тәрәккыять хакында кайгырткан өчен рәхмәт әйтеп, Р. Фәхретдиневкә хат җибәрәләр һәм анда үзләрен дә прогресс өчен көрәшүчеләр дип белдерәләр. Кайбер төбәкләрдә кызлар өчен мәктәпләр ачыла башлый. Минзәлә өязенең Сарман авылында М. Әхмәдиев мәктәп ача һәм анда 65 кыз укый башлый. 1909 елдан башлап Алма-Атада кызларны мөгаллимә Гарифә ханым җитәкчелегендә укытканнар. 1911 елда монда күренекле шәхес Фәхерлебәнат Сөләйманова килә һәм дәресләр бирергә риза була. Мәктәпкә акчаны кардәш Габдулловлар (200 сум), Тажетдиновларның сәүдә йорты (300 сум), Г. Моратов (300 сум), Х. Бутбаев (50 сум) һәм башкалар бирәләр. Укучы кызлар аларга ярдәм итү өчен, эшсез калган эшчеләр фондына акча җыюны оештыралар, үзбәкләр дә булышлык күрсәтә. Кызлар өчен мәктәп Оренбурда да ачыла. «Уральскида Төхфәтуллиннар йортында кыз балалар мәктәбе ачыла»,— дип хәбәр итәләр. Хвалын өязенең Иске Мәстәк авылыннан Сөләйман Сүнчәләев, 7 мәхәлләле бу зур карьяда хатын-кызлар өчен бер генә мәктәп тә юк, ә узган ел 35 кызны укыттылар, дип яза. М. Гафури милләт аналарын үстерү өчен Уфада кызларга махсус мәдрәсә төзелә, дип шатлана. Ул мөгаллимәләр Мәрьям һәм Фатыйма ханымнарга, Алкинага рәхмәт әйтә. «Вакыт», Әстерхан губернасының Яңа Казанка авылында кардәш Сәгыйтовлар хатын-кызлар өчен ике катлы мәктәп салдылар, дип хәбәр итә.

Мәскәүдә атаклы Шамилнең онысы Заһид Шамил рәислегендә татарлар 1907 елда мөселманнар арасында мәгърифәт тарату буенча җәмгыять оештыралар. Газета Казанда 1907 елның 1 декабрендә «Шәрыкъ» клубы» ачу, аның старшинасы итеп И. Терегуловны сайлау, анда 66 кешенең әгъза булып керүе хакындагы хәбәрне дә читләтеп үтми. Редакция татар һәм казакъ телләрендә нәшер ителгән «Аракы агуы», «Кыргыз хрестоматиясе», кебек китапларның дөнья күрүен хуплап билгеләп үтә. А. Газакаев тарафыннан урысчадан тәрҗемә ителгән «Сәламәтлекне ничек сакларга?» дигән китапка югары бәя бирелә.

Редакция Русиядә татарлар өчен укытучылар әзерли торган ике генә булса да югары уку йорты кирәклеге турында чыгышлар ясаган Тукайга һәм Казан җәмәгатьчелегенә теләктәшлек күрсәтә.

Мәскәүдә 1907 елда З. Шамил рәислегендә мөселманнар арасында мәгърифәт тарату буенча җәмгыять оешуы хакында без әйтеп киткән идек инде. З. Шамилнең цензура эшләренә катнашуы була, ул мөселман басмалары өчен җавап бирә. Г. Кариевкә спектакльләр куюда, репертуар сайлауда тыюлар һәм каршылыклар киртәсен исән-имин үтәргә ярдәм итә. Ул Петербургта җирле җәмгыяте хәйриядә актив катнаша, китапханә мөдире булып тора. Шымчы «Борис» әле 1908 елда ук жандармнарга З. Шамилнең мөселман яшьләренең революцион элементларына булышуы, китап сатучыларны булачак тентүләр хакында алдан кисәтүе, кадетлар һәм кайбер социал-демократлар белән элемтәдә торуы, «суллар» белән бер булып эш итүе хакында җиткерә бара.

Гомуми җыелышларда аның белән М. Вахитов, Ш. Манатов, Г. Абязов, Ф. Әмирхан, Литва һәм Польшадан килгән татар студентлары, Г. Исхакый һәм башкалар очраша.

Очрашулар вакытында бәхәсләр чыга. Прогрессив башлангычларга каршы консерватив рухлы бәндәләр генә түгел, 30 тиен көмешкә сатылган патша ялчылары, тәлинкә тотучылар да, берсеннән-берсе уздырырга тырышып, аны буарга маташалар. Күренекле журналист Кәбир Бәкер Казанда чыга торган газетага 1911 елның 21 октябрендә Петербургта булган «Нәшер мәгариф җәмгыяте»нең кичәсе турында «Шәрыкъ кичәсе» дигән мәкалә бастыра.

Кичәнең беренче өлеше татар телендә («Казанга сәяхәт» пьесасы), икенче өлеше урыс телендә «Наян» опереттасы белән бара. Г. Кариев группасы артистлары бик яхшы чыгыш ясадылар, кеше биниһая күп иде, ди автор. «Мондый кичәләр Петербург мөселманнарының аңында тирән эз калдыра»,— дип йомгаклый язмасын К. Бәкер. Бу уңышта, һичшиксез, З. Шамилнең һәм М. Вахитов артыннан баручы студентларның өлеше зур булган.

Г. Исхакыйга иң якын торган кешеләрнең берсе Ш. Мөхәммәдъяров Петербургтагы мөселман җәмгыяте тормышындагы кыен көннәрне сурәтләп калдырган. 1913 елның 12 маенда узган җыелышта үзара сугышып беттеләр, хәтта әләк язу белән куркытуга кадәр барып җиттеләр, ди ул ачынып. Кайберәүләргә әдәби-музыкаль кичәләр ошамый һәм алар идарәгә дин сөреме белән агуланган «үз» кешеләрен тәкъдим итәләр. «Талчукчылар»,— дип кычкырулар күп була. Җыелышта Дәүләт Думасы әгъзасы Ибн. Әхмәтов катнаша. Заһит Шамил акырып утыручыларны, С. Баязитовны оялтырга тырыша. Соңгыларын сайламыйлар һәм алар үзләре белән 150 кешене ияртеп чыгып китәләр.

Бу вакыйга хакында «Вечерняя время» дә язып чыга. Ул бу низагны җәмгыятьнең 1911 елдан сәяси төс алуы, ә моның Петербург мөселманнарына ошамавы белән аңлата. Имеш, мондагы суллар, шул исәптән З. Шамил, хәзрәтләргә каршы икән, дип тәтен җибәрә.

Ш. Мөхәммәдъяров карагруһ бәндәләрнең провокацияләрен гаепли һәм, алга таба да без вак бәндәләрнең этлекләреннән азат булырбызмы, дигән сорау куя.

Бу теманы студент Госман Токымбәтов башлый. Ул үзенә күрә анализ ясый, Петербургта 10 меңләп мөселман яшәвен һәм 20 кешегә бер зыялы туры килүен исәпләп чыгара, аларның чит адәмнәр кебек үзара белешми яшәвенә ачына. Ә мәгърифәткә мохтаҗлар күп. 15 ел дәвамында шәкертләргә, башка сораучыларга һәм бигрәк тә студентларга 14917 сум күләмендә ярдәм күрсәткәнгә, ул мөселман җәмгыятен «нур таратучы учак» дип атый. Татарча, урысча да укыта торган мәктәп ачылган, малайлар һәм кызларны бергә укыту юлга салынган. Агымдагы елда мәктәптә 72 укучы белем алган, соңгы елларда 7 кыз һәм 23 егет гимназияләргә һәм реальное училищега кергән. Һәм болар бай ата-ана балалары түгел. Алар Г. Исхакый әсәрләрен өйрәнәләр. Мәктәпнең башында Мөхәммәдзаһит Шамил һәм мөгаллимә Мәрьям Базаревская торалар. Төрле юллар белән жандармнар З. Шамилнең социал-демократларга һәм социал-революционерларга теләктәшлек итүе, аның фатирында узган җыелышлар турында (монда кешеләр шулкадәр күп җыела торган була, хуҗаларга урындыкларны күршеләрдән алып торырга туры килә) белеп торалар. Кечкенә генә бу деталь җыелганнар арасында сатлык җаннарның һәм агентларның булмавы турында сөйли. З. Шамилгә кемнәр килеп йөрүен охранка белми.

Тормыштагы хәлләрнең һәммәсе дә охранкага мәгълүм булмый һәм кәгазьгә теркәлми. Гомумән, без әле бик күп нәрсәләрне белмибез. Шуңа күрә тарихның серләрен ачарга теләгән укучы З. Шамил оештырган кичәләргә М. Вахитов, аның дуслары һәм иптәшләре дә йөргән икәнен аңларга тиеш, дип яза аның яхшы танышы Г. Токымбәтов. Газета редакторының энесе дә мондый җыеннарда катнашканга күрә, редакциягә бик күп яшерен нәрсәләр дә мәгълүм була. Алдынгы карашлы кешеләр, нинди фиркадә торуларына карамастан, кара көчләргә каршы көрәш алып баралар. Милли-азатлык хәрәкәтенә әсирлар Г. Исхакый һәм Г. Ибраһимов, революциягә кадәр үк социал-демократларга якынайган М. Вахитов һәм Ш. Манатов, партиясезләр һәм кадетлар З. Шамил, Ф. Кәрими, М. Базаревская, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре Г. Фәхретдинов, К. Бәкер һәм башкалар барысы бер булып күтәреләләр.

Мәгълүм бер мәсләктә торып, редакция үзен-үзе тәнкыйть итүдән дә курыкмый, битләрендә фикри дошманнарына да урын бирә. Авыл халкы гарәп һәм урыс сүзләрен кулланудан котылып, «Вакыт»ның телен җиңеләйтүне сорыйлар. Байны да, ярлыны да бер рәткә куеп һәм милләтнең бер бөтенлеге өчен җан атып (монда дин дә үз ролен уйный), газета сыйнфый көрәш идеясен хөкем итә. Ул башта изелүдән котылырга, аякка басарга һәм фәкать шуннан соң гына сыйнфый мәнфәгатьләр хакында уйларга кирәк, дип исәпли. Классик үсеш күзлегеннән

чыгып бәя биргәндә, бу хакыйкатькә хилафлык китерми, чөнки колониаль халыклардагы милли хәрәкәтнең беренче чорын узмыйча, метрополияләр хакимлегеннән котылмыйча, социаль әзерлектә үз изүчеләренә каршы көрәшнең икенче этабына сикерү мөмкин түгел иде. XX гасыр башында Россиядә бу этапларның икесе дә бер йомгакка төенләнделәр. Россия социал-демократлары бу хакта белә иде һәм алар, милли мәсьәләне икенче планда калдырып, социаль проблемаларны хәл итү юнәлешеннән киттеләр.

«Вакыт», социал-демократлар һәм эсерларның эшчәнлеген инкарь итмичә, башкача фикердә торды. Урысларга сыйнфый көрәш алып барырга мөмкин, ә мөселманнарга ярамый, алар — «үги балалар». Алар фикеренчә, халык көчле, ләкин ул революция ягында түгел. Суллар, ягъни эшче мәнфәгатьләрен яклаучылар — азчылык. Декабрь вакыйгалары кораллы күтәрелешнең зарарлы икәнен күрсәтте, шуңа күрә революциягә өндәргә кирәкми, кадетлар юлыннан бару әйбәт.

Шуннан мантыйкның йомшак икәнен сизеп, газета: «Халык хөкүмәтне ярат маганнар ягында»,— дип өстәргә мәҗбүр була. Шуның өчен Думага нәкъ менә социал-демократлар сайланды да. Аларны халык, программалары яхшы булганга түгел, ә бәлки хөкүмәтне дошман иткәнгә күрә яклады. Хәбәрченең фикеренчә, кадетлар, оппозициядә торсалар да, намуслы кешеләр булсалар да, яшерен эш алып бармаганлыктан оттырдылар.

Газетага Кочкар приискаларында (аның хуҗалары Ф. Кәриминең дуслары һәм газетаның химаячеләре бертуган миллионер Рәмиевләр була) эшләүчеләргә мәчет ачу, ач эшчеләр һәм эшсез калганнар өчен акча җыю хакында үз таләпләрен дә өстәргә туры килә. Кадетлар да, аларга теләктәшлек итүчеләр дә тормыштан качалмыйлар. Тормыш мантыйгы аларны каршылыкларны күрергә мәҗбүр итә. Фатих Кәрими үзе сулларның Думаны һәм хөкүмәтне яратмаулары, уңнарның башканы теләве, фәкать кадетларның гына аны үстерергә омтылуы хакында яза һәм «Дума янартау өстендә утыра, анда һава җитми» дигән нәтиҗә чыгара.

Редакция үз мәсләген аңлатырга, кешеләр алдында яхшатлы булып күренергә омтыла. 9 май санында үзен «без милләтчемез» дип тәкъдим иткән билгесез автор үзләрен кадетлыкта гаепләүчеләргә үпкә белдерә... «Өлегә кадәр без кадетларны яклап килдек, бераз сулларны тәнкыйтьләдек, чөнки революцион хәрәкәт артыннан барганда милләтне икегә бүлеп булмый». «Вакыт», «кадетлар яшьләрне үз сафларына чакыралар, алар барлык җирләрне тартып алып бүлүгә дә каршы түгелләр»,— дип раслауга кадәр барып җитә. Ә ахыргы максат һаман искечә кала бирә: ягъни без кадетлар яклы, алар безгә ярдәм итәргә тиеш; без чикләнгән монархия яки «мөхтәрият» өчен көрәшәбез.

Әйе, массаларның социаль хәрәкәте кадетларга да, аларның татар дусларына да йогынтысыз калмый. Шулай да милли рухлылар, 1907 елда сулга авып, «республика» сүзен әйтергә әзер булалар.

Думаның куып таратылуы һәм өченче июнь түңкәреше тәмам аптырашта калдыра. Сәясәтчеләр Думаның куылуына халык битараф калды, чөнки ул идарә итәргә әзер түгел, дигән нәтиҗәгә килә. «Халык алга таба нәрсә эшләр, монысы безгә мәгълүм түгел. Хәзер халыкта милли хисләр уятырга кирәк, сәясәт артыннан куарга ярамый. Сәясәт мәйданында безнең ролебез тәмам»,— дип яза «Вакыт». Шул рәвешле, бөек гамәлләрдә халыкның ролен читләтеп танып, газета ачынып булса да, үзенең көчсезлеген сиздерә.

Ләкин «Вакыт» сәясәттән читләшми һәм читләшә дә алмый. Аңа Русиянең бөтенлегенә янауда һәм Алтын Урданы яңадан торгызырга омтылуда татарны гаепләгән, татарны кыргый итеп сурәтләгән карагруһчыларның һөҗүмнәрен, шовинистларның пычрак ялганнарын кире кагарга туры килә. Шул рәвешле, заман вакыйгаларына бәя биргән, көрәш һәм сыйнфый каршылыкларны да ачкан язмалар дөнья күрә. Шул ук «Вакыт», царизм сәясәте нәтиҗәсендә татар матбугаты югала, милләт телсез кала, дип танырга мәҗбүр була.

«Вакыт»та илләр һәм дөнья халыклары хакында күп кенә кызыклы фәнни сюжетлар, өстән-өстән генә булса да, татар тарихын бирергә омтылышлар абайлана. Газетада музыка һәм сынлы сәнгать, театр үсеше мәсьәләләре дә күтәрелә.

Редакция Бакуда чыккан «Фәюзәт»не, «Молла Насретдин»ны, чувашның «Хыпар»ын, Төркия һәм Русия халыклары басмаларын пропагандалый, «Шәрекъ клубын» һәм Ф. Туишевны да онытмый. «Көчленеке замана» дигән мәкаләсендә газета: «Япония бер сәбәпсез 10-12 миллионлы Кореяны йотты»,— дип яза һәм дөньяда көчнең хакимлек итүенә ачына.

«Вакыт»нын ачыгучыларга ярдәм жыюны оештыруы. Петербургтан башлап Алма-Ата, Коканд, Бохара, Ташкент, Ерак Көнчыгыш һәм Кытай Шинҗәненә кадәр жирләрдә иганәләрнең географиясен өйрәнү махсус тикшеренүләрне таләп итә. Акчалар байлардан да, хезмәт кешеләреннән дә, укытучылардан да, укучылардан да керә. Мондый изге жаннарның исемнәрен жентекләп өйрәнәсе иде.

Кин һәм төрле яклап булмаса да, «Вакыт» фәнни эзләнүләр алып бара, галимнәр белән языша, сүз осталарының язмаларын бирә. Аның яна татар китаплары, махсус әдәби жыентыклар турында мәгълүматлары мөһим. Газета битләрендә хәтта махсус басмаларда да булмаган гажәеп хәбәрләр бар.

«Вакыт» кара көчләргә каршы, хатыннарны азат итү өчен көрәш алып бара. Болар — татар ижтимагый ан тарихындагы ин яхшы сәхифәләр.

Редакциянен шагыйрь Г. Тукайга карата кешелекле мөнәсәбәте турында хатирә дә мәнге калыр.

Шунысы да мәгълүм булсын: редакциядә язганнан һәм язарга мөмкин булганнан күбрәкне белгәннәр. Редакциянен архивын, хәбәрчеләренең хатларын табасы иде. Язучы Фатих Кәрими чын мәгънәсендә талантлы мөхәррир була. Анардан хаталар да һәм үз заманынын каршылыклы проблемаларын анлап житкермәү дә табарга мөмкин. Ләкин ул газиз халкын телсез калдырмаган редактор.

Игенче малае һәм зыялы Фатих Кәрими яңа фикерләр туу хакына мөмкин булганнын барысын да эшләп, сонгы сәгать сукканчы халкы һәм ватаны өчен тырышты.

Рәфикъ НӘФЫЙГОВ,
профессор

**Гомәр Саттаров,**
профессор

# БАШКАЛАБЫЗ АТАМАЛАРЫНА — МИЛЛИ РУХ

Әлеге мәкаләбездә башкалабыз Казан атамаларына хас булган тарихи-лингвистик-топонимик хасиятләр турында сөйләү төп максат ителсә дә, сүзне бераз уратып алып китеп башлау урынлы булыр. Атамалар тарихы шәһәр яки башка берәр торак пункт тарихыннан аерылгысыз булганга, болай эшләү мәҗбүри зарурият тә.

1977 елның җәендә газиз Татарстаныбызның башкаласы Казан шәһәренең нигезләнүенә (тарихи чыганакларга таянып, галимнәр Казан 1177 елда салына башлаган, дип саныйлар) 800 ел тулу датасын олуг бәйрәм-юбилей итеп уздырырга тиеш идек. Бу хакта Татарстан хөкүмәте махсус карар да кабул итте. Мәркәзебезнең ошбу тарихи бәйрәмен үткәрү өчен зур әзерлек алып бардык. Әмма күтәренке дәрт, матди һәм рухи өметләр белән көтелгән бу бәйрәм булмый калды. Дөресрәге, Казанның 800 еллык юбилеен олуг бәйрәм итеп үткәрергә Мәскәү рөхсәт итмәде, бөек шагыйребез Г. Тукай сүзләрен бераз үзгәртеп әйтсәк: «Мәскәүләр якадан тотты», татар халкының һәм казанлыларның якты өметләрен аяк астына салып таптады. Мәскәүнең рус тарихчы-академиклары: «Әле күптән түгел генә Мәскәүнең 800 еллыгын билгеләп үттек, Казанның 800 еллыгын үткәрү аның борынгылыгын, татарларның чал тарихлы мөстәкыйль дәүләтле халык булуын рәсми тану»,— дип, башкалабыз Казанның 800 еллык олуг юбилеен үткәрергә фатиха бирмәделәр. 70 нче елларда Мәскәү рөхсәтеннән, Мәскәү фатихасыннан башка милли автономияләр нәрсә эшли ала иде соң? Һәм әле хәзер дә нәрсә майтара алабыз?

Нәкъ менә тагын ун елдан — 2002 нче елда — сөекле башкалабыз Казанның нигезләнүенә 825 ел тулачак. Бу олуг тарихи датаны, һичшиксез, күркәм һәм зәвыклы зур бәйрәм итеп үткәрү кирәк. Татарстан Республикасының суверен демократик дәүләт статусына ия булуы моның өчен мөһим алшарт, әлбәттә. Иншалла, сөекле мәркәзебез Казанның 825 еллык юбилеен зурлап үткәрербез дип ышанам. Юбилейга әзерлек эшләрен бүгеннән үк башларга, республикабыз һәм башкалабызның хезмәт коллективларын шушы тарихи дата уңае белән җитештерүчән хезмәткә, һәр эштә, һәр тарафта күңел биреп тырышып эшләргә дәртләндерергә тиешбез. Шушы юбилейны, тиешле программасын булдырып, эзлекле эш алып барып уңышлы каршылау һәм нәтиҗәле итеп үткәрү өчен, озакка сузмастан Татарстан Президенты указы белән Татарстан Җөмһүрияте Премьер-министры җитәкчелегендә махсус комиссия оештыру зарурлыгы көн кебек ачык.

Татарстан җөмһүрияте җитәкчеләренең хәзерге вакытта мондый олуг милли чараларны үткәрүдә уңай тәҗрибәләре бар инде. Мондый күркәм тәҗрибәләр һаман туплана, үсә, байый баралар. Мин биредә беренче чиратта, шушы елның маенда Татарстан халыклары корылтаен һәм 19—21 июньдә Бөтендөнья татар конгрессын оешкан төстә, гаять матур, бай эчтәлекле һәм нәтиҗәле итеп үткәрү тәҗрибәләрен күздә тотам. Планетабызның төрле илләреннән килгән делегат-кунакларны Казаныбызны бизәп-төзекләндереп каршы алдык, йөзгә кызыллык килерлек булмады. Уртак фикергә килеп тотынсак, барсын да булдыра алабыз икән бит.

Болары барсы да әйбәт, барсы да күркәм һәм яхшы. Әмма...

Бөтендөнья татар конгрессын үткәрү алдыннан башкалабыз Казан урамнарының исемнәрен үзгәртү, хәзерге вакытта 1800 дән артык урамының яртысының урысча исемнәрен татарчалаштыру мәсьәләсе туган иде. Шушы мәсьәләне хәл итү өчен гамәлдәге елның 28 маенда Казан шәһәр Советы каршындагы Топонимия комиссиясенең утырышы үткәрелде. Утырышны комиссия рәисе, Казан шәһәр Советы депутаты, физика-математика фәннәре кандидаты Марат Лотфуллин алып барды. Комиссия әгъзалары галим-топонимистлардан, тарих-

чы галимнәрдән, филологлардан (арабызда атаклы татар академигы Әбрар Кәримуллин да бар), архитекторлардан, язучылардан, китапханәчеләрдән, музей хезмәткәрләреннән һ. б. компетентлы белгечләрдән гыйбарәт.

Башта утырышта тарих фәннәре докторы Р. Г. Фәхретдинов Татарстан Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми Советы утырышында «Казанның тарихи өлешендәге урамнарның һәм мәйданнарның исемнәрен алмаштыру» турында рәсми тикшереп расланган исемлек-проект белән таныштырды. Хәзерге вакытта Казан урамнарының 90 проценты урысча исем йөртүен, бары тик 10 проценты гына татарча булуын хәбәр итте. Казан урамнарының исемнәрен алмаштыру-үзгәртү проектында атамаларның 50 проценты урысча, 50 проценты татарча булуы күздә тотылуын, ягъни татарча һәм урысча атамалар «баш на баш» булырга тиешлеген аңлатты. Болай эшләү Татарстан Югары Советы сессиясендә 1992 елның 8 июлендә «Татарстан халыкларының телләре турында» Законның җөмһүриятебездә татар һәм урыс телләрен тигез хокуклы дәүләт телләре итеп тануның реаль юридик гәүдәләнешенә туры киләчәк һәм гамәли хокукы чагылышын тәэмин итәчәк.

Топонимия комиссиясе Казанның Үзәк урамнарыннан Ленин урамын — Сөембикә урамы, Кремль эчендәге Шейкман урамына XVI гасырда Казан ханлыгы хөкүмәте башлыгы, бөек бәк Нургали Ширин хөрмәтенә Нургали урамы, Профсоюз урамына Колшәриф урамы, Дзержинский урамына Гаяз Исхакый урамы, Карл Маркс урамына Бакый Урманче урамы, Киров урамына Болгар урамы, К. Насыйри урамына Ш. Мәрҗани урамы, Париж Коммунасы урамына К. Насыйри урамы, Н. Ершов урамына Арча кыры урамы, Куйбышев урамына Рыбнорядский урамы, Бауман урамына Проломная урамы, Ирек мәйданына Азатлык мәйданы, Куйбышев мәйданына Татарстан мәйданы, Татарстан урамына, Татарстан мәйданына кадәр дәвам иттереп, Татарстан проспекты исемнәрен бирергә карар чыгарды. Бу карар хакында Мәскәү (мәсәлән, «Известия») һәм Казан («Шәһри Казан», «Вечерняя Казань», «Ватаным Татарстан» һ. б.) газеталарында язып та чыктылар.

Топонимия комиссиясенең әлеге зарури һәм тарихи карарының Казан шәһәр Советы президиумы һәм администрациясе аппараты тарафыннан шушы көнгә кадәр расланганы, ягъни рәсмиләшкәне юк әле.

«Ватаным Татарстан» газетасы укучылары сорауларына Казан шәһәр администрациясе башлыгы Камил Исхаков җавабы урнаштырылган. «Сезнең борчулар — ул безнең борчулар» дип аталган (исеме ни тора!) мәкаләдә («В. Т.», 1992 ел, 18 июль саны) Казан урамнарының исемнәрен үзгәртү хакында бик вакытлы һәм урынлы сорау бар.

Сорау. «Казан шәһәрендәге кайбер урамнарның исемнәрен үзгәртү озакка сузылды. Шәһәр админстрациясе бу турыда уйлыймы? Насыйров».

Җавап: «Әлбәттә, шәһәр урамнарының исемнәрен үзгәртү мәсьәләсе администрация аппаратында һәм шәһәр Советында берничә тапкыр тикшерелде. Үткән ел шәһәр Советы каршында шәһәр урамнары, мәйданнарының исемнәрен үзгәртү буенча депутатлар комиссиясе оештырылган иде. Аның составына халык депутатлары, Язучылар берлеге, Тарих, тел, әдәбият институты, университет, Татарстан дәүләт музее һәм башка оешмаларның вәкилләре керде. Комиссия урамнарның, мәйданнарның исемнәрен үзгәртү принципларын эшләде. Инде кайбер тәкъдимнәр дә бар. Алар матбугатта басылып чыкты. Озакламый кайбер урамнарның исемнәре дә үзгәртелер».

Әмма кайчан? Ни өчен һаман тартабыз-сузабыз? Казан шәһәр Советының чираттагы сессиясен көтәбезме? Топонимия комиссиясенең карары анда расланырмы? Әйтүе кыен. Чөнки Казан шәһәр Советының байтак кына татар депутатлары да татарлыктан, татарча, үзебезчә, җирле топ халыкныкыча булудан оркиләр, качалар, куркалар, йөз чөерәләр бит.

Шулай итеп, Казанның үзәк урамнарының урысча исемнәрен татарча исемнәр белән алмаштырып, зарур карарны тиешенчә рәсмиләштереп (Бауман урамын Проломная урамы дип, тарих кара тамга салган урам исемен кире кайтару-торгызу бәрабәренә булса да), Бөтендөнья татар Конгрессы делегатлары һәм кунакларын татарча исем алган үзәк урамнардан йөртә алмадык. Өркедек, шүрләдек, курыктык. «Өлкән агай»ның хәтерен саклыдык, кәефен бозмаска тырыштык. Милли үзаң, милли атамалар, милли йөз, рух һәм тарихыбыз хисабына. Боларны инкарь итү, танымау, уятмау-яңартмау бәрабәренә. Татарлыктан, татарча булудан качып, чал һәм бай тарихлы кагъбә-мәркәзебез Казаныбызның милли йөзен, рухын рәнҗетү, сыту, юк итү хисабына. Никадәр

кыйммәткә төшкән авыр, хак һәм хурлыклы бәһа. Татарлармы без, татармы без? Казан — бөтендөнья татарларының баш мәркәзе, төп үзәге, Татарстан җөмһүриятенең башкаласымы? Әллә түгелме? Күпчелек вывескалары, урам-мәйдан атамалары, архитектурасы урысча булган Казан шәһәре башка урыс шәһәрләреннән, әйтик, Рязаньнан, Владимирдан, Вологдадан, йә булмаса, Ярославльдән нәрсәсе белән аерыла? Кайда суверен республикабыз Татарстанның башкаласы Казанның милли йөзе, милли архитектурасы, милли топонимиясе, эргонимиясе, татарча рухы, җаны, сулышы, яшәеше, үткәне, хәзергесе һәм киләчәге? Кайда?

Татарстан җөмһүрияте буйсынуындагы Алабуга, Азнакай, Бөгелмә, Зәй, Зеленодол, Лениногорск, Түбән Кама, Чаллы, Чистай, Әлмәт; район буйсынуындагы Буа, Болгар, Мамадыш, Менделеев, Норлат, Тәтеш, Әгерҗе кебек шәһәрләре, эшчеләр поселоклары, хәтта күпчелек авылларының топонимиясе дә башлыча рус телле атамалардан гыйбарәт, татарча атамалары бармак белән генә санарлык. Шулай булгач, Татарстан Республикасы урбанонимиясенең (шәһәр һәм башка торак пунктлар эчендәге топографик объектлар исемнәренең) үз милли йөзе, милли рухы, татарча булуы кайда? Бармы соң ул? Юк, диярлек бит.

Шулай да бөтенләй өметсезлеккә, төшенкелеккә бирелмик әле. Билгеле ки, табигатьтә һәм җәмгыятьтә барысы да хәрәкәттә, үсеш-үзгәрештә.

Халык саны ярты миллионнан артып киткән, зурлыгы ягыннан Татарстаныбызда икенче урынны биләүче тарихы чал, бүгенгесе яшь-яңа булган Чаллы шәһәрендә урам исемнәрен үзгәртү — яңартуга, татарчалаштыруга җитди мөнәсәбәт, тиешле игътибар күрсәтелә башлады. Халкының зур күпчелеге яшьләрдән торган, татар яшьләре хәрәкәте «Азатлык»ның абруе мәртәбәле булган бу калада милли аң уяну, милли рух җанлану, яңару, үсү процессы бара. Менә шулар тәэсирендә Чаллы урамнарының атамалары яңара, үзгәрә, татарчалаша башлады.

Моннан биш айлар элек һәр җирле яңалыкны тиз тотып алучы һәм оста бәян итүче тәҗрибәле журналист Хәмит Мөхәммәтшинның «Ватаным Татарстан» газетасында «Атамалар яңара» дигән хәбәре басылды. Анда: «Чаллы урамнарында йөргәндә адым саен диярлек тоталитар системадан калган исемнәрне укый идең. Чаллы шәһәр Советы каршында оештырылган топонимика комиссиясе хәзер проспект, урам атамаларын тәртипкә китерү ягыннан зур эш алып бара. Соңгы утырышта Ленин, Мәскәү, Космонавтлар проспектларын Сөембикә, Мәрҗани, Колгали урамнары дип исемләргә тәкъдим ителде. Ленинград урамын Чулман буе урамы, Центральнаяны — Болгар, Комсомоллар урамын Яшеллек урамы дип үзгәртергә карар кылынды»,— диелгән иде. Күптән түгел газетада әлеге карарның, Чаллы шәһәр Советында расланып, юридик яктан гамәлгә ашырылуы хәбәр ителде.

Галим-топонимист буларак шушы сөенечле вакыйгага чиксез куану-шатлануымны, шагыйранә хис-тойгыларымны белдерү өчен, шигъри юлларга күчәм:

## Сөембикә урамы

Сөен, Сөембикә, Чаллыярда  
Бер урам бар синең исемдә!  
Бу дөньяга туып яшәү кирәк,  
Күкрәү кирәк шуның өчен дә.

## Мәрҗани урамы

Энҗе-мәрҗәннәр күп татарларда,  
Асылташтан асыл — Мәрҗани;  
Чал тарихны барлап, халкын нурлап,  
Сарыф булган гомер, дәү җаны.

## Колгали урамы

«Колгали» дигән күркәм урамнар бар  
Мәркәз Казан, чал таш Чаллыда,  
Исемен йөрткән урам булыр әле  
Бөгелмәдә, Әлмәт, Баулыда.

## Чулман буе урамы

Агыйделкәй-елга жырга кергән,
Җанга кергән безгә — татарга;
Агыйделкәй койган, Чулман-елга,
Мөмкин хәзер синең исем белән
Урам исемнәрен атарга —
Чаллы каласының бер урамы
«Чулман буе» диеп атала.

## Болгар урамы

Чал тарихы Чаллы каласында
«Болгар» дигән урам бар икән,
«Болгар» дигән ата-бабаларым
Кадерен җуймас гүзәл яр икән.

## Яшеллек урамы

Яшеллек урамы — яшьлек
Һәм тиндәшлек,
Идегәйдәй иргә, Иделгә:
Идегәй урамнары,
Идел киңлекләре кирәк безгә —
Чын азатлык алган илемә,
Татар телле туган җиремә.

Җөмһүриятебезнең башкаласы Казан урамнарында, аларның атамаларында милли рухыбыз һәм йөзебезнең чагылмавы, Казан урамнары исемнәренең 100 дән 10 сының гына татарча булуы, соңгы елларда Казанга бернинди мөнәсәбәте булмаган, анда тумаган, яшәмәгән һәм эшләмәгән урыс академиклары, маршаллары, генераллары фамилияләрен биреп мәңгеләштерү җәмгатьчелекне, бигрәк тә зыялыларыбызны гаҗәпләндерә, уйландыра, борчый. Бу турыда матбугатта танылган галимнәребез (академик Ә. Кәримуллин, профессор Т. Галиуллин, Г. Саттаров һ. б.), әдипләребез (М. Мәһдиев, Р. Фәйзуллин һ. б.) берничә мәртәбә язып чыктылар.

Ни өчен Казаныбызның урамнарына татар әдәбиятының якты йолдызлары булган шагыйрь Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый, Утыз-Имәни, Курсави, Акмулла, Кандалый, Кормаши, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев, Мөхмүт Галәү, Фәтхи Борнаш, Сибгат Хәким, Н. Исәнбәт һ. б. исемнәрен кушмаска? Шулай эшләгәндә, тарихи милли эчтәлекле шагыйранә урам атамаларыбыз барлыкка килер иде. Атаклы галимнәребез аталы-уллы Хәлфиннәр, Хөсәен Фәезханов, Риза Фәхретдинов, Садри Максуди, Карл Фукс, Николай Катанов, Михаил Худяков, Гайнетдин Әхмәров, Һади Атласи, Галимҗан Баруди, Йосыф Акчура, Газиз Гобәйдуллин; халкыбызның данлы кызлары Сара Садыйкова, Сәҗидә Сөләйманова, Фатыйма Ильская, Гөлсем Сөләйманова, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская; сәнгать-театр эшлеклеләребезнең Мохтар Мутин, Барый Тарханов, Абдулла Шамуков, Нәҗип Җиһанов, Заһид Хәбибуллин, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Фоат Халитов, Хөсәен Уразиков кебек исем-фамилияләре кушылган урам атамаларыбыз һаман юк әле. Алар моңа, һичшиксез, лаек.

Ни өчен әле кайбер проспект-урамнарыбызга тарих һәм дастан геройларыбыз Чурабатор, Идегәй, Җикмәргән исемнәрен бирмәскә. Тарихи даталарыбыз 30 нчы август урамы, 21 нче март урамы, 6 ноябрь урамы исемнәрен кушмаска? Моннан ике ел элек «Вечерняя Казань» газетасында Калинин урамына атаклы якташыбыз, шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе Г. Державин исемен бирүне күтәреп чыктылар. Без бу тәкъдимгә тулысынча кушылабыз һәм аны ихлас күңелдән хуплыйбыз.

1990 елда халык депутатларының Казан шәһәр Советы каршындагы Топонимия комиссиясенең кайбер әгъзалары һәм Баш архитектура-производство идарәсе инициативасы белән безнең җитәкчелектә Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты студентлары тарафыннан Казан урамнарына киләчәктә кушу өчен 500 дән артык татарча күмәклек сүздән торган атама-берәмлекне эченә алган махсус топонимик банк булдырылды. Әлеге топонимик банк алфавит тәртибендә төзелде һәм

һәрбер татарча атаманың русча дөрес язылышы (транскрипциясе) күрсәтелде. Мәсәлән, Абруйлы урам, Азаккы урам, Азатлык урамы, Ак урам, Ак бәхет урамы, Аккошлар урамы, Актирәкләр урамы, Алмагач урамы, Арадаш урам, Аралык урамы, Аргамак урамы, Аркылы урам, Арткы урам, Аскы урам, Атау урамы, Аҗаган урамы — русча транскрипциясе улица Аджаган һ. б. рәвешле.

Шәһәребезнең Баш архитектура-производство идарәсе һәм Топонимия комиссиясе әлеге топонимик банктан тиешенчә, урынлы файдалана башлар, андагы милли топонимик берәмлекләрне кирәгенчә эшкә җигәр, дип ышанасы килә. Казанның Азино-2 микрорайонында җир астыннан чишмә бәреп чыгып, агып яткан, яңа барлыкка килгән бер урамына Чишмәле урамы дигән күркәм исем бирелү моңа матур бер мисал, дәлил.

Казан урамнарының элекке һәм хәзерге исемнәрен махсус өйрәнү шәһәр төзелешләренең үсеше, үзгәреше, ландшафт үзенчәлекләре, халыкның тормыш-көнкүреше, икътисады һәм мәдәнияты, милли составы, тарихи-революцион вакыйгалары, атаклы кешеләре белән яхшырак танышырга, шәһәр һәм шәһәр халкы тарихын өйрәнергә булыша, боларга үзеннән зур өлеш кертә.

Чал тарихлы Казан шәһәре топонимиясен (биредә Казанның урбанонимиясе-урамнары, проспектлары, тыкрыклары, мәйданнары, бакчалары, парклары, базарлары, магазин, кино-театр, учреждение, предприятие, мәчет, чиркәү, стадион, күпер һ. б. исеме тулаем күздә тотыла) формалаштыруда, байтак кына табигый һәм ясалма географик объектларның, аерым танылган шәхес һәм тарихи вакыйгаларның исем-атамалары катнашкан. Шуңа күрә килеп чыгышлары һәм кулланылышлары ягыннан шәһәребез урамнарының һәм башка географик объектларының исемнәре күп төрле һәм катлаулы. Ләкин Казан урамнарының исемнәре тарихи-лингвистик аспектта фәнни яктан җитәрлек дәрәҗәдә тикшерелмәгән әле.

Элекке СССРдагы Вильнюс, Одесса, Ташкент, Сәмәрканд, Томск кебек шәһәрләрнең топонимиясе тарихи-лингвистик яссылыкта тикшереп-өйрәнелеп кандидатлык диссертацияләре якланды. Казан шәһәре һәм аның тирә-юненең топонимиясен кандидатлык диссертациясе темасы итеп соңгы җиде-сигез ел дәвамында Казан авыл хуҗалыгы институты баш архивариусы Асия Шәриф кызы Ганиева тикшерә. Аның бу теманы яктыртуга багышланган 5-6 мәкаләсе матбугатта басылды инде. Әлеге диссертацияне төгәмлауны һәм яклауны тизләтү зарур.

Якын киләчәктә, Мәскәү, Ленинград (хәзер яңадан Санкт-Петербург), Томск һ. б. шәһәрләрнең урам исемнәре сүзлекләре үрнәгендә, «Казан урамнары һәм мәйданнарының аңлатмалы сүзлеге»н төзеп бастыру гаять актуаль һәм муафыйк лексикографик эш-бурыч булып тора.

Ялгызлык исемнәре (кеше исемнәре, кушаматлар, фамилияләр, географик атамалар, кабилә, халык исемнәре-этнонимнар, күк җисемнәренең исемнәре — космонимнар, хайваннар, кош-кортлар исем-кушаматлары — зоонимнар һ. б.), тулаем алганда — тел чаралары белән бәян ителгән тарих, «чал тарих хәбәрчеләре». Менә шуңа барлык төр географик атамалар халкыбызның тузмастутыкмас күңел хәзинәсен, рухи һәм тарихи мирасын тәшкил итәләр. Алар белән белеп һәм сак эш итәргә кирәк. Җирле географик атамалар — тел, тарих, мәдәният һәйкәлләре. Бу кадерле һәм кыйммәтле мирасны тиешенчә барларга, тулыландырырга, чәчми сакларга, өйрәнергә, киләчәк буыннарыбызга тулы-бөтен килеш тапшырырга тиешбез. Милли географик атамаларыбызның тарихи чылбыр-яшәеше беркайчан да өзелмәсен!

Иншалла, башкалабыз Казан атамаларына да милли рух бөркелер, аларның милли йөзләре, төсләре, татарча исемнәре булыр. Замана, җәмгыять хәрәкәттә, яңара, үзгәрә, үсә. Шушы заманчыл социаль-тарихи процесс географик атамалар дөньясына да, шул исәптән Казан урбанонимиясенә дә, үзенең тиешле милли тарихи-лингвистик йогынтысын ясамый калмас, әлбәттә.

# ИМАН НУРЫ

*Замана тәкъдим итә,*
*дустым, замана...*

Бакый Урманче



Әле өйләнешкән генә еллары. Хатынын әниләренә күрсәтергә алып кайткач, язгы урманда хозурланып йөриләр, имеш. Шунда көпә-көндез бүреләр һөҗүм итмәсенме. Көпә-көндез бит, көпә-көндез! Ничек тә сөеклесен саклап калырга омтылып, бер күсәк алып, бүреләр өстенә ташлана...

Юк, тугыз-ун елдан соң бугай. Әнә бит кызлары, энесен җитәкләгән дә, чыр-чу килеп аланда җир җиләге җыеп йөриләр. Аланы шау чәчәктән генә тора лабаса. Бу имәннәрне, бу аланны майлы буяу белән язсаң, хәйран гына картина килеп чыгар иде бит, әй! Ул арадан каяндыр дәһшәтле болытлар агылып килә дә кояшны бөтенләй үк томалый — шау чәчәктәге алан да, чыр-чу килгән балалары да күздән яза. Ата газиз балаларын коткармак булып талпына... Әмма ни сәбәпледер кузгала гына алмый. Ике кулының берсен дә кыймылдатырлык хәле юк икән лабаса. Шуннан хатынын ярдәмгә чакырып сөрән салырга азаплана — тавышы чыкмый...

Әнә шулай гасабиланып, өзгәләнеп, йөрәксенеп, иза чигеп ятканда, бар көчен җыеп, күзен ачу бәхетенә ирешә. Әмма күз кабакларына кургашын койганнар диярсең, шундук ябыла. Бер мизгел эчендә ул янында утыручы хатынын да, аның назлы йомшак бармаклары белән үзенең чәчен аралаганын да, үзенә төбәлгән мәрхәмәтле күзләрендәге мөлдерәмә күңел газабын да шәйләп өлгерә. Әһә, ишеткән икән, ярдәмгә килеп җиткән икән.

Сөекле хатынының өзгәләнү катыш сөенеч тулы тавышы гүя бик-бик ерактан килеп рәссамның колагына бәреләә:

— Күзен ачты! Кызым, әтиегез күзен ачты! Йа раббем!..

Берәүләр әнә шулай, Горький урамындагы травматология клиникасында үлем белән тартыша, авыруның хатыны, улы белән кызы, туган-тумачасы ут йота, ничек кенә хәлен җиңеләйтергә белмичә иза чигә.

Икенчеләре исә махмырдан башлары авырткан килеш газета караштыра. Кыйммәтле папиросын авызында әвәләп, чандыр гәүдәле бәндә:

— Тегә мулла малаена һаман некролог бирмиләр бит әле,— дип сөйләнә.

Эрерәк гәүдәлесе:

— Ашыкма, дускаем, сабыр төбе — сары алтын. Некрологтамыни хикмәт, анысының булмавы да ихтимал. Дөмектерүебез хак булсын,— дип, кәрт өләшергә тотына.

— Хаҗга озатып куюбыз хак инде анысы, хак. Язмас моннан соң чалмалы ишан портретын. Мәчетләр дә язмас...

Рәссам Хәнәфи Нәфыйковны 1987 елның 12 июлендә, кичке якта, өенә кайтып барганда сагалап торып,ниндидер явыз ниятле бәндәләр мингерәүләтәләр, аннары җиңел машинага салып, аулаграк урынга илтеп ташлыйлар, тәмам эшен бетерергә ниятләп, янә дә өстиләр — изәләр, таптыйлар, сыталар...

Кояш ярыйсы ук югары күтәрелгәч,кәҗә сукмагыннан кибеткә баручы үткен күзле бер яшь-җилкенчәк аны күреп ала, телефон-автоматтан милициягә хәбәр итә.

Әмма тикшерү органнарының әллә ни исе китми бу фаҗигагә. Кирәк булса, казыныирлар иде, чокчыныирлар иде — һич кенә дә тапмый калмаслар иде вәхшилек кылучы җинаятьчеләрне. Тик инде әйткәнне эшли, кушканны тыңлый торган чиновникларга сәнгать әһеленең хаҗәте бармыни соң?! Милли сәнгатең булды ни аларга, булмады ни. Җитмәсә бит әле «рядовой художник», бернинди «почетный звание»се» дә юк. Аның хакында кузгатылган «эш» белән күпме генә чиләнсәң дә, түрәләрдән рәхмәт сүзе ишетмәссең, погоныңа йолдыз өстәмәсләр...

Аянычлы хәлдән Хәнәфине газиз хатынының тырышлыгы, уңганлыгы коткара. Табиблар биргән даруларга артык ышанып җитми Лениза ханым, өйдән балдыр-прополистыр ташый. Бакый абзыйларга барып, мумие алып килә. Кайсын эчереп, кайсы белән чигәләрен уып, җәрәхәтләренә сөртеп, ирен акрынлап кына булса да сихәтләндерүгә ирешә бичаракай. Яраса, җанын ярып бирергә әзер торган асыл затның тырышлыгы белән үлем хәлендәге кеше тәмам аякка баса.

Хәнәфи (Канәфи) Нәфыйков Татарстанның Чирмешән районы Иске Үтәмеш авылында яшәүче Абзалетдин абзый гаиләсендә 1938 елның 15 ноябрендә дөньяга килә. Гәрчә рәсем ясауга кече яшьтән күңеле ятса да, шәһәр балалары кебек, сәнгать мәктәбендә тәрбияләнү, әлбәттә, насыйп булмый аңа. Колхозда аз-маз эшләгәч, армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң, Казанга килеп эшкә урнаша: хәлдән килгәнчә бизәү-матурлау эшләрен башкара. Сәнгать училищесын тәмамлаганнан соң, 1962 елны Ташкентның театр-сәнгать институтына барып керә.

Спектакль бизәү һөнәренә өйрәнеп, махсус югары белем алып кайтса да, «Түләк белән Сусылу» операсына багышлаган диплом эшен хупласалар да, яшь рәссамны татар театрына эшкә алырга алай атлыгып тормыйлар. Театрларда эш булмагач, Сәнгать училищесына укытырга керә — яшь рәссамнарга сәнгать серләрен ачуда ярдәм итә. Шул дәвердә аны бер уй бик нык борчый: нишләп әле авылдан яшьләр аз килә? Татарның рәссамнары бит аның, башлыча, авылдан чыга. Ул үзе дә авыл баласы. Күңеле белән бүген дә авылда яши, иҗади сәфәрләргә чыга. Кайсы гына төбәккә юлы төшмәсен, нинди генә кала яки салага барып чыкмасын, иң әүвәл мәчетне эзләп таба, аның рәсемен ясый. Манарасы да сакланган очракта ул аны пастель белән кәгазьгә яисә картонга зур иттереп, матурлап ясап куя: «Авылым мәчете» (1983), «Әҗем мәчете» (1983), «Судактагы борынгы мәчет» (1984) һ. б. Ул чагында һөнәрдәшләре көләләр генә: әйдә, әйдә, музейга сатып алмаслармы, дигән булалар.

Үзенә бүтәннәрнең, бигрәк тә җитәкчеләрнең бераз кимсетебрәк карарга маташуын адым саен сизеп гаҗәпләнсә дә, бирешми Хәнәфи, вакытын әрәм итмәскә тырыша. Ихтимал, көн саен ни дә булса эшләргә кирәклеген сизү, бер жанрдан арыган арада, ял итү сыйфатында, икенчесендә көчне сынап карау чире аңа озын гомерле Бакый ага Урманчедан йоккандыр. Ташкентта институтны тәмамлагач, Казанга сәфәр чыгар алдыннан аңа Һади Такташның талантлы улы — сәнгать фәннәре докторы Рафаэль Такташ мөрәҗәгать итә: аксакалга әманәт тапшыруын үтенә. Хәнәфи, Казанга кайту белән, Урманченың өен эзләп таба, әманәтне тапшыра. Шул килүдән кин күңелле даһи рәссам белән дуслашып ала, акрынлап аның иҗатына күз сала, эшләү ысулын өйрәнә.

Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың, диләр бит. Хәнәфиебез дә үзенең сәләтен, хәйран үзенчәлекле рәссам икәнен төрле жанрда күрсәтә. Бердән, шактый спектакльгә декорацияләр эшли: «Мария Стюарт» (1969), «Түләк белән Сусылу» (1973), «Шүрәле» (1975), «Тукай» (1976), «Алтынчәч» (1976), «Сармат кызы Сәринә» (1986) һ. б. Әле хәтта Мәдәният институты шәкертләре әзерләп яткан спектакльдән дә йөз чөерми — бушлай гына һәйбәтләп бизәп бирә һәм, шул рәвешле, булачак режиссерларның күңелләрен үсендерә. Хәер, күргәзмәләрдә ул ун-унбиш ел буена театр рәссамы буларак катнашып килә. Рәссамнар берлегенә дә нәкъ әнә шул өлкәдә ирешкән уңышлары өчен кабул ителә.

Үз халкыңа фидакяр хезмәт күрсәтүнең төрле юллары бар, моның мөмкинлекләре чиксез. Сәнгать әһеле мәсьәләне үзенчә хәл итә. Әмма шунда да әле үзенең сукмагын салырга омтыла. Ихтимал, батырлыкка аны милли каһарманыбыз Батырша этәргәндер. Бик ихтимал. Чөнки моңарчы тарих тузанына күмелеп яткан (1984 елда, әлбәттә, Җәмит Рәхимевнең бер сүз белән генә афәрин дип бәяләрлек романы булмый әле) гүзәл бер сәхифәне ача, һәм соклануы тышка бәреп чыга — татар халкының каһарман улына мәдхия җырлый, Батыршаның образын иҗат итә.

Хәнәфи Нәфыйковны даһилар исемлегенә теркәмәгән тәкъдирдә дә гаять күркәм бер хәлне әйтми үтү килешеп бетмәс: халкыбызның үзаңын үстерү максаты белән, аның күзен ачарга омтылып, «Ач күзеңне, кардәшем, күр әнә безнең ата-бабаларыбыз нинди булган!» — дип, моннан 15 — 20 ел элек үк көрәш

мәйданына атылып чыга, береннән-бере гүзәл вә камил әсәрләр иҗат итә. Ә инде бүтән һөнәр ияләре көрәшкә ябырылганда ул алар сафында була. 1991 елда татар халкынын мөстәкыйльлеген даулап бер төркем ватандарлар Ирек мәйданында ачлык игълан иткәч, ул аларга, ичмасам бер куышлары булсын дип, үзенең палаткасын китереп бирә, эчәрләренә су ташый — әнә шул рәвешле үзенең теләктәшлеген белдерә. Бүгенге көндә исә Нәфыйков дөньяның төрле почмакларында яшәүче татар рәссамнарын милли тәшкиләткә туплау, аларның иҗатын өйрәнү, күргәзмәләр оештыру дәрте белән яна.

Кызык хәл инде: иҗат иясе еш кына кайсы темалар күңелен җәлеп иткәнен үзе дә тәгаен әйтә алмас иде. Театрга декорацияләр эшләгәндә үк тарихи сюжетларга күбрәк игътибар итә, ешрак юлыга, яратыбрак эшли Хәнәфи. Әнә шул мәхәббәт, нәкыш өлкәсендә активлашып киткәч тә, үзен бик нык сиздерә. Ә инде тора-бара бу тематика аны бөтереп ала, унга-сулга карарлык вакытын калдырмый, яшәвенең максатына әверелә.

Тарихи темаларга юлыккач, рәссамның иҗат офыклары киңәеп китә, халыкка игелекле хезмәт күрсәтү өчен мөмкинлекләре арта. Тарихка мөрәҗәгать иткәндә рәссамның үзенең укымышлы, зыялы булуы ярдәмгә килә. Ул тиз арада үзенә кирәкле вакыйгалар тасвирланган материалны эзләп таба, мәгълүмат туплый, төрле чыганакларны чагыштырып карый, галимнәр белән аралаша, ин әүвәл үзе өчен тарихи дөреслекне тәгаенли-ачыклый, ныклап үзләштерә. Фәкать шуннан соң гына — үзенчә иң зур әһәмияткә ия булырдай бер теманы сайлап алып, шуны ышандырырлык итеп сәнгатьчә яктырту мәшәкатенә башы-аягы белән кереп чума.

Рәссамның иҗатында Болгар темасы лаеклы урын алып тора: «Шомлы төн» (1973), «Болгар урамы» (1975), «Ага Базар» (1976), «Болгарда сакта» (1976), «Болгар чүлмәкләре» (1984), «Болгарда чуен коюм» һ.б.

Казан ханлыгы темасы да татар җанлы рәссамның игътибарыннан читтә калмый. Халкыбызның горурлыгы булган илаһи зат Сөембикәнең газаплы язмышын тасвирлау аның өчен изге бер эшкә әйләнә. Тирән эчтәлекле картина — «Сөембикәнең иленнән сөрелүе» дигән әсәрне 1978 елда язганнан соң автор үзе һич тә күңелендә канәгатьлек хисе тапмый һәм эшен янә дә ун ел буена дәвам иттерә. Гәрчә композициягә әллә ни сизелерлек үзгәреш кертмәсә дә, картинаның яңа вариантларына матур-матур бизәкләр өсти, персонажларның сурәтләрен камилрәк итеп язып чыга, Идел өстенә ябырылган дәһшәтне ачыграк сурәтли, тәгаенләштерә, суның төсен үзгәртә төшә, әнә шундый «вак-төяк»не өстәү нәтиҗәсендә үз алдына куйган максатына ирешә — әсәрнең ышандыру көче бермә-бер арта.

Тамашачының мәхәббәте авторны яңа киндер язуга рухландыра. Бу юлы рәссам ханлыктан ваз кичүгә, иленнән-халкыннан аерылуга, киләчәктә кол булып яшәүгә дучар ителгән ханбикәне бәхилләшү мизгелендә мәңгеләштерә. Илаһи зат Сөембикә үзенең бердәнбер улы һәм кәнизәкләре белән бергәләшеп Ходайга ялвара, дога кыла...

Автор әле үзенең бу эшеннән канәгать түгел, камиллеккә ирешү беркайчан да, беркемгә дә алай тиз генә килми бугай. Әмма әсәр әлеге хәлендә дә гаять нык дулкынландыра.

Улы Раминның рәссам булып китүенә шактый гомер ышанып җитми Хәнәфи. Әтисе иҗатына Раминның һәрвакыт тәнкыйть күзе бәлән каравы, аның бүгенге көндә дә реализм калыбыннан читкә авыша алмавын тәнкыйтьләве тикмәгә булмаган икән...

Шифаханәдән кайткач, рәссамны көне-сәгате белән дачага алып китәргә ниятлиләр. Әмма Хәнәфи моңа ризалыгын бирерлек хәлдә булмый. Ак та дими, кара да дими. Иртән тору белән хатыны ашыкмый-кабаланмый гына түрдәге креслога илтеп утырта аны.

Кара, бигрәк җайлы икән ләбаса бу түрдәге кресло. Башны артка салып, бөтен гәүдәң белән сузылып утырасың да, оеп китәсең. Егылып-шуып төшүдән һич куркасы түгел — култыксалары ышанычлы, нык. Моңарчы Хәнәфинең һичбер вакыт болай җәелеп утырганы булмагандыр. Сәнгать диде, эш диде, шәһәр белән авыл арасында, Академия театры белән Союз арасында чапты да чапты — дөнья куды. Хәер, якты күздә остаханәсеннән чыкмыйча, яңа спектакльләргә декорацияләр хәстәрләде, аннан бушаган арада вакытның кадерен белеп кенә картина язарга тырышты. Язып утырган җирен остаханә димәсәң хәтере калырлык кына: иркен остаханә хуҗалары, бәхетле рәссамнар эше беткән әсәрләрен, киндерләрен, кысаларын куеп торсын өчен генә бүлеп алынган, үзе тәбәнәк, үзе тар, нәкъ тавык кетәгенә тиң бер чарлак почмагы шунда...

Йокылы-уяулы хәлдә, берни уйламыйча, башын артка ташлап, күзен йомып утырганда авыру илаһи бер ләззәт кичерә. Һай, рәхәт икән шулай оеп утырулары!..

Шушы халәтендә бер сәгать утыргандырмы, ике-өч сәгатьме — анысын ул әйтә алмас иде. Ихтимал, кичкә хәтле һичбер хәрәкәтсез утырган булыр иде, тик менә бер мәлне күзен сызык кына ачкан арада каршысында ук утыручы улын шәйләп ала. Тукта, нишләп монда утыра әле егеткәй? Гәпләшмиләр бугай лабаса? Әһә, алдына этюдникгын куйган түгелме? Подрамникка киндер тарттырып, әтисенең сурәтен язып маташа бугай бит! Әнә, буягычын хәйран җилле йөртә, якын затының, яраткан кешесенең кыяфәтен мәңгеләштереп азаплана.

Иркен сулап, Ханәфи тагын татлы оюга бирелә. Әмма шунда ук дерт итеп сискәнеп куя. Тукта, нишләп үләргә ди әле? Әнә ич Рамины олы киндергә сурәтен язып ята. Рәссам ич инде ул егеткәй, бер дә бүтән түгел! Ханәфи үзе дә рәссам лабаса. Улы аның һөнәрен үзләштергән, әтисе җиңел генә үлеп китсә, кем бирер бу егеткә киңәш-акыл? Ю-у-ук, агай, ансат кына оерга, мәшәкатьле-ызгышлы дөньядан китәргә һич хакың юк синең!

Ханәфинең үз һөнәренә янадан кайтуы, рәссам мәшәкатьләренә кабаттан чумуы әнә шушы мизгелдән башлана. Улыннан альбом китерттерә һәм утырган җайга гына шул альбомның ак битенә йомшак карандаш белән иплəп кенә сызгаларга тотына. Каршындагы диварга эленгән, үзе үк сәламәт чагында майлы буяу белән язган нәркисләрне — тын табигать күренешен сызгаларга тотына. Карандаш тоткан уң кулын ватман кәгазь өстеннән йөртүе торган саен кыенлаша бара. Хәле-егәре кимегәннән-кими. Ләкин рәссам үзенекен итә, үҗәтләнеп, тешетырнагы белән тырмашып булса да «эшләргә» тырыша.

Иң ансаты — бакчада бал кортлары, умарталар белән мәш килеп яшәү булыр иде. Тик инде ул чагында кан дошманнарың, башына ук җитмәсәк тә, кешелектән чыгарганбыз икән үзен, рухи үлемгә дучар иткәнбез икән, дип сөенерләр иде. Юк шул менә, бик сөенми торсыннар әле! Рәссамнар исемлегеннән ансат кына сызып ташламасыннар әле! Өр-яңадан эшкә өйрәнер Ханәфи, бөтен кыенлыкларны җиңәр, авызы тулы кан булса да кеше алдында төкермәс — тегеләрне сөендермәс! Киресенчә, бар куәтенә тырышыр, бер ел үтәрме, ике елмы — тик абзагыз элеккегедән күчлерәк рәссамга әйләнер, ул иҗат иткән картиналар халыкның мәхәббәтен яулап алыр!..

Уйлаганы раска килә рәссамның.

Тик ул арада күңелен үстерерлек бер хәл дә булып ала. Киров районындагы сазлыклар янына салынган биш катлы йортка алтынчы кат өстәп, шунда яшь-җилкенчәк рәссамнарга остаханәләр бүленә. Нәфыйковка, син театр художнигы, дигән сылтау белән, гәрчә нәкыш өлкәсенә ныклап кереп барса да, остаханә бирмиләр. Исемлектәге бәхет ияләре, әлбәттә, ризалашалар, саз ерып булса да, барып урнашалар. Тик арада Ханәфине ифрат якын күреп йөргән берәү транспортсыз-нисез җиргә йөрүдән Нәфыйков файдасына баш тарта. Бу юлы түрәләр дә һич каршы килмиләр: әйдә, таякка таянып, шунда йөреп карасын әле җәһәннәм читенә, бик тиз шөрепләре бушар, әллә ни майтара алмас, диебрәк фикер йөртәләр бугай.

Ханәфи өчен бу әйтеп бетергесез бәхет була. Көне-сәгате белән шунда барып урнаша. Зарлана димени гомер буена эшләр җире булмаган профессионал рәссам! Шактый араны ашыкмыйча гына җәяү уза, әллә кайлардан үзенә елмайган сыман тоелган иләмсез озын таш йортның алтынчы катына сабыр гына, култыксага тотына-тотына менә, ходайның һәр бирмеш көнендә эшләргә йөри, шунда омтыла.

Ел әйләнәсендә беркемнең күзенә күренми Ханәфи. Һәрхәлдә, рәссамнарның җыелышына да барып йөрми, остаханәсенә дә берсен-бер чакырмый. Аның янына фәкать якын дуслары гына килгәли. Һәм рәссамның яңа эшләрен, сюжет өстендә баш ватуларын, эзләнүләрен, бүтән төрле иҗат газапларын шулар гына күреп сөенә, авторның күңелен үсендерә, көч бирә һәм дәрт өсти.

Яңа язылган картиналарның күбесендә безне бар кылган табигать анабыз гүзәллеге сурәтләнә.

Биредә шунысын әйтеп үтәргә кирәк: табигать күренешләрен сурәтләгәндә Ханәфи игътибар үзәгенә төсләрнең үзара мөнәсәбәтен куя. Әйтик, аның агач яисә куагы тоташы белән бер ябалдаштан торган сыман тоела. Рәссам һәр яфракны аермачык язу белән мавыкмый, гомумән, әйберне әллә ни тәфсилләп бирми, бәлки төсләрнең үзләрен сөйләтә. Ул, табигать баласы буларак — алан яки болынны, умартачы буларак — умарталыкны төсләр гармониясенә таянып шулчаклы да оста сурәтләп бирә ки, син үзеңне әнә шул аланда яки болында дип

хис итәсен, шушы гүзәллеккә хәйран каласың. Картинадан күзеңне дә ала алмыйсың: әнә генә бер төркем күк чәчәкләр, тегендәрәк — сарылары, кызыллары дөньяга ямь биреп, сөендереп, нурланып утыралар. Син гүя бал кортларының чәчәктән чәчәккә күчүен күрәсең, безелдәвен-көен ишетәсең...

Хәнәфи Нәфыйковның баганалы шома юлдан атламавын, нинди генә камил әсәр иҗат итеп тә һичбер түрәнең күңеленә хуш килмәвен язмышка сылтамый чараң юк. Һәрхәлдә, күргәзмәдә иң нык шаулаган картинасына да Сәнгать музее хуҗалары иң түбән бәһа куялар. Әле анысы да музейга сатып алган очракта гына. Ә калганына ничек тә күз йомып узу, күрмәмешкә салышу юлын сайлыйлар. Монысы ешрак була. Әйтик, Шиһабетдин Мәрҗанинең гаҗәеп зур осталык белән, дин вә мәгърифәт әһелләренә искиткеч зур мәхәббәт белән киндергә язылган портретын сатып алмас өчен генә, музей хезмәткәрләре икенче берәүгә, «Ш» яки «М» хәрефләренең ничек язылганын да белмәгән рәссамга заказ бирәләр. Урыслар мондый очракта: «Удар ниже пояса»,— диләр бугай. Хәер, татарларның карап торган бердәнбер милли Сынлы сәнгать музеенда гомер эчендә бер татар җанлы хезмәткәрнең дә эшләгәне булмады. Дирекциясен әйткән дә юк инде аның... Нәфыйковтай үҗәтләнеп тарих тузанын актаручы, мәчет рәсемнәре ясап маташучы дәрвишләрне бандитлар үтереп ташлады ни, ачка интегеп җан тәслим калды ни — алар өчен барыбер булса кирәк...

Хәнәфи бирешми, сынмый, кыйбласыннан тайчынмый — һаман әле тарихны өйрәнүен, темалар сайлавын, шуларны язар өчен киндерне-кысаны җайлавын дәвам иттерә. Рәссам үзе өчен бөтенләй көтелмәгән тарихи фактны ачкан: Александр Невскийның олуг полководец булып китүендә урыслар гомер буена мәсхәрәләп-сүгеп килгән Батый ханның кулы уйнаган икән ләбаса! Мондый хәлне сәнгатьтә әле берәүнең дә яктыртканы юк икән. Менә шул теманы зур итеп киндердә тасвирлап бирсәң, әйбәт кенә булыр иде бит, әй!

Сәеррәк шәхес инде безнең Хәнәфиебез: күңеленә берәр нәрсә кереп урнашса, башка бернидә гаме юк, фани дөньядан ваз кичкән дәрвишкә әйләнә, көне-төне үзен борчыган уй-фикердән һич кенә дә арына алмый. Хәер, иҗат кешесенең халәте һәркайсыбызга аңлашылса кирәк: шунсыз уңышка ирешү мөмкин түгел. Әнә шулай эзләнә-уйлый торгач, вак-вак детальләренә чаклы игътибар белән сурәтли-яза торгач, рәссамның этюднигында олы бер картина пәйда була. Төсләр гаять уңышлы сайланган, тарихи вакыйганың нәкъ шулай булганлыгына ышандыру-дәлилләү өчен хезмәт итә. Киндернең өске өлеше XVIII йөздә барча җиһанны дер селкеткән шәхескә бирелгән — Батый хан түрдә, алтын-мәрҗән белән бизәлгән зиннәтле тәхеттә утыра. Кыяфәтенә караганда, Чивилихинның эссе-романында күрсәтелгән дармансыз мәхлукка бер дә охшамаган — көчле вә гайрәтле, үткен күзләрен сиңа төбәгән, кулында бизәкле таяк: ачуын китерсәң, хәзер барабанга сугып ала да, җан сакчылары өстенә ябырыла. Ханның пәһлеван икәнлеген исбатлаучы янә бер деталь: рәссам Батый ханның холкын-гадәтен аеруча басым ясап тасвирлау максатыннан чыгып, тәхет артына ханның атын бастырып куя. Иярле ак ат. Сикереп атлан да яу чап. Әнә шундый олпатлы-гайрәтле олуг ханга баш ияргә яшь-яшь урыс кенәзе Александр Невский килгән, тәхет каршында тез чүгеп тора. Аның үз язмышы да, илнең язмышы да менә хәзер хәл ителәчәк. Олуг хан, бик яшь димәсә, алып килгән күчтәнәч-бүләкләрен кулай күреп кабул кылса, ни әйтерсең...

Әнә генә күчтәнәч-бүләкләре. Автор аларны, миниатюра алымына таянып, алгы планда тәфсилләп бирүгә ирешкән: берәү мәйданда аю биетә; икенчесе мичкәдән чүмеч белән аракы өләшә; өченчесе аулаграк почмакта җарияләрен чит-ят күздән саклый.

Миниатюра алымын рәссамның беренче генә куллануы түгел инде бу. Әгәр дә рәссам без кече яшьтән күнеккән, дистәләрчә еллар буена алга сөрелгән, макталган реалистик алым белән эшләвен дәвам иттерсә, әлбәттә, персонажларын тәгаенрәк, ачыграк иттереп сурәтләү белән чикләнер иде. Бүгенге авыл эшчәннәренең, шәһәр гүзәлләренең портретларын яки табигатьнең берәр мизгелен язганда, һичшиксез, төгәллеккә омтыла, объектны дөрес чагылдырырга тырыша. Ә инде тарихи материалны реалистик планда тасвирлап караганнан соң, үзе үк канәгатьсезлек белдерә. «Ничек инде ул борынгыларны бүген дөнья көтүчеләр төсле иттереп ясыйсың?» — ди ул үз-үзенә. Һәм Ташкентта укып кайтуы, андагы рәссамнарның Европа кануннарына буйсынмаулары, шуннан алган тәэссорат Нәфыйковны бөтенләй икенче юл сайлауга этәрә. Иң әүвәл, мәсьәләне искечә, тапталган юлдан барып кына хәл итә алмаячагына үзе инана. Безнең бабайлар бит Шәрык белән күбрәк эш иткәннәр, димәк ки аларны гәүдәләндергәндә, һичшиксез, Шәрык сәнгате алымнарына мөрәҗәгать итү кулай булыр, дип фикер йөртә.



*Китап сүзе. (1992 ел)*

Бу алым белән эш иткәндә Хәнәфи бөек француз рәссамы Һенри Матисс юлына баса — игътибар үзәгенә төсләрнең үзара бәйләнешын, аларның бере белән бере чарпалашуын куя. Ләкин яңача яза башлау рәссамга авыр бирелә, эзләнүләре озакка сузыла. Әйтик, Матиссның шактый әсәре («Гарәп каһвәханәсе», «Әңгәмә», «Музыка дәресе», «Бию» һ.б.) гомумән, шартлы рәвештә, контурлар белән генә бирелгән. Шуларга карап, тамашачы персонажларны тәгаен күзаллый. Даһи рәссам примитивизмга ук барып җитми җитүен, аның рәсем ясап чыныккан кулы форманы әнә шул контурларга карап та шәйләрлек итеп бирә, тик инде кешенең авыз-борынын, кашын-күзен мөмкин кадәр төгәлрәк тасвирлауны үзенә максат итеп куймый, төсләрнең берләшен генә алга сөрә.

Әйе, Хәнәфи Нәфыйковның миниатюра алымы белән язган киндерләре иман нуры белән балкый, матур вә камил, милли сынлы сәнгатебезнең Алтын Фондына кереп калачак чын иҗат җимешләре. Ә инде рәссамның әнә шулай, реализм элементларын да кертеп, төсләргә басым ясавы, ихтимал, монарчы беркемдә очрамаган, фәкать аңа гына хас яңа ысул китереп чыгарыр.

Һәрхәлдә, сәнгать фәннәре докторы Рафаэль Такташ Үзбәкстаннан кайткан чагында моны бик тиз шәйләп ала. Бөтендөнья татар конгрессы уңае белән оешкан күргәзмәдә Нәфыйковның картиналарын күргәч:

— Хәнәфи, син вакытны бушка уздырмагансың! — дип сөенә һәм авторны кочаклап үбә.

Гадәттә, борынгы заманны телгә алганда, һәркем сәясәтне, төрле сугыш хәлләрен күздә тотучан. Рәссам Нәфыйков исә мәдәният әһелләренә махсус картиналар багышлый, аларның образларын гәүдәләндерә: «Мөхәммәдьяр» (1978), «Чичән» (1982), «Шиһабетдин Мәрҗани» (1986), «Бакый Урманче» (1986), «Тукай чәчәге» (1987), «Габдерәхим Утыз Имәни» (1987), «Акмулланың соңгы төне» (1988), «Кол Гали» (1990) һ.б.

Күргәзмәдә без һәр картинаны әзер хәлендә генә күрергә гадәтләнгәнбез. Ә бит аларның берсе дә тиз генә язылмый. Бүгенге көндә, әйтик, Хәнәфи татар халкының күркәм бер сыйфатын — китапка булган мөнәсәбәтен, борын-борыннан килгән гадәтен өч киндердә чагылдыру нияте белән яши. Триптихның сул канатына «Китап сүзе» дигән исем биреп, анда хәзрәтнең китап укыганын тыңлап утыручы ир-ат мәҗлесен гәүдәләндерә; уң канатын «Фал ачу» дип атый һәм борынгы авыл өенә җыелган хатын-кызларны тасвирлый; уртадагы картинада китапны оста вә матур итеп күчереп язучыны сурәтли һәм «Хәттат» дигән исем бирә. Озаклап уйлый торгач, композициясен дә таба инде югыйсә. Мәгәр әле шуннан соң да миниатюра алымы кушканча төсләрнең бер-беренә тәңгәл килеп торуына ирешү өчен шактый озак баш вата. Остаханәсенә соңгы баруымда рәссам әле эшен дәвам итә иде. Читкәрәк китеп, кырыс кына бер күз ташлады да:

— Музыкасы табылды бугай инде. Хәзер поэзия белән ямьләндерәсе иде менә!.. — диде.

Укучы, әлбәттә, журналның тышлыгында урын алган «Чичәннәр ярышы» дигән картинага игътибар иткәндер. Бу әсәрен Хәнәфи Нәфыйков 1978 елда иҗат итә. Күпне укыган зыялы буларак, ул халкыбызның борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешен аермачык күз алдына китерә һәм әнә шуны бүгенге тамашачыларга да тасвирлап бирү нияте күңеленә кереп урнаша.

Вакыйганы сурәтләү өчен рәссам Казан каласы янындагы болынны ала. Шунда иң түргә ханның тәхетен ясап куя, ул тәхеткә ханның үзен, аның янына ханбикәсен утырта. Болынга җыелган халык зур түгәрәк хасил итеп аларның ике ягына тезелгән. Ләкин игътибар үзәгендә — мәйданның ике ягына чыгып баскан ике чичән. Шулар бәйге тота: коралсыз-нисез генә алышалар, акыл зирәклеген, фикер йөгереклеген исбатлау максаты белән кара-каршы бер беренә шигырь әйтешәләр. Шигырь әйтешүнең күпмегә сузыласын берәү дә белми. Тизрәк фикер йөртүче, үткенрәк-гыйбрәтлерәк шигырь чыгарып, тегесен өнсез-җавапсыз калдырганы җиңеп чыгачак. Аны тамашачылар алкышлап, хан исә үз кулы белән бүләген бирәчәк.

Әлеге картинага карап без борынгы бабаларыбызның әнә шулай мәйданга җыелышып, телебезнең кодрәтенә вә байлыгына соклануын, шигъри сүзнең көенмоңын ишетеп ләззәтләнүен күз алдына китерәбез. Әдәпле вә инсафлы халыкның җир эшеннән, мал-туар караудан, төрле һөнәрдә бил бөгүдән азмы-күпме ял итүенә, иң әһәмиятлесе — шигъри сүздән тәм табуына ышанабыз. Тарихны өйрәнеп, безнең әби-бабаларыбызга зур хөрмәт белән язылган шушы нурлы әсәр күңелләребездә изге хисләр уята, шигърияткә мәхәббәтебезне арттыра. Тамашачыны ышандырырлык, аның күңеленә хуш килерлек, җанына җылы өрерлек, уйланырга җим бирерлек сәнгать әсәре иҗат иткән икән, димәк ки рәссам үзенең олуг максатына ирешкән дигән сүз.

Әнә шул рәвешле, халыкка тугрылыклы, фидакяр хезмәт күрсәтүенә рухланып, рәссам Хәнәфи Нәфыйков татарның шанлы тарихын тагы да ныклабрак өйрәнә, береннән-бере гүзәлрәк вә камилрәк картиналар иҗат итә.

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**

Китап күзәтү

# ХӘТЕР ТӘРӘЗӘЛӘРЕ

Гаять тә авыр, катлаулы заманда яшибез. Кануннар үзгәрә, фикерләр үзгәрә, кешеләр дә бик тиз үзгәрәләр. Хәтта иртәгә дөньяның, илнең-көннең нинди буласын әйтеп бирү читен.

Менә шундый вакытта язучылар җиде юл чатында басып кала. «Социалистик реализм» кануннарын яхшы үзләштергән өлкән буын әдипләргә никадәр авыр икәнен күз алдына китерәм. Җитмеш ел буе бер төрле идеологиягә буйсынып яз, яз да, инде килеп ул идеяләрнең дә бик үк дөрес түгеллеге ачыклансын — бик тә кызганыч хәл бит бу! Дөрес, рус әдәбиятында А. Солженицын, В. Шаламов, В. Аксенов, В. Быков кебек үз иманнарына хыянәт итмәүчеләр булган. Бездә дә бар андыйлар. Әйтик, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗев кебек, партия рамкаларына сыеша алмаган әдипләр, теге елларда ук намуслары кушканча язганнар. Моның өчен күпме кыен ашаганнар, әмма башкача язуга күчмәгәннәр. Көлке дә, кызганыч та заманнар булган инде: «әсәрләреңдә уңай геройлар юк» дип күренекле әдибебез Әмирхан Еникины сүксеннәр, имеш...

Яшь язучы Вахит Имамовның «Күке» повестында бер генә төп герой да уңай түгел. Беренче карашка, әсәрдә мәңгелек тема — мәхәббәт өчпочмагы, ягъни гаиләсен ташлап икенче хатынга йортка кергән ир — «күке» турында сүз барса да, повестьтагы төп лейтмотив — ул да булса: бүгенге мәктәп тормышы, мәгариф системасы. Монда бүгенге «кода-кодагыйлык», әшнәлек, «көчленеке — замана» принцибы бик ачык күренә. Дөресен әйтергә кирәк, автор укытучылар тормышын, алар арасындагы каршылыкларны оста итеп ачып биргән. Болар — М. Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романындагы романтик укытучылар плеядасыннан түгел. Шулай шул — замана үзгә, чор башка.

Повестьта әллә ни көч куймыйча гына укыта торганнарның, өстәгеләргә ялагайлана белүчеләрнең ничек итеп мактаулы исемнәр алуы ышандырырлык итеп тасвирлана.

Намуслы, тырыш һәм үз укучыларында гаделлек, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләүче укытучылар мине гафу итсеннәр: алдарак әйтеп кителгән начар сыйфатлар шактый күренә башлады укытучылар арасында. Әмма бу — алар гаебе түгел, ә замана чире. Әйе, җәмгыятьтәге тискәре күренешләр киләчәк буынны тәрбияләүчеләр арасына да үтеп керде. Әнә, повестьтагы Зайцев дигән акыллы, принципиаль укытучыны да бөгә ул система, аны мескен дәрәҗәсенә калдыра.

Повестьта автор күтәргән тагын бер зур проблеманы әйтеп китәргә кирәк. Ул — җәмгыятьтә шактый гына югары урын тоткан кешенең мораль яктан таркала баруы, аның җансыз робот хәленә төшүе. Үзенең әйтер сүзе булмаган, флюгер кебек теге якка да, бу якка да борылучылар күбәйде тормышта. Әсәрнең төп герое Якуб Мортазин образында бу бик ачык чагыла.

Аның үз хатынын, балаларын ташлап икенче хатынга йортка керүен аңлап була, тик аклап булмый. «Педагог» Мортазин шуннан соң малайлары язмышы белән кызыксынмый да диярлек, өенә дә хатыны үлгәч кенә кайтып килә. Капма-каршы образ буларак, аның олы улы Илдарны китерергә була. Әмма автор бу образны тулысынча ачып бетермәгән дияр идем. Аның әтисенә охшамаган холык-фигыле дә өстән-өстән генә күрсәтелә. Ләкин үзсүзле бу егетнең тормышта үз урынын табарына ышанырга була.

Әсәрнең теленә килгәндә, авторның бер кимчелеге әсәрне укый башлагач та күзгә ташлана. Эш шунда ки, аның бөтен геройлары да диярлек филолог яисә галим кебек гел тәгъбирләр, мәкальләр кыстырып кына сөйләшергә яраталар. Менә бер генә өзекне карап китик.

«И очсыз да соң ир-ат, мескен,— дип үзалдына ачынып сөйләнде ул.— Яна итәк очы күргән идем, бәхет кошы тоткан мосафир кебек, баш югалттым. Күрше тавыгы һәрчак күркә булып күренә инде ул, аның ние гажәп? Калдык күмергә кабат ут кабынмый, әйдә, тиле булма. Хыялында аргамаклык яши диеп кенә йөк атларын беркайчан да тәртә арасыннан сөйрәп чыгармыйлар». Болай итеп, әсәрнең герое түгел, автор уйлый, безнеңчә. Һәм ул үз фикерен геройларына да китереп тага.

Вахит Имамовның «Нәзер» дигән китабына кергән шул исемдәге повесть бер гаилә язмышын гына чагылдырса да, дүрт-биш дистә еллардагы вакыйгаларны үз эченә ала. Бу яктан карағанда Хәйдәр язмышы аеруча гыйбрәтле. Сугышка кадәр туып, шул елларның авырлыгын күргән яшүсмер, колхоз сарыгын урлап суюда гаепләнеп, төрмәгә эләгә. Аннан чыгып күп тә үтми, нахакка гаепләп тагын утырталар. Дөрес, бу юлы чын жинаятьчене тотканчы — ягъни биш «кенә» ел утыра, әмма авылга кайтып төшкәндә инде ул ир уртасын узган кеше була.

Авылда да көтеп торучысы юк: әтиәнисе үлгән, нигез исән дә, иске йорт тора. Абыйсы Миңнехан күптән инде үз нигезен корган. Алай гына да түгел, Хәйдәрнең яшьли сөеп йөргән кызы Зөбәйдәне үзенең хатыны иткән һәм балалар үстереп яталар. Ихаталарына, бакчаларына керсәң, әйләнеп чыкмалы түгел. Нәкъ элекке кулак инде менә!

Әмма шушы урында автор белән бераз бәхәскә керәсе килә. Утызынчы елларда без таза хәлле крестьяннарны — илне туйдыручыларны кулак диеп Себергә сөрдек. Сугыштан соңгы елларда да эшчән, тырыш кешеләргә авыл жирендә яшәргә ирек бирмәделәр — йә бакчаларын кистеләр, йә терлек санын киметтерделәр. Мондый сәясәтнең нәтижәсе күз алдында: күпләр шәһәргә китеп төпләнде, авылларда эшләргә кеше дә калмый башлады. Хәзер кайберәүләр бик кайтырлар иде дә — буыннар өзек, юллар киселгән...

В. Имамов Миңнеханны әнә шулай авылның кулагы кыяфәтендә тасвирлый. Укучыда аңа карата нәфрәт уятырга тырыша. Дөрес, мораль яктан бераз каралтып, кырыс, саран кеше итеп күрсәтеп үз максатына бераз ирешә дә ул. Әмма мин үзем, мәсәлән, әнә шундый эшчән кешеләр яклы. Алар — авылның киләчәге, дип саныйм. Бу очракта автор андыйларга карата совет чорында яшәп килгән караштан, психологиядән генә арына алмаган, дип фаразлыйм.

Ярар, Хәйдәр авылга кайтып төште бит әле. Ул ни эшләргә тиеш иде соң? Йорт-жирне аякка бастырасы килгән кеше «шабашка»га чыгып китәргә яисә колхозныкын урлап яшәргә тиеш иде кебек. Тик ул бүтән юлны сайлый — буш яткан урында бакча үстерә башлый. Үзенә бер тиен дә алмыйча, бүтәннәргә булсын дип тырыша. Югыйсә, ничә ел төрмәләрдә яткан кеше күңелендә жәмгыятькә, кешеләргә карата гел әшәкелек кенә булырга тиеш иде бит. Менә шушында инде автор ике туганны чәкәләштерә. Халык Хәйдәрне ярата башлагач, ягъни ул абыйсы Миңнеханның «тамагына сөяк булып» тыгылгач, Миңнехан түзми, төнлә бакчадагы алмагачларны кисеп чыга!..

Повестьта Хәйдәр-Зөләйха мөнәсәбәтләренә дә шактый зур урын бирелгән. Зөләйха Миңнехан белән яшәсә дә, гел Хәйдәрне уйлап яши, күңеле белән гел аның янында. Минемчә, әгәр автор соңыннан аларны кавыштырса, бу хәл дөреслеккә күбрәк туры килер иде. Дөрес, монысы — аның үз эше, үз фантазиясе. Мин бу очракта авторны аңлыйм. Татар хатынының элек-электән килгән тыйнаклыгы, иргә буйсынучанлыгы кебек сыйфатларга хыянәт итмәвен күрсәтергә теләгәндер ул.

Гомумән, бу повесть күңелдә жылы тәэсир калдыра һәм яшь язучыга карата зур өметләр уята.

Ләкин әсәрдә әле ышандырып бетерми торган урыннар да бар. Мәсәлән, ике бертуган — Миңнехан белән Хәйдәр арасындагы мөнәсәбәтләрне, тагын алар арасында торган Зөләйханы, һәрнәрсәдә акча күрә торган Миңнеханны аңларга була, тик Хәйдәрнең бушка бакча үстереп йөрүен ныграк мотивлаштырасы бар, кебек. Әсәрнең бу өлеше бераз ясалмарак килеп чыккан төсле. Дөньяда бәлки андый «жүләрләр» дә бардыр, жирне шулар тотып тора, ди бит бер гыйлем иясе. Ләкин шулай да яшь язучыга чама хисен югалтмаска кирәктер.

Хикәяләргә килсәк, бирердә бигрәк тә «Табылдык» хикәясе характерлы. Ул болай башланып китә: «Авыл советына кечкенә сабыйны житәкләгән бер ир килеп керде. Бу кешенең халык телендәге кушаматы «Жансыз Тимер» иде. Хәзер дә кушаматына хыйлаф адым ясыйм әле диде бугай, ул кан өшеткеч салкын итеп әйтте:

— Артык бала таптым, кем ала?»

Шушы өч-дүрт жөмләдә дә автор укучыга шактый күп мәгълүмат биреп өлгерә. Гомумән, В. Имамов укучы күңелендә нәфрәт уятырлык кеше турында язса да, аны каралтырга тырыш-

мый, шуңа да андыйлар тора-бара хәтта кызгандыра да башлый. Автор геройларның холкын әкрен-әкрен генә ача. «Нәзер» повестындагы Хәйдәр, Зөләйха, Миңнехан образлары менә шул хакта сөйли.

Һәрхәлдә, авторның «Кәнәфи» һәм «Сәет батыр» дигән тарихи әсәрен укыгач, мин моңа тагын бер кат ышандым. Аларның беренчесе «Аргамак» журналында, икенчесе өлешчә «Шәһри Казан» газетасында басылып чыкты. Кайбер очракларда геройларын артык акыллы итүен санамаганда, бу әсәрләр дә язучының осталыгы үсә баруын күрсәтәләр. Иң мөһиме, Вахит Имамов заманыбызга хас күренешләрне вакытында тотып ала белә. Әйтик, Уфа предприятиеләренең берсеннән елгага фенол кебек агулы матдә агу, аның Камага да килеп житүе турында безнең матбугат шактый шаулады. Чыннан да, чаң кагарлык вакыйга бит! Ә Вахит Имамов аны инде повестында чагылдыруга ирешкән. Автор анда бу фажигагә китергән сәбәпләрне, калын ишекләр артында барган хәлләрне кыю ачып сала.

Уйлап карасаң, безнең тормышыбыз хәтер тәрәзәләреннән тора... Әдипләрнең максаты әдәби геройлар аша шуларны ак кәгазьдә теркәп калдыру. Әдәбиятка талантлы язучы кирәк, дип сөенеч аласым килә. Аның хәтер тәрәзәләрен ачып күрсәткән әсәрләрен укып, без күп тапкырлар сөенербез әле.

**Атлас ГАФИЯТОВ.**

# ЯЛГЫЗЛЫКТАН — ХАЛЫККА, ХАКЛЫККА!

Тукай, күпме каһәрләнгән патша заманында 27 ел гына яшәп тә, 33 китап чыгарырга өлгергән! Бу 1907 елның 15 ноябреннән алып 1912 елның 30 декабренә кадәр арада. Ягъни, нибары биш ел эчендә! Ә Эдуард Мостафин, дөньяда 47 ел яшәп, нибары өч кенә китап чыгарган.

Өч һәм утыз өч...

Аерма бик тә зур бит бу саннарда!

Дөрес, монда Тукай белән Мостафин арасында нинди дә булса чагыштыру китерү әдәпсезлек тә кебек, әмма бу аларның шагыйрьлек дәрәжәсен яисә халык алдындагы рольләрен билгеләү максатында түгел, ә «элек һәм хәзер» тәгъбиренә яңача караш кына. Һәм, сүз уңаеннан, уйлау өчен бер фикер: биш ел эчендә шуның кадәр китап чыгарган Тукай аларның килереннән тамак туйдыра алган, ә хәзерге биш-ун китап чыгаручылар ерак китә аламы соң?

Эдуард Мостафин алтмышынчы елларның урталарында ук шагыйрь булып танылган иде. Үз яшьтәшләре генә түгел, татар поэзиясенең Нури Арсланов кебек аксакалы аны, 1968 елны Казан радиосы аша чыгыш ясаганда, «иң өметле яшьләрнең берсе», дип атап киткән иде. Казан университетында һәм Мәскәүдә Әдәбият институтында укыганда да шагыйрь Эдуард Мостафин дигән кешенең шигырьләренә ихтирам белән карау, аның, һичшиксез, талант иясе икәнен тану бар иде. Әмма ул беренче китабына бик урау юллар белән килде. Бары тик 1979 елны гына басылып чыкты аның тәүге шигырьләр җыентыгы. «Елның бишенче фасылы» дип аталган ул китап дөнья күргәндә шагыйрьгә 35 яшь иде инде.

Кадер юк талантларга! Элек тә, хәзер дә... Бигрәк тә хәзер!

Тагын... Аның язганнары да шул чорда Суслов җитәкләгән идеологиягә туры килми иде. Ник күтәрсеннәр ди андый темага язган шагыйрьләрне?! Ул бит «коммунизм җырын» җырламый, ул бит «кирәкмәгән әллә нәрсәләр» турында яза. Җитмәсә сукбай, теләсә кайда эшләп-яшәп йөри. Партиядә дә әгъза түгел...

Чыннан да, 1945 елны Башкортстанның Краснокама районы Касево авылында туып, Сауз авылында үскән Эдуард Госман улы Мостафин урта мәктәпне тәмамлауга үк ил гизәргә чыга. Күңелендә яткан шагыйрьлек жене, шигърият ташы дөнья йөрергә кушкан аңа. Чөнки тик яткан таш мүкләнә, ә йөргәне шомара:

*Яшьлек,*
*Аллаһ да юк әле, диней дә.*
*Язларыңны ташлап китеп бардың:*
*— Иман җыйгач кайтам,— диден дә...*

Шагыйрь үз алдына зур максат куйган: Иман җыю!

Эдуард Игаркада була. Урта Азия һәм Уралда төрле жирләр, төрле шәһәрләр гизә. Төрле эшләрдә эшли. Әмма кешеләр һәм дөнья белән танышу башында ук ул бер нәрсәне аңлый, тоя, күрә: дөреслек дигән нәрсә юк икән бит. Әллә ул башка төскә кереп яшеренгәнме? Дөреслек юкта ышаныч та юк:

*Ышанычың булмый икән —*
*Тормыш кон дә кыямәт.*

Әнә шулай, матур дөньяга яхшылыклар эзләп чыгып киткән шагыйрь алдана һәм аның садә хыяллары челпәрәмә килә. Иң беренче эш итеп ул аларның ватыкларын җыя. Алдану ватыкларын. Ул ватыклар жанында эретелеп, кәгазь битенә канлы-яшьле юллар булып тамалар:

*Адаштыммы, саташтыммы соң әллә*
*мин,*
*Нигә әле искә төшә күргән төшләр?*
*Үз җиребез, үз күгебез!*
*Яшәү өчен*
*Кирәк, әлбәт, матур эшләр,*
*Үткен тешләр.*

Матур эшләр өчен «үткен тешләр» дә кирәклеген аңлый шагыйрь, чөнки дөнья катлаулы, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрендә алдау, сату, икейөзлелек, хәттә явызлык дигән нәрсәләр дә бар. Менә шунда ул «чәчәкле каләм»ен ташлап, утлы-бозлы-сагышлы каләмен кулга ала. Утлы каләм бигрәк тә аның «Ут. Кәгазь. Каләм» исемле 1992 елда чыккан соңгы җыентыгында ачык күренә:

*Утым яна. Алда — кәгазь,*
*Кулда — каләм... Ни языйм?*
*Төнгә керәм бер ялгызым —*
*Уйларым бимазалый.*

Һәр кешенең үзенчә җыры булган кебек, һәр шагыйрьнең үзе генә яратып язган темасы бар. Сугыш елларында дөньяга килгән Фәйзуллин-Гатауллиннар буынының да, алардан соңрак туган Зөлфәт-Әгъләм-Мостафиннарның да. Хәтта биш-ун еллар гына элек поэзия сараеның ишеген ачып кергәннәрнең дә.

Эдуардка килгәндә, ул — эт-мәчеләр һәм ялгызлык шагыйре. Эт-мәчеләр? Ә нишләп эт-мәчеләр? Шагыйрь жаны икенче бер жанга сыена. Җанны жан тарта. Кеше жанына гына түгел, ә хайваннар жанына да. Кеше алдарга-алдашырга мөмкин, ә хайваннар — юк. Шул яклары белән алар, бәлки, шагыйрь күңеленә якындыр да:

*Ак көчекләр килә ак дөньяга,*
*Күбәләкләр зәңгәр канатлы...*

Әмма бу көчекләр дә бүреләр арасында икән бит:

*Бүреләрдән аралап бир миңа*
*Күбәләкләр куган көчекне!*

Ә бит бу ак көчек — шагыйрьнең жаныдыр шикелле миңа...

Шагыйрь жаны — ялгыз. Ул үзе кебек алдауны белмәүче, тугры һәм гадел жанны эзли. Ул бар, әлбәттә! Аны табарга гына кирәк. Ә чит жирләрдә ялгызлык бигрәк тә нык сизелә:

*Мин таныдым монда үксезлекне,*
*Ялгызлыкның сары сагышын.*

Гомере көзенә дә шагыйрь ялгыз кертә:

*Бер ялгызым керәм Сентябрьгә:*
*Туң баланнар яна таң булып.*

Аның мәхәббәте дә сагышлы:

*Соңгы көзе бу көз — мәхәббәтнең*
*һәм үксез үксез күңелнең.*
*Скрипка моңы, хыялларның*
*Сары көзе булып түгелдең.*

Эдуард Мостафин — төн шагыйре, төннән яктылык эзләүче. Шигырьләре дә төнлә языла, ул үзенең жанын күбрәк төнлә тыңлый. Ә Җаны, Рухы — моңлы, сагышлы... Көндезен дә, төнлә дә:

*Бу төн — минем дөньям.*
*Мин яраткан*
*Зәңгәр төнле, йолдыз күзле кәләш.*
*Бу төн — минем җылы учларыма*

*Өзелергә әзер авыр тәлгәш.*
*Бу төн — минем бәйге, минем ирек.*
*Минем елга ага, йөзеп китик.*
*Шушы төндә барлык көймәләрне*
*Чишеп,*
*Чылбырыннан азат итик.*

Эдуард күңелле җан иясе һәм бу аның иҗатында ачык күренә. Ул кимсетелү, рәнҗетелүләргә каршы. Дөньядагы бер генә җан иясен дә рәнҗетмәскә кирәк! Аның шигырьләрендә әнә шул хис, теләк дөрли. Утлы каләменнән төшкән юллар дөрли:

*Кошлар очсын биекләрдә,*
*Чапсын болан киңлекләрдә.*
*Балык йөзсен үз суында,*
*Һәр киек тә бирсен тавыш.*
*И табигать, кеше җаны,*
*Рухы өчен нинди табыш!*

Ә шагыйрь һаман яза, әйтеп калырга тырыша:

*Яза-яза хатыныннан,*
*Акылыннан язды ул.*

Әйе, шагыйрь хатыннан да язарга мөмкин. Әмма дөньяда иң авыры — бу да түгел. Яңа хатын, юлдаш табарга була. Дөньяда иң авыры дусларсыз калу да түгел — яңа дуслар табарга була. Дөньяда иң авыры — ничә миллиард кеше яшәгән җирдә бер ялгызың калу. Аһ, ул ялгызлык!

Ә икенче... язу — «акылдан язу» — шагыйрьнең һәрвакыт күпмедер «тилемсә», «юләр»рәк булуына ым. Ләкин шунсыз шигырь дә тумый бит. Шигырь тусын өчен шагыйрь җанында ут булырга тиеш. Әнә шуның яктысы, балкышлары, сихерле-серле сүзләр булып, кәгазьгә төшә. Каләм аша. Һәм кәгазь терелеп китә, кәгазь җанлана. Чөнки аның өстендә теп-тере Шигырь ята. Яңа туган бала кебек. Хатын-кыз баланы тәне белән тудырса, шагыйрь үз баласын җаны белән тудыра. Ул да — тудыручы. Әмма яңа туган бу балага йөз яшь тә, мең яшь тә булырга мөмкин. Чөнки шигырь меңьеллык яшәеш тәҗрибәсен үз аңына сеңдергән, җанына орлык төшкән шагыйрьдән туган.

Бар шагыйрьләр — тормышның чәчәген генә күрәләр һәм аңа дан җырлыйлар. Җырласыннар, андыйлар да кирәк. Күңел көрлеге, оптимизм өчен! Матур ич!

Бар шагыйрьләр — тормышның төбен, ачы тамырларын күрәләр һәм шул турыда сөйлиләр. Хәтта елыйлар. Еласыннар, андыйлар да кирәк. Гыйбрәт өчен. Уйлану өчен. Андыйлар шигъриятe дә ямьсез түгел! Поэзия ямьсез була алмый.

Эдуард Мостафин да ялгызлык, караңгы төн, сагыш-үкенечләр шагыйре. Дөньяның үксез баласы. Бу яктан күпмедер Тукайга охшаган ул. Ә мондый охшашлык кимсенү тудырмый. Андый шагыйрьләр күңеленә фани дөньяның бар ачысы җыела. Алар, лакмус кәгазе сыман, тормыш төсләрен төгәлрәк күрсәтәләр. Алар — җәмгыять барометры, алар социаль хәлләрнең мөшкеллеген, кеше җанындагы борчулы хисләрне, депрессия күренешләрен экспрессив рәвештә яктырталар. Әмма мондый шагыйрьләр яшәүгә кул селтәмиләр. Аларда яшәү теләге ифрат көчле:

*Эт кебек шыңшыйсы килә.*
*Бүре сымак улыйсы.*
*Нигә әле кеше булып*
*Уйлыйсы да уйлыйсы?..*
*...Килә шулчак кешеләрдәй*
*Елыйсы да көләсе.*

*Килми бер дә үләсе.*

Соңгы китабында шагыйрь Эдуард Мостафин халыкка һәм туган телгә нык якынайды гына түгел, ә килеп үк сыенды. Ялгыз шагыйрь үзен халык кочагында итеп тойды, ә халкы булмаган шагыйрь шагыйрь түгел инде. Ләкин ул халкына да аз гына кинаябелән килә:

*Ә корабың кайда? Шуны эзлә!*
*Җитте!*
*Башкаларның көен көйләмә!*

Дәрдемәндләр «корабы» хакында сүз бара. Вакыт океанында халыкны алып барган кораб турында. Туган телебез фаҗигасен ачык һәм тирән тоя шагыйрь:

*Сүзләр дә, вөҗдан шикелле,*
*Кыйнала икән, туган.*
*Телем җәүһәре — сүзләрнең*
*Күпмеләре туралган!..*
*Кыйналган «дини» булганга,*
*Артык милли булганга.*

«Чулман төбәге» этюдлары һәм «Мин бәләкәй чакларда» поэмасында да халык һәм хаклык мәсьәләләре күтәрелә. Шагыйрь үз иманына нык ышана: Җирдә матурлык булсын өчен, Җирдә яхшылык булсын өчен Хак-Дөреслек тантана итәргә тиеш. Әгәр ул юк икән — матурлык та, яхшылык та булмаячак! Шуңа да дөреслекне эзләргә,

табарга һәм ул хакта әйтергә кирәк. Бергәләп эзләргә!

Иң мөһиме: Дөреслекне эзләү дәвам итә. Бу эзләү ялгышлар аша бара, чөнки хатасыз юл юк. Шагыйрь Э. Мостафин, дөньяга үпкәләп, дөреслекне үзе генә, ялгыз гына эзләп тә карады. Һәм ул үз алдына куйган максатына күпмедер иреште, тәҗрибә алды: Иман җыйды! Иманлы булды!

Бу — халкына якынаю иманы. Аның бүгенгесе, киләчәге өчен борчылу гамьнәре. Шуның өчен яшәү. Эзләнсен татар шагыйре, эзләнсен аның Җаны! Аның эзләнүе, тормыш төпләренә төшә-төшә нидер актарынуы да кирәк. Тик кенә тормасын бу Җан! Чөнки анда, чылбырларын чыңлатып, 440 еллык Коллык Хисе дә утыра. Аз гына куркушурләү иңдеме, әлеге хис баш калкыта башларга мөмкин. Ә бу — хәтәр! Бу — шагыйрьләр юлы түгел!

Бездән һаман тарлык, мескенлек чыгып бетмәгән әле. Талантлы милләт улларын үстерү, башкаларга күрсәтү түгел, үз халкың арасында популярлаштыру да ифрат дәрәҗәдә начар куелган. Бездә, мактаучыларга караганда, тукмаучылар күбрәк түгел микән әле...

Илле яшенә якынлашып килүче Эдуард Мостафин да, ниһаять, үз бәясен алырга тиештер. Үзе әйтмешли:

*Үлеп карау кирәк микән*
*Чамаларга кем икәнең?*
*Исән чакта белү кыйммәт*
*Ни тартканың, ни җиккәнең!*

**Рафаэль ХУҖИН.**

# МОҢ ӨЧЕН РӘХМӘТ БЕЛӘН

ИЛДАР ЮЗЕЕВКА 60 ЯШЬ ТУЛУ УҢАЕННАН БЕР ЛИРИК СӘХИФӘ



Моңга битараф йөрәкләр бар микән татарда? Юктыр, мөгаен... Әгәр дә ул нәкъ менә халкымның үзеннән булып, якты, уйчан, шул ук вакытта яшьлеккә хас көчле, дәртле, димәк һәр күңелгә якын, кадерле моң булса... Шигърияттә дә шулай ахрысы: күпме шагыйрь сине җәлеп итә, күпме мавыгулар була, исемнәр, төрле калыплар, алымнар белән җенләнәсең,— ахырда барыбер үзенә якын, яшьтән үк күңелгә үтеп кергән нигезгә — моңга кайтасың. Җанны уяткан хисләрне, гади, әмма халыкчан, тормышчан фикерләрне танып, үз итеп куанасың, тагын тыңлыйсың, туймыйсың. Карасаң, ул синең яшьлегеңнең генә түгел, гомереңнең дә юлдашы икән. Инде илле яшеңне узып китсәң дә, бала кебек әсәрләнеп, беренче кичерешләреңә кайтасың, аларга тугрылыгыңны тоясың. Шулай булмыйча, Моң бит ул, Шигырь бит ул!

...Илленче еллар уртасында, инде бала күңеленә дә сизелгән бертөсле, бер калыплы, моңсыз, тәмсез, әзер җаваплы, күпсүзле, ялган пафослы «шигырь» уратмасын җимереп, безнең Марс шикелле тын авылларга, яшь йөрәкләргә дә саф сулышлы җилләр үтеп керде... Кара әле, Такташ кебек үк ихлас, чын шигърилек, табигыйлек, бай күңел дөньялы яңа шагыйрьләр дә бар икән дип, «ах» иттек без. Моң тылсымы, җыр, шигырь көче әсир итте безне. Бу — яшь шагыйрь Илдар Юзеевның «Резидәкәй» җыры, «Таныш моңнар» поэмасы, шул исемдәге китап белән очрашуыбыз иде. Китапта — шагыйрь сурәте, уйчан, мөлаем йөз, шагыйранә сибелгән озын чәчләр... әле без ачыклап әйтә алмасак та, күңел белән сизенгән сыйфаты — зыялылык, затлылык төсе... Юк, беренче күрү, тәэсирләр алдамый бугай — хис аңа тугры калачак... Башка поэмаларын да — «Тормыш җиңә», «Фәрит-Фәридә», «Әнкәйләр»не дә яраттык. Алар да без омтылган романтика, янар яшьлек, саф йөрәк, мәхәббәт турында. Бу — безнең шагыйрь, шиксез, безнең моң иде. Инде Казанга килгәч, бик ерак һәм серле күренгән шагыйрьләр, әдипләр мохите белән танышкач та бу тәэсир алдамады. Без моңның дәвамлы агышының, сикәлтәле, бормалы юлларының шаһиты да булдык. Шигырьләрдән бигрәк, иркен сулышлы поэмалар, өзелмәгән кыллар яңгырашы үсә, тирәнәя, катлаулана барды. Үзгәрә, хәтта проза-публицистика ярларына да кереп аккандай, кырысланып, күләмлерәк поэмаларга күчте: «Тынлык белән сөйләшү», (1964), «Соңгы сынау» (1968), «Карурман» (1971), «Таш диварлар авазы» (1973) мәйданга чыкты. Лирикага фәлсәфи, эпик, драматик жанрлар кушылды, шигъри театр кебек гәүдәләнеп, «Очты дөнья читлегеннән» (1980), «Мәңгелек белән очрашу» (1982) насыйп булды һ. б. Ә моң шул ук, таныш, якын иде, ул һаман үзенә ияртә алды, ышандыра алды. Әйе, бүгенге үзгәрешләр, ихтыярсыз әдәбиятка да килгән «ревизияләр», дәреслекне әйтәм дип, кумирларны әйләндереп салган болгавыр бу заманда да чын шигырь үзгәрми, искерми кала. Тоталитар система биргән «асыл тәрбия», белем, әзер чынлыклар бәласе һәркайсыбыздагы кебек, И. Юзеевка да кагылгандыр, мөгаен... «социаль шигърилек», политик категорияләр, ялгышулар, эзләнүләр дә бардыр... әсәрләрнең күләме, композиция җыйнаклыгы ягыннан бәхәсләшеп тә буладыр. Әмма, минем карашка, И. Юзеев бүген дә укучы өчен чын, алдаусыз, табигый талантлы, халыкчан рухлы, сүз байлыгы белән чын матурлык дөньясы тудыра алган зур

шагыйрь булып, Моң иясе булып кала... Бу моң башлап кайда яралган соң?.. Илдар Гафур (укытучы, татар әдәбиятына тагын Нил Юзеевны да биргән, хөрмәткә лаек кеше) улы Юзеев 1933 елның 3 январенда халкыбызның миллион ярымга якыны яшәгән Башкортстанның Янавыл районы Ямады авылында туган. Бик үзенчәлекле, бай табигатьле төбәктә, жырга, сәнгатькә гашыйк якта. Бу төбәктә Гали Чокрый туган. Безнең көннәрдә исә моннан Н. Фәттах, С. Сөләйманова, Ә. Маликов, Ә. Атнабаев кебек күренекле әдипләр, шагыйрьләр чыкты. Шушы бәрәкәтле җирдә туып үскән Илдар Юзеев ун яшендә үк шигырьләрен район газетасында бастыра (1943 елда беренче шигыре чыга — димәк, шигырьгә килүенә дә 50 ел икән!).. «Кызыл Таң» газетасында, «Әдәби Башкортстан» (хәзерге «Агыйдел») журналында, Уфада күренә аның исеме. Аннары Казанда... 1950—54 елларда ул — Казан педагогия институтының филология бүлеге студенты. Аннан — 12 ел буе «Пионер» («Ялкын») журналында җаваплы секретарь, «Чаян», «Казан утлары» журналларында бүлек мөдире. Иң озак эшләгән урыны — Татарстан Язучылар берлегенең әдәби консультация бүлеге. Ул — ун елдан артык Язучылар берлеге идарәсе рәисенең яшьләр белән эшләү буенча урынбасары... 1958 елдан үзе шул берлектә әгъза булган шагыйрь озак еллар яшь талантлар үстерү, аларга республика семинарлары, конференцияләр оештыру өчен көч куя, остазлык итә, «сигез йөз яшь язучы йә шагыйрь булмый ул» дигән «рәхмәт сүзләре» ишетсә дә, үҗәтләнеп, «яңа Тукайлар» эзли, көрәшә. Ул — республиканың Г. Тукай һәм М. Җәлил бүләкләре лауреаты, РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. СССР һәм РСФСР язучылары съездлары делегаты, шул оешмаларның һәм Татарстан Язучылар берлеге идарәләре, «Сөембикә» журналы редколлегиясе әгъзасы булды. Шагыйрь, драматург, публицист... Балалар әдәбиятында да, юмор-һәҗү мәйданында да өлеше бар. Боларның барсының да нигезендә әлеге Моң. Шул Моңга тугрылык аны алтмышка якын җырга гомер бирергә этәрә.

Нинди генә җырлар әле! «Яшь наратлар» (Җ. Фәйзи), «Кайтам инде» һәм «Бөркет турында җыр» (С. Садыйкова көйләре), «Серле чәчәк» (М. Яруллин), «Кыр казлары артыннан» (М. Имашев музыкасы) һ. б. Юк, җырга гына сыймыйча, либреттога да күчә бу Моң — композитор Р. Кәлимуллин белән бергә иҗат ителгән «Ерактагы күккүк авазы» операсы да яңгырый, бәхетебезгә күккүк сакауланмый әле...

Берничә сүз — драматург Юзеев турында. Яшьлеккә биргән ант, хыял тудырган «Янар чәчәк»тән башлаган шагыйрь бүген шактый сандагы пьесалар авторы. Иң күп куелганы — «Сандугачлар килгән безгә» дигән моңсу комедия. Аны Казанда да, Уфада да, Тувада да, Каракалпакстанда да яратып карадылар, ул рус тамашачыларына да ошады. «Бөркетләр кыяга оялый», «Онытылмас бәет», «Кыр казлары артыннан» кебек әсәрләре дә шундый бәхетле язмышка очрады. Моңсу комедия кебек шигъри яңа жанр, фаҗига, драмалар... «Ак калфакны төшердем кулдан», «Гашыйклар тавы»... Болары — яңа эзләнүләр, табышлар... Барыннан да бигрәк шигъри чаралар муллыгы, символлы сурәтләр, фикерләр, романтика һәм кырыс тормыш бәрелеше, шигырьгә генә сыймаган хис агышы...

Утызга якын китап. Татар, башкорт, рус телләрендә. Арада калын тупланмалар, «Шигырь китапханәсе» сериясендә чыккан «Мәхәббәт китабы»... Алтмыш яшенә әзерләгән сайланма поэмалар китабы исеме дә укучыны битараф калдырмастыр: ул да — «Таныш моңнар»... Әйе, зур иҗат юлы булган, Тукай, Такташ, Туфан, Җәлилләрнең шигъри мәктәбеннән үсеп күтәрелгән, инде мәртәбәле аксакал исәпләнергә лаек шагыйрь шул үк туган нигезгә — Моңга дәшә. Чишмә башына омтылгандай, Моңга кайта. Мәңгелекнең үзе кебек гади, халыкчан моңга.

«Алты яшәр юлдан кайтса, алтмыш яшәр күрешә килер», дигәннәр. Ә алтмыш яшьлек чал шагыйрь, күпне күргән, сабыр, олпат ир белән илендә кемнәр генә күрешә килмәс икән? Якташлары да, каләмдәшләре дә, укучылары да... гомумән, төрле якка чәчелгән, бүген инде берләшүгә омтылган халкыбыз да... дисәм, арттыру булырмы? Чөнки халыкның җаны бит ул Моң. Әнә шул Моңнан аерылгысыз өлкән каләмдәшемә рәхмәт сүзе белән эндәшәм мин бүген.

**Рәдиф ГАТАШ**



*Танылган балалар шагыйре, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәкимҗан Шәяхмәт улы Халиков 1933 елның 16 гыйнварында Арча районы Мамыш авылында туган. Җидееллык мәктәптән соң Арча педучилищесында укый, аннары читтән торып Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый, озак еллар үз районында укытучы булып эшли. 1963 елдан Казанда яши: «Ялкын» журналында мәктәпләр бүлеге мөдире, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында әдәби хезмәткәр, Татарстан Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросы җитәкчесе, «Идел» альманахы мөхәррире, «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф») журналы редакциясе хезмәткәре вазифаларын башкара. 1973 елдан — Язучылар берлеге әгъзасы.*

*Шигырьләре башта күмәк җыентыкларда («Яшьлек таңы», «Кайнар хисләр» һ. б.) күренде. 1969 елда кече яшьтәгеләр өчен «Йолдызлар ничәү?» исемле беренче мөстәкыйль китабы басылып чыкты. Аннары шагыйрьнең «Шук бабай» (1970), «Энәбикә» (1973) һ. б. китаплары, шул исәптән, күләмле «Иң шатлыклы көнем» (1983) тупланмасы дөнья күрде. Рус телендә чыккан китаплары да бар.*

*60 еллык бәйрәме белән котлап, без бу санда укучыларыбызга Х. Халиковның нәниләргә атап язган яңа шигырьләр бәйләмен тәкъдим итәбез.*

## Хәкимҗан Халиков

### Яратам

Бик яратам Тәнзиләне,
Бәп-бәләкәй булса да,
Йокысыннан әлегә ул
Һәр көн елап торса да.

Кочагыма алып аны:
«Хәерле көн, сеңлем! — дим.—
Беләсеңме, мин бит сине
Бик сагынып килдем»,— дим.

Ул да көлә, мин дә көләм,
И көләбез бергәләп!
Ул бит әле кулдан кулга
Күчеп йөргән күбәләк.

Ул еласа, ни өчендер
Үзем елаган сыман,
Ул елмайса, өебездә
Кояш елмайган сыман.

## Юкка түгел

Әти кайтса, сеңлем шундук
Каршысына очып бара.
Әни кайтса, «Әнием!» — дип,
«Сагындым!» — дип, кочып ала.

Барыбызны әнә шулай
Авызына карата ул.
Ләкин бер дә юкка түгел:
Яратканга ярата ул.

## Тәтиме соң?

Сеңлем беркөн: — Синнән тәти
Беркем дә юк, әнием,— ди.
Әни көлә:— Начар әни
Буламы соң, нәнием,— ди.

— Ник булмасын! — диде сеңлем.—
Алай булса, әйтимме соң:
Бәбиләрен мәэмә иткән
Әниләр дә тәтиме соң?

## Әнием орышканда

Орышып та алгалый
Әни кайчак сеңлемне.
Ә Тәнзилә:— Кычкырып
Орышма,— ди,— син мине.

Ишетсәләр күршеләр,
Сине усал диярләр...
Аннан бездән көләрләр.

## Оялтты

Тәнзиләбез өстәл өстен
Курчак белән тутырган.
Ә уртада, киерелеп,
Аю-әппәс утырган.

Аюын да, куяның да,
Җыеп ал, дим, барын да.
Сеңлем исә, ялт-йолт карап,
Тора һаман янымда:

— Моңа кадәр алар сине
Бик ярата иделәр.

Шуңа күрә бүген сиңа
Кунак булып килделәр.

Ә кунакны каршылыйлар
Бары якты йөз белән,
«Әйдә, түрдән узыгыз!» — дип,
Тәмле-татлы сүз белән...

Күр әле син, кирәк чакта
Таба бит ул сүзен дә!
«Уйныйбызмы?» — дигәнемне
Сизми калдым үзем дә.

## Җиләккә баргач

Жырлый-жырлый җиләк җыям
Чәчәкле чиләгемә.
«Абый, кайчан кайтабыз?» — дип,
Йөдәтә Зилә генә.

«Чиләк тулгач»,— дигән идем,
«Уф-ф! — диде: арган икән.—
Эх, чиләкнең кечкенәсен
Аласы калган икән...»

## Болай булса

Аптырыйм мин Илгизгә,
Кайчак әллә нишли ул:
Кәҗәләнгән чагында
Бер сүз әйтсәң — тешли ул.

Күз астыннан аннары
Сиңа карап ала ул.
Болай булса, күрерсез:
Тиздән тешсез кала ул.

## Кунаклар

Кошкайларга җим сибәм,
Алар минем кунаклар.
Ашханәмдә өй дә бар,
Теләгәне кунаклар.

Тамаклары тук булгач,
Әйбәт булыр төшләре.
Төшләренә керсен тик
Тәмле җимеш төшләре.

## Суга сала

Саттар чак-чак батмый калгач
Инештәге сап-сай суга,
«Ник батыра яздың?!» — диеп,
Чыбык белән суга суга.

## Сафсата сата

Ясадым, дип, мин кичә
Үзйөрешле чабата,
Сафа сата сафсата...
Сафсатага шаккатып,
Вафа телен шартлата.

## Әминә Бикчәнтәева

(1913—1986)

Балалар язучысы Әминә Әхмәт кызы Бикчәнтәева 1913 елның 26 гыйнварында Казан шәһәрендә эшче гаиләсендә туган. Җиде сыйныф һәм педагогия курслары тәмамлаганнан соң берничә ел балалар укыта. 1934—38 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Аннан соңгы елларда Ә. Бикчәнтәева «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә, Татарстан радио комитетында эшли һәм шулай ук районнарда балалар укыта, тулай торакта тәрбияче булып эшли. Ә 1952—55 елларда Татарстан китап нәшриятында редактор хезмәтен башкара. 1958 елдан — профессиональ язучылык хезмәтендә.

Ул — бөтен гомерен һәм иҗатын балалар тәрбиясенә багышлаган язучы. Ә. Бикчәнтәева 1938 елда яза башлый. Кече яшьтәге балаларга адресланган беренче китабы 1940 елда басылып чыга. Аннан соң авторның ике дистәгә якын шигырь һәм проза китаплары дөнья күрә. Ә. Бикчәнтәева — «Ана йөрәге» һәм «Мин аңлыйм сине» исемле повестьлар авторы да. Яшүсмерләр тормышына багышланган бу әсәрдә язучы кызыклы язмышлар иҗат итә, коллективның шәхескә көчле тәэсирен күрсәтә.

Язучының балалар өчен кыска хикәяләре дә бар. Бу жанрда аның «Хуҗа Насретдин балалар янында» дигән хикәяләр циклы аеруча яратып укыла.

Ә. Бикчәнтәева 1958 елдан Язучылар берлеге әгъзасы иде.

## SADRЬJ ÇƏLAL

# DIM BUJЬNDA

Ənə kyrəsezme, qojaşnьꞑ jьlь nurlarь astьnda jaltьrьj-jaltьrьj Dim aƣa.

Ənə anьꞑ qьrьjьnda ciksez kiꞑ ʙolonnoq, annan jьraq ta tygel, tallьq.

Ənə jьraqta Qaş ʙelener-ʙelenməskenə ʙulьp suzьla; zəꞑgərsu hava aşa anьꞑ ɵstɵndəge qara urman totonnənep kyrenə. Jaqtь sunьꞑ ɵstɵndə vəqar ʙeləngenə aq qoşlar jozop jɵri; ʙolonnoqta tɵrlɵ qoşlar sajrьj; ara-tirə aqcarlaqlarnьꞑ acь tavьş ʙelən qьcqьrƣannarь işetelep kitə; kɵn jɵzɵndə qarcьƣa, digən usal qoşnoꞑ çentekləp çirdən yzenə çim qarap ʙarƣanь kyrenə.

Monda hər nərsədən irkennek, ʙəxet aꞑqьj. Bu kiꞑ ʙolonnarƣa qarav ʙelən kyꞑelgə: „mondьj maturlьq, mondьj ʙajlьq ecendə adəmneꞑ ʙəxetsez ʙuluvь mɵmkin tygelder“ digən uj kilə.

Ənə taƣьn jьraqta, Dim ʙujьna utьrƣan, ike məcetle zurƣьna avьl. Jaqьnьraq ʙarьp qarasaꞑ, anьꞑ ʙer citendə urman şikelle, qujь ʙer ʙaqcalьq kyrenə. Baqca ʙik kyptən utьrtьlƣan ʙulsa kirək: andaƣь aƣaclar inde təmam qartajƣannar. Baqcaƣa qarav ʙelən, aꞑar inde kyptənnən ʙirle adəm qulь oronmaƣanьn ʙelergə ʙula. Anьꞑ qojroƣo Dim ʙujьna ʙarьp terələ. Ikence ʙaşьndaƣь, aƣaclar arasьnnan aslь-ɵslɵ zurƣьna aƣac ɵjnɵꞑ taşlandьq xəraʙasь kyrenə. Anьꞑ manzarasь ƣajət kyꞑelsez: tərəzələr taqta ʙelən tomalanƣan, tyʙəsendəge qalajlar, ʙujavlarь kyptən uꞑƣan, jaꞑƣьrdan kygərenep, samavьr morçasь toslo, celtər, celtər ʙulьp ʙetkənnər. Basqьclar jantajƣan, morçalarƣa cəvkələr, tərəzə ʙaşlarьna da kygərcennər ojalaƣannar.

Işek aldьna, joryce ʙulmaƣanƣa, jəm-jəşel cirəm yskən; ʙɵtɵn çir ʙuş, ʙɵtɵn nərsə tьnƣьna nərsəder kɵtə....

Садрый Җәлалның «Дим буенда» исемле хикәясеннән бу өзекне без «Яңалиф» нәшриятында 1929 елда басылып чыккан китабыннан алдык. Латин әлифбасы нигезендә язу һәм укуга күчүнең беренче елы буларак, китерелгән өзектә байтак кына хәреф хаталары очрый. Без аларны төзәтеп торуны кирәк тапмадык. Укучыларыбыз ул хаталарны үзләре тояр һәм тарихи бер күренеш итеп кабул кылыр дип ышанабыз.

# КИТАПЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

## Кадерле укучылар!

Казан шәһәреннән читтә яшәүчеләргә китаплар җибәрүче махсус «Китап-почта» кибете (Октябрьская урамы, 18) ябылды — ул хәзер «Төрки китап» кибетенең (420066, Казан шәһәре, Чистай урамы, 3) «Китап-почта» бүлегенә әверелде. Сез аннан быел һәм әүвәлге елларда дөнья күргән түбәндәге басмаларны сорап алдыра аласыз:

Габдулла Тукай. **Шигырьләр, поэмалар.** 1990 ел. 256 бит, рәсемнәр белән. Б. 1 с. 80 т.

Габдулла Тукай. **Кәҗә белән сарык әкияте.** 1991 ел. 10 бит, төсле рәсемнәр белән. Б. 1 с. 20 т.

Гаяз Исхакый. **Зиндан.** *Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре.* 1991 ел. 670 бит. Б. 8 с.

Валентин Беркутов. **Безнең мәнниәрдә — вакыт.** *Фәнни-популяр басма.* 1992 ел. Б. 8 с. 75 т.

**Йөртә безне язмышлар.** «Чит илләрдәге милләттәшләребез» сериясеннән. 1992 ел. 240 бит. Б. 5 с. 65 т.

Габделҗаббар Кандалый. **Шигырьләр һәм поэмалар.** 1988 ел. 558 бит. Б. 1 с. 70 т.

**Кем ул? Нәрсә ул?** *Балалар өчен сурәтле энциклопедия.* 3 том (Р дан Я гача). 1987 ел. 222 бит. Б. 2 с. 80 т.

Джек Лондон. **Мартен Иден.** *Роман.* 1992 ел. 382 бит. Б. 8 с. 75 т.

**Мажаралар дөньясында.** *Повестьлар, хикәяләр.* 1990 ел. 256 бит. Б. 55 т.

Рафаэль Мостафин. **Кабан күле серләре.** *Тарихи-документаль повесть.* 1990 ел. 142 бит. Б. 35 т.

Эдуард Мостафин. **Ут. Кәгазь. Каләм.** *Шигырьләр һәм поэма.* 1992 ел. 80 бит. Б. 1 с. 50 т.

Шиһабетдин Мәрҗани. **Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар** (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). 1989 ел. 416 бит. Б. 1 с. 60

**Пәйгамбәрләр тарихы** (Кыйссасел әнбия). *Фәрит Яхин хикәяләвендә.* 1992 ел. 144 бит. Б. 11 с. 25 т.

**Саламторхан.** *Татар халык әкияте.* 1989 ел. 18 бит, төсле рәсемнәр белән. Б. 40 т.

**Сагыналар сине якын дуслар.** *Сара Садыйкова турында истәлекләр.* 1991 ел. 200 бит. Б. 65 т.

Һади Такташ. **Әсәрләр.** Өч томлык. 2 том. 1981 ел. 478 бит. Б. 90 т.

Хәмит Төхфәтуллин. **Камил Мотыйгый.** *Фәнни-популяр очерк.* 1992 ел. 80 бит. Б. 5 с.

Рәүфә Уразман. **Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре.** 1992 ел. 96 бит. Б. 5 с. 38 т.

Нурихан Фәттах. **Сызгыра торган уклар.** *Тарихи роман.* 1, 2 китаплар. 1991 ел. 800 бит. Б. 12 с. 03 т.

Равил Фәхретдинов. **Моңдадыр безнең бабайлар.** *Археолог язмалары.* 1992 ел. 176 бит. Б. 12 с. 50 т.

Мөсәгыйт Хәбибуллин. **Илчегә үлем юк.** *Роман.* 1990 ел. 382 бит. Б. 1 с.

Альфред Халиков. **Беренче дәүләт. Болгар иле.** 1991 ел. 216 бит, рәсемнәр белән. Б. 11 с. 25 т.

Сәмәния Шәрипова. **Дәваларның олысы вә асылы** (Әбугалисинаның дәвалау серләре). 1992 ел. 158 бит. Б. 12 с. 50 т.

Рәшит Әхмәтҗанов. **Моңлану.** *Шигырьләр һәм поэмалар.* 1991 ел. 432 бит. Б. 2 с. 70 т.

### Урыс телендә:

Гумер Баширов. **Суровое испытание** (Кырыс сынау). *Повестьлар, хикәяләр, эссе.* 1991 ел. 270 бит. Б. 2 с. 80 т.

Фоат Валеев. **Сибирские татары** (Себер татарлары) Мәдәнияте һәм көнкүреше. 1992 ел. 208 бит. Б. 11 с. 25 т.

Гаяз Исхаки. **Идель-Урал.** 1991 ел. 64 бит. Б. 3 с. 75 т.

Мирсаид Султан-Галиев. **Статьи, выступления, документы.**

*(Мәкаләләр, чыгышлар, документлар).* 1992 ел. 518 бит. Б. 25 с.

Габдулла Тукай. **Избранная проза** (Сайланма проза). 1992 ел. 128 бит. Б. 8 с. 75 т.

Карл Фукс. **Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Краткая история города Казани.** (Статистик һәм этнографик яктан Казан татарлары. Казан шәһәренең кыскача тарихы). 1991 ел. 210 бит. Б. 15 с.

Нияз Халитов. **Архитектура мечетей Казани** (Казан мәчетләре архитектурасы). 1991 ел. 192 бит, рәсемнәр белән. Б. 6 с. 25 т.

**Хөрмәтле укучылар! Игътибар итәсездер, хәзер яңа китаплар басылу бик нык кимеде, ә дөнья күргәннәренең бәясе ай саен арта бара. Шуңа күрә элгәреге елларда нәшер ителгән, бәясе арзан, әмма эчтәлеге бай китапларның кадерен белик. Аларны алмый калсак, үкенерлек булмасын!**

## КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!

Мөхтәрәм милләттәшләр!

Журналыбызның үткән елгы саннарында (№№ 7—12, 1992 ел) без, башка күп кенә газета-журналлар кебек, матди ярдәм алу өчен **Редакция фонды** оештыруыбызны белдереп, Татарстанда, Россиядә, БДБ дәүләтләрендә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә мөрәҗәгать иткән идек. Беренчеләрдән булып иганәлек кылган оешмаларга рәхмәтләребезне дә җиткергән идек (№ 7, 1992 ел). Редакция фонды хисабына иганә акчалары күчерүчеләр артканнан-арта бара. Без аларның кайдан, кемнәр булуларын укучыларыбызга хәбәр итеп торырга булдык.

Безгә ярдәм кылучы милли рухлы эшмәкәрләр һәм аерым кешеләр менә алар: «Канон» фәнни-производство предприятиесе (4080 сум), «Интех» фирмасы (3960 сум), «Нафта» фирмасы (3960 сум), Чиләбе өлкәсеннән Әнгам Фәтхиев (1000 сум), Түбән Камадан Мизхәт Гыйндуллин (200 сум), Коми ССРның Ухта шәһәреннән Марат Шундеев (150 сум).

Без аларның һәммәсенә зур рәхмәтлебез!

Безгә ярдәм итәргә теләүчеләр хәл кадәри акчаларын түбәндәге адрес белән күчерә алалар:

**420066, г. Казань, ул. Декабристов, 1. Волжско-Камский акционерный банк РКЦ ГЦБ. Р/счет № 700161998/2345114 МФО 265005. Для Фонда редакции журнала «Казан утлары».**

## ТАТАР КИТАБЫНА — 270 ЕЛ

Милли мәдәниятебез тамырлары ерактагы гасырлар тирәнлегенә китүен һәммәбез дә беләбез. Хәзер табыла торган меңләгән санлы кульязма китапларда халкыбыз тарихының якты да, фаҗигале дә сәхифәләре теркәлгән.

Татар басма китабына быел 270 ел тулуын галимнәребез ышанырлык итеп расладылар. Әнә шул мөһим датага багышлап, җөмһүриятебез башкаласы Казанда һәм татарлар яшәгән бүтән төбәкләрдә күп кенә чаралар үткәрелде.

21 декабрьдә Татарстан Фәннәр Академиясенең Бауман урамына урнашкан бинасында фәнни конференция уздырылды. «Татар китабы: тарих һәм хәзерге заман» дип исемләнгән бу конференцияне Татарстан Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан дәүләт университеты, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Матбугат һәм информация министрлыгы, Татарстан Республикасының Милли китапханәсе оештырды.

Конференцияне кереш сүз белән Милли китапханә директоры, Татарстан халык депутаты, шагыйрь Разил Вәлиев ачты.

Аннан соң докладлар белән академиклар Әбрар Кәримуллин, Миркасыйм Госманов чыкты. Китап тарихы һәм аны бүген саклау мәсьәләләре турында башка белгечләр дә кызыклы чыгышлар ясадылар.

Татар китабының 270 еллыгына багышланган тантана кич белән Кәрим Тинчурин исемендәге Драма һәм комедия театры бинасында дәвам итте. Һәр ике бинада да зур күләмдә оештырылган китап күргәзмәләре бар иде. Шулай ук китап сәүдәсе дә булды.

Китап бәйрәме татарлар яшәгән бүтән төбәкләрдә дә матур гына билгеләп үтелде.

## КИҢӘШЛЕ ЭШ ТАРКАЛМАС

Декабрь башында Казанга Башкортстан Республикасының иң зур сәяси һәм милли хәрәкәтләре лидерларыннан торган делегация килде. Аның составында Башкортстан бәйсезлеге өчен халык хәрәкәте комитеты рәисе Ф. Фазылов, аның рәистәше язучы А. Филиппов, комитет әгъзасы журналист В. Матвеев, «Урал» башкорт халык үзәге җитәкчесе М. Колшәрипов, Башкорт хатын-кызлар берлеге һәм Башкорт халык партиясе идарәсе әгъзасы Т. Карамышева, Башкорт халык конгрессы рәистәше, икътисади фәннәр докторы А. Хәйруллиннар бар иде.

Кунаклар Татарстан милли хәрәкәте җитәкчеләре белән очраштылар, ике республика һәм татар-башкорт милләтләре өчен үтә мөһим булган мәсьәләләрне тикшерделәр, киләчәктә бергәләп һәм киңәшеп эшләү турында килештеләр.

8 декабрь көнне һәр ике республика вәкилләре Пресса йортында журналистлар өчен матбугат конференциясе үткәрделәр, күпсанлы сорауларга җавап бирделәр. Мондый очрашу ике республика халыкларының тагын да якынаюына ярдәм итәр дип ышанырга кирәк.

## ЯҢАЛЫК: «ГЫЙФФӘТ ТУТАШ» КОНКУРСЫ

Хәзер төрле ярышлар, конкурслар күп уздырыла, әлбәттә. Үзебезнең татар мохитен алсак та, соңгы елларда гына «Нәүрүз чибәре», «Озын толым» дигән гүзәллек бәйгеләре булып үтте. Ә 15 декабрь көнне кич Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасында мондый гүзәллек конкурсларының иң кызыклысы — «Гыйффәт туташ» бәйгесе үткәрелде.

Әлеге ярыш-тамашаны Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты, Бөтендөнья татар хатын-кызлары берлеге һәм «Сөембикә» журналы редакциясе оештырды. Ул милләтебезнең саф, акыллы, уңган һәм чибәр кызларын барлауга багышланган иде.

Бу ярышның спонсорлары да бик данлыклы оешмалар һәм предприятиеләр: «КамАЗ» акционерлык җәмгыяте, «Тасма» берләшмәсе, компрессорлар заводы, Кукмара тегү фабрикасы, Арча аяк киемнәре берләшмәсе, «Болгар» фонды, студентларның бизнес үзәге, «Мирас» ширкәте иде. Әнә шуңа күрә дә ярышта җиңеп чыгучыларга бүләкләр күркәм булды.

Әлеге кичәдә милләтебезнең йөзек кашы булган сәнгать эшлеклеләре һәм танылган җырчылар да катнашты.

«Гыйффәт туташ» конкурсы чын-чыннан милли бәйрәмгә әйләнде. Татарлар яшәгән башка төбәкләрдә дә әнә шундый бәйгеләр ешрак уздырылсын иде. Алар безгә халкыбызның үз йөзен, милли гореф-гадәтләрен саклауда ярдәм итәчәк.

## ШАХМАТ ҺӘМ ТАТАР

Авыр физик эшләрдәге тырышлыгы, яу кырларындагы каһарманлыгы белән дан казанган татар милләте вәкилләре кешенең зиһен көчен сыный торган шахмат дөньясында үзләрен ничек күрсәтә? Безнең милләт бу яктан башка халыклар белән янәшә торып көч сынаша аламы?

440 ел буена нык изелгән булуга карамастан, бүген бу сорауга без «әйе» диеп уңай җавап бирә алабыз! Чөнки дөнья күләмендә

танылган шахматчылар Рәшит Нәҗметдинов, Алисә Галләмова, Артур Йосыпов һәм Гата Камскийларыбыз бар безнең!

Казан шәһәре үзе дә бик еш кына шахмат турнирлары үзәгенә әйләнеп китә. Мисал өчен, декабрь аенда безнең башкалада халыкара шахмат фестивале булып узды. Анда танылган гроссмейстрлар һәм халыкара спорт мастерлары катнашты. Якташларыбыз һәм милләттәшләребез дә турнирдагы уеннарда уңышлы чыгыш ясадылар.

Үткән айның ахырында дөнья күләмендә танылган яшь гроссмейстер Гата Камский үзенең әтисе белән Казанда булды. Бу рәсем әнә шул чакта төшереп алынды.

### ДАҺИ ЯКТАШЫБЫЗНЫ ИСКӘ АЛУ

Күренекле галим Н. И. Лобачевскийның тууына 200 ел тулуга багышланган бәйрәм башкалабыз Казанда зур күләмдә билгеләп үтелде. 1 декабрь көнне Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасында шул уңайдан тантаналы җыелыш булды. Аны кереш сүз белән Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе президенты М. Хәсәнов ачты. Аннан соң Казан дәүләт университеты ректоры Ю. Коноплев доклад сөйләде. Тантанага килгән кунакларны Казан шәһәре администрациясе башлыгы К. Исхаков котлады.

Бу тантанада шулай ук чит илләрдән һәм башка республикалардан килгән күпсанлы галимнәр дә катнашты. Алар безнең якташ галимебез турында җылы сүзләр әйттеләр.

Соныннан җөмһүриятебез сәнгать осталары концерты булды.

### ЯҢА ТЕАТРЛАР

Шушы елның ноябрь аенда Казанда театр училищесының Укучылар театры ачылды. Бу көнне театрга килгән беренче тамашачылар училищеның IV курс студентлары башкаруында Мостай Кәрим пьесасы буенча әзерләнгән «Айгөл иле» спектакленең премьерасын карадылар.

Шактый яхшы җиһазландырылган сәхнәсе һәм 100 кешегә исәпләнгән залы булган бу театрда Казан тамашачылары өчен даими рәвештә училище укучыларының диплом спектакльләре һәм концертлар күрсәтеләчәк.

Яңа театрга килергә теләүчеләр өчен аның адресы: Профсоюз урамы, 19 нчы йорт.

* * *

Казан шәһәре хакимияте Островский урамындагы 12 нче йортны Мәдәният министрлыгы карамагына тапшырды. Биредә Татар яшьләре театры булырга тиеш. Бинаның гомуми мәйданы — 1520 квадрат метр. Анда 300 урынлы тамаша залы һәм шулай ук 150 урынлы яктылык музыкасы залы җиһазландырыла, бинага ремонт ясала.

Ә Татар яшьләре театры труппасы әлегә республика районнарында гастрольдә йөри. Аның художество җитәкчесе — Фәрит Хәбибуллин.

Яңа театр артистларының тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту чаралары да күрелә. Островский урамындагы шул ук 12 нче йорттан 9 фатир яшь белгечләр өчен бушатыла. Киләсе елда яңа театр үзенең беренче тамашачыларын кабул итәчәк.

### *Тышлыктагы сурәтләр*

Тышлыкның беренче битендә: рәссам Хәнәфи Нәфыйковның «Чичәннәр ярышы» дигән әсәре.

**М. КОЗЛОВСКИЙ** фотосы.

Тышлыкның дүртенче битендә: танылган язучы Ринат Мөхәммәдиев.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фотосы.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Татарстан китап нәшрияты берсен-нән-берсе кызыклырак китапларны чыгара кила. Соңгы вакытта, мисал өчен, «Әдәби мирас» дип исемләнгән ике җыентык басылып чыкты. Болар — киләчәктә дәвамлы рәвештә басылачак яңа сериянең беренче карлыгачлары. Әле дөнья күргән тәүге китапларда кайчандыр укучылар тарафыннан бик яратылып укылган, әмма хәзер төрле сәбәпләр аркасында күләгәдә кала килгән кызыклы әсәрләр тәкъдим ителә. Ф. Әмирханның «Шәфигулла агай» һәм «Картада оттырылган Зөлхәбирә» хикәяләре, М. Гафуриның «Кеше ашаучылар» поэмасы, Г. Монасыйпның «Таранчы кызы яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» романы һ. б. — әнә шундыйлардан. Китапларда шулай ук яңа бәетләр һәм дастаннар да урын алган. Хәзерге чор әдипләренең кызыклы әсәрләре дә тәкъдим ителгән.




Күптән түгел арабыздан киткән зур шагыйребез Нури Арсланның «Сайланма әсәрләр»е дөнья күрде. Аңа шагыйрьнең ярты гасырлык иҗатыннан иң яхшы үрнәкләр тәкъдим ителгән. Алар арасында сокланып укыла торган поэма һәм риваятьләр дә, робагый һәм балладалар да, шагыйрьнең иң яратып иҗат иткән жанрыннан җырлар белән шигырьләр дә бар. Китапка шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов кереш сүз язган. Ә Рәис Даутов тәфсилле библиографик белешмә биргән.

Бу җыентыкларны сез китап кибетләреннән таба яки түбәндәге адрес буенча соратып алдыра аласыз:

**420057, г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга — почтой».**

Бәясе 20 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный катал